

# КАЗАН УТЛАРЫ

5
МАЙ
1982

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

5
1982
МАЙ

*Бу санда*

СССРның ТӨЗЕЛҮЕНӘ 60 ЕЛ

**Ф. САФИН.** Ил бәйрәмен котлап. Шигырь . . 3

«КАЗАН УТЛАРЫ»НА 60 ЕЛ

Әдәбиятыбызның якты көзгесе. Анкетага җаваплар . . 4
**М. МӘРДИЕВА.** Эзләнүләр һәм үсеш юлыннан . 20

ЖУРНАЛ ТАРИХЫНЫҢ ЯКТЫ СӘХИФӘЛӘРЕ

**Һ. ТАКТАШ, М. ҖӘЛИЛ, Ф. КӘРИМ.** Шигырьләр. 33

БӘЙРӘМ БУКЕТЫНА МАЙ ЧӘЧӘКЛӘРЕ

**Н. АРСЛАНОВ, С. БАТТАЛ, М. САДРИ, Г. ЛАТЫЙП, Г. АФЗАЛ, И. ЮЗЕЕВ, Ф. ЯРУЛЛИН, Р. ФӘИЗУЛЛИН, Р. ГАТАШ, Рәш. ӘХМӘТҖАНОВ, Р. МИҢНУЛЛИН.** Шигырьләр . . . 36

**С. ХӘКИМ.** Эзлиләр Европа буйлап . . . . . 43

**Н. ФӘТТАХ.** Сызгыра торган уклар. Роман . 50
**Ф. ХӨСНИ.** Мәшәкатьле озын сәфәр. Юл язмалары . . . . . . . . . . . . 118

ДУСЛАР ЖЫРЫ

**Л. ОШАНИН.** Әдәбият институтын тәмамлаган дусларыма. Шигырьләр . . . . . . . . 149

«ПРАВДА» ГАЗЕТАСЫНА 70 ЕЛ

**А. АЙНЕТДИНОВ.** Казанышларыбыз елъязмачысы 152

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

ОЧЕРК ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

Ш. ХАММАТОВ. Яңадан сафка . . . . . . 156

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

С. МАННАПОВ. Хәтер . . . . . . . . . . . 169

ӘДӘБИ АЛМАШЫБЫЗГА ЯРДӘМГӘ

И. С. ТУРГЕНЕВ, Ф. ӘМИРХАН, М. МАКСУД, Ф. ӘСГАТЬ, Г. КУТУЙ, Җ. Х. ҖӘБРАН, Ә. КАСУМОВ, С. ДАНИЛОВ. Нәсерләр . . . . . . 178

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 191

Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ

Редколлегия: ШАМИЛ БИКЧУРИН, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ *(баш редактор урынбасары)*, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН, НИЛ ЮЗИЕВ

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Г. Салихҗанова*

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-09, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-63, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 25/I-1982 ел. Басарга кул куелды 9/IV-1982 ел. ПФ 09016. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65049. Заказ Ю-38. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1982 ел.

# СССРның төзелүенә 60 ел

## Фәннур Сафин

### Ил бәйрәмен котлап

Нинди чүлләр кичеп килдең, күңел,
Кай тарафка синең юл бара?
Яңа туган гүзәл кыйсса кебек
Әйтер сүзең бармы дөньяга?

Тынлыкмы син, тыныч-сабырмы син,
Тау елгасы сыман ярсумы?
Гамьсезме син, ихлас көрәшчеме,
Нәрсәгә дә булса каршымы?..

Яшисеңме — ягъни кайныйсыңмы
Уртасында җилле заманның?
Хисләреңне төнге утлар итеп
Чояргәме җирдә ярaлдың?

Тоташ моңмы, серле сараймы син,
Җырлаганда чыккан тавышмы?..
Җир өстенә йолдыз атылганда
Йөрәк тоткан айлы сагышмы?

Мин җир буйлап киләм сине уйлап,
Акыл һаман сине кайгырта.
Киләм сиңа, түргә узам. Барлыйм —
Йөргән кебек гаҗәп бай йортта.

Җан бездән дә алдан тоядыр ла,
Ашкына гел туар таңнарга.
Ил бәйрәмен иңнәр күтәргәндә
Күңелләрдә Сөю яңара!

# ӘДӘБИЯТЫБЫЗНЫҢ ЯКТЫ КӨЗГЕСЕ

*Журналыбызның олы юбилее уңае белән редакция бер төркем язучыларга: «Казан утлары» сезнең иҗади тормышыгызда нинди роль уйнады»? дигән сорау белән мөрәҗәгать иткән иде. Түбәндә редакциягә килгән җавапларны урнаштырабыз.*

## Гомәр Бәширов: «ЯКТЫ ТӘРӘЗӘЛӘР»

Матбугат йортына якынлашканда мин һәрвакыт ничектер үзеннән-үзе бишенче каттагы якты тәрәзәләргә күтәрелеп карыйм. Мин анда эшләгән еллардан соң инде бик күп вакыт узды, тормышка да зур үзгәрешләр керде, әдәбиятка да бик күп яңа көчләр килде. Ләкин шуңа карамастан, ул тәрәзәләр минем җаныма якын, мин аларны оныта алмыйм, алар минем күңелемдә кадерле истәлекләр уяталар, бергә эшләгән дусларымны, иптәшләремне исемә төшерәләр. Ул истәлекләрнең күңелгә аеруча газиз булып, аеруча онытылмастай булып калганнары, ихтимал, журнал редакциясендә бергә эшләгән иптәшләрнең матур әдәбиятка кайнар мәхәббәтләре, чиксез ихтирамнары, сәнгать һәм әдәбиятның яшәешкә тәэсир көче бинийһая дип аңлаулары, шунлыктан, аңа мокатдәс эш дип карап, җаннары-тәннәре белән бирелеп эшләүләредер.

1936 елда мин «Совет әдәбияты»ның җаваплы секретаре булып эшли башлаганда журналның редакторы Гомәр Гали, поэзия бүлегенә Хәсән Туфан җитәкчелек итә, редколлегия члennары профессор Галимҗан Нигъмәти, Шәриф Камал, Кәрим Тинчурин һ. б. иде. Журналга керәчәк әдәби әсәрләрнең зурларын, җитдиләрен редколлегия утырышына куеп күмәк рәвештә фикер алышу кебек яхшы гадәт бар иде, кайчагында шул фикер алышулар әдәбиятның теге яки бу жанры, әдәби алымнар, гомумән фәлән шагыйрьнең яки әдипнең яңа әсәрләрендә кая таба үсүе хакында кайнар бәхәскә дә әйләнеп киткәли иде. Ул чагында ук барлык шагыйрьләрнең һәм шигырь сөючеләрнең кумирына әверелгән Хәсән Туфан шигырь уку ритмына яшь авторның кулъязмасын селки-селки, әсәрдә оригиналь образ, философик фикер барлыгын раслларга керешә. Зур белеменә, озак еллар әдәбият фәне укыту тәҗрибәсенә таянып, Галимҗан Нигъмәти сабыр гына үз сүзен әйтә. Шәриф абзый да үз фикереннән тиз генә кире кайта торган кеше түгел иде. Фатих Сәйфи-Казанлы исә гомумән бәхәсне бик тә яратыр иде. Ул да түгел, күп әсәрләргә ирония белән карарга, инкарь итәргә яратучан Гомәр Толымбайский, зур гәүдәсе белән чайкалгалап, кычкырып көлеп җибәрә. Кайчакларны бу сүз көрәштерүләр шундый кызып китә, Гомәр Гали, карандашы белән лампа абажурына суккалап, бәхәсләшүчеләрне тынычландырырга мәҗбүр булыр иде.

Кайбер укучыларда шундый сорау туарга да мөмкин: нинди бәхәс? Нәрсә турында шулкадәр кызып бәхәсләшергә? Эш шунда ки, ул елларда яңа аякка басып, яңа ныгып килүче совет әдәбиятының иҗат алымнары, гомумән әдәбият фәне хәзерге кебек барлык нечкәлекләренә кадәр җентекләп өйрәнелеп, эшләнеп бетмәгән иде әле, әдәби иҗатка бәйләнешле күп кенә катлаулы теоретик мәсьәләләрне тирәнтен өйрәнәсе, ачыклыйсы бар иде. Борынгыдан калган бай әдәби мирастан ни рәвешле, ничек файдаланырга? Аның кайсы өлеше хәзерге заман таләпләренә хезмәт итә ала, кайсы өлешеннән ваз кичәргә туры киләчәк? Ул вакытта, мәсәлән, Фатих Әмирханны буржуа язучысы дип танып, аның әдәби мирасыннан баш тартырга өндәүчеләр дә юк

түгел иде... Азмыни әдәбиятта уйлануны, фикер алышуны сорый торган катлаулы сораулар? Фәлән әсәр хәзерге әдәбиятка берәр яңалык өстиме, әллә элеккеләрне генә кабатлыймы? Бу әсәрдә нинди яңа образ, яңа сүз, яңа алым бар? Андый бәхәсләр вакытында Мирсәй Әмирнең «Агыйдел» повесте еш кына уңай яктан үрнәк итеп китерелә торган иде. Кыскасы, бу кешеләр журналга килгән әсәрләрдәге һәр яңалыкка, талантлы әсәр язган һәр авторга чын күңелдән куана беләләр, андыйларга журналда киң юл ачалар иде. Менә шундый бәхәсләр кайбер көннәрне ярты төнгә кадәр сузылгалый, тынып калган Казан урамнарыннан мин шул хакта юл буе уйланып кайткалый идем.

Аннан соң мин матур әдәбият, аның халык тормышында нинди әһәмиятле урын тотуы, аның эстетик тәэсиренең халыкта әдәп, әхлак тәрбияләүдә башка берни белән дә алыштырып булмый торган зур көч булуы хакында күп нәрсә белдем. Бу хакта зур съездларда, фәнни конференцияләрдә исеме бөтен дөньяга танылган мәшһүр галимнәр, язучылар фикерен дә ишеттем. Ләкин болар барысы да соңыннан гына килеп өстәлделәр. Сәнгатькә һәм матур әдәбиятка кайнар мәхәббәт һәм бөек ихтирам, алар халык тормышында могҗизалар тудырырга сәләтле дип инану, әдәби иҗат белән эш иткәндә саф вөҗданлы, пакь куллы булу — менә болар, һичбер җилләр-давыллар да үзгәртә алмастай катгый әхлак кагыйдәләре булып, минем күңелдә әнә шул якты тәрәзәле кечкенә бүлмәдә ныгып калдылар.

Истәлекләрнең күбесендә без әдәбиятны яки сәнгатьне әйдәп баручы эрерак затлар яки башкалардан аерылып торучы зур талантлар турында язарга гадәтләнгәнбез. Ихтимал, шулай кирәктер дә ул. Чөнки ул затлар үзләрен генә түгел, заманнарына хас типик халәтләрне дә гомумиләштереп күрсәтергә ярдәм итәләр. Ләкин сәнгать һәм әдәбият язмышын ул гали затлар фәкать үзләре генә хәл итеп бетерә алмый, аларга ярдәмче көчләр дә бар бит әле. Алар җәмәгатьчелек күзенә артык чалынмыйлар, исемнәре дә, теләсә кайсы басмада булсын, вак хәрефләрдән генә җыела. Әмма аларның хезмәтләре ифрат зур тырышлык, түземлелек, пөхтәлек һәм төгәллек таләп итә, алар автор язган һәр сүз өчен генә түгел, һәр хәреф өчен дә җаваплылык хисе белән эшлиләр. Кыскасы, алар тырышлыгыннан башка бер генә басма да дөнья күрә алмый. Болар — техник редакторлар, корректорлар, секретарьлар.

Журналист Габдулла Гомәр дә әнә шундый тыйнак һөнәр кешесе иде. Егерменче кырыгынчы еллар арасында матур әдәбиятта һәм көндәлек матбугатта аны белмәгән, аңа йомышы төшмәгән берәр кеше булдымы икән? Ул шулкадәр «үз» кеше, шундый ияләшкән сөйкемле иптәш иде, хәтта аның исем-фамилиясен дә икесен бергә кушып «Агомәр» дип кенә йөрттеләр. Әмма үзенә берни дә дәгъва итмичә, күбесенчә күләгәдәрәк торырга яратучы шушы тыйнак кеше журнал редакцияләрендә башкарган күп еллык намуслы, тырыш хезмәте белән аны белүчеләрдә озак онытылмаслык яхшы истәлек калдырды. Элекке зыялыларча һәрвакыт җыйнак костюмнан, һәйбәт галстук бәйләп, алтын чылбырлы пенсне киеп йөрүче бу интеллигент кыяфәтле журналистны без яратып «аяклы энциклопедия» дип атый идек. Бу исемгә бик тә лаек иде Габдулла, чыннан да аның белмәгәне юк иде. Кайсы зур әдәби вакыйга кайчан һәм кайда булган, ул хакта материалны каян табарга? Кайсы язучының фәлән әсәре беренче мәртәбә кайда басылган, аңа беренче рецензияне кем язган? Фәлән дөнья классигының мәшһүр әсәрен кем тәрҗемә иткән? Кайсы журнал яки газета кайчан чыга башлаган? Шуның ише тагын мең төрле сорауга һичбер мәшәкатьсез фәкать аннан гына җавап алып була иде.

1937 елның урталарыннан «Совет әдәбияты» журналын Габдулла Гомәр белән без икәү чыгара башладык. Мин вакытлы редактор вазифасын үтим, Габдулла Гомәр исә берүк вакытта җаваплы секретарь да, техник редактор да, корректор да, метронпаж да, җитмәсә, журналның тиражын тәэмин итәрлек кәгазь даулау да аңа йөкләнгән иде. Ул эшкә иртүк килә, журнал чыгасы көннәрдә типографиядә төнгә калып эшли, билгеле, эштән чыгып арый иде. Әмма мин Габдулланың бер генә мәртәбә дә зарлануын ишетмәдем. Аның каравы, журналның әле генә төпләнгән, буяу исе дә таралып җитмәгән яңа санын иртә белән редакция өстәленә китереп салганда аның шатлануын күрсәгез иде! Калын пенсне пыяласы артында аның зәңгәр күзләре елтырый,

үзе рәхәтләнеп елмая. Үзенең матур хезмәте нәтиҗәсенә чын күңелдән куанып яшәүчеләр миндә гомер буе тирән ихтирам хисе уята торган булдылар. Шушы шатлыклы вакыйганы билгеләп, без аның белән кара-каршы утырып сөйләшә-сөйләшә бик тәмләп чәй эчә торган идек.

Бөек Ватан сугышы башланып берничә ай узуга, язмыш безне яңадан шул ук журнал редакциясендә очраштырды. Матбугат йортының бишенче катында кечерәк кенә бүлмә (хәзер анда китап нәшрияты музее), бүлмә уртасында тимер мич. Аның бер ягында мин журналга килгән кулъязмаларны редакцияләп утырам, мичнең икенче кырыенда Габдулла үзенә йөкләнгән эш белән мәшгуль. Тимер мичнең шунысы яхшы — аның янында кулларга да җылы, кара савытындагы кара да бозланып катмый. Язучылар союзының хәзер инде дүрт кешелек кенә булып кечерәеп калган партия оешмасының (Хәсни Кәрим, Гази Кашшаф, Кави Нәҗми һәм мин) җыелышлары да, төрле утырышлар да шушы мич янында уздырыла иде.

1941 елның 16 ноябре көнне иртә белән без эшкә килгәндә бөтен матбугат йорты шау-гөр килеп тора, коридорлар, Габдулла Тукай клубының залы, күрше бүлмәләр Мәскәү язучылары, аларның гаилә әгъзалары белән тулган, сәхнәдәге зур рояль өстендә рәттән тезелешеп балалар йоклап ята. Аларның әти-әниләре исә кайберләре Чистайга озатуны, кайберләре Казанда квартирага урнаштыруны көтәләр иде.

Безнең редакциянең ишеге төбендә мин портретлары буенча электән үк таныш булган уртача гына буйлы, чәченә чал керә башлаган, ябык кына чибәр кеше белән очраштым. Бу италия язучысы Джерманетто Джованни иде. Хатыны белән икәү утырырга урын булмаганлыктан, басып торалар, балалары чемодан өстендә аркасын стенага терәп йоклап утыра иде. Габдулла белән без бер-беребезгә карашып алгач ук аңлаштык. Ишегең төбендә шундый хәлләр булып торганда ни җаның белән ул бүлмәдә тынычлап эшләмәк кирәк? Джерманеттоны гаиләсе белән бүлмәгә кертеп урнаштырдык та үзебез белеш-таныш, дус-ишләр бүлмәсенә «өйдәш» булып кердек.

Джованни Джерманетто ифрат якты чырайлы, иркен күңелле, чын мәгънәсендә интеллигент кеше иде. Бездән гафу үтенә-үтенә, ул квартира табылганчы гаиләсе белән редакция бүлмәсендә яшәп торды. Тырыша торгач, Габдулла Гомәр аны Болак буенда яшәүче бик һәйбәт кешеләргә илтеп урнаштырды. Шул көннән башлап бу кунагыбыз Язучылар союзы янында оештырылган агитбригаданың иң актив членнарыннан берсе булып китте. Ул русча ярыйсы гына белә иде — завод-фабрикаларда, Тукай клубында оештырылган кичәләрдә фашизмның ерткычлыгын фаш итеп ялкынлы речьләр белән чыга башлады. Кичәләрдә итальян теленә тәрҗемә итеп Г. Тукай шигырьләрен дә укый иде.

Татарстан язучылары Мәскәү кунакларын, туганнарча якты чырай белән каршы алып, байтагысын үз квартираларына керттеләр. Кунаклар Казанда һәм Чистай шәһәрендә урнашып берникадәр тормышлары тәртипкә салынганнан соң, Г. Тукай клубында әдәби кичәләр булып алды. Ул кичәләрдә, Джерманеттодан тыш, тагын француз драматургы Жан Ришар Блок, немец язучысы Вилли Бредель, Мәскәүдән Александр Фадеев, Алексей Толстой, Демьян Бедный, бездән Кави Нәҗми, Нур Баян катнашуы истә калган. Габдулла Гомәр белән безгә, журнал чыгарудан тыш, байтак кына җәмәгать эшләре дә башкарырга туры килә иде.

Тагын шунысын да онытмыйк, сугыш вакытында журналларның күбесе чыкмый башлады. Әмма хәзерге «Казан утлары»ның абыйсы «Совет әдәбияты» юкарак булып калса калды, тиражын киметсә киметте — ничек итсә итте, әмма бер генә санын да чыгармыйча калмады. Моның өчен барыннан да элек партия өлкә комитетының ул еллардагы секретаре Самат иптәш Мөхәммәтовны һәм миннән соң редактор булып килгән, бу юнәлештә зур фидакарьлек күрсәткән мәрхүм Гази Кашшафны рәхмәт сүзләре белән искә алырга кирәк.

...Менә истәлекләр тәмамланып та килә. Иң әһәмиятле фактларны искә төшердем кебек. Инде нокта куярга да бик вакыт. Менә хәзер... Ләкин күңел түрендә тагын нидер бар икән ләбаса, кулның нигәдер нокта куясы килми... Шул чакны телефон чылтырады. Алсам, Диләрә Зөбәерова икән.

— Гомәр абый! Кырык беренче елда редакция ишеге төбендәге чемодан өстендә йоклап утырган баланың исемен әйтимме? — диде.

Мин хәйран калып сүз таба алмыйча торганда, Диләрә аңлатып та бирде:
— Ул Иоанна исемле. Хәзер бик чибәр ханым инде, Мәскәү радиосында бик җаваплы эштә. Алар әнисе белән Казанны һаман искә алалар, рәхмәтләре бик зур...
Әнә шундый искиткеч акыллы да, гыйбрәтле дә ул тормыш.



## Афзал Шамов: «ӘДӘБИ ДУС, ЮЛДАШ»

«Казан утлары»ның беренче исеме, балачагы — «Безнең юл». Мин аның беренче санын, басылып чыккан көннәрендә үк кулыма тотып, һәр юлын, һәр битен шатланашатлана күздән кичергән, укыган кешеләрнең берсе.

Журналның чыга башлавын без, ягъни укучылар, әдәбият сөючеләр, бик куанып, сагынып көтеп алдык. Ул көннәрдә әле татар телендә зур әдәби журнал юк иде. Халык бик мохтаҗ иде аңа. Яңа әдәби әсәрләргә бик сусаган идек. Әдәби әсәрләргә генә түгел, үткен каләм белән язылган, тирән эчтәлекле гыйльми, сәяси, иҗтимагый мәкаләләргә дә сусаган идек без.

Ул елларда әдәби-нәфис журналның булмавы бер дә гаҗәп түгел. Чөнки авыр еллар, дәһшәтле еллар иде ул чакта. Гражданнар сугышы әле тәмамланып кына килә, ил хуҗалыгы хәрабә хәлендә, яшь совет Россиясенең күп кенә өлкәләрендә, бигрәк тә Идел буенда, Татарстанда мәрхәмәтсез ачлык хөкем сөрә. Кайдадыр бандитлар айкалып йөриләр, Урта Азия республикаларында басмачылар тынгылык бирми — авылларга, кечерәк шәһәрләргә һөҗүм итәләр, совет оешмаларын яндыралар, җимерәләр, талыйлар, коммунистларны, активистларны үтерәләр, канга батыралар. Ил чикләре дә тыныч түгел. Ерак Көнчыгышта әле интервентларга каршы каты сугышлар бара...

«Безнең юл» журналының чыга башлавын без бәйрәм кебек итеп каршыладык, аны Коммунистлар партиясенең, Совет хөкүмәтенең татар халкына биргән зур бүләге санап кабул иттек.

Журнал беренче саннарыннан ук, хәзерге «Казан утлары» шикелле, әдәби, иҗтимагый-политик журнал булып чыга алмады. Анда әле, әдәби әсәрләргә караганда, башка темаларга, аеруча иҗтимагый-политик темаларга, хуҗалык мәсьәләләренә багышланган мәкаләләргә күбрәк урын бирелә иде. Әдәби әсәрләр, кагыйдә буларак, журналның соңгы табакларында гына басылдылар.

Журналның күләме зур түгел иде. Беренче саны 56 битле булып басылса да, шуннан соңгылары 48 битле генә булып чыктылар. Кәгазе начар, хәрефләре тонык, техникасы да бик нык яхшыртуны таләп итә иде. Әле дә хәтердә: беренче саны, кулдан-кулга йөри-йөри, укыла-укыла, биз тиз тузып, тетелеп бетте. Шулай да ул күпләргә җан азыгы булып өлгерде.

Журналның беренче редакторы Г. Ибраһимов булмаса да, аның чыга башлавы, эчтәлегенең яхшылануы, урнаштырылган әдәби әсәрләрнең сан ягыннан арта баруы, аның тирәсенә күренекле әдипләрнең, шагыйрьләрнең һәм әдәбият белгечләренең тупланувы, һичшиксез, атаклы әдипнең әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге белән турыдантуры бәйле. Татарстан партия архивында моны раслый торган мөһим документ бар (15 фонд, 459 эш, 79 бит).

1926 ел башында Г. Ибраһимов, ВКП(б) Өлкә комитетының җаваплы хезмәткәрләре белән очрашып, аларга үзенең «Безнең юл» журналының эчтәлегеннән канәгать түгел икәнен, кайбер очракларда анда газеталарда гына урын алырга тиешле мәкаләләрнең басылуын, тиражының азлыгын, чираттагы саннарның вакытында чыкмавын, хәтта иркенләп утырып эшләрлек урыны да юклыгын сөйли һәм өлкә комитетында моңа игътибар итүләрен, журналга матди-мәгънәви ярдәм күрсәтүләрен үтенә.

Әдипнең бик урынлы сүзләрен искә алып, журнал мәсьәләсе шул ук елның 26 январендә Өлкә Комитетының матбугат бүлегендә тикшерелә. Утырышка кайбер язучыларны, журналистларны да чакыралар. Журнал турындагы докладны Г. Ибраһимов үзе ясый. Докладында ул Өлкә Комитетының журналга игътибары җитенкерәмәве, аның эше, торышы, планы белән чын-чынлап кызыксынмавы, аны тарату эшләре белән җитәрлек шөгыльләнмәве турында сөйли һәм журналның эшен, басылачак әсәрләрнең эчтәлеген, әдәби сыйфатын яхшырту өчен нинди чаралар күрергә кирәклеген әйтә.

Докладта күтәрелгән мәсьәләләр турында чыгып сөйләүче иптәшләрдән Ф. Бурнаш, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Галиев, С. Атнагулов, Ш. Фәхретдинов һәм башкалар Г. Ибраһимов тәкъдимнәрен яклыйлар һәм аларны тормышка ашырырга, журналга матди-мәгънәви ярдәм күрсәтергә кирәк дигән фикерне куәтлиләр. Матбугат бүлеге коллегиясе журналның эшен, торышын яхшыртуга юнәлдерелгән карар чыгара. Карарда «Безнең юл» асылда әдәби-нәфис журнал булырга тиеш һәм шул ук вакытта анда гыйльми бүлекне дә сакларга кирәк дип басым ясап әйтелә; тиражын арттыру, бәясен киметү, үз вакытында бастырып чыгару һәм башка практик чаралар да билгеләнә. Шул ук утырышта журналның яңа редколлегиясе дә раслана: аңа Галимҗан Ибраһимов, Гомәр Галиев һәм Гаяз Максудов иптәшләр кертелә.

Бу карарның уңай нәтиҗәсе булгандыр дип уйларга кирәк, шуннан соң чыккан саннарда төп урынны әдәби әсәрләр белән торалар. Әйтергә кирәк, «Безнең юл» үзенең беренче саннарыннан ук башлап укучыларның яратып укый торган журналы, әдәби дусты, юлдашы булды, аларны коммунистик рухта тәрбияләде, партиябез куйган зур планнар һәм бурычларны тормышка ашырырга, көрәшкә өндәде. Журнал Г. Ибраһимов, Г. Галиев, Г. Нигъмәтиләр башлап җибәргән бу матур традицияне хәзер дә уңышлы дәвам иттерә.

Журнал тыныч төзелеш елларында гына түгел, ә илебезнең иң авыр көннәрендә, Бөек Ватан сугышы елларында да укучыларның якын дусты, юлдашы, аларга җан азыгы бирүче, аларны көрәшкә, Бөек Җиңүгә рухландыручы булып яшәде. Дөрес, ул фронтларга подписка белән җибәрелми иде. Шулай да аның кайбер саннары төрле юллар белән сугышчыларга барып җитә торды. Кулларына эләккән һәр санны алар бик кадерле, бик тансык нәрсә итеп, хәтта өйләреннән, әти-әниләреннән, җанкисәкләреннән килгән сәлам хаты шикелле итеп каршы алалар һәм сугыш арасында аны аерым-аерым да, бергә җыелышып та укыйлар иде.

Без дә, язучылар да, фронтта чакта «Совет әдәбияты»ның һәр санын бик сагынып, зарыгып көтеп ала идек. Ул елларда журнал редакциясендә эшләгән иптәшләргә рәхмәт, алар фронтларда чыга торган татар газеталарына һәм кайбер язучыларга журналның бирер данәсен җибәреп тордылар. Дөрес, килми калган чаклары да булгалый иде. Нишлисең, фронтта төрле хәлләрнең булуы мөмкин. Шуңа күрә без мондый очракларда тылдагы иптәшләребезгә үпкәләми идек. Күрергә, укырга насыйп булмаган саннарны башка юллар белән табарга тырыштык. Сорасак, гаиләләребез дә, дус-ишләребез дә гозеребезне кире какмыйлар, кирәкле санарны ничек тә табып җибәрәләр, безне шатландыралар иде.

Журналның яңа саны килгән көн безнең өчен үзенә күрә бер бәйрәм була иде. Буш минутларда аны, кулдан-кулга йөртеп, башыннан ахырынача укып чыгасың. Буш минутларда гына түгел, ә төн йокыларыбызны калдырып булса да укый идек. Бик кадерле кунак иде ул безгә. Аның ярдәмендә без әдәби хәрәкәтне генә түгел, ә Татарстанның экономик хәлен, халкыбызның уй-фикерен, сагышын, нинди теләкләр, нинди хисләр белән яшәвен белеп тора идек. Безнең өчен дә ул туганарыбыздан, сөйгән ярларыбыздан килгән сәлам хаты дәрәҗәсендә иде.

Кайчак, фронтның алгы кырыена барганда, аны, үзебез белән алып китеп, мөмкин булган җирләрдә сугышчыларга да укый идек. Димәк, журнал политик пропаганда коралы булып хезмәт итте. Фронтовиклар һәрвакыт диярлек журналда басылган әдәби әсәрләрне, Татарстан хезмәт ияләренең тормышын, көнкүрешен, көрәшләрен чагылдырган мәкаләләрне бик кызыксынып тыңлыйлар, ә соңыннан безне төрле сораулар белән күмәләр иде. Сорауларның күп өлеше Татарстанга, халкыбызның тормышына, уй-фикеренә бәйләнешле мәсьәләләр турында була иде. Туган-үскән яклардан килгән һәр хәбәр, һәр яңалык белән бик кызыксыналар, барысын да белеп торасылары килә иде аларның.

Бервакыт, мин, 1943 елның җәендә, июнь аенда булса кирәк, фронтның алгы кырыена барганда, «Совет әдәбияты»ның редакциябезгә яңа гына килгән февраль-март айларының кушма санын иптәшләремә сиздермичә генә кыстырып алып киттем. Бу эшемне аларның хупламавын, үпкәләячәкләрен белсәм дә, аны алып китмичә булдыра алмадым. Чөнки анда сугышчыларга укырлык шигырьләр дә, кыска хикәяләр дә шактый иде. Шуның өстенә татар халкының фронттагы улларына, кызларына язган сәлам хаты да басылган иде. Шуңа күрә аеруча кадерле сан иде ул. Без, хәрби кор-

респондентлар, ул хатны мөмкин булган һәр җирдә татар сугышчыларына укый идек. Укырга мөмкин булмаса, эчтәлеген сөйли идек.

Кызганычка каршы, бу юлы мин аны сугышчыларга иркенләп укый алмадым. Фронтның мин барып чыккан җире бик тынычсыз иде, шуңа күрә татар сугышчыларын бер тирәгә туплап булмады. Шулай да редакциягә кайтып китәр алдыннан гына берничә сугышчыны үз яныма чакыртып ала алдым. Алар белән яңадан сөйләшәсем, командирларыннан алган кайбер мәгълүматларны ачыклыйсым, блокнотыма теркәлгән материалларны тулыландырасым бар иде. Шушы ике-өч көн эчендәге сугышларда батырлык күрсәткән егетләр иде алар.

«Тынычрак» дип саналган бер землянкага җыелдык. Эшемне тәмамлагач, хәрби сумкамнан әлеге журналны чыгардым, татар халкының сәлам хаты турында берничә сүз әйттем, бик кирәкле дип тапкан урыннарны укып та күрсәттем. Сугышчыларның кайберләре сәлам хатының барлыгын белсәләр дә, укымаганнар икән, бик кызыксынып тыңладылар. Ахырда журналдагы бер-ике шигырьне дә укыдым. Ә. Фәйзинең «Дулкыннар сөйли» исемле поэмасын аеруча ошаттылар. Ул Сталинградта барган сугышларга, Кызыл Армиянең тиңсез батырлыгына багышланган иде.

Яныбызда бер лейтенант та бар иде. Соңгы сугышларда аның ротасы дошманның берничә атакасын кире кайтарган, батырлык күрсәткән иде. Менә шул лейтенант,— хәзер исеме дә, фамилиясе дә хәтеремдә калмаган,— журналны кулына алып, эчтәлеген укып чыкты да:

— Карагыз әле, иптәш капитан, монда укырлык нәрсәләр күп икән! — дип, соклanып кычкырып куйды.— Хәтта татар халкының сәлам хаты да бар. Әгәр мөмкин булса, миңа биреп калдырыгыз әле моны.

— Юк,— дидем мин, башымны кире кагып,— бирә алмыйм. Үзебезгә кирәк. Редакциябезгә бер генә дәнә килә. Иптәшләрем дә укымаган әле аны.

— Бик кызганыч,— диде лейтенант.— Алайса, сез аны миңа бер-ике көнгә генә биреп торыгыз. Мин аны сугышчыларга укытыр идем.

Егетнең бу үтенечен дә үти алмаячагымны әйттем:

— Монда эшем бетте, хәзер редакциягә кайтып китәм.

Бу сүземне ишеткәч, лейтенант кына түгел, землянкадагы башка сугышчылар да күңелсезләнделәр, хәтта бу аларның йөзләренә дә чыкты. Миңа, ничектер, уңайсыз булып китте. Дөресе, оят булып китте. Кичә генә әле бу егетләр утларга кергән, дәһшәтле үлемнең күзенә карап барганар, батырлык күрсәткәннәр, җаннарын аямаганнар, ә мин үзебезгә кирәк дигән булып, аларга шул бер дәнә журналны бирәлмим. Нәрсә инде бу, кешелеклелекме, түгелме? Минем урында башкалар нишләрләр иде? Әгәр мин, алар урынында булып, кемгә булса да шундый үтенеч белән мөрәҗәгать итсәм, ә ул үтенечемне кире какса, нишләр идем икән? Ничек тәэсир итәр иде икән миңа?..

Бераз сөйләшеп торганнан соң мин, үз-үземне җиңеп, журналны лейтенант кулына тоттырдым:

— Тик менә нәрсә, лейтенант, зинһар, берәр атнадан редакциягә җибәрә күр. Югалтасы булма!

Егет әллә шатлыгыннан, әллә, гадәтенчә, болай гына чатнатып җавап бирде:

— Юк, иптәш капитан, тыныч булыгыз, югалтмам. Мин аны — пистолетымны, автоматымны саклаган шикелле саклап тотармын.

Редакциягә кайтып керүем белән үк иптәшләр миннән журналны сорадылар. Дөресен сөйләп бирергә туры килде.

Редакторыбыз үз сүзле, бераз кырыс холыклы кеше иде,— бу эшемне бер дә ошатмады:

— Ялгыш иткәнсең,— диде, ул миңа шелтәле-шелтәле.— Кем нәрсә сорамас. Күз яшьләре белән ялынып сорасалар да, бирмәскә кирәк иде. Бөтен фронтка бер журнал бит ул. Ә син аны ротага биреп калдыргансың...

— Борчылмагыз, кайтарыр.

— Кайтарыр, кызыл кар яугач. Кит!

Чынын әйтим, лейтенантның аны кире кайтаруына үзем дә ышанып җитми идем. Фронт. Сугыш. Нинди генә хәлләрнең булмавы мөмкин!

Иптәшләрем алдында акланмыйча булдыра алмадым.

— Карагыз әле, иптәшләр,— дидем мин аларга,— нигә бу чаклы бәйләнәсез миңа? Мин бит аны кырда ташлап калдырмадым, ә фронттагы сугышчыларга бирдем. Анда да вакытлыча укып торырга гына бирдем. Укырлар да кире кайтарырлар. Югалмас... Борчылмагыз, зинһар! Тагын шуны да исегездә тотыгыз: журнал бит алар белән бергә сугышларга керәчәк, атакаларга барачак...

Белмим, сүзем редакторга ничек тәэсир иткәндер,— анысын әйтә алмыйм, әмма язучы Абдулла Әхмәткә бик ошады (ул да минем белән бергә хезмәт итә иде). Ул гадәтенчә, имән бармагын югары күтәреп:

— Ох ты! — дип, рухланып кычкырып җибәрде.— Ох ты! «Совет әдәбияты» фашистларга каршы атакага бара!.. Гаҗәп зур вакыйга бит бу, иптәшләр!.. Капитан, биреп калдырып, дөрес эшләгән.

Шулай да мин Казаннан, Гази Кашшафтан, журналның шул куш санын соратып алырга кирәк таптым (сугыш елларында аның редакторы иде ул). Дустым сүземне тыңлады, җибәрде.

Бер-ике айдан соң әлеге, алгы кырыйда лейтенантка биреп калдырган журнал да редакциягә кире әйләнеп кайтты. Тик инде ул бик тузган, тушкырылган, окоп тузаннары белән каралган, укырлыгы калмаган иде.

Хәзер, күп еллар үткәч, бу вакыйганы исемә төшерәм дә күңелемнән горурланып уйлыйм:

— Тыныч төзелеш чорында да, авыр сугыш елларында да журналыбыз, шөкер, меңнәрчә укучыларның җан азыгы, әдәби дусты, юлдашы булды, хәтта ул сугышчылар белән бергә явыз дошманга каршы атакаларга да барды. Бөек Җиңүне даулады...

## Әхмәт Исхак: «ТАГЫН ДА ЯКТЫРАК, КӨЧЛЕРӘК ҺӘМ ЕРАККАРАК!»

«Казан утлары»!

Әгәр миннән: нәрсәнең исеме җисеменә бигрәк тә туры килә, дип сорасалар, аз гына да уйлап тормыйча, безнең әдәби журналыбыз «Казан утлары», дип җавап бирер идем. Бу — күпертеп тә, арттырып та әйтү түгел. Бу — чыннан да шулай. Үзегез күз алдына китереп карагыз! Планетабызның гаять зур өлешен эченә алган күп милләтле Совет иленең урта бер җирендә урнашкан автономияле республикабызның башкаласы Казан шәһәрендә чыга торган бу журнал республикабызда гына түгел, бәлки Советлар Союзының төрле почмакларында яшәүче социалистик милләттәшләребезгә — күп миллионлы татар халкына рухи нур балкытып торучы якты маяк ролен уйный. Тиражы соңгы елларда инде йөз меңнән артып киткән журналыбызның һәр номерын, кулдан кулга йөртеп, дистәләрчә кеше укуын исәпкә алсаң, совет кешесенә художество чаралары белән идея тәрбиясе бирү эшендә аның нинди зур урын тотканын күз алдына ачык китереп була.

Безнең өчен — татар совет язучылары өчен — ул әдәби осталыгыбызны үстерүгә өзлексез ярдәм итүче гаять зур мәктәп тә булды һәм булып кала. Журнал кичергән алтмыш ел вакыт эчендә аның тирәсендә тупланып, өйрәнеп, тәрбияләнеп, берничә буын язучыларыбыз үсте, танылды һәм күп милләтле совет әдәбиятында үзенә лаек урынны алды. Бүгенге көндә дә ул әдәбиятыбызга елдан-ел күбрәк санда килә торган талантлы яшь шагыйрь, прозаик, әдәбиятчы һәм тәнкыйтьчеләрне үз тирәсенә туплау, тәрбияләү һәм үстерүдә дәвам итә.

Үземнең әдәби иҗатымны да мин «Казан утлары»ннан аерып карый алмыйм. Әгәр дә «Кызыл кошлар» исемле беренче шигырем 1923 нче елда «Кызыл шәрык яшьләре» журналында басылган булса, берничә елдан соң «Шинель турында» дигән шигырем «Казан утлары»ның юл башы булган «Безнең юл» журналында басылып чыкты. Минем өчен бу гаять зур шатлыклы вакыйга булды. Моны мин олы әдәбиятка аяк басуым дип хәтерлим. Аннары журналның «Атака» исеме белән чыккан номерларында тәрҗемәләрем, тәнкыйть мәкаләләрем һәм чәнечкеле шигырьләрем басылып

торды. Ә «Совет әдәбияты» исеме белән чыккан номерларында бик күп шигырь, публицистик һәм тәнкыйди мәкалә һәм тәрҗемәләрем даими рәвештә урын алып килде. Бөек Ватан сугышы елларында да журнал белән элемтәм өзелмәде. Ерактан, Кызыл Армия сафларыннан җибәргән әсәрләрем аның сәхифәләрендә еш кына басылып торды. Аннан соңгы елларда да журнал битләрендә бик күп әсәрләрем басылып торды.

Шул трибунабыз һәм әдәби мәктәпнең даими укучысы — шәкерте буларак, аның сәхифәләрендә өзлексез басылып торган теоретик һәм тәнкыйди материаллар минем дә үсешемә тәэсир итми калмагандыр. Шул алтмыш ел буена мин аңа язып кына түгел, һәр елны язылып, бер номерын да калдырмыйча укып бардым, барам һәм әле дә сабак алам һәм өйрәнәм. Миндә аларның барлык диярлек подшивкалары саклана һәм мин алардан һәрвакыт файдаланам.

Журналның бик әһәмиятле тагы бер ягына тукталмый үтеп булмый. Бу — халкыбызның, илебезнең һәм әдәбиятыбызның борынгы тарихына, аларны өйрәнүгә һәм яктыртуга багышланган җитди фәнни материалларны мөмкин булган күләмдә урнаштырырга тырышуы. Андый материалларны урнаштырырлык махсус журналларыбыз булмавы шартларында «Казан утлары»ның бу тырышлыгы аеруча мактауга лаек. Андый материалларны мин аеруча яратып һәм шатланып укып барам. Журналның әдәби тормышыбызда һәрвакыт булып торган әһәмиятле даталар, вакыйгалар һәм фактлар турында информациягә мөмкин кадәр урын табарга тырышуы да укучыларның рәхмәтенә лаек күренеш.

«Казан утлары»ның киләчәктә тагын да яктырак, көчлерәк һәм ераккарак балкуын телим.

## Фатих Хөсни: «БЕЗНЕҢ БИШЕГЕБЕЗ»

«Казан утлары» журналының чыга башлавына да 60 ел була икән! Күр әле, гомер ничек тиз уза. Әле кайчан гына, аның «Безнең юл» исеме белән чыккан чакларында, без аның ишеген шакырга да базмыйча, тирәсендә яланаяклап чабып йөргән малайлар идек. «Яланаяклап» дигәнем — образлап әйтергә тырышудан. Чөнки без яшь әле, күп нәрсәгә тешебез үтми, ә журналда Һади Такташ, Кави Нәҗми, Хәсән Туфан, Гомәр Толымбайский, Фәтхи Бурнаш кебек танылган исемнәр басыла. Ул да түгел, Урал ягыннан Хәнәф Наум, Казаннан Галимҗан Нигъмәти кебек тәнкыйтьчеләр әдәбиятның яки культура фронтының актуаль проблемалары турында «әтәч сугыштырып» алалар. Як-якка каранып, исәп-хисап белән эш итү юк, сүз ачык, гыйбарәләр үткен, әйтсәләр — чынлап та әйтәләр иде. Әле дә исемдә, Гомәр Гали мәрхүм шундый ачы телле әдәби бәхәсләрнең берсендә Фатих Сәйфи-Казанлының форма мәсьәләсендә талымсызрак эш итүенә кинаяләп: «...Сәйфинең аның персонажлары егылганда Галимҗан булып егылсалар, торганда Сабирҗан булып торалар» дип, шаяртkan булып әйтеп куйган иде. Әйбәт шаярту! Хәзерге әдәбиятчыларыбызда булсын иде шундый әче, туры тел!

Әнә шундый шау-шулы, кызыклы бәхәсләр, оригиналь талантлар белән мыжгып торган чорда, тирәсендә яланаяклап, йөгереп йөрешли, курка-ояла гына мин дә ул кызыклы дөньяга — әдәбиятка кереп киттем.

Аңа тикле «Яшь ленинчы», «Кызыл яшьләр» газеталарында вак-төяк «көйле иманнар» бастырып, чак-чак кына кыюлык җыйгач, 1927 елда, ниһаять, «Безнең юл» журналының ишеген шакып карарга җөрьәт иттем. Алып барган өч-дүрт шигырьдән берсен журналның ул чактагы редакторы Гомәр Гали, иптәшләре белән сөйләшкәннән соң, бер шарт белән басарга булганлыгын әйтте. Ләкин куйган шарты бераз аптыраткыч иде. Мин шигыремнең астына «Мөхәммәтфатих Хөснетдинов» дип имза куйган идем, Гомәр Галигә бу ошамаган. «Только имзаңны бик озын куйгансың, моның башыннан алып азагына барып чыкканчы, утырып, ял итеп алырга кирәк булачак. Әгәр үзең риза булсаң, без аны болай итәбез. Башындагы «Мөхәммәт»не киеп атабыз, койрыгындагы «ов» белән шулай ук бәхилләшергә туры килер, каласың «Фатих Хөсни» булып...» Бары тик бассыннар гына, мин бөтенесенә риза идем. Уенмыни, мин

«Безнең юл»га аяк басам бит. Хәерле сәгатьтә, дөньяга алып чыксын мине «Безнең юл»!

Һәм горурлык хисе белән шуны әйтә алам: алып чыкты ул мине. Һәрвакыт һәм бөтен әйберләрем өчен гел башымнан гына сыйпап торды дип әйтә алмыйм, башыма сугулар да, алып барган язмаларны кочаклатып, кире борып җибәргән чаклары да, әлбәттә, булды. Ләкин бу яратып, үз кешеләрең тарафыннан борылу, яхшыракны күрергә теләп, минем яхшыракка да көчем җитәрлек булуына ышанып, кире бору булды...

«Безнең юл», «Атака», «Совет әдәбияты» һәм ниһаять, «Казан утлары» — образлап әйткәндә, болар бөтенесе безнең юл, безнең ышанычлы юл, хәтта юл гына да түгел, безне үстергән «яшел бишегебез» булды. Бу журналда басылу, анда үзеңнең имзаңны күрү, дөресен әйткәндә, безнең барыбыз өчен дә, олыларыбыз өчен дә, кечеләребез өчен бигрәк тә бәйрәм иде. Элек тә шулай булды, хәзер дә шулайдыр дип уйларга кирәк. Җыеп кына әйткәндә, безнең әдәбиятыбызның күзгә күренердәй барлык әсәрләре дә иң элек журналда беренче чыныгу алды бит.

Аерым алганда, минем үземнең укучы кабул иткән һәм үзем яратып язган барлык әсәрләрем — «Йөзек кашы», «Җәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы ел», «Гыйльмениса һәм аның күршеләре», «Язмыш шуклыгы» дигән роман һәм повестьларым, күп санлы барлык хикәяләрем якты дөньяга әүвәлән «Казан утлары» яктысында атладылар һәм моның өчен журналга — анда эшләп киткән һәм эшләп килүче каләмдәш иптәшләремә чын ихластан әйтелгән рәхмәтемне җиткерәсем килә.

Әсәрләремне бастыру белән бергә, төрле елларда һәм төрле срокларда мин үзем дә журнал редакциясендә гади әдәби сотрудник булып, кулымнан килгәнчә, журналны чыгарышуда өлешемне керттем. Гази Кашшаф, Газиз Иделле, Ибраһим Гази, Кави Нәҗми, тагын бер мәртәбә Гази Кашшаф, Габдулла Гомәр, Гариф Ахунов, Зәки Нури, минем редакторларым буларак, болар белән күп вакыт якынтын очрашып, алардан киңәш сүзләре ишетеп, шундый яхшы иптәшләрем булганлыгы өчен куанып яшәдем. Мине теге яки бу дәрәҗәдә иҗатка очындыруда аларның да өлеше, әлбәттә, бар. Кыскасы, барысы өчен дә, барысы өчен дә бөтенесенә рәхмәт, дөньяга рәхмәт, мине шундый кызыклы мәйданга китергәнлеге өчен язмышыма да рәхмәт әйтмичә кала алмыйм.

## Нури Арсланов: «ЯРЫША-ЯРЫША...»

Һәр татар язучысының иҗади хезмәтендә «Казан утлары» журналының нинди роль уйнавын бәяләп бетерү мөмкин булыр микән?! Безнең бердәнбер калын журналыбыз буларак ул бөтен әдәби йөкне үз җилкәсенә алган. Аны тәҗрибәле олы язучылар өчен укучылары алдында үз хезмәтеннән хисап бирү трибунасы дип исәпләсәк, күпләгән яшь язучыларыбызга үсү, үрләү, үзенең талант йөзен күрсәтү мәйданы дип әйтү дә бик хаклы булыр иде. Күпме еллардан бирле инде ул шушы изге бурычын үтәп килә.

Язу эшендә тәҗрибәң арткан саен язган әсәрең өстендә күбрәк эшләү фарыз булып кына калмый, бөтенләй гадәткә әйләнеп китә. Кат-кат төзәтәсең, кучерәсең, тагын үзгәртәсең һәм, ниһаять, инде тәмам тегәлләнде дигән нәтиҗәгә килгәч кенә редакциягә тапшырасың. Журналда чыккач ул инде укучылар милкенә әйләнеп, тагы да бер нечкә иләктән үтә. Укучылар, кай чакта, хатлар язып үз фикерләрен синең белән уртаклашалар. Арада бик уйланырга мәҗбүр итә торганнары да була. Шулай итеп шигырьләр, китап булып чыкканга кадәр, үзләре дә яхшыралар, шомаралар һәм авторга да үз сәләте югарылыгына күтәрелергә ярдәм итәләр. Безнең журналыбыз «Казан утлары» әсәрләрне кабул иткәнгә кадәр дә, үз битләрендә басып чыгаргач та, минемчә, иҗади мәктәп вазифасын дәвам иттерә. Чөнки мин, мәсәлән, әсәрләремне аңа тапшыргынчы, журнал сәхифәләрендә чыгарлык булсын, аның таләпчәнлегенә туры килерлек булсын, аның һәм минем йөзгә кызыллык китерерлек булмасын дип, кат-кат күздән кичерәм, ә журналда чыккач: кемнәр ни әйтерләр икән дип көтәм, кызыксынам, дулкынланам. Бу соңгысы инде чын имтихан була.

Моннан ун ел элек, мин, беркадәр вакыт, «Казан утлары»ның шигърият бүлеге

мөдире булып эшләгән идем. Ул елларда безгә күп яшьләр килде һәм күбесе оста язылган яңа шигырьләр белән куандырдылар. һәркайсысы үзенчә кыюлык белән үз авазын иркен яңгыратты. Бу җилкенчәклек миндә дә аваздашлык табып, рухны күтәреп җибәргәндәй тәэсир итте. Өстәвенә, шул сәләтле яшьләргә тәрбияче вазифасындагы кешегә — миңа алардан калышырга да ярамый иде, әлбәттә. Ул чакта бу яктан мин беркадәр Хуҗа Насретдингә охшаганмын булса кирәк. Ул бервакыт, гадәтенчә, бер кызык итим әле дип, базар чатындагы мичкәгә баскан да:

— Әй, җәмәгать! Фәлән урында, фәлән бай рухына бирәр дирһәм акча бирәләр! — дип кычкыра башлаган бит. Моны ишетеп халык бер-бер артлы шул якка таба юнәлгән. Бераздан тиз-тиз атлап баручылар да күбәйгән. Аннан, ниһаять, йөгерә дә башлаганнар. Моны күреп: «Тукта әле, чыннан да шулай бугай...» дип, Хуҗа үзе дә шул тарафка йөгереп киткән, имеш. Шуңа охшап, мин дә яшьләр өермәсенә кушылып йөгереп киткән булсам бер дә гаҗәп түгел!

Журналда хезмәт иткән чагымда сигез ел чамасы яшьләр белән якын аралашуым, аларга биргән үз киңәшләремә һәм аларның кыю, көр тавышларына колак салып, өйрәтеп тә, өйрәнеп тә яшәвем үзе миңа бер иҗади мәктәп булды. Шуңа күрә дә «Казан утлары» минем тормышымда — мәктәбем дә, лабораториям дә, клубым да.

Әгәр дә әдәбият мәйданында нинди дә булса уңышым бар икән, аның өчен үземне, беренче булып «Казан утлары» алдында бурычлы саныйм һәм әлеге яшьләр — хәзер инде үсеп җиткән шагыйрь дусларым белән бергә киләчәктә дә ярыша-ярыша җырларга ашкынам!



## Ләбибә Ихсанова: «ИҢ БӘХЕТЛЕ ЧАГЫМ КЕБЕК...»

Моннан ун-унбиш еллар элек редакциягә барганда, еш кына, ательеда закройщик булып эшләгән танышымны очрата идем. Буш вакытларында урамда йөрергә ярата иде ул. Ашыкмыйча, җай гына атлап килә, ә күзе кешеләрнең өс-башында. Мине ул үзе теккән пальтоны танып ала: йөзенә матур һәм рәхәт бер елмаю чыга, кайчандыр үзенең клиенты булган кешегә хөрмәт белән баш иеп, исәнләшеп китә... Мин аның хәлен аңлыйм. Ул үз эшен бик ярата, кешеләрнең матур киенеп йөрүләрен күреп шатлана, үз һөнәре белән горурлана. Эш остасында гына була торган профессиональ горурлык анда. Шагыйрь әйткәндәй, «бер горурлык яна битләрдә!..»

Кайда да булса берәр җирдә кулына «Казан утлары» тоткан кешене очратсам, таныш өемнең өстәлендә шул журналны күрсәм, я булмаса, аның турында сөйләшеп торуларын ишетсәм, мин дә шул танышым кебек шатлана идем. Без чыгарган журнал бит ул дип әйтәсем, я аларның сүзләренә кушылып журналның хәлләре турында сөйлисем килә иде. Әле булса шул хиснең миндә беткәне юк.

Гомернең ун елдан артыгы шушы редакциядә эшләп узган, журналның йөзләгән санын чыгаруга кул тигән, көч кергән. Кемнәр белән генә кара-каршы утырып сөйләшенмәгән дә шул елларда, күпме генә кеше белән хат-хәбәр алышынмаган, нинди борчулар һәм мәшәкатьләр кичерелмәгән... Барысы да әдәбият өчен, халкыбызның культура мирасы хакына.

Әнә Гаградагы язучылар иҗат йортыннан Шәйхи ага Маннур хаты килгән. Без күрсәткән фотоны ошатмаган, үзенең яңасын җибәрә алмавына борчылган. һәрвакыттагыча, уенын-чынын бер итеп, Малеевкадан Фатих Хөсни яза: «Гыйльменисаә апаны, машинкадан соң, монда бик тәмләп, бер карап укып, каләм тидерәсе җиренә каләм тидереп чыктым. Яңа ел номерына бик аптырау хәлендә калсагыз — әйбернең соңгы ноктасы куелган. Әгәр хәзердән үк «җиз иләктән» үткәрә башлыйбыз дисәгез, бүген үк почта белән җибәрәм». Редакция сотрудниклары белән җыелып, Ялтадан, Гариф Ахуновның (аның редактор булып эшләгән вакытында) күңелне күтәрә торган хатын укыйбыз: «Монда типографиядән Скороходова дигән ханым ялга килде. Ул безнең журналның бик төгәл һәм тыныч эшләнүен, ай башында ук чыгуын мактады: «Беренче сан безнең кулда инде, 2—3 битләрдә фотолар бар» дип төп-төгәл әйтеп бирде. Миңа ул хәл, әлбәттә, күңелле булды».

Журналның менә шулай төгәл һәм тыныч эшләнүе өчен редакция бүлмәләрендә бик күп тынгысыз көннәр кичерергә туры килә иде безгә. Күз карасын талдырып,

калын-калын кулъязмалар укудан башлана ул эш. Аннан соң редколлегия утырышларында кызып-кызып бәхәсләшүләр. Хәтердә әле, талантлы гына бер прозаикның яңа повестен «сытәргә» туры килде. Әлбәттә, ул безгә рәхмәт әйтеп утырмады, утырышның ахырында үпкәләп үк чыгып китте. Аның каравы, тынычлангач, бераз суына төшкәч, әсәрен өр-яңадан эшләп килде. Кайчагында журналга кирәк материалның нинди сәнга керүе турында да кызып-кызып бәхәсләшә торган идек. Менә шуннан соң гына башлана инде ул типографиягә төшәсе санны эшләү.

Андый көннәрне үзем утырган кечкенә бүлмә штабка ошап кала. Тимер-бетон стеналар һаваны начар үткәргәнгә, бүлмә ишеге төбенә кадәр ачык. Хәер, ул болай да ябылып тормас иде. Бүлекләрдә эшләүчеләр, корректорлар, машинисткалар минут саен кереп-чыгып торалар: бер материалны кыскартасы бар, икенчесенең исемен алыштырырга кирәк, бу сүзне язучы үзенчә язган, ә сүзлектә ул башкача алынган — хәл итәсе бар. Шул арада командировкага җыенучы берәр автор килеп керә. Аның белән сүзең бетми, телефон шалтырый — автор корректураларын укыган, төзәтүләр белән риза түгел... Ярата идем мин шундый тыгыз, тын алырга да вакыт булмаган көннәрне. Хәтта журнал басылырга төшеп киткәч, бушап калган тыныч көннәрдә бераз күңелсезрәк тә була башлый.

Безнең эштә тагын бер күңелле вакыт — журнал басылып бетәр алдыннан сигнальный экземпляр киләсе көннәр була. Менә техник редактор бер кочак журнал күтәреп килә. Аңар ияреп үк бүлмәгә башка иптәшләр кереп тула, кулдан тартып алгандай журналны алып бетерәләр, кайсы утырып, кайсы баскан көйгә, тиз-тиз актара башлыйлар. Ул сандагы һәр материал таныш югыйсә, бәхәсләшә-тартыша төзәтелгән, кат-кат укылган. Шулай да күрәсе килә, журнал булып төпләнгәч ничегрәк чыкты икән: материал кеше күзенә күренерлек итеп урнаштырылганмы, матур хәрефләр белән җыелганмы, буявы тигез төшкәнме... Бу минутларда безнең барыбызны да айлар буе тырышып эшләгән эшебезнең нәтиҗәсен яхшы итеп күрәсе килү тойгысы биләгән була — үз эшебез белән горурланасы килү, профессиональ горурлык тойгысы.

Бәхетле язучы редакция казанында кайнап ала, дип уйлыйм мин. Анда бит кешене генә «өйрәтеп» утырмыйсың, үзең дә күп нәрсә аласың. Редакциядә эшләү төгәллеккә, җыйнаклыкка, үзеңнең язганнарыңа редактор күзе белән, объектив карарга өйрәтә. Шуларның иң әһәмиятлесе — син әдәби процессның иң уртасында, син заманның әдәбиятка булган таләпләрен һәрчак якыннан сизеп, белеп яшисең. Поэзия бүлегендә эшләгән Нури ага Арслановның: «Бу яшьләр белән аралаша-аралаша үзем дә яшьләрчә яза башладым әле» дигән сүзе хәтердә.

Редакциягә инде яшьләр килде. Алар да безнең кебек җаннарын биреп эшлиләр, хәтта яшьләрчә кызыграк та итеп эшлиләр әле. Журналыбызның олы бәйрәмә көннәрендә мин аларга уңышлар телим. Профессиональ горурлыкны югалтмасыннар.

## Гариф Ахунов: «ГОМЕРЕМ БУЕ РӘХМӘТЛЕ»

«Казан утлары» журналы редакциясендә ун ел буе эшләдем. Әдәби хезмәткәр, проза бүлеге мөдире, җаваплы секретарь, баш редактор. Шулай булгачыннан, «Казан утлары»ның минем тормышыма йогынтысын сүз белән әйтмәсәң дә аңлашыла торгандыр.

«Казан утлары»нда Кави Нәҗми, Афзал Шамов, Таҗи Гыйззәт, Нәкый Исәнбәт, Риза Ишморат, Мирсәй Әмир, Шәйхи Маннур, Хәсән Туфан, Габдрахман Әпсәләмов, Фатих Хөсни, Әмирхан Еники, Сибгат Хәким кебек өлкән буын язучылар белән танышa алу бәхетенә ирештем. Шушы журналда эшләгәндә Гомәр Бәшировның «Намус» романын аркылыга-буйга өйрәнеп, Галимҗан Ибраһимов иҗатына барып тоташтым.

Журналның редакторы Гази Кашшаф мине колагымнан тартып диярлек әдәбиятка алып керде, көне-төне, арып хәлдән тайганчы эшләтте, авыр кара эштән курыкмаска өйрәтте. Проза жанрында эшләүне дә ул миңа көчләп диярлек такты, юкса минем я тәнкыйтьче, я шагыйрь булып китәргә ниятем бик зур иде. Гази абый — минем әтием урынындагы, кеше, олы остазым — безнең буынга, әдәбиятка сугыштан соң килгән

яшьләргә якты күз белән карап, ярдәм кулын сузып торды, безне гел кайгыртып яшәде. Муса Җәлилне — шагыйрьне һәм геройны яратырга, олыларга, күп милләтле совет әдәбиятының горурлыгы, йөз аклыгы итеп танырга иң башлап ул өйрәтте.

Журналда эшләгәндә, татар әдәбиятының үсеш тенденцияләрен, тугандаш әдәбиятлар гаиләсендә тоткан зур урынын күрдем, барлык жанрларны укып, күзәтеп барырга гадәтләндем, шул гадәтем бүген дә саклана.

Ниһаять, «Совет әдәбияты» — «Казан утлары» журналында эшләгән дәвердә татар әдәбиятына кем чынлап, күңелен биреп, намус белән хезмәт итә, кем әдәбиятны кәсеп итеп кенә карый, кем аңардан үзенең шәхси мәнфәгатьләренә азык кына эзли,— шуларны аерырга, шуларның икесенә ике төрле мөнәсәбәттә булырга өйрәндем.

Гомумән дә минем язучылар арасына килеп элгүем, язучы булып китүем әдәби журналыбыз белән бәйле. «Казан утлары»на гомерем буе рәхмәтлемен.

Чыга башлавына 60 ел тулган олы бәйрәм көннәрендә әдәби журналыбызның барлык хезмәткәрләренә, язучы-авторларына, йөз меңләгән укучыларына чын күңелдән бәхет, сәламәтлек, яңадан-яңа иҗат шатлыклары телим.

## Мөхәммәт Мәһдиев: «МИНЕМ ЯРДӘМЧЕМ, КИҢӘШЧЕМ...»

«Казан утлары» журналы белән беренче танышуым 1938—39 елларда булгандыр дип уйлыйм. Кышлар салкын, ягарга утын җитми, әмма без — малайларның бер юанычы бар: ай саен мәктәпкәме — кемгәдер «Совет әдәбияты» журналы килеп тора һәм без җыелышып шуны укыйбыз. Я мәктәпнең тузан, коры стена исе килеп торган классларына төштән соң җыелып, я җылырак өйле берәр иптәшебезгә кереп, мич каршында, утын шартлаганын тыңлый-тыңлый, сәкегә ятып укыйбыз. Нәрсәләр истә калган соң? Ни гаҗәп — барысы да тәрҗемә. Аеруча истә калганнары И. Франконың «Якты̇га таба», Шолом Алейхемның «Кара ясаучы малай», М. Ю. Лермонтовның «Гашыйк Гариб» әсәрләре икән. Карале, нигә без бүген дә дөнья әдәбиятының кайбер үрнәкләрен бу журналда биреп бармыйбыз? Нигә, мәсәлән, Ч. Айтматовның «Гасырга тиң көн» романыннан бер өзек (әйтик, манкорт турындагы өзекне), В. Шукшин хикәяләрен (мәсәлән, «Кәкре каенга терәтте» хикәясен), В. Быков, Н. Думбадзе, Г. Матевосян әсәрләреннән берәр өзек бирмәскә?

Без үскән елларда мәктәп дәреслекләрендә Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Х. Туфан, Ш. Усманов, Ф. Бурнаш юк иде, чын әдәби әсәр безгә аеруча кыйммәт иде. Безнең дәреслекләрдәниләр бар иде икән? Хәтерләмим. «Безнең әйберләрне сатканда», «Хәзер ансат ул, элек кыен иде» кебек хикәяләр... менә шуларны укыдык бугай. Әммә! Йөрәкләрне тетрәткән, тын буыла-буыла кат-кат укыган хикәяләр бар иде. Ул — Лев Толстойның «Пароходта пожар», «Акула» хикәяләре һәм Боб исемле бер этнең янгын вакытында бала дип белеп бер курчакны коткаруы турындагы хикәясе иде. Уку өчен, шулай итеп, материал күп булмаган. Инде әнә шул чын әдәбиятка сусаган күңелгә, рухка «Совет әдәбияты»ның чираттагы бер саны килеп керү, айлар буе ачлы-туклы тереклек иткән кеше алдына бер бөтен икмәк турап, табагы белән итле, токмачлы аш китереп куюга бәрабәр иде. Авыр елларда салкынны, ачлыкны оныттырган, рухыбызны баетып килгән «Совет әдәбияты» журналына, ул елларда аны чыгарган кешеләргә рәхмәт. Әдәбиятны иң әйбәт уку — бала вакытта, яшүсмер вакытта уку.

Карагыз әле, нинди бәхет ул: әдәби әсәр үзе укылган, әмма редакторы кем, редколлегия әгъзалары кем, тиражы күпме, ничә табаклык — шулары белән бөтенләй кызыксынмыйсың, бары тик әдәби азыкны — яхшы әсәрне йотасың гына. Сиңа шул гына кирәк. Чын уку, әдәбиятны чынлап җанга сеңдерү — бары тик шулай гына... Мин журналның яңа санын алган саен шул елларны, шул елларда басылган әсәрләрне сагынам, картаю билгесе икәнен аңлаган көе сагынам.

Инде журнал, язучы буларак, минем тормышымда нинди роль уйнады? Мин әдәбият дөньясына бик соң килдем — «Казан утлары»нда беренче мәкаләм басылганда утыз бердә, беренче хикәяләрем басылганда утыз алты яшьтә идем. Әммә шулардан башлап бу журнал минем иң зур ярдәмчемә, киңәшчемә әйләнде. Мин

яза башлаган чорда журналның баш редакторы тышкы кыяфәте белән элекке реальный училище укытучысы кыяфәтле Абдулла Гомәр иде, аннан минем әсәрләремнең язмышын хәл итүдә баш редакторлар Газиз Мөхәммәтшин, Рафаэль Мостафин, Гариф Ахунов, Зәки Нурилар катнашты. Шунысы белән бәхетле булдым: минем «Казан утлары»на китереп биргән бер генә әсәрем, бер генә мәкаләм дә басылмый калмады.

Журналда басылган мәкалә, хикәя, повесть, романнарымны яхшыртуга, хаталардан чистартырга, ниһаять, югары идеялелек, сәнгатьчә камиллеккә табa үстерүдә шул елларда баш редакторлардан тыш журналның бүлек мөдирләре, редакторлары Фәрваз Миңнуллин, Яхъя Халитов, Гәрәй Рәхим, Вакыйф Нуруллин ярдәм иттеләр. Хәтта үземнең лекцияләремне тыңлаган, миңа университетта имтихан тапшырып йөргән Ринат Мөхәммәдиев, Марсель Галиев кебек яшьләр дә ярдәм итте — чөнки алар журналның эчке лабораториясен яхшы белә.

«Казан утлары» журналы — алты миллионлы татар халкының әдәбияты көзгесе. Бу шундый көзге ки, монда бәяне күтәреп кую була алмый. Үзеңнең язучы буларак кем икәнеңне беләсең килсә, теге яки бу шәһәрнең нәшриятларында басылу өчен көч түгеп йөрмә, бер генә тапкыр булса да «Казан утлары»нда басыла. Әйе, бер генә тапкыр. Акыл иясе белән бер очрашып, бер сөйләшеп утыру да җитә икән...

## Рафаэль Мостафин: «ЭЗЛӘНҮ ТУКТАЛМАСЫН!»

«Казан утлары»н әдәбиятыбызның һич тутыкмас көзгесе дип атарга була. Әдәби тормышыбызның уңышлары да, җитешсез яклары да журнал битләрендә чагылыш таба, ап-ачык күренә. Әдәбият үссә, журнал да күтәрелә, күп санлы яңа укучылар яулый. Әдәбият бер урындарак таптанса, яңа кызыклы әсәрләр тумаса, журналның дә популярлыгы кими төшә.

Әдәби журнал, бигрәк тә «Казан утлары» кебек бердәнбер калын журнал, әдәбият үсешенә актив йогынты ясый. Ул үз битләрендә бастырып дөньяга чыгарыр өчен иң яхшы, иң камил әсәрләрне сайлап ала. Ул авторлар белән эшли, аларга әсәрләрен җиренә җиткереп чыгарырга булыша. Ул язучыларга заказлар биреп,— бигрәк тә очерк, публицистика, әдәби тәнкыйть жанрларында — иң кирәкле темаларга, иң мөһим булган проблемаларга яңа әсәрләр яздыра. Журнал редколлегиясе ихлас күңелдән, ару-талуны белми эшләсә, әдәбият та үсә, һәр хәлдә, аның үсеше өчен уңай шартлар тудырыла. Төгәлрәк итеп әйткәндә, журналны мин әдәбиятның яшәү ысулы дип атар идем. Әлбәттә, бу бердәнбер ысул түгел — әдәбият китаплар, газета битләре, радио-телевидение тапшырулары ярдәмендә дә, хәтта телдән-телгә күчеп тә яши ала. Ләкин, журнал — бик мөһим, китап басмасы белән бер дәрәҗәдә мөһим ысул.

«Казан утлары» минем өчен дә язылган мәкаләләрне, рецензияләрне, очеркларны бастыру өчен бер мәйдан гына булып калмады. Тәнкыйтьче буларак, мин шушы журнал битләрендә формалаштым. Ул булмаса, күп әсәрләрем дөньяга да тумаган булыр иде. Туса да, башкачарак булып (я газетчарак, я китапчарак) туарлар иде. «Казан утлары» — ул безнең барыбызның да уртак язмышыбыз дияргә була.

Мин егерме елдан артык инде журналның актив авторы булып киләм, күп еллар буе редколлегия әгъзасы булдым, журналның җаваплы редакторы булып та (1965—68 еллар) эшләдем. Шул дәвердә бер нәрсәгә инандым: журналны туплаган-формалаштырган вакытта иң элек укучы турында уйларга, аны ачык итеп күз алдына китерергә кирәк. Бердәнбер журнал булгач, анда басылырга дәгъва итүчеләр әлбәттә бик күп була. Берсенең бернича ел буе әсәре журналда басылганы юк икән, ә бит ул да — Язучылар союзы члены, аның да басылырга хакы бар... Икенче берәүләр хәтта «җалу» язып теңкәгә тия... Өченчесе, сәләте чамалы булса да, эштә билгән постыннан файдалану ягын карый... Дүртенчесе кайчандыр казанган даны яктылыгында яшәп калырга чамалый... Чын әдәбиятка һәм әдәбиятчыга һич хас булмаган мондый таләпләр — бихисап. Аларга игътибар итеп, барын да исәпкә ала башласаң — беттең, принципиальлегеңне югалттың дигән сүз. Ә әдәбиятта, шул исәптән, редакция эшендә, бер генә принциптан чыгып эш итәргә мөмкин һәм кирәк: укучыга бу әсәр кирәкме?

Аның идея-художество ягы ни дәрәҗәдә? Яңалыгы нидән гыйбарәт? Әллә ул инде күптән билгеле нәрсәне генә кабатлыймы?

Мәсьәләнең икенче ягы да бар. Журнал укучылар өчен чыга дигәнгә беркем дә каршы килми. Әмма бит укучының белергә, аның зәвыкларын, таләпләрен даими өйрәнергә кирәк. Моны белми торып, укучылар белән тыгыз элемтә булдырмыйча, «укучылар өчен эшлибез» дигән коры сүзнең берниндк әһәмияте юк һәм була да алмый.

Һәр журналның үз йөзе булуы таләп ителә. Моңа ничек ирешергә? Минемчә, журналда эшләүчеләр, аның юнәлешен хәл кылучылар чын мәгънәсендәге иҗади шәхес булырга тиешләр. Аларны театрның баш режиссеры белән тиңләргә мөмкин. Материалларга кул куеп, булган кадәресе белән генә канәгатьләнеп утырмыйча, алар бөтен язучылар коллективының эшен бер ноктага туплыйлар, юнәлеш бирәләр. Редколлегия фикеренә таянган тәкъдирдә дә, алар үз зәвыкларын онытырга, аны яшерергә тиеш түгелләр, киресенчә, үз-үзләренә төпле ышанырга тиешләр. Һәм, кирәк икән, бөтен җаваплылыкны да үз өстенә ала белергә тиешләр. Шунда гына журнал үз йөзен табачак.

Журнал киләчәктә дә туктаусыз эзләнсен, бәхәсле мәсьәләләрдән һәм яңача язылган, үзенчәлекле әсәрләрдән курыкмасын иде! Ул укучы белән, тормыш белән, халык белән элемтәне һәрвакыт ныгытсын иде! Шулай булганда гына яңадан-яңа үрләр яуланыр!

## Илдар Юзеев: «КИЛӘЧӘКТӘ ДӘ БАЛКЫР УЛ!»

Безнең балалык еллары Ватан сугышы чорына туры килде. Әтиләр сугышта, тормышны картлар, хатын-кызлар һәм кечтән килгән кадәр без, балалар, арбага-чанага да, сабанга да җигелеп алып барабыз. Керосин юк, китап-журналларны кичке караңгылыкта мич яктысында укыйбыз. «Совет әдәбияты» журналы ул елларда бик тә сагындырып кына килә, кайвакыт ике саны бер булып та чыга иде. Шуның өстенә почта да тоткарлана. Күз ачкысыз кышкы бураннарда авыл читенә чыгып, еш кына почтаны каршылый идем. Тол хатыннар сугыштагы ирләреннән хәбәр көтә. Ә мин әтидән хат һәм Казан кебек нурлы «Совет әдәбияты» журналын көтәм. Әтидән хат юк, ә журнал бар! Ул әтидән килгән хат кебек! Анда — Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Шәраф Мөдәррис, Сибгат Хәким шигырьләре, Гадел Кутуй нәсерләре, Афзал Шамов, Габдрахман Әпсәләмов, Атилла Расих хикәяләре... Журналда басылган әсәрләр тәэсирендә мин, ун яшьлек малай, капитан-артиллерист әтиемә шигырь белән хат язам:

**Дошманнарга төбәп аткан чакта,**
**Калтырамаслык булсын кулыгыз,**
**Сугышларда батыр булыгыз,**
**Сәлам белән «шагыйрь» улыгыз...**

Журналның элегрәк басылган саннарын табып, Газиз Иделленең «Дәүләт Бәдриев» пьесасын, дус малайлар белән җыелып, «сәхнә»дә — мунча ләүкәсендә куябыз. Икенче класста укыганда, үзем «Алсу гөлләр» исемле «пьеса» язып, анысын инде тагын да зуррак «сәхнә»дә — өйдә уйнадык. Өйдән мәктәп сәхнәсенә күтәрелдек: мин язган «Моңлы җыр тавышы»н үзебезнең пионер отряды көче белән куйдык.

Уеннан уймак чыгып, соңрак «Совет әдәбияты» мине моңлы, дәртле, нурлы Казанга — Тукай, Такташ, Сәйдәш Казанына тартты. Тора-бара журналның укучысыннан аның авторы, соңрак — штаттагы хезмәткәре булдым, әмма барыбер аның даими укучысы булып калдым. Менә кырык ел инде «Казан утлары»ның яктысын, нурын, җылысын тоеп яшим.

Кыскасы, «без — татар совет язучылары — «Казан утлары»ннан чыктык», дисәм, бу сүзләргә каләмдәшләремнең күбесе кушылыр иде дип уйлыйм. Язганнарымның күбесе: поэмалар, сәхнә әсәрләре, шигырьләр, җырлар, тәнкыйть мәкаләләре укучыларга журнал аша барып ирешә. Иозләгән, меңләгән укучылар белән бәйләвең өчен, үзеңнең тиражың кадәр рәхмәт сиңа, кадерле журналыбыз!

Моннан кырык ел элек син миңа кар-бураннар аша ерактан яктыручы моңлы хыял идең. Хәзер син, алтмыш яшькә җитүгә карамастан, ару-талуны белмәгән, йөзләгән-меңләгән дусларыңа иң якын сердәш тә, замандаш та, шул ук вакытта ерак киләчәк тә булып каласың...

Күз алдыма китерәм: кайдадыр ерак киләчәктә, безнең балачакны кабатламаган тугыз-ун яшьлек бала, авыл яки шәһәр читенә чыгып, почта көтә, «Казан утлары»н көтә... Һәм мин, моннан кырык ел элек почта көткән малай, ул балага ерак еллар аша җылы сәлам юллыйм һәм журнал битендә «көт, киләчәктәге энем, «Казан утлары» килер!» — дип хәбәр җибәрәм кебек.

## Равил Фәйзуллин: «ЖУРНАЛ ЯЗМЫШЫ — БЕЗНЕҢ УРТАК ЯЗМЫШ»

Һәр басма китап минем өчен үзе бер җисем, үзе бер тере организм кебек. Ул, гүя, синең якын бер әңгәмәдәшең. Ул сиңа кычкырмый-нитми, каршы сүз әйтми генә нәрсәдер аңлата, ниндидер гыйбрәтле хәлләр турында сөйли, нәрсәгәдер өнди... Син дөньяның матурлыгын һәм катлаулылыгын ныграк төшенә башлыйсың. Кешелек тарихының мәңгелек категорияләре — Яхшылыкка һәм Яманлыкка, Мәхәббәткә һәм Нәфрәткә, Хаклыкка һәм Ялганга, Тугрылыкка һәм Хыянәткә, Тынычлыкка һәм Сугышка, Гүзәллеккә һәм ямьсезлеккә... үзеңчә гадел мөнәсәбәтеңне ачыклый төшәсең. «Ташка» басылган һәр чын иҗат әсәре — мәңгелекнең дә, мизгелнең дә кабатланмас бер чагылышы бит. Исеме журнал дип аталса да, үзендә дистәләрчә әсәрләрне бергә җыеп, һәр ай саен даим чыгып килә торган «Казан утлары» дигән китап та әнә шундый олы миссияне үтәүче басмаларның берсе. Шуңа күрә дә ул йөз меңләгән укучыларның якын дусты, ышанычлы фикердәше булып үсте, зурайды.

Өебездә «Казан утлары»ның («Безнең юл», «Совет әдәбияты» исемендә чыкканнарын да исәпләп) 500 гә якын саны саклана. Төпләнмәләре күзләрне иркәләрлек ямьле булмаса да, кәгазь тузаны таратып, бүлмәдәге урынны шактый ук биләсәләр дә, миңа алар үзем өчен зур байлык-хәзинә булып күренә. Әдәбиятыбызның, гомум мәдәниятыбызның, юк, алай гына түгел, бөтен халкыбызның соңгы 40—50 ел эчендәге тарихы бит аларда! Киң мәгънәдәге рухи культурабызның хроникаль елъязмасын шушы журналлардан булмый, бүтән нинди чыганактан белмәк кирәк! Шөкер, шушы журналыбыз бар!

Үзенең туган нигезе яки әти-әнисе турында уйлаганда, һәркем үткәненә үз күңел тәрәзәсе аша карап, үзе генә белгән газиз хатирәләрне хәтеренә алган кебек, мин дә «Казан утлары»ның бәләкәй генә иҗат дөньямда зур һәм якты эз калдыра башлаган вакытны, үземнең саф һәм хыялый яшьлек елларым белән бәйләп искә алам. 1965 еллар. Журналның баш редакторы булып Рафаэль Мостафин эшләгән чак. Бүлекләрдә — Н. Арсланов, В. Нуруллин, Я. Халитов, М. Хәмитовлар. Университетны бетерер-бетермәс чагым. Вакытлыча мине дә бүлек мөдире итеп эшкә алдылар. Нәкъ шул айларны журналның исеме «Совет әдәбияты»ннан «Казан утлары»на әйләнде. Журналның исеме алышынуы турында укучыларга, бигрәк тә аны Татарстаннан читтә алдыручыларга, мөмкин кадәр тизрәк җиткерергә кирәк иде. Юкса, нәкъ журналга язылу вакыты, буталышлар килеп чыгасын көт тә тор. Җитмәсә, «Совет әдәбияты» дигән исемдә тагын бер журнал — төрекмән язучылары журналы да чыгып килә. Баш редактор, бүлекнең төп эшләреннән бераз бушатып, мине шушы журнал тарату эшенә утыртты. Чит республикаларда һәм өлкәләрдә чыга торган газеталар өчен «сез яши торган өлкәдә фәлән мең татар яши, яңа исемдә чыгачак журналны сездә фәлән мең данә таратырга мөмкинлек бар» дигән мәгънәдәге ике йөздән артык хат җибәрелде. Ул мәкалә-хатларда, шулай ук журнал турында — тарихы, бүгенгесе, актив язучылары, басылачак әсәрләр турында да шактый тәфсилле мәгълүмат бар иде. Баш редактор имзасы белән җибәрелгән ул мәкаләләрнең бик күбесе басылып чыкты. Һәм, әйтергә кирәк, нәтиҗә дә шактый матур булды: тираж бер ел эчендә 20 меңгә артты. Бу күркәм нәтиҗәне без җибәргән хатлар гына китерде дип әйтеп булмый, әлбәттә, ул елларда тиражларны арттыруга бик нык игътибар бирелә иде, шуңа күрә бик күп язучылар һәм әдәбият сөючеләр матбугат таратуда җиң сызганып

эшләделәр дә. Бу эшкә бөтен күңелен салып эшләгән кешеләрнең берсе аеруча хәтердә калган: ул — Тәуфикъ Әйделдинов. Велосипедка утырып, өндәмә материаллар тулы биштәр асып, ул үз теләге белән бер үзе берничә өлкәне урап чыгып, подписчиклар җыеп йөрде. Китап киштәсендә минем дә ул чаклардан калган бер истәлек саклана: кечкенә генә портатив фотоаппарат. Кырына исем-фамилиям уелган һәм «Казан утлары» журналын актив тараткан өчен» дип өстәлгән...

Журналда кеше күзенә күренерлек басыла башлау да нәкъ шул елларга туры килә. Дөрес, аңарчы да аз-маз басылгаладым. Әмма берәгәйле басылу шул 1965 елны булды. 11 нче санда тулы тугыз биткә сузылып «Нюанслар иле» дип исемләнгән кыска шигырьләр циклы чыкты. Баш редактор, үз өстенә шактый җаваплылык алып, шулай күләмле итеп бирергә тәвәккәлләгәндә, минем журнал тарату эшендәге беркадәр хезмәтемне дә искә алган булса кирәк. Журналда шуннан бирле чыгып килгән шигырьләрем, бергә җыйсаң, үзе бер 5—6 табаклык китап булыр иде. Шунда ук төрле елларда, төрле рухта һәм күләмдә унлап әдәби-публицистик мәкаләм чыкты. Арада профессор И. Нуруллин белән икәү әңгәмә рәвешендә язылганы бүгенге поэзиянең үсеш тенденцияләре турында шактый ук кызыклы бәхәс кузгатырга сәбәп булды. Яңа китапларыма карата тәнкыйтьчеләрнең, шагыйрьләрнең, гади укучыларның фикерләре дә журналда әледән-әле күренеп тора. Әлбәттә, төрле кешенең төрле фикерен төрлечәрәк кабул итәсең, һәм шул ук вакытта мондый хәлнең бик тә табигый икәнен аңлап, канәгатьләнеп куясың. Журнал белән шулай язышып һәм аңлашып яшәүне — күпчелек язучыларыбызның табигый язмышы дип санарга кирәк.

Журналыбызга 60 яшь. Байтак гомер бу, тибет календаре белән исәпләсәң — бөтен бер гасыр. Зур юбилей. Бу аерым язучының бәйрәме генә түгел, бу йөзләгән мәртәбә олырак бәйрәм. Гадәт буенча, юбиляр турында гел генә диярлек мактап сөйлиләр. Әмма дустанә рәвештә, эш тагын да яхшыга барсынга әйтелгән теләкләр дә әдәп кагыйдәсенә сыя бугай. Алга таба журналның художество сыйфатын, бөтен язучылар коллективы, редакция хезмәткәрләре белән берлектә, бик нык үстерәсебез бар. Журналның хроника өлешен оештыруны да ныклы бер тәртипкә саласы иде. Гадәттә, бер-ике генә биттән торган ул язмаларның тарих өчен әһәмияте ифрат зур. Еш кына иҗтимагый әһәмияте юк дәрәҗәсендә булган (әйтик, фәлән язучы фәлән тулай торакта чыгыш ясады дигән кебек) информацияләр еш кына басылып та, илкүләм әдәби процесс өчен әһәмияте булган белешмәләр онытылып калынгалый. Болары бер хәл. Минемчә, иң мөһиме — журналның илкүләм дәрәҗәсен бик нык күтәрергә кирәк. Журналда басылган әсәрләр турында үзәк матбугатта фикер алышуларны күбрәк күрәсе килә, шундый яхшы журналның барлыгын киңрәк белдерәсе килә. Ә без бу юнәлештә гафу итәлмәс дәрәҗәдә сүлпән эшлибез әле. Бер генә мисал: Зур совет энциклопедиясенең соңгы басмасында «Казан утлары» турында белешмә күренми. Казакъ телендәге «Жулдыз», башкорт телендәге «Агыйдел, бурят телендәге «Байгал» («Байкал») турында бар... 1980 елны чыккан, 80 меңләп сүз-белешмәле «Совет энциклопедик сүзлеге»ндә дә бүтәннәр бар, ә безнең журнал юк... Энциклопедияләр — бөтен дөньяга таралып, миллионнар укый, өйрәнә торган югары дәрәҗәдәге документаль китаплар бит. Барлыгыңны горур белгертә алу үзе дә зур дәрәҗә булыр иде...

Журналыбыз тарихи биографиягә ия, илебез үсеше казанышларына керткән өлеше шактый, ул бүген һәм киләчәктә танылган әсәрләр иҗат итәргә сәләтле зур коллектив язучыларның уртак басмасы. Аның киләчәктә тагын да колачлырак, тагын да мәгънәлерәк булачагына, миллионнарча әдәбият сөючеләрне сөендерәчәгенә һич шик юк!

* * *

Мөнҗия Мәрдиева

# ЭЗЛӘНҮЛӘР һӘМ ҮСЕШ ЮЛЫННАН

Якты нурларын Татарстан, Башкортстан һәм башка бик күп ерак төбәкләргә мул сибеп, «Казан утлары» журналы халкыбызның әдәби зәвыгын, эстетик карашларын тәрбияләүгә, үстерүгә зур өлеш кертә, иҗадият сихеренә бирелгәннәрне тарта, талантларны куәтли, үзе дә эзләнә, байый, сыйфатлана бара — партия, ил, халык теләкләрен чагылдырып яши: рухи идеаллар ныклыгына ышандыра, өмет-ниятләр, дәрт-хыялларга тылсым куя, чакыра, эз күрсәтә, юл сала... Аның исеме дә башта «Безнең юл» була.

Илебездәге әдәби, иҗтимагый-политик басмалар арасында, иң гомерлеләрнең, бай хәзинә, зур тәҗрибә туплаганнарның берсенә әверелгән бу журнал Г. Ибраһимов инициативасы белән оештырыла. Ул аның редколлегия председателе дә була. «Безнең юл»ның беренче редакторы итеп Г. Мансуров билгеләнә.

«Әдипләргә, шагыйрьләргә, гыйлем-әдәбият мөхибләренә» юлланган мөрәҗәгатендә редакция түбәндәгеләрне яза:

«Хәлләрнең гадәттән тыш авыр булуына карамастан, «Безнең юл» журналын чыгара башладык. «Безнең юл»ның чыгуы татар җөмһүриятенең мәркәзендә — Казанда булса да, бу мәҗмуга Русиянең төрле якларында яшәгән һәммә татар-башкорт халыкларына хезмәт итүне үзенә максат итеп ала. Менә шул авыр, зур бурычны үтәүдә без эчке, Волга-Урал, Сибириянең төрле почмакларында эшләүче әдипләр, шагыйрьләр, барлык гыйлем-әдәбият мөхибләренең ярдәменә ышанып, эшкә керештек. Үтенәбез: бер яктан, бу журналның таралуына, икенче яктан, гыйльми-сәяси, әдәби материаллар, мәкаләләр җибәрү белән, бу журналга булышсыннар иде... Эшче-крестьян гаммәсенең азатлыгы юлында эшләүче иптәшләр бу журналны үзләренең уртак хезмәтләре итеп карасыннар һәм шулай булышсыннар иде»[1].

Яшь Советлар республикасы гаять авыр көннәр кичергән вакыт була бу. «Безнең юл»га актив язышучылардан, баштарак аның редколлегия әгъзасы, соңыннан редакторларыннан берсе Гомәр Гали журнал чыга башлаган чорны болай тасвирли:

«Ачлык, контрреволюция, коралы контрреволюция җиңелде.

Кичә генә тын торган завод-фабрикалар тирәсендә яңадан хәрәкәт көчәйде. Әнә шул тирәдән пролетариат иле өчен иң моңлы, кирәкле, иң тансык музыка ишетелә башлады — көчле гудок тавышлары яңгырадылар. Күгәргән рельслар яңадан ялтырый башладылар, һәрбер яңа состав поезд үткән саен яктырак чырай белән карый башладылар — тимер юлларга җан керде.

Ачлык... җиңелеп бетмәгән иде, ләкин инде ул вакытта «ачлык Советлар властена үлем китерә» дигән гайбәтләрнең төпсез икәнлекләре дә, эшче-крестьяннар властеның моннан да җиңеп чыгачагы да һәркемгә ачык иде инде.

Хәзер ул термин азрак онытылып бара: моннан берничә ел элек без «беренче, икенче, өченче фронтлар» дигән сүзне еш ишетә, еш әйтә идек. 1 нче фронт — дошманга, контрреволюциягә каршы коралы көрәш фронты, 2 нче фронт — җимерек илне, җимерек хуҗалыкны игә китерү, юлга салу фронты, 3 нче фронт — мәдәни барыш, мәдәни көрәш фронты.

Моннан биш ел элек — «Безнең юл» чыга башлаганда алдагы ике фронт әнә югарыдагы иде.

Билгеле, алдагы ике фронтта алга барган саен өченче фронтка юнәлдерелгән игътибар да күбәйде. Мәдәният фронтында — төрле тармакларында, төрле флангларында, төрле позицияләрендә — алга бару да көчәйде. «Безнең юл» татар крестьяннарының мәдәни барышларының матбугат бүлегендә әнә шул алга баруны гәүдәләндергән фактларның берсе, кирәклесе һәм дәвамлысы булып туды.

---

[1] «Безнең юл», 1922, № 2.

Ул вакытта төрле фронтларда алга бару бар иде. Башланган иде. Ләкин ул баруларның әле чиксез авыр хәлләрдә булганлыгын да һәрвакыт истә тотарга кирәк...»[1]


Ә менә журналга әдәбият мәсьәләләрен күтәреп күп кенә мәкаләләр язган тәнкыйтьче Г. Сәгъди сүзләре:

«...Әз генә бер мөмкинлек табылу белән Совет вакытлы матбугаты әдәби-гыйльми тикшеренүләр, әдәби тәнкыйтьләр өчен тиешле хәрәкәтне кузгатып җибәрде.

Татар дөньясында бу хәрәкәтне үзе аркылы беренче мәртәбә ачык, җитди рәвештә гәүдәләндереп чыгучы журнал «Безнең юл» булды. Марксизм нигезендә бу хәрәкәтнең беренче тарихи маягы да татар дөньясында шул журнал булып чыкты.

Баштә үзенең төп характеры, тибы ачык билгеләнеп җитә алмау кебек хәлләр эчендә булуга карамастан, журналның бу юлдагы тикшеренүләргә урын бирүе һаман киңәя, җитдиләнә бара»[2].

Әнә шул рәвешле, «Безнең юл» белән «Казан утлары» арасындагы турыдан-туры бәйләнеш, дәвамчанлыкның иң әһәмиятле сыйфаты — әдәби тәнкыйть, әдәби-гыйльми тикшеренүләр алып бару белән билгеләнә. «Безнең юл» укучыларга гыйльми-сәяси, әдәби-иҗтимагый айлык калын журнал итеп тәкъдим ителә. Анда ленинизм идеяләрен пропагандалау, партия тәгълиматын, карарларын, киң үзәгендәге бурычларны халык массасына җиткерү максатын күздә тоткан теоретик мәкаләләргә шактый киң урын бирелә. Бу эштә журналга совет-партия җәмәгатьчелеге, язучы һәм журналистларыбызның танылган вәкилләре ярдәм итә.



Журнал «Ленинның Максим Горькийга хаты»н басып чыгара (1925, № 2). «Ленинизм нәрсә» (И. В. Сталин, 1925, № 2), «1905 ел революциясе һәм В. И. Ленин» (Х. Кәрим, 1925, № 11—12), «Февраль революциясе турында В. И. Ленин» (1925, № 3), «Татарстан җөмһүриятен төзегәндә В. И. Ленин» (Г. Ходаяров, 1925, № 2) кебек мәкаләләр журнал программасында күрсәтелгән «Ленинизмны өйрәнү юлында» циклын

[1] Галиев Г. «Безнең юл»ның 5 еллык унае белән. «Безнең юл», 1927, № 6—7.
[2] Сагъди Г. «Безнең юл»да әдәби-гыйльми тикшеренүләр, тәнкыйтьләр. 1927, № 6—7.

(1925, № 1) тәшкил итәләр. «Безнең юл»ның 1924 елны февраль-мартта чыккан саны (№ 4—5) тулаем диярлек, В. И. Ленинга, аның күпъяклы эшчәнлеген яктыртуга багышланган.

Журнал революцион хәрәкәт тарихын өйрәнү эшенә дә керешә. Г. Ибраһимов («Татар-башкорт пролетариаты хакында материал җыю мәсьәләсе», 1922, № 3; «1905 ел революциясендә татарларның хәрәкәтләрен өйрәнү өчен материаллар җыю турында», 1925, № 1; «1905 ел революциясе турында», 1925, № 9—10), И. Рахматуллин («Татарлар арасындагы революция хәрәкәтенә материаллар», 1925, № 4), Ф. Сәйфи-Казанлы («1905 ел революциясе», 1925, № 11—12), Г. Мансуровның («Революция хәрәкәтендә татарларның тоткан урыны», 1922, № 1) фәнни мәкаләләре әнә шундыйлардан.

«Безнең юл»да шулай ук совет төзелеше, профсоюзлар тормышы, яшьләр хәрәкәте, атеистик тема мәсьәләсе, техникум һәм вузларда уку-укыту эшләре карала.

Матур әдәбият әсәрләре, әдәбият-сәнгать өлкәсендә тикшеренүләр белән бергә журналда тел һәм тарих мәсьәләләре, матбугат тарихына багышланган материаллар да аз түгел. Бу юнәлешләр «Безнең юл»да гына түгел, журнал башка исемнәр белән чыккан елларда да дәвам иттереләләр.

1926 елга кадәр журналның титул билгеләмәсе, структурасы үзгәрми. Башта журнал Татар Социал Шуралар җөмһүриятенең Мәркәз Башкарма Комитеты һәм Халык комиссарлары Советы органы була; 1923 елның мартыннан — Татарстан Халык мәгариф комиссариаты, 1925 елның азакларына кадәр РКП(б)ның Татарстан өлкә комитетының агитация-пропаганда бүлеге карамагында чыга, шул елның 9—10 нчы саныннан алып, «Безнең юл» яңадан Татарстан Халык мәгарифе комиссариаты органына әйләнә. 1926 елда аның билгеләмәләреннән сәяси сүзе төшеп кала, журнал әдәби-гыйльми, иҗтимагый басма буларак чыгарыла: беренче битләр әдәби тәнкыйть мәсьәләләренә бирелә башлый, матур әдәбият әсәрләренә дә урын киңәя. 1928 елның мартеннан «Безнең юл» — Татар мәдәнияты йорты катындагы әдәби-гыйльми, иҗтимагый айлык журнал: матур әдәбият әсәрләре журналның түр битләренә күчә, «Театр-музыка», «Мәдәни фронтта» дигән бүлекләр ачыла.

Кискен үк булмаса да, журналның мондый үзгәрешләр кичерүе нәрсә белән аңлатыла соң? Төрле оешмалар карамагында булуы беләнме? Әмма 1926 елга кадәр «Безнең юл»ның төп хосусияте, чыгаручы оешма алмашынуга карамастан, нигездә үзгәрешсез кала. Шулай да 1925 елны, РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты органы булганда, журналда иҗтимагый-политик мәсьәләләрнең куелышы, 1922 елга караганда кечәя төшә.

Әллә журналның, Г. Сәгъди әйткәнчә, «үзенең төп характерын, тибын» таба алмый интегүе генә буламы бу? Юк, дип уйлыйсы килә. Чөнки әдәби журнал чыгару тәҗрибәсе вакытлы татар матбугатында «Әлгаср-элҗәдид» (1906—1907 еллар), «Шура» (1908—1918 еллар), «Аң» (1912—1918 еллар) практикасында ук туплана.

Әмма «Безнең юл» — башка чор журналы, яңа иҗтимагый-экономик формациягә хас матбугат органы. Чор таләпләренә җавап бирү өчен ул көчле идеология чарасы, социалистик төзелеш коралы булырга омтыла. Партия, газета-журналлар чыгаруны тәртипкә салу өчен, аерым басмаларның юнәлешен, кем өчен чыгарылуын (аудиториясен), структурасын, иншалау үзенчәлеген билгеләү тәртибендәге эзләнүләргә дә аерым әһәмият бирә. Бу мәсьәлә белән В. И. Ленин да нык кызыксынган. Әле Октябрьга хәтле үк А. М. Горькийга язган мәгълүм хатларында ул калын журналда партияле публицистиканы беллетристика белән кушу турында сүз йөртә, андый журналда, әдәбият бүлегеннән тыш, политика, фән, тарих, иҗтимагый тормыш бүлекләре булдыру кирәклеген әйтә. В. И. Ленинның бу теләге 1921 елны «Красная новь» журналы булып тормышка аша, аны оештыруда ул үзе дә катнаша. «Безнең юл»да, гыйльми-сәяси, әдәби-иҗтимагый басма буларак, «Красная новь» тибындагы журналны хәтерләтә. Ул үзенең беренче елларында ук партия сүзен матур әдәбият белән берләштерүче журнал була, анда иҗтимагый-политик мәкаләләргә шактый киң урын бирелеп килә.

«Безнең юл»ның мондый юнәлеш алуына тагын бер сәбәп бар. 1926 елга кадәр бездә татар телендә чыга торган махсус партия журналы булмый (рус телендә мондый журнал, 1920 елны оештырылып, «Вестник Татарского областного Комитета

РКП(б)» исемен ала, хәзерге «Коммунист Татарии» журналының тарихы шушы журналдан башлана). Ә бит бу чорда җанлана башлаган буржуаз идеологияне тар-мар итү, татар хезмәт ияләрен марксистик-ленинчыл рухта тәрбияләү эшен ныклап, киң колач белән алып бару ихтыяҗы бөтен кискенлеге белән куела. Шуңа күрә «Безнең юл» политик агитация һәм пропаганда бурычларын да үтәргә тиеш була. Дөрес, иҗтимагый-политик мәсьәләләрне 1918 елда ук чыга башлаган «Мәгариф» журналы да яхшы гына яктыртып килә, ләкин аның төп максаты, әлбәттә, мәктәп-мәгариф, культура төзелешенә юнәлтелгәнлектән, ул иҗтимагый тормышның, бигрәк тә аның партия сәясәтенә баглы бөтен якларын җитәрлек дәрәҗәдә күрсәтә алмый, һәм бу табигый да. 1920—1923 елларда «Кызыл шәрык» исемле журнал да чыгып килә. РКП(б) Үзәк Комитеты каршында оештырылган Россия коммунист (большевик)ларының Мәркәз бюросының икътисади-иҗтимагый, сәяси, әдәби, фәнни айлык журналы буларак, ул партия тормышын шактый киң яктыртса да, аның төп бурычы үзгә — Көнчыгыш халыклары арасында Коминтерн идеяләрен пропагандалау, Көнчыгышта революцион һәм милли азатлык хәрәкәтләрен һәрьяклап өйрәнү.

Ниһаять, 1926 елда татар телендә махсус партия журналы — «Җитәкче» чыгарыла башлый. «Безнең юл»ның бурычлары җиңеләя, ул инде төп игътибарын әдәбият һәм культура мәсьәләләренә юнәлтә, әдәби әсәрләрне мулрак басу мөмкинлегенә ирешә. 1925 елның 9—10 нчы санында ук редакция мондый белдерү ясый: «Гыйльми-мәдәни мәсьәләләргә, тәнкыйтькә, матур әдәбиятка, театр-сәнгать эшләренә тагы да киңрәк урын бирү өчен, журналның программасына үзгәрешләр кертелде. Журналның эчягын — мәгънә төзелешен, мөндәриҗәсен (эчтәлеген — М. М.) тагын да баету юлында чаралар күрелде. Атаклы язучыларыбыз белән договорлар ясалды. Журналның һәр санында рабкорлар, селькорлар арасыннан күтәрелеп килә торган яшь язучыларыбызның әсәрләрен кертә бару юлында эшләр эшләнде».

Үзенең бишьеллыгын «Безнең юл» әдәби әсәрләргә, әдәби-гыйльми тикшеренүләргә һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләренә киң мәйдан бирүче журнал рәвешендә каршылый һәм шушы юнәлешне һаман үстерә-тирәнәйтә бара.

Әдәби журналның йөзен иң әүвәл, әлбәттә, әдәбият мәсьәләләренә багышланган тикшеренүләр, тәнкыйть мәкаләләре билгели.

Егерменче еллар — татар совет әдәбият белеме һәм тәнкыйтендә яңа әдәбиятның социологиясен билгеләү, татар әдәбияты һәм тарихы мәсьәләләре тирәсендә барган бәхәсләр, идея-эстетик эзләнүләр кискенләшкән чор. Әлбәттә, «Безнең юл» да бу мәсьәләләрдән читтә кала алмый. Аларның дөрес куелышына, дөрес хәл итү юлларын билгеләүгә Г. Ибраһимов шикелле тәҗрибәле, абруйлы шәхеснең ярдәме зур була. Яңа тип совет әдәбиятын үстереп җибәрүдә бигрәк тә аның «Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» исемле мәкаләсе (1922, № 1, 2) әһәмиятле урын тота. Галим әдәби мирасны марксистик методология нигезендә өйрәнүне башлап җибәрә, әдәбият тарихына идеалистик карашларны тәнкыйть итеп, фәнни-материалистик принципларга таянырга чакыра: «Әдәбиятлар, фәлсәфәләр, гыйльми ысуллар, диннәр, әхлаклар,— кыскасы, бөтен идеология хәрәкәтләренең һичбере күктән яумаган кебек, нинди дә булса бер даһиның тик үз башыннан уйлап чыгаруы белән дөньяга килмиләр,— дип яза ул.— Боларның фикерләре, рухлары, мөндәриҗәләре — һәммәсе тарихның мәгълүм дәверендәге мәгълүм бер матди, иҗтимагый катлаулар туфрагында үсеп чыга торган чәчәкләр генәдер... Әдәбиятлар, фәлсәфәләр, гыйльми ысулларны тикшерүдә, аеруда бердәнбер дөрес юл — боларны җитештергән иҗтимагый-икътисади нигезләр буенча язу һәм шул нигез мизаны белән бәһа, кыйммәт куюдыр».

Г. Ибраһимов, татар әдәбиятының феодализм чорыннан алып Октябрьгә кадәр үткән юлын дәверләргә бүлеп күрсәтә.

Татарстан Халык мәгарифе комиссариаты каршындагы Гыйльми Үзәк председателе буларак, Г. Ибраһимов татар әдәбияты әсәрләрен барлау, бастырып чыгару турында да кайгырта һәм «Әдипләргә, шагыйрьләргә мөрәҗәгать» дигән хезмәтендә (1925, № 3) болай дип яза:

«Иске һәм яңа татар әдәбиятын тикшерү, өйрәнү эше хәзерге көндә бик нык бара. Бу турыда мәктәпләр дә, түгәрәкләр дә эшлиләр. Ләкин бу әдәбияттан күбесенең басылган нөсхәләре матбугат дөньясында бик аз калган яки бөтенләй беткән

Шуңа күрә мәктәпләр, китапханәләр, аерым өйрәнүчеләр бу турыда материал таба алмый аптырыйлар яки китапханәләр төзелгәндә дә зур читенлек чыга. Безгә бөтен татар әдәбиятының искесен, яңасын бер җепкә — бер күренешкә тезеп, билгеле бер система буенча басып чыгаруның кирәклеге ачык...»

«Тел, әдәбият дәресләренең кирәкле бер тармагы (татар халык әдәбияты турында) исемле мәкаләсе белән (1926, № 5—6) Г. Ибраһимов халык иҗаты әсәрләрен барлау-өйрәнү мәсьәләсен күтәреп чыга. Халык иҗатын өйрәнүгә багышланган мәкаләләр, фольклор әсәрләре үрнәкләрен бирү журналның традициясенә әйләнә, һәм ул бу көнгәчә дәвам итә.

Журналның эчтәлеген тирәнәйтү, дәрәҗәсен күтәрүдә тел культурабызны, әдәбият һәм театр тарихыбызны зур фидакарьлек белән өйрәнгән тәнкыйтьче-галим Г. Сәгъди мәкалә-рецензияләренең әһәмиятен дә күрсәтергә кирәк. Татар әдәби тәнкыйте тарихын күзәтүгә багышланган «Бездә әдәби тәнкыйть» (1927, № 10), татар әдәбияты тарихын китаплар тасвирламасына кайтарып калдырудан сакланырга кирәклеген искәртүче «Әдәбият тарихымы, язмалар тарихымы?» (1923, № 12) — әнә шундыйлардан.

Журналда шулай ук Г. Рәхим, Х. Вәли, Г. Толымбайский, Г. Нигъмәти, Г. Гали, Ф. Бурнаш һ. б. тәнкыйтьчеләр, әдәбият галимнәре дә катнаша.

Шуны да әйтергә кирәк, башлангыч елларында, тематик диапазоны киң булгангамы, әллә аерым игътибар җитмәү сәбәпледерме, журнал поэтика үзенчәлекләре һәм гомумән дә форма һәм эчтәлек, стиль, сюжет, композиция, тип һ. б. шундый әдәби-гыйльми мәсьәләләр буенча зур тикшеренүләр бирә алмый. Ниһаять, 1929—1930 елларда Г. Галинең «Стиль һәм аның эволюциясе» (№ 1, 2), Х. Туфанның «Яңа шигырь техникасы турында» (№ 6—7) исемле мәкаләләре дөнья күрә, һәм, шул рәвешле, журнал үз кимчелеген үзе төзәтә башлый.

Әдәбият тарихына материаллар туплауда, гыйльми-теоретик мәсьәләләр күтәрү, тәнкыйди фикерне чарлау ягыннан күренекле галим һәм әдипләребезнең юбилейларын билгеләп үтү әһәмиятле. «Безнең юл» моны да искә ала. Мәсәлән, 1923 елның 8—9 санында Г. Тукайның үлүенә ун ел тулу уңае белән Г. Сәгъдинең «Татар шагыйрьләре арасында Тукай», Ф. Бурнашның «Тукай хакында тәнкыйтьчеләр» дигән мәкаләләре урнаштырыла. Г. Сәгъди бөек халык шагыйрен урынсыз тәнкыйть итүчеләр белән килешми, аның иҗатын һәрьяклап тикшерә, югары бәяли: «Тукай... татарның иң беренче көчле... йөрәк шагыйре,— дип яза.— Йөрәк шагыйрьләрендә... күзәтелгән нәрсә: самимият, чын күңелдән булу, эчтән кайнап чыгу. Тукайда бу хосусият тәгәл мәгънәсе белән бар. Тукайның шигырьләрендә аның үзлеге (шәхсияте, Тукайлыгы) бик ачык күренеп тора. Бу хосусият даһи сәнгатькярләрнең хосусиятеннән санала...

Тукай тезмәдә татарча... садә әдәби тел эшләп бирде. Безне җиңел, әдәби сөйләргә, саф рәвештә көйләргә өйрәтте. Анда чәчмәдә дә осталык күрәбез. Ул шигырь мәктәбе тудыра алды. Ниһаять, Тукайда, һәрнәрсәдән бигрәк, гаммәгә якынлыкны, ярлыларга дуслыкны күрәбез».

Г. Тукай мирасын пропагандалау, аның иҗатын бозып аңлатырга маташучыларны дәлилле фаш итүе ягыннан Ф. Бурнашның алда әйтелгән мәкаләсе дә кыйммәтле. Аның бу һәм шагыйрь иҗатына багышланган башка мәкаләләре Совет чорында Тукайны өйрәнү белемен фәнни нигездә коруга да булышты.

Татарстан хөкүмәте карары белән, 1928 елның 10 мартында Г. Ибраһимовның әдәби-гыйльми эшчәнлеге бәйрәм ителә. «Безнең юл»ның 2 нче саны шушы юбилейга багышланып чыга. «20 еллык бөек әдәби хезмәт» дигән мәкаләсендә, Исхак Рәхмәтуллин, бу юбилейның әһәмиятен билгеләп, болай яза: «Бу бәйрәм, әлбәттә, бу кешенең, бер әдипнең бәйрәме генә түгел, бәлки бөтен татар хезмәт массасының зур бәйрәмедер. Бөек әдипнең әдәбият-мәдәният үсеше юлындагы хезмәтенә йомгак ясап, аңа тиешле кыйммәт билгеләп, татар хезмәт массасы һәммә нәрсәдән дә элек үз әдәбияты, мәдәни-гыйльми үсүенә йомгак ясый, шул үсүнең үлчәвен билгели». Журналда, әлеге мәкаләдән тыш, «Галимҗан Ибраһимов — төрек-татар үйчысы», «Галимҗан Ибраһимовны өйрәнү һәм «Казакъ кызы», «Галимҗан Ибраһимов үзенең 20 еллык хезмәт гомерендә ничек эшләп барды» дигән мәкаләләр һ. б. материаллар бирелә.

Г. Тукай һәм Г. Ибраһимов иҗатлары турындагы саннар «Безнең юл»да әдәби-

мәдәни тормышның һәрьяклап чагылдырылуын күрсәтү өчен мисал итеелде. Журналыбыз тарихында Г. Тукай, Г. Ибраһимов һәм башка бик күп әдипләребезне хөрмәтләп чыгарылган саннар аз булмады, һәм аларның һәркайсында беренчел, нигез традицияләрнең матур дәвамы чагыла.

Егерменче еллар сәнгать алдына да кискен сораулар куя, сәнгать мәсьәләләрен күтәреп чыккан тәнкыйтьтә ярсулы бәхәсләр тудыра. Ф. Бурнашның яңа сәнгать, аның характеры һәм эчтәлеге мәсьәләләренә багышланган «Татар театр әдәбияты» (1922, № 1) исемле мәкаләсе татар драматургиясе тарихын сыйнфый позицияләрдән яктырткан беренче хезмәтләрдән санала. «Дәүләт татар академия театры» (1927, № 4—5) дигән мәкаләсе исә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының 1926—1927 елгы сезонын күзәтүгә багышлана. Ф. Бурнаш артистлар уены, репертуар турындагы фикерләр белән генә чикләнми, театрның гомумән татар сәнгатендә тоткан урыны турында уйлана: «Академик театр татар театры өчен гомумән күрсәткеч урын тотарга, татар театр мәйданындагы ирешелгән нәтиҗәләрне сәнгать, иҗат калыбына салып ныгыта торган, аларны җыя торган үзәк булырга, гомумсәхнә сәнгатенең академик мәсьәләләрен, чараларын татар театр галәменә кертүдә төп базис булып барырга тиеш. Татарның аерым тормышын, типларын, аларның характерларын, тормыштагы аерым оригиналь хәлләрне гәүдәләндерүгә, безнең театр сәнгатебездә классик характер бирүгә без бик аз әһәмият биргәнбез һәм бирәбез. Татар театры үзенең эшләрендә шушы төп әсасларга басарга тиеш».

Татар театр сәнгате мәсьәләләре шулай ук М. Парсинның, театраль сезон нәтиҗәләрен йомгаклап язылган «хисап урынына» тибындагы күзәтүләрендә («Татар театры», 1925, № 4; «Казан татар театрының 20 нче сезоны», 1926, № 4) дә тикшерелә. М. Галинең Өммегөлсем Болгарская турындагы язмасы (1925, № 11—12) сәнгать эшлеклеләренең иҗади портретларын бирүгә этәргеч ясый, һәм журнал мондый материалларга һәрвакыт зур игътибар биреп килә.

Солтан Габәшинең «Музыканың эшләнеше» (1926, № 7—8) исемле мәкаләсе һәм Г. Рәхимнең сәхнәдә беренче татар операсы куелуы уңаеннан язылган рецензиясе («Сания», 1926, № 7—8) белән «Безнең юл» музыка сәнгатенә багышланган сәхифәләрен ача.

Журналның театр, музыка, рәсем сәнгате, шулай ук культура тарихы, тел мәсьәләләрен иңләргә омтылуы табигый. Культура тормышының бу өлкәләрен яктыртып барырлык махсус журналлар булмаганлыктан, милли республика шартларында бу вазифаны әдәби журнал үтәргә тиеш була. Һәм бу хәзер дә шулай.

Әдәби тәнкыйтьнең яхшы куелышы, сәнгать мәсьәләләренә һәм, гомумән, халкыбызның мәдәни тормышына, аның тарихына игътибар «Казан утлары»на әнә шулай «Безнең юл»дан ук килә икән. Моны иң яхшы әдәби әсәрләрнең башлап шушында басылуы мисалында да күрергә була.

20 нче еллар — совет әдәбиятында яңа темалар үзләштерү, яңа геройлар эзләү чоры. Революция, гражданнар сугышы героикасын данлау, яңа тормыш, яңа әхлак өчен көрәш, искелек калдыкларын фаш итү — «Безнең юл»да басылып килгән шигырь, хикәя, пьеса, нәсерләрнең төп темалары. Журнал үз тирәсенә М. Гафури, Ш. Камал, Г. Камал, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Толымбайский, Г. Газиз, К. Әмири кебек өлкән язучыларны туплый. Киң хезмәт массасы арасыннан революция белән күтәрелеп чыккан яшь талантларны тарта, аларга мәйдан бирә, иҗат юнәлеше күрсәтә. Шулар арасында Һ. Такташ, М. Максуд, Ф. Әсгать, М. Җәлил, Ш. Усманов, Г. Кутуй, Н. Нәҗми, М. Әмир...

Әнә шул көчләр яңа хисләр турында җырлый, яңа зәвыкларны идеал итә, яңа образлар тудыра. 1922 елгы саннарда М. Гафури («Сулган гөлләр», № 1); Г. Газиз («Милләт ничек тәрәккый итсен», № 1; «Фаҗигале төннәрдә», № 2) хикәяләрә, Ф. Әсгать («Таш кала», № 5), М. Максуд («Ике бәйрәм», № 4) нәсерләре, З. Бурнашева, З. Байчурина, К. Әмири, Г. Толымбайский шигырьләре басыла. Шул ук елны «Урман кызы» (№ 4), «Нәләт» (№ 5) әсәрләре белән татар әдәбияты мәйданына Һ. Такташ килеп керә. Соңыннан бу журналда аның «Мәңгелек вәгазе» (1923, № 3), «Күктән сөрелгәннәр» (1923, № 6—7), «Мәхәббәт тәүбәсе» (1927, № 2), «Мокамай» һәм «Алсу»лары (1929, № 2) дөнья күрер. 1923 елдан башлап Г. Кутуй шигырьләре басыла башлый.

Журналда К. Нәҗми, Ш. Усманов, Х. Туфаннарның хикәя-шигырьләре зур урын ала, аның фатихасы М. Әмир, Ә. Еники, Ф. Хөсни, Ш. Маннурларны да рухландыра.

1927 елның 3, 4—5 саннарында М. Горькийның «Макар Чудра» хикәясе (С. Җәләл тәрҗемәсе) бирелә, 1928 елның 8 санында Г. Толымбайскийның «Максим Горький килеп китү уңае белән», С. Фәйзуллинның Л. Толстой турында «Бөек художник, алама философ» исемле мәкаләләре урнаштырыла. Бу фактлар журналның рус әдәбиятына, аны пропагандалауга да игътибар итә башлавын раслый.




«Безнең юл»га язышучылар аның белән киңәшләшүчеләр, аны укучылар да күп булган, ул илебезнең ерак өлкәләренә кадәр барып җиткән. Бу урында тагын Г. Гали истәлекләренә кайтыйк: «Архангельскида эшләүче татар рабкорының «хикәя»се, татар язучыларының Мәскәүдән җибәрелгән әдәби парчалары, Кавказдан — Бакудан очкан нефтьле шигырьләр, Төркстаннан җибәрелгән мамыклы конвертлар, Башкортстаннан җибәрелеп-басылып торган язмалар, конвертлары кырым фруктлары белән бизәлгән Симферополь хатлары, шахкомнарда эшләүче татар шахтерларының «служебный записка»ларга тутырылып язылган Донбасс парчалары — барысы да «Безнең юл»ның СССР масштабына таралып утырган бөтен татар эшче, крестьяннарның журналы икәнлеген беркетәләр. Шулай таныталар. Шулай таныйлар» (Күрсәтелгән мәкалә, 22 бит).

1930 елга кадәр журнал «Безнең юл» исеме белән чыга. Аның дәвамы «Яңалиф» (Татарстан Мәгариф халык комиссариаты һәм Совет язучылары оешмасының айлык әдәбият, сәясәт, сәнгать, экономика һәм тәнкыйть журналы, редакторы Фатих Сәйфи-Казанлы) һәм «Атака» (Татарстан Пролетариат Язучылары Ассоциациясе — ТАПП органы, редакторы Г. Гали).

Һәр ике журналда да агымдагы әдәби сәясәтнең төп проблемалары яктыртыла, әдәбиятның мөһим күренешләре турында тәнкыйть материалларына урын бирелә. Совет әдәби тәнкыйте тарихына кирәрлек материалларны күбрәк «Яңалиф» битләрендә табарга була. Әдәби хәрәкәтне күзәтү, бәяләү, юнәлешләр бирү бу журналда даимирәк, җитдирәк төстә алып барыла; бигрәк тә Г. Нигъмәти («Әдәбият фәненең үсеш юлы нинди булырга тиеш», 1930, № 1, 3; «Әдәбиятта формализм — буржуаз карашы», 1930, № 4 һ. б.), Х. Вәли («10 ел эчендә татар әдәбиятында стиль эволюциясе», 1930, № 1; «Шигырьләрдә аваз төзелеше», 1930, № 2 һ. б.) мәкаләләре еш басыла.

Ике журнал арасындагы аерымлык сәнгать мәсьәләләрен яктыртуда да күренә. Әйтик, «Яңалиф» зур сәхнә мәсьәләләрен кайгырта (мәсәлән, Г. Айдарский, «Реконструкция чорында театр», 1930, № 2; Г. Рәхим. «Эшче» операсы турында, № 3), «Атака» күбрәк кече формалар театрын тикшерүгә игътибар итә (1931 елның 5, 6—7 санында басылган материаллар) Татарстан һәм башка өлкәләрдәге халык театрлары турында сөйли.

«Яңалиф» күләмлерәк хикәя, повесть, поэмалар, пьесаларны мәгъкүл күрә. Моны М. Галәү («Күпнең берсе», 1930, № 2), Ш. Камал («Соргылт күзле карт бүре», 1930, № 4, 5), А. Алиш («Ике эт», 1930, № 5), Мирсәй Әмир («Озату хикәясе», 1930, № 4), И. Гази («Көмеш сулы Нурминка», 1931, № 1, 2) хикәяләре, Ә. Айдарның «Ташбай» исемле маҗаралы повесте (1931, № 1, 2), Ф. Хөснинең «Җир тыңлый» романын-

нан (1931, № 3), һ. Такташның «Киләчәккә хатлар» (1931, № 4), Ф. Кәримнең «Аникин» поэмасыннан (1932, № 7) өзекләр, Х. Туфанның «Бибиевлар» поэмасы, «Аккордлар» шигыре (1930, № 5, 6), К. Тинчуринның «Кандыр буе» пьесасыннан өзек (1932, № 5) һ. б. раслый.

«Атака» Ш. Камал, К. Нәҗми, М. Гафури, Г. Толымбайский, Ф. Сәйфи-Казанлы, М. Әмир, Г. Иделле, И. Рәми, Д. Фәтхи, Н. Баян, Ф. Кәрим, Г. Мөхәммәтшин, Г. Хуҗи, М. Садри, И. Салахов, М. Сөндекле һ. б. кыска хикәяләре һәм шигырьләре, совхоз, колхоз, культура, бигрәк тә илебездәге социализм индустриясе төзелеше турында Ш. Камал, Ф. Хөсни, А. Алиш, И. Туктар, А. Әхмәт, К. Әмири, Г. Иделле, М. Гали очерклары белән тулып чыга. Очерклар арасында Урал, Кузбасс, Донбасс, Днепрострой, Магнитогорск, Кузнецктан алып кайтылганнары шактый (А. Әхмәт, «Беренче чуен», 1932, № 9—10; Х. Әһли, «Урал-Кузбасс гигантлары», № 13—14; К. Әмири, «Чуен һәм корыч шәһәре», 1932, № 15—16, А. Алиш, «Кран», 1931, № 7, И. Туктар, «Уралмаштройда ике көн», 1930, № 3).




«Атака» шулай ук илне саклау, сизгерлекне көчәйтү темасын киң яктыртып килә. Бераздан ул ТАПП һәм Татлокафның (Кызыл Армия-флот язучыларының Татарстан оешмасы) берләштерелгән органы булып әверелә. Татлокафчылар иҗатын характерлап, М. Әмир болай яза: «...Ел ярымлык эш чорында Татлокаф оборона әдәбияты мәйданына байтак кына иҗат продукциясен бирде. Татлокаф оешканга кадәр татар матур әдәбиятында Кызыл Армиянең бүгенге тормышын күрсәткән әсәрләр бөтенләй юк дәрәҗәсендә булса, Татлокаф оешканның соңында бу юклык күзгә күренерлек тизлек белән каплана башлады. Татлокафчылар тарафыннан эшләнгән иҗат продукциясе «Кызыларлармеец» газетенең әдәбият сәхифәсенә генә сыймый башлады. Элек татар пролетариат язучылары ассоциациясе органы булып килгән «Атака журналы ТАПП һәм Татлокафның уртак органына әйләнде. Шул көннән башлап бу журналның 50 проценты Татлокаф иҗаты, Татлокаф материаллары белән чыгып килә»[1].

Дикъкатьне «Атака»ның тагын бер үзлегенә юнәлтик.

Татар пролетариат әдәбиятының электән танылган әдипләре белән бергә, ТАПП органы буларак, «Атака» завод-фабрикалардан күтәрелә торган яшь эшче әдәби көчләргә киң урын бирә. Мәсәлән, «Атака» татар әдәбиятына ударниклар призывын уздыруда ТАПП секретариатының өндәмәсен, «завод-фабрикаларда башлангыч әдәбият түгәрәкләре өчен программа» (1930, № 8—9) урнаштыра. «Эшче-ударниклар әдәбиятка киләләр», «Станоклар өстендә язылган шигырьләр» рубрикалары башлап язучылар иҗатын чагылдыра. Журнал шулай ук ТАПП секцияләренең, әдәби түгәрәкләрнең эшен күзәтеп, «Тәнкыйть-библиография» бүлегендә яшь язучылар әсәрләренә дә анализ биреп бара.

Әйтергә кирәк, «Безнең юл» үз битләрендә пролетариат язучы-шагыйрьләре иҗатын тикшерүгә ныклы игътибар бирә алмады. «Безнең юл»ның дәвамы буларак «Атака» бу юнәлештә җитди адым ясады.

ВКП(б) Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать оешмаларын яңабаштан кору турындагы (1932) карары чыкканнан соң Татарстан совет язучылары союзын оештыру ко-

[1] Әмир М. Оборона әдәбиятының магнитостройлары өчен көраш. — «Атака», 1932, № 7.

митеты төзелә, 1933 ел башыннан аның органы — «Атака», «Яңалиф»ларнең дәвамы булып — «Совет әдәбияты» (ә 1965 елның 6 санынннан «Казан утлары») исеме белән чыга башлый.

«Совет әдәбияты»ның 1 нче саны (Г. Нигъмәти редакциясендә) укучыларга «әдәбият, сәнгать һәм тәнкыйть журналы» итеп тәкъдим ителә, 2 нче саннан башлап, бу билгеләмәгә публицистика сүзе өстәлә. Журналда әдәби-публицистик характердагы очеркларга, марксизм-ленинизм мәсьәләләрен пропагандалаучы, әдәбият методологиясенә багышланган мәкаләләргә күбрәк урын бирелә башлый. «Әдәбият, сәнгать, тәнкыйть һәм публицистика» дигән атама 1948 елда «Әдәби һәм иҗтимагый-политик» дигән билгеләмә белән алыштырыла һәм ул, журналның төп юнәлешләрен, структурасын, башка үзенчәлекләрен җыйнаграк калыпка салып, яхшырак чагылдыра.


Bөten illərneꞑ proletarlarь berləşegez!

# SOVET ƏDƏBIATЬ

REDKOLLEGIƏ:
Ƣ. NIƢMƏTI.
Ƣ. RIZVAN.
Q. NƏÇMI.
X. TUFAN.
Ƣ. ƢƏLI.
Z. ƢƏLI.
K. TINCYRIN.

ECTƏLEK 1

ƏXMƏT FƏJZ.—Fləjtələr.—Şiƣr. ——— 3
A. ŞAMOF.—Ana.—Xikəjə. ——— 9

Журналның «Совет әдәбияты» исемендә чыга башлавы совет әдәбиятында социалистик реализм методын үзләштерү өчен көрәш башланган елларга туры килә. Шуның өчен әдәби тәнкыйтькә багышланган мәкаләләр арасында Ф. Кирпотинның «Социалистик реализм» (1939, № 4—5), Г. Нигъмәтинең «Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре» (1933, № 11—12), К. Нәҗминең «Социалистик реализм өчен» (1936, № 4) дигән хезмәтләрен күрәбез. Алга таба журнал язучыларның I Бөтенсоюз съезды материалларына, М. Горький, А. Фадеев мәкаләләренә урын бирә. Бу чорда шулай ук Г. Гали һәм К. Тинчурин мәкаләләре еш басыла, соңга таба Х. Хәйри, Г. Кашшаф исемнәре күренә башлый.

«Совет әдәбияты» китаплар күзәтү, яңа чыккан әсәрләргә бәя бирү эшен дә тәртипле алып бара, шунлыктан «Тәнкыйть-библиография» бүлеге бик җитди төс ала. Шул уңайдан, әдәби журналның очерк жанрына беренче тапкыр тәнкыйть күзе белән каравы, бу жанрның критерийларын билгеләргә омтылуы ягыннан кызыклы булганга, Х. Хәйринең «Магнитогор очерклары» исемле рецензиясен искә аласы килә. Автор А. Әхмәтнең «Дөнья гиганты һәм аның каһарманнары» (1932 елны Урал өлкә нәшрияты тарафыннан чыгарылган) дигән китабына анализ ясаганда, фактлар, цифрлар белән мавыгып, тормыш, көрәш картиналарын художестволы сурәтләү турында онытмаска кирәклеген искәртә, «кыйммәтле фактны художество калыбында эшләп, укучы өчен кызыклы җиңел һәм аңлаешлы рәвештә» бирергә чакыра.

«Атака» башлаган эшне дәвам итеп, «Совет әдәбияты» әдәби түгәрәкләр эшенә күзәтчелек итә. Мәсәлән, 1933 елны чыккан саннарда Вахитов заводы, 40 нчы завод, Күн техникумы, рус әдәбияты түгәрәкләренең яшь иҗат көчләре, кызылармиячеләр иҗаты белән танышырга була.

Яшь авторларга квалификацияле иҗади булышлык күрсәтү өчен, журнал «Консультация» бүлеге ача. 1933 елның 1 санында «Совет әдәбияты» консультациясе» исеме белән Х. Туфан мәкаләсе бирелә. Х. Туфан авторга аның әсәренә карата конкрет киңәшләр бирү белән генә чикләнми, әдәбият теориясенә кагылышлы фикерләре белән дә уртаклаша: «Әдәбият мәсьәләләрен кирәгенчә аңлап җитмәвебез кимчелекләрне бетерергә уңайсызлый»,— дип яза ул.— «Әдәбият Магнитострое төзү» лозунгысын зур әйбер язу дип ялгыш аңлавыбыз кебек, «социализм геройларын бирү» лозунгысын да тиешенчә төшенеп җиткәнебез юк әле. Социализм төзү героен сурәтләп, тип итеп бирәсе урында, билгеле бер ударник геройны турыдан-туры «фотографияләү» белән ялгышабыз». Фикерләрен дәвам итеп, Х. Туфан шулай ук «стиль», «метод» төшенчәләренә дә туктала, аларга аңлатмалар бирә.

Журнал мондый төр консультацияләргә тагын берничә тапкыр әйләнеп кайта. Моңа мисал итеп, Л. Җәләйнең «Башлап язучылар иҗатына карата» (1945, № 9), дигән консультациясен алырга була. Татиздат каршындагы әдәби консультация бюросына килә торган әдәби әсәрләрнең бер өлешен тикшереп, карт галим, тел белгече шулай ук, аерым әсәрләргә карата конкрет фикерләрен, киңәшләрен әйткәннән соң, тема сайлау, аны сәнгатьчә образлар белән чишү проблемаларына туктала.

Журналның бу чор саннарында авыл темасына язылган очеркларның (бу жанрда бигрәк тә Г. Галиев, Г. Бәширов, А. Әхмәт, М. Гали активлык күрсәтәләр) күплеге күзгә ташлана. Әгәр «Атака» журналы Татарстанда гына түгел, Советлар Союзының башка өлкәләрендә барган бөек төзелешләрне иңләп, күбрәк производство темасына очерклар язу тәҗрибәсен тупласа, «Совет әдәбияты» үзенең очерклары белән авыл хуҗалыгы темасын үзләштерү юлында җитди адым ясый. Моңа колхозчы-ударникларның Татарстан съездына багышлап үткәрелгән кыска сроклы әдәби конкурс та (1933 елның февралендә игълан ителә) булышкандыр дип уйларга кирәк. Конкурска авыл хуҗалыгын социалистик нигездә яңабаштан кору темасына язылган инсценировка, хикәя, шигырь, җыр белән бергә, очерклар да кабул ителә.

Бу елларда М. Әмир, А. Шамов, Г. Бәширов (Г. Разин), Ф. Хөсни хикәяләре, Ш. Маннур, Х. Туфан, Г. Мөхәммәтшин шигырьләре белән бергә журналда күләмлерәк әсәрләр: Ә. Фәйзинең «Флейталар»ы (1933, № 1), Ш. Усмановның «Легион юлы» (1933, № 2—3), Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы (1935, № 9—12), М. Җәлилнең «Алтынчәч»е (1939, № 3—5) һ. б. урын ала.

М. Горькийның «Ана», «Артамоновлар эше» романнарыннан өзекләр бирег (Ф. Бурнаш, С. Әдһәмова тәрҗемәләрендә), журнал үз укучыларын рус әдәбияты әсәрләре белән таныштыруны да җәелдереп җибәрә.

Бөек Ватан сугышы елларында журналда «Фронттан килгән шигырьләр», «Ватан сугышы эпизодлары», «Ватан сугышы кырларында», «Ватан сугышы язмалары», «Советлар Союзы Геройлары» рубрикалары ачыла. Журнал сугышның алгы сызыгыннан, хәрби вакыйгаларның кайнар эзләреннән йөрәк ялкыны белән язылган шигырьләр һәм совет солдатларының батырлык үрнәкләрен күрсәтүче хикәя-очерклар, шагыйрь-язучыларыбызның уй-хисләрен, хатирәләрен сеңдергән язмалары белән тулып чыга.

Журналның ул еллардагы саннары канлы көрәш кырларында хәрәкәттәге армиядә, партизаннар сафында, фронт газеталарында каләм һәм автомат белән батырларча көрәшкән язучы һәм шагыйрьләребез — М. Җәлил, Ф. Кәрим, Н. Баян, А. Алиш, Г. Кутуй, Х. Мөҗәй, М. Максуд, Г. Насрый, Ш. Мөдәррис, И. Гази, Г. Әпсәләмов, Ш. Маннур, Г. Бакиров, А. Шамов, Г. Галиев, Р. Ишморат, Х. Госман, М. Садри, Ә. Маликов, З. Нури һ. б. лар иҗатлары тупланмасы һәм дәһшәтле көннәр ельязмасы буларак аеруча кадер-хөрмәт уяталар. Белоруссия җирләрендә атаклы партизан отрядларында сугышкан Җәүдәт Хәбибуллинның «Белоруссия урманнарында» (1943, № 5—7) һәм «Партизан хикәяләре» (1943, № 9—10), «Сугышчы блокнотыннан» рубрикасы белән бирелгән язмалар, журналны чыгаруда совет сугышчыларының үзләре дә катнашканлыгы турында сөйли.

Әне, бу авыр сынау елларында журнал зур популярлык казанды, әдәбиятны халыкка аеруча нык якынайтты. Журналны халык ничек яратканын өлкән язучыларыбыз истәлекләреннән дә, Х. Госманның инде сугыш елларында ук язган һәм басылып чыккан «Тукай фронтта» (1943, № 4) исемле мәкаләсеннән дә күренә.

Бу популярлыкның сәбәбен халык күңеленә иң үтемле тәэсир чаралары таба

белүендә дә күрергә кирәк. Күтелмәгән фаҗига алдында халыкның рухын ныгыту, изге сугышта җиңәчәгебезгә ышандыру, патриотик хисләр, фашизмга нәфрәт тәрбияләү максатын тормышка ашыру өчен иң элек публицистик мәкалә мәйданга чыга. 1941 елның 7 нче саны Ш. Камалның «Без җиңәчәкбез» дигән чыгышы белән ачыла. 9 нчы санда «Җиңелмәс халык», 12 нче санда «Азатлык сугышында татар халкы» (К. Нәҗми) исемле мәкаләләр бирелә. Бу циклны И. Эренбургның «Нәфрәт» һәм «Кеше ашаучылар фәлсәфәсе», Көнбатыш антифашист язучылары Л. Фейхтвангер, Т. Драйзер, Б. Ольден, Э. Синклер, Ж. Ришар-Блок әсәрләреннән һәм чыгышларыннан өзекләр дәвам иттерә.

Журнал үз битләрендә бөек Ватаныбызга һөҗүм иткән дошманны рәхимсез кыйнарга чакырып язылган «Фронтовик татарларга татар халкыннан сәлам хаты»н (1943, № 2—3) һәм бу хатка төрле фронтлардан килгән җавапларны урнаштырып бара. Беренче Украина фронтындагы татар сугышчылары, мәсәлән, болай яза:

«Туган Татарстаныбыз!

Син бөек Ватаныбызның аерылгысыз өлеше. Ана үзенең баласын күкрәгенә кысып саклагандай, ул үзенең һәрбер халкы турында, синең язмышың турында кайгырта. Син, Советлар Союзының башка республикалары белән бергә бер үк кояш астында яшисең, бер үк сугышчан байрак астында көрәшәсең.

Рус-Украина һәм Советлар Союзының барлык халыкларының уллары легендар Сталинград стеналары янында Ватаныбыз өчен, илебез өчен, Идел өчен, димәк, безнең Татарстаныбыз өчен дә, якыннарыбызның бәхете өчен дә үз-үзләрен аямыйча, әкияттәге батырлардай сугыштылар. һәм менә хәзер без, татар егетләре, кардәш Украина өчен, Ватаныбызның бөтенлеге һәм азатлыгы өчен сугышабыз. Украина — Татарстанның газиз туганы, Совет Ватаны — аларның газиз анасы» (1944, № 7—8).

Көчле ватандарлык рухы белән сугарылган мондый материаллар татар халкында бердәмлек, интернациональ дуслык хисләрен көчәйтүгә булышлык итә. Очерклардагы публицистик пафос конкрет документаль фактлар белән ныгытыла бара, аларның тәэсир итү көче тагын да үсә. Журнал очерк жанрына бу елларда аеруча киң урын бирә.

Бу чорда совет халкының сугыштагы батырлыгын һәм тылдагы фидакарьлеген гәүдәләндергән күләмлерәк әсәрләр дә иҗат ителә. Алар арасыннан журналда Ф. Кәримнең «Гөлсем» (1942, № 5), «Идел егете» (1942, № 6); Ф. Хөснинең «Йөзек кашы» (1942, № 3) повесте, М. Әмирнең «Миңлекамал» (1944, № 7, 8, 9) драмасы басылып чыга.

Журналның сугыш чорында дошманны җиңүгә керткән өлеше зур ихтирамга лаек. Кайбер республикаларда әдәби журналлар сугыш кыенлыклары аркасында вакытлыча туктап торганда да, безнең әдәби журналыбыз эшен дәвам иттерә, дошманны җиңүгә үз өлешен кертә.

Бөек Ватан сугышы хатирәләре нигезендә язучылар яңа әсәрләр иҗат итте. Госман Бакировның «Сугышчы көндәлеге», Г. Әпсәләмовның «Маньчжур язмалары», «Корея хикәяләре» 1946 елгы саннарны бизи. Бераздан журнал укучыларына Г. Әпсәләмовның «Ак төннәр»е (1947), «Алтын йолдыз»ы (1949), «Газинур»ы (1951), Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре» (1953) җиткерелә. Н. Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» (1957), Г. Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше» (1960), Ш. Маннурның «Муса» (1965) әсәрләре басыла. Бөек Ватан сугышы темасы еллар үткәч, С. Хәким, З. Нури поэмаларында, Ә. Еники («Без дә солдатлар идек», 1972), М. Мәһдиев («Ут чәчәге», 1980) повестьларында, язучы-эзтабарларыбыз Ш. Рәкыйпов, С. Шакир очеркларында, фронтовик язучылар истәлекләрендә яңача яңгыраш алды.

Журнал сәхифәләрендә илне төзекләндерү өчен барган көрәш сулышын, халкыбызның күркәм мораль сыйфатларын, аның революцион үткәнен чагылдыручы яңа әсәрләр урын алды. Дәүләт премиясенә лаек булган Г. Бәширов («Намус», 1948) һәм К. Нәҗми («Язгы җилләр», 1948) романнары, И. Газинең «Онытылмас еллар»ы (1949), М. Әмирнең «Ялантау кешеләре» (1953), «Саф күңел»е (1959), Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар»ы (1959), Ф. Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» (1961), Г. Гобәйнең «Без үскәндә»се (1963), Ә. Еникинең «Йөрәк сере» (1958), «Рәхмәт, иптәшләр»е (1962) һәм «Рәшә»се (1963), Г. Ахуновның «Хәзинә»се (1962), А. Расихның «Ике буйдак» романы (1964), Х. Вахит пьесалары, Х. Туфан, Н. Арсланов, И. Юзеев поэмалары һәм шигырь-

ләре журнал аша киң катлам укучыларга барып иреште. С. Хәкимнең «Ленин фәрманы белән» (1959), Р. Ишморатның «Давылга табан» (1963), З. Нуриның «Ленинга чәчәкләр» (1970), Г. Әпсәләмовның «Күк күкрәр» (1973) әсәрләре беренче тапкыр журналда басылып, татар телендә лениниана материалларын тулыландыруга зур өлеш булып керде.

Нык үскән социализм шартлары язучыларыбыз алдына илебез халыкларының туганнарча дуслыгын, хезмәттәге батырлыгын тагын да калкурак итеп күрсәтү, замандашыбызның мөһим проблемаларын күтәрү бурычларын куя. Әдәби хәзинәбезне яңа геройлар, яңа проблемалар, яңа алымнар белән баеткан әсәрләрдән Ш. Бикчуринның нефтьчеләр турында язылган «Каты токым», Э. Касыймовның «Томан аша», Ә. Баяновның КамАЗ төзүчеләр тормышыннан алып язылган «Ут һәм су» романнарын укучы яратып кабул итте. Бүгенге авылның социаль-экономик, иҗтимагый-әхлак проблемаларын күтәреп чыккан М. Мәһдиев («Каз канатлары», «Кеше китә — җыры кала»), М. Хәбибуллин («Икмәк кадере», «Чоңгыллар»), В. Нуруллин («Күпер чыкканда», «Аккан су юлын табар»), Ф. Хөсни («Мәйдан») повестьлары, табигать һәм кеше мөнәсәбәтләренә багышланган М. Әмир («Балыкчы ялганнары»), Г. Бәширов («Туган ягым яшел бишек», «Җидегән чишмә») әсәрләре шулай ук «Казан утлары»нда дөнья күрде. Журнал тарихи-революцион һәм тарихи темага язылган әсәрләргә дә киң юл ачты: «Ямашев» (А. Расих), «Көмеш дага» (Җ. Тәрҗеманов), «Әтил суы ака торур» (Н. Фәттах), «Яшьнәп үткән яшьлек» (В. Нуруллин) һ. б.

Совет кешесенең коммунизм төзүдәге мактаулы эшенә аның күркәм сыйфатларын тагын да тулырак чагылдыруны, хикәя жанрын тагын да активлаштыруны, язучылар игътибарын бүгенге көн проблемаларына ныграк җәлеп итүне максат итеп, «Казан утлары» бүгенге хезмәт кешесенә багышланган конкурс үткәрде (1978—1979 еллар). Бу — гомумән, әдәбиятыбызда хикәя жанрының тагын да җанлануына йогынты ясады.

Әлбәттә, журналның йөзен проза әсәрләре генә билгеләми. Өлкән буын шагыйрьләребез тудырган яңа әсәрләр белән бергә, алар эстафетасын кабул иткән Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Г. Рәхим, Р. Мингалимов, Р. Гатауллин, Зөлфәт, К. Сибгатуллин һ. б. ларның поэма һәм шигырьләре, драматургларыбызның яңа сәхнә әсәрләре басылып килә. «Казан утлары»ның яшьләр иҗатына да игътибары елдан-ел арта бара, тугандаш халыклар әдәбиятыннан иң яхшы үрнәкләрне, чит илләрдәге прогрессив язучыларның танылган әсәрләрен урнаштырып килүе белән исә журнал шулай ук интернациональ дуслык идеяләрен пропагандалауга зур өлеш кертә.

Язучыларның иҗат активлыгын үстерүдә, әдәби хәрәкәтнең төп юнәлешләрен билгеләүдә тәнкыйтьнең юл күрсәтүчелек роле бәхәссез. Әгәр 20—30 нчы елларда татар совет әдәбияты үсешен галим һәм тәнкыйтьчеләрдән Г. Ибраһимов белән Г. Нигъмәти күзәтеп, җитәкләп барса, сугыштан соңгы чорда язучыларның иҗат практикасын тикшерүгә М. Гайнуллин, Г. Халит, Х. Госман, Х. Хәйри, Г. Кашшаф, И. Нуруллин, Н. Юзиев кебек галимнәр килеп кушылды. Журнал битләрендә басылган мәкалә һәм рецензияләр мондый эзләнүләрнең социалистик реализм методын үстерү, чорга лаек уңай герой идеалын табу, проза, поэзия, драматургия жанрлары һәм әдәби осталык үзенчәлекләрен өйрәнү юнәлешендә барганлыгын һәм бу мәсьәләләрне тикшерүдә шактый күп авторлар (Г. Бәширов, И. Гази, Т. Гыйззәт, Г. Әпсәләмов, Ф. Хөсни, Ә. Исхак, Х. Туфан, Ш. Маннур, З. Нури һ. б.) даими һәм актив катнашканлыгын ачык чагылдыралар.

КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы мәгълүм карарыннан (1972) соң, журналда социалистик реализм сәнгатен тагын да үстерү турында кайгыртучанлык белән сугарылган эчтәлекле материаллар күбрәк басыла башлады. Р. Мостафинның «Тәнкыйтькә — тәнкыйть уты» (1972, № 4) мәкаләсен урнаштырып, «Казан утлары» тәнкыйтьнең коммунистик төзелештә үсә барган роле һәм аның актуаль проблемалары турында җитди сөйләшү башлады. Нәтиҗәдә тәнкыйтьнең гомуми әдәби процесста тоткан урыны, жанр үзенчәлекләре, принципиальлеге, әдәбият һәм җәмгыять каршында җаваплылыгы мәсьәләләре, сәнгатьчә эзләнү процессында активрак булырга тиешлеге, тәнкыйть арсеналын форма һәм стиль ягыннан төрләндерү, баету юллары конкретрак ачыклана төште. Әдәби тәнкыйтьнең практик бурычларын, теория һәм методология проблемаларын тикшерү И. Нуруллин, Г. Халит һ. б. мәкаләләрендә дәвам иттерелде.

Заманыбызның мөһим иҗтимагый һәм әхлакый мәсьәләләрен бөтен тулылыгы белән яктырту, нык алга киткән социализм иле кешесенең эшен һәм характерын психологик тирәнлек белән гәүдәләндерү, әдәби әсәрләрнең гражданлык хисен үстерү турында кайгыртып, «Казан утлары» бүгенге татар совет прозасы һәм поэзиясе мәсьәләләре турында фикер уртаклашуга да киң мәйдан бирде (Ф. Хатипов, Ф. Миңнуллин, Ф. Мусин, Х. Госман, Н. Юзиев, Т. Галиуллин, Р. Мөхәммәдиев һ. б. мәкаләләре һәм «Бүгенге поэзия турында сөйләшү» материаллары).

Проблемалы мәкаләләр белән бергә, рецензияләрнең ешрак басылуы, яшь тәнкыйтьчеләргә, укучылар фикеренә урын бирелүе соңгы елларда журнал битләрендә тәнкыйтьнең гомумән җанлануы турында сөйли. Тәнкыйть материалларының эчтәлек (социаль-эстетик анализның көчәюе) ягыннан да, форма (иншалауны диалог яки уйланулар, түгәрәк өстәл янында сөйләшү рәвешендә кору) ягыннан да сыйфаты күтәрелүе сизелә. Шулай да журналда әдәби-эстетик анализны әсәрнең тел үзенчәлекләре белән бәйләнештә алган мәкалә һәм рецензияләрнең дә күбрәк булуын күрәсе килә.

Әдәбият тарихына караган мәкаләләр ярдәмендә һәм әдипләребезнең юбилейлары уңаеннан «Казан утлары» үз укучыларын төрле буын язучыларыбызның иҗаты белән таныштырып бара. Әдәбият, әдәби осталык дәресләре хезмәтен үтәгән мондый материаллар яшь язучылар өчен дә файдалы.

Әдәби-иҗтимагый журнал буларак, «Казан утлары» публицистикага-очеркларга, юлъязмаларга, публицистик мәкаләләргә — җитәрлек урын бирә. Очерк жанрының үзенчәлекләрен тикшергән мәкаләләр дә баса. Киләчәктә бу юнәлештә дә эшчәнлек тагын активлашыр дип һичшиксез ышанырга мөмкин.

«Казан утлары»ның тематик диапазоны киң. «Безнең юл» традицияләрен дәвам итеп, ул сәнгать мәсьәләләрендә, культурабыз тарихына карата да киң җәмәгатьчелекне кызыксындырырлык тирән эчтәлекле материаллар биреп бара.

Журналның 60 еллык данлы эшчәнлеге — ул татар совет әдәбиятының хәрәкәте, аның үсеш этаплары көзгесе; театр, музыка, рәсем сәнгате тирәсендә барган эзләнүләр юлы; ул татар халкының иҗтимагый-политик фикере формалашу һәм шулай ук фән-культурабыз тарихы чыганагы.

«Казан утлары» — бүген җитлегү чорында. Аның эчтәлеге тирәнәйде, укучылар даирәсе киңәйде, иншалау ысуллары, структурасы камилләште. Ул Советлар Союзының барлык республикаларында, крайларында, өлкәләрендә тарала: тиражының 70 ләп процентын Татарстаннан читтә яшәүче укучыларыбыз алдыра. Димәк, ул илебездә чыгарыла торган иң зур әдәби-иҗтимагый журналлар рәтенә нык басты, хәзер ул ил күләмендәге җәмәгать һәм әдәбият тормышында күренекле урын алып тора.

## Һади Такташ

# Җырланачак җырлар турында

*Авыл... җырчың синнән*
*Бөтенләйгә китәм, ди...*
*...Кырларыңда, авыл, большевикча*
*Хисләр үссә дә,*
*Кем урыр соң, бар да шулай*
*Ташлап китсәләр?*

. . . . . . . . . .

*...Арт урамда берәү*
*Авыр башын салган цементка,*
*Ул эчмәгән үзе, ләкин аны*
*Җырланмаган җырлар исерткән...*

Х. Туфан. «Җырланмаган җырлар турында»
(«Безнең юл», № 10)

Туфан!
Таш урамда башын салган егет
Синең тиргәвеңне ишетте.
Әйе,
Аны әле җырланмаган,
Җырланачак хисләр исертте!..
Бөек җиңү алып килгән хисләр
Сыеша алмый таша күңелдә;
Әйтче:
Кайсын шунда җырлап бетереп була
Безгә тигән кыска гомердә?
Һәрбер фронт безгә зур көрәштә
Тиңсез җиңү алып китерсә,
Һәрбер җиңү алып килгән хисләр
Үзе белән безне исертә...
Ә җырлаучы кайда шул хисләрне?
«Җырчы» урыны көтә иясен.
Бөек еллар җырда үз Ленинын
Тудыралмый калды, күрәсең...
Маңгай бөдрәләрен туздырып, мин
«Мазут» суы аккан урында
Уйлыйм, Туфан,
Әле җырланмаган,
Җырланачак хисләр турында...
Ташлап киттем Тамбов урманнарын,
Нишлим? —
Шау-шуларга йөрәк чыныккан.
Давылларда туып канатланган
Бунтарь йөрәк качты тынлыктан.
Хәзер инде Тамбов урманнары

Төшкә генә минем керерләр,
Ләкин
Дус агайлар минем җырларымда
Мәңге шәүлә булып йөрерләр...
«Әүхәди»не минем җырларымда
Әле, Туфан, бик күп күрерсез,
Минем белән әле киң кырларда
Бик күп атлар көтеп йөрерсез....
Ләкин бүген менә «арт урамнан»
«Мазут» суы аккан урында
Уйлыйм
Җырланмаган,—
Киләчәктә
Бер җырланыр җырлар турында.

*«Безнең юл» журналы, 1926 ел, 11—12 сан.*

# Муса Җәлил

## Боз ага

Ак күбекләр чәчеп, ярдан ашып,
Киң болынга җәелеп су ага.
Дулкынланып, ташып, күмәкләшеп,
Тау-тау булып ярылып боз ага.
Бозлар ага...
Калын бозлар белән
Дулкын-дулкын булып төн ага,
Төннәр ага...
Кара төннәр белән
Ил өстеннән бөтен кер ага.

Бозлар ага...
Кара, салкын кышның
Саклап яткан калын бозлары...
Күңелләрне баскан авыр көчнең
Бар ачысы, кары, тозлары.
Бозлар ага...
Салкын бозлар булып
Ага илнең кара чүпләре.
Язгы көчле ташкын сулар булып
Ага төннең пычрак кортлары.
Бозлар ага...
Әнә, Идел буйлап
Боз артыннан килә ямь агып.
Киң шатлыкның иркен җырын җырлап
Агып килә бәйрәм шатланып.
Килә... Сабан, сука, тырмалардан
Коралланган эшнең гаскәре.
Килә... Чәчәкләрдән, хөрмәләрдән
Тиң яралган илнең яшьләре.

Килә... Әнә, алтын башаклардан
Бәйләп куйган туклык көлтәсе.
Килә... Әнә, гөлдән, чәчәкләрдән
Бизәп куйган ирек иркәсе...

Бозлар ага...
Агып илдән китә
Җанның салкын, авыр бозлары...
Арттан, әнә,
Балкып ямьле иртә,
Килә илнең батыр кызлары...

Бозлар ага...
Аксын, аксын бозлар,
Бозлар агу шатлык түгелме?!
Якты җәйнең җанлы эш иртәсен
Каршылавы нинди күңелле!

*«Безнең юл» журналы, 1923 ел, 2 (14) сан.*

## Фатих Кәрим

### Сибәли дә сибәли

Төнге җилдә көзге яңгыр
Сибәли дә сибәли;
Янымдагы иптәш кенә
Миңа берни сөйләми;

Уема да кертмәдем мин
Аның бу төн үләсен,
Разведкадан кайткан чакта
Тиде немец пулясы.

Өс-баш юеш. Көрәкләргә
Үзле балчык сылаша;
Кабер казыйбыз тынлыкта,
Җил генә ыңгыраша.

Кайгыдан каралып торган
Япь-яшь нарат төбенә
Япь-яшь иптәшне күмгәнне
Күрә бары төн генә.

Япь-яшь иптәшне күмәбез,
Беркем берни сөйләми,
Көзге төндә яңгыр гына
Сибәли дә сибәли.

*«Совет әдәбияты» журналы, 1942 ел, 11—12 сан.*

## Нури Арсланов

### Үз-үземә

Шагыйрьләр изге җаннардан саналганнар,
Ил вөҗданы булыр өчен яралганнар.

Акыл булган Хас Хаҗипләр тамахында [1].
Илләр булса ханнар, биләр табанында.

Шагыйрь кеше масаймас үз сәләтенә,
Тик үзгәләр сокланырлар сәнгатенә.

Бәхет шунда — бөекләрдән үрнәк алсаң,
Гали булып, гадиләрчә җирдә калсаң.

Сине дә бит умартачы диләр оста,
Чынлап шулай икән — әйдә сыйла, кыста,

Йола саклап, авыз иттер шул балыңнан
Киң илеңне, якты хисләр тубалыңнан!

## Салих Баттал

### Тансык күренеш

Ярышта җиңеп, җыр көйләп
кайтам күңелле генә.
Туры килдем мин урамда
балалар төркеменә.

Күзләрендә — кызыксыну.
Мин сорадым шул хакта.
— Исерек карыйбыз,— диләр...
Киттек җыйнау бер якка.

Менә исерекләр нинди
сирәк күренеш хәзер!
Барабыз. Миңа да чыкты
мавыктыргыч эш хәзер.

Бу урамда юк ул исерек.
Борылдык без чатка да.
Җыйнаулашып барып кердек
без ачык бер капкага.

[1] Хас Хаҗипләр — Йосыф Баласагунлыга — борынгының дәүләт эшлеклесе һәм бөек шагыйренә ишарә. Тамахында — ягында, тирәсендә.

Анда да юк... Мин төшендем
эш нидә икәнено:
исерек караучыларның
күзләре миндә генә!

Текәлгәннәр мине камап...
Исерек карыйлар, имеш!

Менә нинди хәлгә калдым
ап-аек һәм шат килеш!

Әйттем:— Эш хәмердә түгел,
балалар, шатлыкта,— дип.
Җавап бирделәр:— Абый, син
нәкъ шуңар тансык та бит!

## Мөхәммәт Садри

### Киев турында җыр

*Герой-шәһәрнең 1500 еллыгына*

Саумы, Киев! Рус җиренең
Иң тәүге башкаласы!
Борынгысы, иң матуры,
Иң сөекле анасы!

Саумы, Шевченко җиренең
Соклангыч башкаласы,—
«Яңа, хөр, бөек семьяда» [1]
Син хаклы макталасың!

Ворошилов, Щорсларың
Һәм Сидор Ковпакларың,
Данга күмде азат җирнең
Һәр почмак, һәр якларын.

Киң Днепрдан күптән аккан
Кайгың һәм аһ-зарларың,—
Бәхет җырын җырлый синең
Бәхетле кобзарьларың.

Бастым Шевченко һәйкәле
Янына якын гына:
«Бәхет елъязмасын язам»
Ди миңа ул тын гына.

Кан-яшь түккән дәвер үткән,
Хәзер эш, иҗат алда,
Хезмәт бизи сине, Киев,
Һәр җир, һәр «Арсенал»да [2].

Якты Киев! Бөек Киев!
Янып яраткан калам,
Бүгенгеңне җырлаганда
Үткәнне искә алам:

Фашист ерткыч котырынып
Сине җимерә иде.
Талап, көчләп, каның эчеп,
Җаның кимерә иде.

Өсләренә Днепрның
Сузып хәлсез кулларың,
Чакырдың, көттең үзеңә
Илнең батыр улларын.

Без килдек, килдек, туганым,
Кичеп ут диңгезләрен,
Юк итеп Идел, Дугада
Фашистларның үзләрен.

Иделдән, Урал буеннан,
Ярсу Иртыш янынннан
Килеп, ут кичеп сикердек
Сиңа Днепр ярыннан.

Тәмуг итеп дошман өчен
Тирә-ягың шул чакта,
Ашкынып кереп ташландык,
Киев, синең кочакка.

Изге туфрагыңны үптек,
Синдә кояш балкыды,
Киттек соңгы сугышларга
Синең җирең аркылы...

Менә хәзер зур табынга
Дәштең батыр улларың,
Киң һәм шат Днепр аша
Суздың җылы кулларың.

---

[1] Т. Г. Шевченко шигыреннән.
[2] Батырлыгы белән атаклы завод.

Әйе, Киев, Тантанаңа
Күңелләр оча гына,
Ватан-Ана сыны булып
Аласың кочагыңа.

Һәр батыр дустың кулында
Чәчәкләрең бәйләме;
Котлы булсын, нурлы Киев,
Җылы, нурлы бәйрәмең!

*1982. Киев-Ирпень*

## Галимҗан Латыйп

●

Мин төшемдә шигырь яздым:
Кояшлы бер көне язның.
И мактыйлар, мактаталар,
Борын үсте, үзем «аздым».

Мин төшемдә шигырь яздым:
Чәчәкле җәй, күге биек.
Җыелыш бара, сөйли берәү
«Килде яңа талант»,— диеп.

Мин төшемдә шигырь яздым,
Хәерле юл тели берәү,
«Мөфтилеге» хәттин ашкан,
Ул үзенә әзли терәү.

Мин төшемдә шигырь яздым:
Бозлы салкын яңгыр ява,
Көтмәгәндә давыл чыгып,
Өстемә бер имән ава.

Мин төшемдә шигырь яздым:
Тамчы тама әвенемнән.
Миңа мактау язган адәм
Чын юхага әверелгән...

## Гамил Афзал

### Бурыч

Бәхет елмаеп карады,
Чәчәкләр сузды кебек:
Кара чәчләрең агарды,
Яшьлегең узды, егет.

Күзләрең шыксыз караңгы,
Моңлырак көннәр килә.
Күз нурын түгеп карадым,
Йөз суын түгәм, димә.

Әле дә йөрәк тибә бит,
Күзләрең күпне күрә;
Язмышым кырын карады,
Газаплар чигәм, димә!

Табигать шулай көйләнгән:
Җәй үтә, көзләр килә;
Синең өчен күп түләнгән,
Син дә үз бурычың түлә!

## Илдар Юзеев

### Киләчәккә аваз

*Хәзерге реактив самолетлар тавыштан тизрәк очалар*

«Сөям. Киләм»,— диеп
хәбәр бирдем дә мин,—
очтым сөйгәнемә,
күккә мендем дә мин.
Төштем. Берәү дә юк:
тавыш — артта калган,
үзем — ракетада,
сүзем — артта калган.
«Сөям» дигән сүзем
килер соңга калып,
сүзсез иркәләүгә
торма гаҗәпләнеп.

...Кичер мине, Заман,
тизлек — арта бара,
үзем — киләчәктә,
сүзем — артта бара.
Киләчәккә карап,
якты сагыш белән,
Узган, Бүгенгедән
аваз-тавыш бирәм.
Җыр-хәбәрем сезгә
булыр таныш, ят та...
Соң булса да, бәлки,
барып җитәр атта.

## Фәнис Яруллин

●

Күптән инде әйтешкән юк
«Яратам» дигән сүзне.
Бу сүзнең матурлыгын без
Онытып бетермибезме?
Ә бит әле кайчан гына
Бу татлы сүзнең көче
Бәхеттән елата иде,
Яктырта иде кичне!

Бу сүзнең канатларында
Күкләргә менә идек.
Еш әйтсәк тә, аның бит без
Кадерен белә идек.
Бәлки бу сүз күп тапкырлар
Үлемнән саклагандыр.
Хисләрне яңарткандыр да
Җаннарны сафлагандыр.

Онытмыйк, дустым, онытмыйк
Без бу сүзнең барлыгын,
Аннан башка дөньяларның
Ярлылыгын, тарлыгын
Онытмыйк!

## Равил Фәйзуллин

### Дулкыннар кочагында

Егылсам да, торып йөгерсәм дә,
туфрактан-җирдән көч алам.
Кош нәселеннән булсам да, тик
дәрьяларда гына оча алам!

Бу кулларым Җирдә эш майтара:
казый, юа, ярлар коча ала...
Болытларга карап сузылсам да,
дулкыннарда гына оча алам!

Дулкыннарда чакта куллар — канат.
Чалкан ятып талпын, кагын син!
Зәңгәр күктә очып барган аккош
күзләреңне назлап чагылсын!

Су өстендә куллар безнең — канат!
Җир-Күк өчен — алар кул гына...
Кош күк оча Кеше! Оча!.. Түбәнендә —
һава урынына — су гына!
Аермалар бары шул гына.

Кемнәр әйтә, Күктә оча! — диеп,
Кеше фәкать суда оча ала!
...Әнә, күрегез, ничек кагына
яр читендә нәни бер бала!

## Рәдиф Гаташ

### Мөһаҗир

Пристань,
Яшел дебаркадер,
Ак пароход. Күк төтен...
Төтен күк язмыш юлыннан
Йөз ел элек, яшь бер шагыйрь,
Мөһаҗир!
Син кая, нигә киттең?

Уфылдаган да пароход
Кузгалган булыр ярдан.
Таш кебек катып, киткәнсең,
Күз алмый туган ярдан,
Билгесез якка табан.
Ә ярлар күмелә барган,
Ил ерагайган һаман...

Күпме карагансың читтә
Алсу шәфәкъка табан:
— Гомерләр дә шулай байый,
Туган җир күздән югалган,
Буталган дөнья, заман...
Кая йөзәбез, кая без?
Корабка туктар җир һаман
Күренми...
Ил, бул аман!
Кайда соң, адашкан җаның
Кайда ул ялга талган?
...Юк, читләрдә онытылмаган
Тик якты көнгә омтылган,
Кояшка баккан Казан:
Кайталар томан артыннан,
Күк горизонт аръягыннан
Васыятьләр илгә һаман —
Ачы шәраптай моң, җырлар...
Язмышы мөһаҗирләрнең
Әй ачы икән, яман...

Кай җирдә соң синең кабер,
Исемең билгесез мөһаҗир! —
Соңгы сәламеңне кем
Алып кайтты гыйбрәт өчен? —
Ил, Ватан күңеле иркен,
Соңгы сүз сыя...

Пристань.
Кемнедер монда көтмим.
Уйда әллә бер-бер язмыш,
Әллә күгелҗем төтен.

## Рәшит Әхмәтҗанов

### Сабан туенда

Сабан туе бүген. Авылыбызга
Йөзләп кунак кайткан бер көнгә.
Җырлый-җырлый бергә бөтенебез
Күтәрелдек үргә — иркенгә.

Дус-ишләрне күрү шатлыгыннан
Барлый алмаганбыз барсын да:
Батыр калган тимер тәнле егет,
Батыр түгел икән асылда.

Егет батыр калгач, яшь-җилкенчәк
Күккә чөйгән иде батырны —
Агай әйтеп куйды: «Бу батырга
Алмаштырмас идем атымны.

Ә ул алыштырды — ташлап китте
Иген үскән туган туфрагын.
Минем йөзне балам акламады...
Нәрсә диеп әйтим мин тагын!

Әй, иманын бер яңартыйм»,— диеп,
Алып батыр сыман кузгалды;
Кулга урап чиккән сөлгене, ул
Мәйдан уртасына юл алды.

Көрәшне ул яңабаштан шулай
Башлады,
Я, монда кем хаклы? —
«Мә, таны, дип җирне»
Җиргә бәрде
Ул үз улын — тансык кунакны.

## Роберт Миңнуллин

### Каракалпак шагыйре Ибраһим Йосыпов турында шаян шигырь

Ул бездән — Тукай җиреннән
Ерак торган Ибраһим,
Тик Тукайны үзләренчә
Җырлаттырган Ибраһим.

Үз язмышын, үз бәхетен
Чүлдә тапкан Ибраһим,
Чүлдән килеп, сабан туйда
Чүлмәк ваткан Ибраһим.

«Иң оста чүлмәк ватучы»
Дип ат алган Ибраһим.
«Йөз чүлмәк булса да ватам»—
Дип мактанган Ибраһим.

Чүлмәк ватып, кызлар күзен
Яндырган ул Ибраһим.
Татарстанны чүлмәксез
Калдырган ул Ибраһим.

Сабан туйда гайрәтләнгән,
Хәтта азган Ибраһим —
Чүлмәк ватам дип... җир шарын
Вата язган Ибраһим!

# Сибгат Хәким

## Эзлиләр Европа буйлап

**1**

Берлин — Дрезден... Буталып
Вокзаллар арасында,
Уйланып язмаган белән
Язганнар арасында,
Тоеп икенче сугышның
Ерак эшелоннарын,
Өченчесенең якында
Тоеп еш адымнарын,
Янып июль кызуында,
Ике хис арасында,
Сугышлар эчендә калган
Ике бичара сыман,
Йөрдек без Әминә [1] белән,
Чишәргә төннәр серен,
Йөрдек янында элекке
Дрезден төрмәсенең.
Хәзер ул — университет:
Теләге томкыннарның,
Ишек алдында уртада
Торган тып-тын сыннарның
Васыяте тормышка ашкан,
Әлегә яшь, юк даны.
Тарихы: политик төрмә,
Империянең суд залы.
Сүтелгән камералары,
Сипләгәннәр, бушаган,
Тәрәзәләреннән һаман
Карый кебек Мусалар.
Алишлар, Курмаш, Симайлар
Кайда дип сорасагыз,
Текәләр унбер тәрәзә —
Унбер моң, унбер сагыш.
Шул йортта хөкем иткәннәр,
Барсының бер язмышы,
Әллә өлгермәгән инде
Дрезден башчапкычы,
Башларын Плетцензееда
Чапканнар... Эх, Дрезден...

---

[1] Әминә — Муса Җәлил хатыны Әминә Җәлилова.

Йөрдек без Әминә белән
Чәчәк тотып көнозын.

Дрезден галереясе
Түгел бу, бу суд залы.
Коридор буенча алып
Киләләр күк Мусаны.

Бу хакта сүзем алдарак,
Күп әйтер сүзем сезгә.

Илемнән Әминә белән
Килеп шул Дрезденгә,
Калын ишекләр, залларны
Соңгы чик төсле күреп,
Йөрдек суд карарын көткән
Ике чит кеше кебек.

2

Эзлиләр Европа буйлап...
Заман, кая яшердең?
Ахыры якынлашкан чакта
Егерменче гасырның,
Канлы тырнак эзе калган,
Заман гел юа барган
Салкын, тын стеналардан,
Җимерелгән диварлардан
Исемен күреп, күңелне
Тәмам беркетеп менә,
Урнына кадерле чәчәк
Салып бер бөртек кенә,
Бер минут уйланыр өчен,
Ерак авыллар аша,
Илләр һәм чикләр, коймалар,
Шлагбаумнар аша,
Сорашып: кайда дип монда
Имперский төрмәләр,
Эзлиләр, җирдә җитәрлек
Иркен, иске төрмәләр.
Дрезден. Империя суды.
Кергәч, кеше мескенгә
Әйләнсен, югалып калсын,
Дәшмәсен дип, өстендә
Тора мәһабәт манара,
Тора өстә очланып,
Баса элекке Германия
Күге, аста без — халык.
Әй, өнсез куркыныч дөнья,
Кузгалып кемнең теле
Каршы сүз дәшәр, кешеләр,
Әйтерсең, ком бөртеге.

Дрезден. Фучик Мусага
Үзенең урнын биргән,
Эзлиләр чехлар, татарлар,
Эзлиләр унбер илдән.

Купкан халыклар, дөньяның
Бу нинди мәхшәре бу?
Сугыш-җинаятьтән торган
Бу нинди җир шары бу?

Үзенә, кызы Чулпанга
Юк сыныкларны тотып,
Фронтлар — сугышлар аша,
Ут сызыкларын үтеп,
Хәвефле — хәтәр елларның
Үтеп шик-шөбһәләрен,
Үтеп һәм сүтеп — корылган
Нахак сүз киртәләрен,
Килде күк Әминә судка,
Еракта залның башы,
Зал белән җан арасында
Заманнар яңгырашы.

Хөкемгә антифашистлар:
Испаннар, итальяннар,
Немецлар һәм башка бөек
Халыклар үтә залдан.
Аларның артта таяныч —
Данте һәм Бахлары бар,
Рәхимле булуны судтан
Сорарга хаклары бар.
Ә синең, татар? Баш ватма
Эзләп, санап аларны,
Татарга таяныч — Идел,
Болгар хәрабәләре.
Болгар һәм Идел... Юк синең
Гете һәм Дантеларың,
Корбан ит үзеңне, күрәш
Акканчы тамчы каның.
Башкача түгел, тик шулай...
Ятканчы атып калыйм,
Дигәндер үлемгә карап
Барганда Фатих Кәрим.
Корбан ит, фәкать тик шулай.
Бөтен бәлаләрдән үт,
Дошманга, танкка каршы
Бетон баганалар күк
Тырпайган чәчле Кәримне
Күргәндер Кенигсберг,
Елмаеп соңгы үрендә
Торганда негр кебек...

Азмыни бездә Кәримнәр
Корбанга бара торган;
Кырык бер Кызыл мәйданы —
Бәйрәме парадыннан
Туп-туры сугышка кергән
Егетләр, яуга каршы...
Билгесез биеклекләрдә
Заманнар яңгырашы...

3

Дрезден. Империя суды:
Тарих, нинди хатаң бар?
Әйт, нигә икенче тапкыр
Европада татарлар?
Керә татарлар. Ябыклар.
Озын юллар алҗыткан.
Килә татарлар гасырлар
Аша исән Азовтан.
Уза французлар, поляклар,
Татарлар мыскыллау күк
Ишетелә, бөек халыклар
Эшенә кысылган күк.
Нигезе Идел ярында,
Оясы Ослан-тауда.
Язмышы һәрвакыт читтә —
Моабит, Шпандауда...
Татарлар унбер... Каян ул?
Мәскәү, Столешников.
Йорт унбер. Беренче бүлмә.
Баскыч, өстәге ишек.
Столешниковтан килә
Ул беренче, ул унбер...
Бөтен тарих буйлап килә,
Күрәшәбез: үлем — бер...

Суд залы. Еракта Казан.
Казан — язмышы башы...
Казан — Дрезден арасында
Заманнар яңгырашы.

Әй Казан «Барабыз»лары...
Берсендә Такташ чапты —
Җилләп, буранлап, давыллап,
Барсын да ташлап чапты.
Төшеп үрәчәләреннән
Арык «Барабыз»ларның,
Бишьеллыкларга җигелгән
Ярсу паровозларның
Берсендә Муса очты күк,
Данлы чор, Такташ чоры,
Казанның шагыйрьләр белән
Яшәгән, шашкан чоры.
Октябрь белән уянган
Татарның — Хәйрулланың
Дөньяга тудырган чоры
Үзенең Байроннарын.
Берсе — Тамбовтан, ә берсе
Оренбур — Мостафадан,
Җырларын байрак иттереп
Күтәрде кебек Казан.
Талантлар чоры... Казанга
Мондый зур бәхет каян?
Уйланып Урал ягыннан
Керде күк Гомәр Хәйям.

4

Дрезден. Суд залы. Унбер...
Европа, сугыш чоры...
Кайдадыр яңгырый кебек
Сәйдәшнең оркестры.
Сәйдәшнең үлемсез маршын
(Бу хис елаткан, беләм)
Бөтен дөньядан җыелган
Оркестрантлар белән
Уйнап керерләр күк залга,
Сәхнә тар алар өчен,
Ул марш яралган фронт,
Сахра-далалар өчен.
Азат итәрләр, ут яна
Кара карлыган күзләр,
Тукайда сүнгәч, Мусада
Кабат кабынган күзләр...

Күрдем мин тагын нәфрәттән
Шундый елтыр күзләрнең
Янганын, өскә килгәндә
Өере «юнкерс»ларның.
Фронт. Взводым. Солдатлар.
Күбесе көнчыгыштан.
Каршылап таңны, окоптан
Кояшка күзен кыскан
Солдатлар... Бомба астында
Чүп-үлән тырнап киткән,
Туфрагын-тузанын сөрткәч,
Кинәт ялтырап киткән
Ул хәтәр күзләр... Солдатлар...
Рух тере, үзәк тере.
Шуларда Муса күзләре,
Көнчыгыш үҗәтлеге...
Унбер милләтле взводым,
Җиткәнче үрең менеп,
Сугышның, унбер палачын
Асканчы Нюренберг...

5

Суд залы. Унбер... Әй Муса,
Юылган синең эзләр,
Арада еллар, лагерьлар,
Арада Дрезденнәр.
Тарихка — алты камера...
Берсенә сарылып баскан
Мусаның Әминә бары
Ерактан саубуллашкан
Авазын гына ишетте.
Язмышлар яман ачы.
Ике арада, бушлыкта
Заманнар яңгырашы...

Әминә ишек алдында
Уйга талган сыннарның

Тора берсе кебек басып,
Арасында шуларның
Бердәнбер татар хатыны.
Июль, балкый ал төсләр...
Юата аны чәчәкләр
Тоткан антифашистлар.
Юата унбер ил, илләр
Алган култыклап аны.
Чәчәкләр ява бар яктан
Хөрмәтләп, котлап аны.
Тарихка — алты камера...
Шагыйрьнең сөйгән йорты
Кайсысы? Кайсысы Муса,
Кайсысы Симайныкы?
Мусалар фидаилеге...
Еш кына чумам уйга,
Татарга башкача түгел,
Бары, дим, шулай гына.
Дрезден, төрмә... Дөньядан
Кинәт аерылдым сыман.
Күземә Әминә булып
Карый кайгылы сыннар...

6

Тарихка — алты камера...
Күнеп кагыйдәләргә,
Йөрдем мин карап караңгы
Шомлы камераларга.
Берсеннән Муса дәшәр күк:
«Килгәнең Дугалардан
Көттек, коткара алмадың
Син безне богаулардан...»

Ачы җилләренә түздем
Рус кышы — дуамалның.
Клин, Калинин, Ржевның,
Атаклы Дугаларның
Солдаты синең алдыңда
Гаепле, гөнаһлымын,
Юлларда төртелдем озак,
Шелтә бир, колакны бор...

Йөрдем һәр почмакны карап,
Җир сөргән сабан ята.
Юк, гильотина ул, тыңлап
Куркыныч заман ята.
Төрмәләр, гильотиналар,
Сугыш поскан бункерлар...
Эх, сагындыра шул чакта
Арыш үскән киң кырлар.
Котылып тизрәк күңелгә
Шом салган уйларымнан,
Кайтасы иде әйләнеп
Бер Сабантуйларыннан.
Эх, сагындыра шул чакта...
Өлгергән яңа иген.

Мусалар белән бергәләп,
Шул яңа Германиянең
Гизәсе иде кырларын.
Рәхмәт якты көннәргә...
Йөрисе иде сокланып,
Бодайлы бункерларга.
Татарстанмы ул, барыбер,
Әллә ул ГДРмы,
Бертигез шатлана алам,
Бертигез сөям җирне.
Күрермен микән бу каты
Дөньяның йомшаруын,
Тоташ бер иген кырыннан
Торганын җир шарының.

7

Тынычлык... Кайда бар аның
Көрәшсез бирелгәне?,
Буш йортларга бәреп кергән
Көнбатыш Берлиндәге
Яшьләрнең гаугасын ишетәм,
Заман гел юа битен;
Кайчандыр Муса утырган
Карт төрмә — Моабитның
Урнына яңасын сала,
Искесе булган дип тар,
Юк, йортлар түгел яшәргә,
Яшьләргә — моабитлар...

Эзлиләр Европа буйлап.
Мусаны Дрезденнән
Без дә эзләдек, калыкты
Моабит нигезеннән.
Йөзләгән илләр аркылы
(Барыбер, нинди урам)
Баралар Лорка, Җәлилләр
Һәм Пабло Нерудалар.
Өченче сугышка каршы
Баралар: кире чиген!
Улларын, кызларын эзләп,
Эзеннән икенченең
Килә икенче бер төркем,
Арган, сусаган, бара...
Сугышлар ялганмасын дип,
Яннан Мусалар бара.

*1981. Берлин — Казан*

Нурихан Фәттах

# СЫЗГЫРА ТОРГАН УКЛАР

РОМАН

*Беренче китап*

## Бишенче баб

### I

Алар яңадан кузгалып киттеләр. Алдан күзәтчеләр барды, ян-яклардан, арттан коралллы алайлар барды. Тигез җиргә җәелгән язгы ташу кебек, аяк астыннан ашанып, күп санлы көтүләр барды. Озын олаулар булып, биек түбәле арбалар шыгырдады. Көндәгечә далада атлар пошкырды, бияләрен көнләп, яшь айгырлар үзара сугышты. Җирне-күкне яңгыратып, үгезләр үкерде. Көндәгечә, баш өстеннән каркылдашып, каргалар очып үтте. Югарыдан, җирнең өстен яктыртып, кышкы кояш көндәгечә балкып торды.

Күрекле бикә Туңгак алыпны Дингез-күл буенда үлем түшәгендә калдырып киткәннән соң кинәт кенә басылып, боегып калды. Ул яңадан үзенең җил үткәрми торган иркен арбасына кереп утырды да почмакка посты һәм йомшак якасына чумып, беркем белән сөйләшмичә, берни белән кызыксынмыйча барды да барды.

Туңгак алыптан аерылгач, Албуга элеккегә караганда да ныграк сүзсезләнеп, кырысланып калды. Аның күңелендә нииндидер зур, әһәмиятле үзгәрешләр барлыкка килде сыман. Ул нидәндер котылып, бушанып, ниндидер иреккә чыккандай булды, ләкин шушы ук вакытта, бөтен киләчәген каплап, аның өстенә яңа борчулар, яңа сораулар ябырылып килгәне дә сизелде.

Иртән кояш җир астыннан чыгып, кич яңадан җир астына кергән кебек; яз көнендә барлык үлән, барлык бөҗәк туып, үсеп, кыш көнендә үлгән кебек, үзенең дә кайчан да булса бер үләчәген; үз күбәләгенең тәннән чыгып, тәңре катына очачагын ул белмәде түгел. Җир йөзендә барлык нәрсә шулай: туа, яши, үлә. Яңадан туа, яңадан яши, яңадан үлә.

Ләкин кояш төшлеккә дә җитми туктап калса, күктән егылып төшсә, кире артка таба тәгәрәсә, җирдәге үләннәр, бөҗәкләр — бар тереклек нишләргә тиеш соң? Алай булса, ул чагында җирнең өстен каран-

---

Ахыры. Башы 3—4 саннарда.

гылык каплар иде, дала өстендә бертуктаусыз җил дә буран уйнап торыр иде, барча тереклек үлеп бетәр, кешеләр ачтан кырылыр иде.

Шулай ук Тәңре углы, тагын углан, әле ныклап яши дә башламыйча, гомереңең әле бер күлемен дә үтмичә, таза-сау килеш, яшь айгырдай куәтле килеш, көтмәгәндә үлеп китсә, үтерелсә, аның иле-көне нишләргә тиеш соң?! Алар да, тәңре биргән сихри көчтән мәхрүм калып, үлеп-кырылып бетәчәк түгелмени?

Төшлектәге таза, яшь кояшның түбәдәге айның, йолдызларның кинәт җиргә төшеп үлеп-кырылып бетүләре башка сыймас нәрсә булган кебек, аның да — яшь, таза тучи бәк угланның үлеме дә башка сыймас нәрсә булмас иде мени? Инде шулай да берәрсе аның юлына үлем тозагы корып куйган икән, барлык җаны-тәне белән, бар тырышлыгы белән, бар осталыгы белән ул әлеге тозакны юк итәргә тиеш түгелмени? Тиеш!

Кортларның-бөҗәкләрнең, ташларның-агачларның яшисе килгәне кебек, Туман каганның, Котлуг бәкнең... — барлык башка җанлы-җансызның яшисе килгәне кебек, аның да яшисе килә. Ул яшәргә тиеш. Бер көн эчендә кояш җирне әйләнеп чыккан кебек, ул да үзенә тиешле гомерне яшәргә, үз төшлегенә, үз биеклегенә күтәрелергә тиеш.

Туңгак алып! Антыңны бозып син миңа куркыныч серенне ачтың, син минем күңелемдә яшәү дәрте, көрәш дәрте кабыздың. Син миңа сак булырга, уяу булырга кисәттең.

Ләкин дала киң, далада юллар күп — ат юллары, арба юллары, тычкан юллары... Шуларның кайсыннан китәргә? Кирәк юлны сайлаганда ялгышмаммы, Туңгак алып? Бутамаммы арба юлы белән тычкан юлын?

Сорау артыннан сорау туды, борчу артыннан борчу туды. Әлегә бер сорауга да җавап таба алмады. Шулай да ул кайгырып-уфтанып кына да яши алмый иде. Күп нәрсәдән хәбәрсез, белексез булса да, әле бик үк житлекмәгән, ныгымаган булса да, ул үзенең кем булуын, кем булырга тиешлеген онытмады. Энисе, энеләре, туганнары, каралар — ирләр, хатыннар — барысы да аны үзләренең башы дип, якчысы дип беләләр. Барыннан да элек ул аларның ышанычын акларга тиеш. Киң далада терлек куган оста көтүче кебек, ул да аларны үлемсез, кыран-талаусыз тигез юлдан, туры юлдан алып барырга тиеш.

Бармы җирдә шундый тигез юл? Бар көтүен бергә туплап, таратмыйча, имгәтмичә, барып җитә алырмы ул үзенең агылына[1] тикле?

## II

Икенче көн инде менә аның күңелен шундый уйлар талый. Энисенең үз кайгысы башыннан ашкан, Адай әле яшь. Теләсә дә, теләмәсә дә аңа менә бары үзенә таянырга кала.

Албуганың бер ягыннан — Адай, икенче ягыннан Кәлтә бара иде. Алар, тирән уйга баткан кайгылы тагин угланның алай-болай кытыгына тиеп, ачуын китермәс өчен, икесе дә читтәнрәк, арттанрак киләләр. Тагин углан иелгән авыр башын күтәреп, башта сул ягына, аннары уң ягына карады. Адай белән Кәлтә, аңа нидер кирәклеген аңлап, шундук атларын кызулый төштеләр, аның һәрбер сүзен тартып алырга әзер булып, аның күзләренә карап бара башладылар.

— Без монда, абый! — диде беренче булып Адай.

— Минем янга йөзбашы Җирән килсен, — диде Албуга.

— Ул койрыкта. Үзем алып килермен, абый,— диде Адай.

— Бар.

Кәлтә, тагын берәр сүз чыкмасмы дип, тагин угланның авызына

[1] Агыл — мал-туарны ябып кую, бергә туплау өчен махсус корылма. Утар.

карап барды, ул эндәшмәгәч, сиздермичә генә артка калды. Албуга исә, Кәлтәне күру белән, түбет кызы Каратутны исенә төшерде. Бикә кызны Кәлтәгә берсүзсез бирде. Бүген Кәлтә кыз куенында булды. Түбет кызыннан соң уй җепләре шундук Табылдыкка, Табылдыктан Сөенечкә барып ялганды. Яшь угланның йөрәге сыкрап куйды. Кызлар турында аның уйлыйсы килмәде. Аңа хәзер ничек тә андый нәрсәләрне онытып торырга кирәк, аңа хәзер ныклык кирәк.

— Кәлтә! — диде ул, үзе дә искәрмәстән.

— Мин монда, олуг тучи бәк! — диде Кәлтә, үзенең кирәге чыгуга сөенеп.

Ләкин аның белән сөйләшергә сүз табылмады. Алар эндәшмичә, сөйләшмичә беравык янәшә бардылар.

— Кызыңны яратасыңмы, Кәлтә?

— Яратам, олуг тучи бәк! — диде Кәлтә, никтер каушый калып.

— Син инде гел аның турында гына уйлыйсыңдыр?

— Ы... — диде Кәлтә төртелеп. — Юк, синең янда булганда уйламыйм, олуг тучи бәк!

— Ялганлыйсыңмы? — Албуга ялт кына юлдашына карап алды.

— Юк, ялганламыйм.

Тавышы, күз карашы буенча Албуга аның чыннан да ялганламавын аңлады.

— Мин менә булдыра алмыйм — гел искә төшә, — диде ул, күңел йомшаклыгына бирелеп.

Кәлтә, әдәп саклап, эндәшмичә калды. Ике арада уңайсыз тынлык урнашты. Шул чакны арттан Адай белән йөзбашы Җирән килеп җитте. Туңгак алып Диңгез-күл буенда торып калгач, Җирәннең йөзе ачылып киткән иде. Ул үзен хәзер бик кирәкле кеше, бәхетле кеше итеп сизә иде бугай. Моның шулай икәнлеге аның һәрбер хәрәкәтендә, һәрбер сүзендә, бөтен кыяфәтендә сизелеп тора иде.

— Кулына ук-җәя тота алырдай ничә ирем бар минем? — диде Албуга йөзбашы Җирәнгә.

Бәхетле Җирән бөтенләй мондый сорау көтмәгән иде, ахрысы. Исенә төшерә-төшерә ул үзалдына кычкырып санарга кереште.

— Минем кул астында өч йөз сиксән... — диде ул, санының очына чыгып.

— Синең кул астында түгел, — минем кул астында күпме? Бөтенесе?! — диде тәгин углан.

Башка вакытта Җирәннең тук, тыныч йөзе аның ачуын китерсә, бүген аның кирәгеннән артык шат, ягымлы йөзе саруын кайнатты.

— Синең кул астында, олуг тучи бәк тәгин углан, бер мең чамасы... — дип башлады яңадан Җирән.

— Төгәле, төп-төгәле күпме? — диде Албуга, янә дә аның сүзен бүлдереп.

Шат кыяфәтле Җирән, авызына суккандай тынып калды, як-ягына тырпаеп торган матур кара мыек чылгыйлары мескенләнеп салынып төште, йөзен шундук кара кайгы басты. Чынында ул тәгин угланның үзеннән нәрсә соравын да төшенеп җитмәде. Моңарчы ул бикәнең ирләрен генә белде һәм алар тулысынча аңа буйсыналар иде. Башка ирләр турында ул рәтләп берни белми иде. Ул ы-мы итте, тирләп чыкты һәм иң ахырда, нәрсәдер аңлатмакчы булып, тәгин угланның сөйләргә рөхсәт итүен үтенде.

Албуга туктады, атын кире борды. Башкалар да туктап калдылар. Тәгин углан үз янындагы кечкенә төркемнән алдарак бара иде. Туктагач, ул өч кешелек төркемгә каршы якта булып чыкты. Җирән өч кешелек төркемнең уртасында — аның бер ягында Адай, икенче ягында Кәлтә иде. Җирән үзенең көтмәгәндә камалышта калуын бик тиз шәйләп алды.

— Сез ммине... нишләтмәкче буласыз? — диде ул агарынып. Калтыранган кулы белән ул шундук кылыч сабына тотынмакчы булды.

Тәгин углан, тынычлыгын саклап, иреннәрен кысып, аның шул калтыранган кулына карап торды. Адай белән Кәлтә шулай ук аның һәрбер хәрәкәтен күзәтеп тордылар.

— Мин сине исән калдырам, Җирән! — диде Албуга, олы бер киң күңеллелек белән.

Җирәннең кулы, калтыравыннан туктап, җансыз нәрсә кебек салынып калды. Матур мыеклы йөзе тартышып куйды.

— Мең яшә, олуг тучи бәк! — диде ул.

— Мин синнән төгәл сан сорыйм — син калтырап төшәсең. Мин борылып, синең йөзеңә карыйм — син коралга тотынасың,— диде Албуга, шелтә белән.

— Кичер мине, олуг тәгин углан! Мин аңлап җитмәдем, — диде Җирән, үзенең хатасын танып.

— Аңламасаң, сора,— диде Албуга.— Тыңла, йөзбашы Җирән, мин яңадан аңлатам: корал тота алган, кереш тарта алган... алтмыштан алып уналтыга чаклы булган барлык ирләрнең төгәл санын белергә. Шулар арасыннан алып ирләрне, яхшы атучыларны барларга. Бүген кич, авыл булып туктар алдыннан, йөзбашларын, унбашларын, алыпларны, яхшы, төз атучыларны бергә җыярга. Инде аңлашылдымы?

— Барысы да син әйткәнчә булыр, олуг тучи бәк, — диде Җирән, җиңел сулап.

— Сиңа Кәлтә булышыр, — диде Албуга һәм Кәлтәгә карады.

Булышырмын! — диде Кәлтә шундук.

— Мин үзем генә дә булдырырмын! — диде Җирән, ашыгып.

Ул моны Кәлтәдән баш тартасы килгән өчен түгел, тәгин угланга ярарга тырышудан әйтте бугай. Ләкин мондый ялагайлыкка тәгин угланның бер генә керфеге дә селкенмәде.

— Мин аңлаешлы итеп әйттем: сиңа Кәлтә булышыр, — диде ул коры гына.

Кичкә таба әйтелгән җиргә йөзбашлары, унбашлары, алыплар, сугыш осталары җыелгач, тәгин углан аларга үзенең беренче боерыгын җиткерде.

— Иртәгәдән алып... корал тота алган барлык ирләр ук атарга, аркан, сөңге ыргытырга, кылыч белән чабарга өйрәнә башлыйлар. — диде ул кычкырып. — Ун кешелек алайда бер өйрәтүче була. Алай башы алып ир, оста сугышчы булса, үз ирләрен үзе өйрәтә. Алай булмаса, унбашына ярдәмгә бер оста бирелә. Сугыш уенынан беркем читтә калмый — көтүчеләр дә, олаучылар да, ашчылар да... төнгекөндезге торгаклар, аерым сакчылар... беркем дә! Берәүләр иртәнге күлемдә күнексәләр, икенче берәүләр — кичке күлемдә. Кемнең кайчан күнегүен меңбашы... Кәлтә...

— Кәлтә?!

— Меңбашы?! — диештеләр ирләр, исләре китеп.

Тәгин углан, иреннәрен нык кыскан хәлдә, ирләрнең тынычланганын көтеп торды. Аның эндәшмәвен күреп, ирләр, киресенчә, ныграк шауларга тотындылар. Тәгин угланның боерыгы беркемнең дә күңеленә хуш килмәде. Өлкәнрәк ирләр үзләрен болай да оста сугышчылар дип исәплиләр иде, шунлыктан белгән нәрсәне яңадан өйрәнеп тору аларга көлке тоелды. Яшьрәкләр исә күбесенчә үз көчләренә, җитезлекләренә исәп тоталар һәм шулай булгач, аларга да ук атарга, сөңге ыргытырга өйрәнеп торуның бернигә кирәге юк иде.

Сөн ире — тумыштан ук сугышчы. Сөн малае дүрт-биш яшьтән сарык, тәкә сыртына эләгеп китә, биш-алты яшьтән юашрак атка атлана. Шул ук вакытта ул өлкәннәр ясап биргән кечкенә ук-җәя белән тычкан, йомран ише вак җәнлекләр аулый башлый. Унөч-ундүрт яшь-

тә инде ул чын атка атлана һәм үлгәнче аттан төшми. Сөн ирен сугыш эшенә чынында беркем өйрәтми — ул үзе өйрәнә — башта өлкәннәрдән күреп, аннары төрле яуларда катнашып Тумыштан сугышчы булса да, шулай да аны менә дигән сугышчы дип әйтеп булмый. Кайчагын-да аның угы читкә оча, сөңгесе тиешле җиренә барып җитми яисә кылычы йомшак булып чыга. Үзе ул, Төпсә кебек, еш кына баш-баштаклык күрсәтә һәм Төпсә кебек үк бөтенләй кирәкмәгәнгә баш-сыз кала.

Ләкин арада менә дигән алыплар да бар! Туңгак алыптай туры-лыклы батыр ирләр бар, Кәлтәдәй кыю, карусыз ирләр бар. Аңа, тә-гин угланга, нәкъ менә шундый ирләр кирәк. Берәү, икәү генә түгел, барысы да шундый булган батыр, кыю, турылыклы ирләр кирәк!

Төрле яктан кычкырган, көлгән тавышлар ишетелде.

— Син безне яуга җибәр, улым. Без сиңа шунда күрсәтербез ос-талыкны!— диделәр өлкән ирләр, күрәләтә мыскыл белән.

— Төне буе керфек какмый сакта тор да, көндез яңадан ук атарга тотын, имеш! — диделәр таза ирләр, ачыктан-ачык ризасызлык белән.

— Яшьләр өйрәнсен. Кереш тартып бездән бармак битләре каеш-ка әйләнгән! — диделәр картраклар.

— Укны җилгә очырырга ярамаганлыгын гына беләбез! — диделәр яшьләр, өлкәннәр сүзен куәтләп.

Шау-шу кәчәя башлагач, тәгин углан, берни әйтмичә, башта Кәл-тәгә, аннары Адайга карап алды, үзеннән артта — йөзбашларына, унбашларына, алып ирләргә капма-каршы якта зур бер төркем булып торган егетләренә күз салды. Егетләр арасында сүз кайтаручы, оста-ручы кешеләр күренмәде. Төпсәнең башы чабылган теге көннән соң аның элекке егетләре генә түгел, алар арасындагы «башбаштаклар» да үзләренең тәгин угланнары тирәсенә ныграк туплана төштеләр. Алар аның күзенә генә карап тордылар.

Менә әле дә егетләрнең үзенә эттәй турылыклы булуларын күреп тоеп, яшь угланның үз-үзенә ышанычы арта төште. Күп яулар күргән, күп яралар алган таза, батыр ирләргә ул тыныч кына карап торды да, сүз башларга җыенып кулын күтәрде.

— Бүгеннән башлап Кәлтәне меңбашы итеп билгелим! — диде ул өзелгән сүзен ялгап.

Ләкин аны тагын бүлдерделәр. Кәлтәнең меңбашы булуына яшь-ләр сөенеч белдерделәр — алар шундук тилереп шауларга, кычкырыр-га тотындылар. Бары өлкәннәр, картлар гына артык куанырга ашык-мадылар. Йөзбашы Җирән көнләшүеннән, хурлануыннан кара янып чыкты. Тәгин углан кемне дә булса меңбашы итеп куя икән, иң элек, билгеле, ул аны — атаклы йөзбашы Җирәнне куярга тиеш иде! Аның якыннары, коралларын баш өстенә күтәреп селки-селки, ризасызлык белдерделәр.

Кырын күзе белән генә тәгин углан янә үзенең егетләренә карап ал-ды. Тавыш басылганын аңа тагын көтеп торырга туры килде. Ул, бер-ни булмагандай, сүзен яңадан ялгап алып китте:

— Минем кул астындагы барлык ирләр сугыш уенында меңбашы Кәлтәгә буйсыналар. Кемнең кайчан уенга чыгачагын, кемнең кайчан сакта-каравылда торачагын — барысын да меңбашы Кәлтә белән ки-ңәшеп эшлисез. Минем уң кулым — Адай, сул кулым — Кәлтә. Алар-ның боерыгы — минем боерыгым. Минем боерыкны...

— Аңлашылды!

— Шулай булыр! — диделәр яшьрәк ирләр, шау-гөр килеп.

— Ярар, ярар! — диделәр өлкәнрәк, шомарганрак ирләр, таралыша башлап.

Аларның шулай сүзне әйтеп бетерергә дә ирек бирмичә, әледән-әле үзен бүлдерүләре һәм гомумән санга сукмагандай кыланулары Албу-

ганың кытыгына тиде. Үз-үзен никадәр тыярга тырышмасын, шулай да ул түзмәде — агарынып, калтыранып:

— Мин сезгә таралырга кушмадым! — дип кычкырды.

— Тыңлыйбыз, тыңлыйбыз — тагын ни бар? — диделәр шома ирләр, урыннарына кире килеп.

— Тыңласагыз, шул: минем боерыкларны Жиренә житкереп үтәргә!

— Үти алмасак, нишләтерсең, улым? — диде Жирән янындагы бер алып ир тыныч кына.

Төпсәнең үтерелүе һәм аннан да бигрәк Жирәннең куркытылуы өлкән буын ирләрдә ачу һәм үртәлү тудырган иде.

— Боерык аңлашылмаса, сорарга — ирек. Аңлашылган боерыкны үтәмәгән өчен... кемнең кем булуына карамастан, башы чаптырылачак!

— У-о!

— Мондый эшкә кем өйрәтте сине, балам!

— Кем булсын — Туңгак алып!

— Ул инде теге дөньяда — өйрәтсен күрмәсләрне![1] — диештеләр төрле яктан алып ирләр.

Кайберәүләр көлеп куйды, кайберәүләр сызгырып жибәрде. Шулай да күпчелек, бигрәк тә яшьләр, тып-тын торды. Утны-суны кичкән, үлемнең үзе белән якалашкан кырыс ирләр, алып ирләр — унбашлары, йөзбашлары, билгеле, аның теге «башбаштак» егетләре кебек кенә түгелләр иде. Алар белән саграк, уйлабрак сөйләшергә кирәк. Сөйләшкәндә яшь углан булып түгел, уң кул түчи бәк углан булып сөйләшергә кирәк булачак. Шунсыз аларны, күрәсең, барыбер бөгеп, үзеңә кирәк якка аударып булмас иде. Аларны бөгеп, үз ягыңа аударып булмый икән, яшәү турында, үлемне жиңү, көч туплау һәм үлем белән көрәшү турында хыялланырга да кирәкмәячәк иде.

— Язмыш сезне — миңа, мине — сезгә бәйләде, — диде ул, алып ирләргә карап. — Безнең бүгенге көнебез караңгы, киләчәгебез якты. Минем киләчәк сезнең кулда, сезнең киләчәк минем кулда. Якты киләчәкне яулап алу өчен миңа көчле куллар, кыю йөрәкләр кирәк. Алар — сез! Бер кулым бер якка, икенче кулым икенче якка тартса, дошман алдында йөрәгем калтырап төшсә, мин беркайчан да үлемне, кара язмышны жиңә алмаячакмын. Миңа йөз ук атып, йөзен дә дошманның күкрәгенә туры тидерә ала торган төз атучылар кирәк. Миңа эттәй ышанычлы, ач бүредәй усал, юлбарыстай кыю ирләр кирәк. Бармы сезнең арада шундый ирләр?

— Бар! — диделәр төркемдәгеләрнең күпчелеге бер авыздан.

— Булырмы шундый ирләр! — диде Албуга.

— Булыр! — диделәр күпчелек, шулай ук беравыздан.

## III

Сугыш уеннары икенче көнне иртән иртүк башланды. Кәлтә белән, үзенең егетләре белән тәгин углан уенчыларны карап-тикшереп йөрде. Калкулык артларында ирләр өчаяк таганга куелган карачкыларга ук аттылар, сөңге ыргыттылар. Тәгин углан ирләрне читтән генә күзәтеп торды. Эленке-салынкы кыланганнарга бер сүз әйтмәде — яннарыннан узып кына китте. Тырышып, чын күңелдән аткан ирләргә, аларның алай башларына, өйрәтүчеләренә мактау сүзләре әйтте. Төркемнәр янынан ул бер мәртәбә узып китте, ике мәртәбә узды, хәтеренә алган кешеләрен кайтып-кайтып күзәтте. Шул рәвешчә ул кемнең нинди сугышчы, нинди кеше булуын белергә тырышты.

[1] Күрмәс — явыз рухлар.

Кич, көтүләр, арбалар туктап, бөтен ил-көн авыл булып утыргач, ул яңадан үзенең йөзбашларын, унбашларын, алыпларын җыйды. Чын күңелдән тырышучыларга мактау сүзләре әйтте, булдыксызларга кисәтү ясады.

Икенче көнне карау-тикшерү эшен ул тулысынча Кәлтәгә тапшырды. Адай белән, егетләре белән ул үзе дә башкалар кебек далага сугыш уеңына чыкты.

Шулай итеп, тагин угланның теләге тормышка аша башлады: барлык ирләр, чын яўдагы кебек, көннең-көне буена диярлек кереш тарттылар, сөңге, аркан ыргыттылар, кылыч уйнатып чаптылар. Бик күпләрнең уен азагында телләре аркылы салынып төште. Кичкә таба далада, авыл тирәсендә яшьләрнең шат тавышлары ишетелмәс булды. Олылардан күрмәкче балалар да тынып калдылар.

Ачыктан-ачык каршы килгән, ризасызлык белдергән ирләр, ачуларын йотып, шулай ук дәшмәс булды. Бары хатыннар гына тынарга, авыз йомып торырга теләмәделәр. Җыйнаулашып алар бикә янына килделәр, аңа үзләренең зарларын белдерделәр. Сөн хатыны болай да барлык авыр эшне үзе башкара иде. Сыер саву, өй сүтеп өй кору, ашарга пешерү, бала-чага карау, кием тегү — барысы да аның өстендә. Ирләрнең корал тотып ат өстендә чабудан башка күзгә күренгән эшләре дә юк иде. Шулай да иртә-кич алар хатыннарына әз-мәз булышкалыйлар. Инде алар көн дә таш кискәндәй арып-алҗып кайта башлагач, хатыннарның моңа, билгеле, ачулары килде.

Улларының үзгәрүләрен, ябыгып, тартылып калуларын бикә үзе дә күрде. Ябыгудан, ару-алҗудан бигрәк алар юкка-барга үртәлә башладылар. Энесе Адайга әз генә дә якты йөз күрсәтмәде — башкаларга карата ничек булса, аңа да шулай ук кырыс, таләпчән булды. Адай баштарак берни эндәшмәде, ләкин соңыннанрак бер-ике мәртәбә энисенә абыйсын яманлап алды. Бикәнең моңа шулай ук эче пошты. Өлкән улы белән ул ачуланмыйча, тыныч һәм олыларча сөйләште.

— Углым,— диде ул аңа уйчан гына.— Кызыңнан аерылгач, синә күңелсез. Йөрәк януыңны басмакчы булып, син үзеңне дә, ирләреңне дә юкка интектерәсең. Сөн илендә беркайчан да ирләр бер караңгыдан икенче караңгыга чаклы бушка ук атмаганнар. Сөн ирен ук атарга, атта йөрергә өйрәтәм дип көлкегә генә калмассың микән соң?

Соңгы сүзләрен ул чын күңелдән кайгырып әйтте. Ләкин мондый сүзләр яшь угланның йөрәгенә пычак белән кадагандай тәэсир итте. Әнисе аңа үз сүзләрен түгел, Төпсә кебекләр, Җиреннәр һәм башка барлык башбаштаклар, булдыксызлар сүзен сөйли кебек тоелды.

— Әни!— диде ул агарынып.— Килешү буенча, ирләрне син тулысынча миңа тапшырдың.

— Минем аларны кире алырга җыенганым юк.

— Шулай булгач, син миңа каршы килмә!

Ул болай ук дип әйтергә теләмәгән иде, ләкин менә кирәк чагында теленә тиешле сүз килмәде һәм ул үзенең тупаслыгыннан үзе үк кызарынып китте.

— Мин инде сиңа каршы сүз дә әйтә алмый башлармын микәнни?— диде ана, бик нык хәтере калып.

— Алай түгел! Тыңлале, әни!— диде Албуга.— Сөн ире атта да яхшы йөри, уктан да төз ата. Тик менә яу вакытында ул аткан ун укның сигезе-тугызы җилгә оча. Ник? Ул бары яу алдыннан гына, ярышлар алдыннан гына үзенең ничегрәк атканлыгын тикшереп карый. Минем кул астында меңгә якын кораллы ир бар. Кыек-мыек аткан, боерык тыңламаган шул бер мең чамасы ир белән сине, үземне, туганнарымны, бар байлыгымны мин ничек саклармын да ничек яклармын? Минем бер ирем — ун иргә, ун ирем йөз иргә торырлык булганда

гына мин теләсә нинди дошманны аяк астына сала алачакмын. Менә ул ничек, әни!

Бикә өлкән углының хаклы икәнлеген аңламый булдыра алмады. Шул ук вакытта ул икенче бер нәрсәне дә белде: аның өлкән углы көннән-көн үсә бара, үзгәрә бара. Иң аяныч лысы шул: ана белән угыл арасында күзгә күренми торган бушлык барлыкка килгән иде, һәм ул бушлык көннән-көн зурая.

— Диңгез-күл буенда торып калган ир дә шундыйрак сүзләр сөйли иде, — диде бикә уйчан гына, улы белән килешкән сыман итеп.

Диңгез-күл буенда торып калган ирнең кемлеге, исемен әйтмәсәң дә, билгеле иде. Күз алдында булмаган кешенең исемен гомумән телгә алмаска тырышалар. Телгә аласы кеше авыру яисә яралы булса, аның исемен кычкырып әйтү бөтенләй тыела. Үлгән кешене, тереләргә яманлык эшләмәсен өчен, бөтенләй телгә дә алмыйлар, аның турында читләтеп тә сөйләмиләр иде.

— Ул өйрәткәндә мин күп нәрсәне төшенеп җитмәгәнмен, әни, — диде Албуга, әнисенең «теге ирне» искә төшерүенә сөенеп. — Үз башыма төшкәч менә барысын да аңлый башладым.

— Бар нәрсәне бутап, бозып бетермәсәң ярый инде, — диде әнисе.

— Төне буена мин аның белән киңәшеп чыгам, әни, — диде Албуга. — Ятсам да, торсам да, көндез дә... кайда да ул мине күзәтеп кенә тора кебек.

— Мин дә күрәм аны төштә, — диде бикә көрсенеп.

— Хәлләнсә без аны алып кайтыр идек, иеме, әни? — диде Албуга.

— Әйе шул, — диде әнисе, ничектер икеле-микеле итеп.

— Миңа киңәш кенә биреп торса да нинди яхшы булыр иде! — диде тагын углан, хыялланып. — Әллә барып алабызмы соң, әни?

— Юк, юк! — диде бикә куркып, кулын селтәп. — Аягына бассын. Кирәк булса, үзе эзләп табар.

— Әни! Ни сөйлисең син?! — диде Албуга гаҗәпләнеп.

— Антын бозган кеше мантымый. Ул барыбер исән калмаячак, — диде әнисе, дәһшәтле пышылдап. — Онытыйк аны, углым, онытыйк!

## IV

Ак урдадан кузгалып китүләренә ун көн булгач, төш урталарында алар Байык буе үзәненә килеп җиттеләр. Бар яктан да ачык, шәрә дала артта калды. Алда — еракта, уңда да, сулда да, бер-берсе артына посып-яшеренеп, очлы, биек таулар калкып утыра иде. Далага якынрак тау итәкләре монда да әле шәп-шәрә иде, арырак, бигрәк тә тау араларында, уенты җирләрдә сирәк-сирәк куаклар, әрәмәләр күренгәли. Куаклы, әрәмәле калкулыклар артында исә тоташ кара урман белән капланган һәм кайбер тау сыртларында, кыя башларында пычак йөзедәй шома ташлар ялтырап күренгән киртләч-киртләч биеклекләр башлана.

Шул таулар, урманнар арасыннан агып чыккан Байык суының киң үзәннәре җәй көнендә ямь-яшел үлән белән каплана иде. Хәзер монда ап-ак булып юка кар катламы ята. Моннан сулда төньяк-көнбатыш юнәлештә — Котлуг бәк, Котлуг бәктән болайрак, көньяктарак аланнарның Күкәл буыны агасы Елдырым бәк кышлавы булырга тиеш. Үзенә дигән кызны Албуга менә шул авылдан барып алырга тиеш иде.

Бөтен ил-көн, таулар арасындагы үзәнлекләргә кереп тормыйча, өстен боз каплаган елганың сул ягында, ике шәрә калкулык итәгендә туктап калды. Бу тирәдә үлән тапталмаган, ашалмаган иде — аяк астында терлекләргә әле биш-алты көнлек азык бар. Кешеләр оя-оя бу-

лып, таралып, билгеле бер тәртиптә өйләр кордылар, арбаларын җайлап куйдылар. Мал-туарны тирә-як болыннарга көтүгә кудылар.

Яңа җирдә өй урыны сайлау һәм арыклау, өй торгызу эшләрен — барысын да бикә үзе башкара. Шуңа күрә мондый эштә улларының булышлыгы аңа бөтенләй диярлек кирәкми иде. Тәгин углан, көтүләрне саклау һәм шулай ук сугыш уеннарым дәвам итүне меңбашы Кәлтәгә йөкләде дә, үзенең яңа җирләрен — биләмәләрен карарга китте.

Кайдадыр шушында, Байык суының уң ягында, карурманлы таулар арасында дунхуларның биш йөз өйлек Харасун буыны булырга тиеш иде. Харасуннар — Начин нойон кешеләре. Качып киткән Начин нойонның менә шул Харасун буыны, җирләре-биләмәләре белән, каган боерыгы нигезендә, Албугага күчәргә тиеш иде.

Начин нойонның язмышын беләләр микән мондагы дунхулар? Беләсәләр, үзләрен ничегрәк тотарлар да, белмәсәләр ничегрәк тотарлар? Тәгин угланны, барыннан да элек, шундыйрак сораулар кызыксындырды. Белексез бәкләре сыман алар да киреләнеп маташмаслармы? Ни генә булмасын, үзенә буйсынган халык янына барганда Албуга үзенең егерме дүрт егетеннән, Адайдан башка беркемне дә алмады. Ул монда яуларга килмәде, ә үзенә тиешлене алырга килде!

Ул шулай дип уйлады һәм, бернинди өстәмә саклык чарасы күрмичә, елга үзәне буенча, ашыкмыйча гына үргә таба күтәрелүендә булды. Биш-алты чакрым чамасы җир киткәч алар сул яктан, әле бер тау, әле икенче тау арасыннан килеп, төп үзәндә бергә кушылган күп санлы терлек эзләре күрделәр. Эзләр шундый күп иде — җир өстендәге тигез кар юрганы, йөзләгән, меңләгән ат, сыер, сарыкларның тояклары белән тишкәләнеп беткән, кайбер урыннарда исә тапталып, боздай тыгызланып калган иде. Төртке-төртке тояк эзләре арасыннан тасма-тасма булып, шулай ук көпчәк эзләре сузылган иде. Барлык эзләр елга буенча үргә, карурманлы таулар ягына таба китә. Димәк, кемнәрдер күченеп киткән. Көнчыгышка, куе урманнар арасына яисә бөтенләй таулар аръягына ук!

Тәгин углан эзләр буенча барды. Юлда сынган ук сабы, күмер, кимерелгән сөяк, тире кисәкләре кебек нәрсәләр күренгәләде. Кичкә таба алар өч-дүрт өйлек авыл урынына тап булдылар. Түгәрәк өй урыннары ап-ак җир өстендә кара тап булып ята. Түгәрәк тапларның уртасындагы учаклар инде сүнгән, көлләре суынган иде.

— Абый, әйдә артларыннан куа китәбез! — диде Адай кайнарланып.

— Алар инде ерак киткәннәрдер. Куып җитә алмабыз.

— Җитәрбез, абый.

Анын шулай бер дә юктан җилкенүе абый кешенең ачуын китереп куйды.

— Миннән узып, юк-бар киңәшең белән буталып йөрисе булма! — диде ул аңа усал гына.

Адай, үпкәләп, авызын турсайтып, иптәшләре янына китеп барды. Бераздан егетләр дә, Адай фикерен куәтләп, төрле яктан киңәш бирә башладылар. Тәгин углан туктап калды. Болай булгач ныклап сөйләшми ярамый иде.

— Мин сорамаганда миңа киңәш бирмәскә! — диде ул, егетләргә карап. — Урынсыз киңәш бирү — шул ук буйсынмау белән бер. Буйсынмаган, боерыкны үтәмәгән кешенең башы чаптырылачак — моны беләсез. Инде шуны да белегез: харасуннар киткән икән, китә бирсеннәр! Үзләре белән алар терлекләрен, арбаларын, балаларын, хатыннарын алып киткәннәр. Көтүлекләрне, тауларны-урманнарны, Байык суын алып китә алмаганнар. Безнең җир безгә калган. Шулай булгач сез — егерме дүрт кеше мең кешегә каршы барабыз дип, кая ашкынасыз?

— Үлемгә! — диде Тишек-Таш.

Егетләр тып-тын булдылар. Тәгин углан аларга кире борылырга боерды.

Кире кайтканда алар уң якта, кара таулар-урманнар арасында нәчкә генә булып күккә күтәрелгән ике-өч төтен баганасы күреп алдылар. Вакыт инде соң булса да, алар шул төтеннәр ягына карап киттеләр. Кемнәр икән алар? Әллә урманнар арасында качып калган кешеләр дә бармы монда? Таулар арасыннан сузылган сукмак буенча алар шактый озак бардылар, чокыр-чакырлар, чытырманлыклар аша үтеп, көтмәгәндә нииндидер чишмә буендагы кечкенә бер яланга килеп чыктылар. Каршыда, ялан уртасында, кыргый хайван тиреләре катыш агач кабыклары капланган очлы башлы алачыклар тырпаеп утыра иде. Алар күреп килгән төтен баганалары нәкъ менә шул алачыкларның түбә тишекләреннән бөркелеп чыга. Мондый очлы түбәле кайры-тире алачыкларда кыргый җәнлекләр аулап көн күрүче урман кешеләре яши иде.

Көтмәгәндә атлы-кораллы ирләр килеп чыгу белән, яланда кинәт ыгы-зыгы купты. Ят кешеләргә каршы ярсып өрә-өрә этләр ташланды. Алачыклар арасында булашкан кешеләр, киресенчә, куркып, кычкырып, каядыр качып китәргә тырыштылар. Арада бер-ике чәрелдек хатын-кыз тавышы ишетелеп китте, кайдадыр балалар елаша башлады.

Тәгин углан үз егетләренә ары бармыйча, ялан кырыенда туктап калырга кушты.

— Качмагыз, качма! — дип кычкырды ул урман кешеләренә.

Аның кычкыруын ишетеп һәм шулай ук кораллы ирләрнең бернинди яманлык эшләмәүләрен күреп, качучылар туктадылар да бераз вакыттан кире килделәр. Урман кешеләренең берсе — бөтенләй диярлек шәрә хатын — күкрәгенә кысып яшь бала тоткан иде. Коты алынып, күзләрен зур ачып ул ялан аяк килеш туп-туры кар өстендә басып тора. Алачыктан чыгып йөгергәндә ул, күрәсең, өстенә киенергә дә онытkan иде. Ул, ахрысы, хәзер дә җылы кием турында түгел, бәлки исән калу-калмау турында гына уйлый. Үз гомере, баласының гомере өчен курку кышкы салкыннан куркуга караганда көчлерәк тә, дәһшәтлерәк тә иде бугай.

Агач арасында ирләр нииндидер киек тунап яткан булганнар ахрысы — аларның канга буялган кулларында таш пычаклар бар иде. Арадан берсе ярсып, абалап өргән этләрне кире чакырды да, килүчеләргә каршылык күрсәтергә нияте юклыгын белдереп, кулындагы пычагын җиргә ташлады. Башкалар да пычакларын аяк астына теләр-теләмәс кенә ташладылар. Шәрә хатын нидер мыгырданып, яшеренгәндәй итенеп, шулай да ят кешеләрдән күзен алмыйча, алачыкка кереп китте.

Тәгин углан атыннан төште, коралларын Адайга биреп, әлеге кешеләр янына килде. Ымлыклар белән, кул-баш хәрәкәтләре белән ул аларга бернинди начарлык эшләргә җыенмавын аңлатты. Ирләрнең өлкәнрәге дусларча елмайды да бай киемле яшь ирне үзләренең алачыгына керергә өндәде. Тәгин углан хуҗа артыннан тар, кысан өйгә керде. Учактагы чи утын дөрләп китә алмый азапланa иде — шунлыктан өй эче шактый караңгы һәм төтенле. Сирәк сакал-мыеклы, кысык күзле хуҗа таш савыттагы майлы чүпрәккә ут кабызды. Яктырып киткәндәй булды. Хуҗа сөн телен яхшы гына белә иде. Дөрләп китә алмаган учак янында аякларын бөкләп утырган килеш ул Албугага үзе белгәнне сөйләп бирде.

Харасун дунхулары кичә генә иртүк кузгалып киткәннәр. Өлкән бичә белән тәгин угланның монда күченеп киләсен дә, Начин нойонның теге якка качып китүен дә алар алдан ук белеп торганнар. Бу арада нииндидер чин качаклары килеп, аларны — Харасун дунхуларын — котыртып йөргәннәр. Сөннәр сезнең хатыннарыгызны, мал-туар-

ларыгызны тартып алачак, үзегезне кырып бетерәчәк, дигәннәр; Начин нойон янына, таулар аръягына качыгыз тизрәк дигәннәр. Дунхуларның бу яктагы яхшы көтүлекләрне ташлап китәселәре килмәгән, аннан соң алар таулар аша үтеп булмас дип тә курыкканнар. Ләкин таулар арасында урман кешеләре генә белә торган юллар, сукмаклар бар икән. Дунхулар, кылавыз итеп берничә урман кешесен үзләре белән алганнар да, бөтенесе берьюлы кубып, теге якка качып киткәннәр.

Тәгин углан хуҗаны бүлдерми генә тыңлап утырды. Хуҗа сөйләп бетергәч тә ул аңа берни эндәшмәде.

— Моңарчы ничек яшәгән булсагыз, шулай яши бирегез. Дунхуларга ни түләгән булсагыз, миңа да шуны түләгез, — диде ул урман кешесенә.

Киткән чакта ул хуҗага көмеш саплы тимер пычагын бүләк итеп бирде. Ит тунаучы ирләрнең таш пычагы аңа бик тупас күренгән иде. Чыннан да, бүләккә хуҗа бик сөенде. Аның, билгеле, үзенең дә бу юмарт, бай угланга бирәр нәрсә бүләк итәсе килде. Ул агач ботагына эленгән һәм бөтенләй диярлек туналган боланның бер як арт санын тиз-тиз генә чабып төшерде дә Албугага тоттырды.

— Урманда киек күп. Тагын кил, куна кил, — дип сөйләнде ул, бертуктаусыз кабаланып.

Кич карангыда алар авылга кайтып җиттеләр. Тәгин углан үзе өчен корылган ялгыз өйдә кунды.

Иртән ул әнисе янына керде. Элеккерәк чактагы кебек алар — әнисе, балалар бергәләп, күңелле итеп аш ашадылар. Ашагач-эчкәч бикә белән өлкән углы арасында сөйләшү-киңәшү булды. Сүз күбесенчә быел кышны кайда, ничек кышлау турында барды. Бикә үз улының кичәгенәк кайларда булуы, ниләр күрүе белән кызыксынды. Харасун дунхуларының күченеп китүләренә ул бөтенләй кайгырмады. Тәгин угланга ул соңгы көннәрдә кирәгеннән артык тыныч һәм пошмас булып күренде. Мондый үзгәреш аңа бик үк ошап җитмәде. Бер ирне — унга, ун ирне — йөзгә әйләндерәм дип кара тиргә батып азапланганда, кимендә биш-алты йөз таза ире булган Харасуннарның кул астыннан ычкынып китүләренә аның әз генә дә борчылу белдермәве тәгин угланга бөтенләй аңлашылмады.

— Урда өчен урын карадыңмы соң, улым?

— Өлгермәдем, әни. Бүген тагын йөреп кайтмакчы булам.

— Син инде быел үзеңә аерым урда корырсың, улым. Яшь бичә алып кайткач аерым торырсың.

Аның тавышында бераз гына моңсулык, бераз гына көнчелек һәм үпкә сизелгәндәй булды. Албугага әнисе алдында ни өчендер уңайсыз булып китте.

— Әни, бер-беребезгә без якын гына торырбыз, — диде ул, аның күңелен табасы килеп.

— Мин бу якларны беләм, синең белән урын карарга дип барып йөрмәм, — диде бикә, сүзне икенчегә борып. — Яланда, далада кешеләр бер-берсеннән читтә яшиләр. Таулар арасында ачык җирләр, көтүлекләр тар, кысан. Теләсәң дә, теләмәсәң дә бер-береңә якын утырасың. Тау аралары кышлау өчен генә яхшы. Даладагы иркенлеккә берни җитми, улым. Җир өчен, көтүлек өчен талаш, ызгыш күбесенчә кыш көне таулар, үзәннәр арасында була. Шуңа күрә, улым, җирне үзең генә бүлмә. Үзеңә яхшырак урынны сайлап ал да, калганын ил агаларына, аксакалларга тапшыр.

— Ярар, шулай итәрмен, әни.

— Харасуннарның китүенә кайгырма син, улым, — диде бикә, улының уйларын аңлагандай. — Көн-кунган тауларның бу ягы гомер-гомергә сөннәрнеке булган. Дунхулар — теге якта. Бу яктагы дунхуларның барысы да яуда бөлгенлеккә төшкән әсирләр, коллар алар. Ачык

жирдә, далада яши алмаганга, каганнар аларны шунда — таулар арасындагы үзәннәрдә калдырганнар. Теге яктагы дунхуларда бернинди түрә юк, тәртип юк. Алар теге син күргән урман кыргыйларыннан әллә ни аерылмыйлар. Кем көчле, алар шуңа буйсына. Үзенә кыенлык килсә, дунху бар нәрсәсен ташлап кача, үз көчен сизсә, шундук борынын күтәрә. Дунхудан беркайчан яхшы сугышчы чыкмаячак.

— Теге... алып ир миңа бөтенләй икенче төрле сөйләгән иде, — диде Албуга, әнисенә каршы килеп. — Алар юлбарыстай көчле, сабый баладай юаш дигән иде.

— Теге ир... дунхулар турында сиңа тагын нәрсәләр әйтте? — диде бикә әкрен генә, сак кына.

— Алар таркау. Бер йодрыкка тупласаң, алардан сөңге дә ясап була, ук та ясап була дип әйтте.

— Әй! Сөңге-ук дигәннән, сиңа әйтәсе сүзем бар икән әле, улым,— диде бикә, нидер исенә төшереп. — Кичәгенәк корал ясаучы осталар килде. Алар монда Байык буенда яхшы каенлыклар бар диләр. Ук сабы, сөңге сабы ясарга шул яхшы каенлыктан каен кисәргә рөхсәт сорадылар. Мин синнән башка берни белмим дидем.

— Мин дә синнән башка берни белмим, әни!

— Юк, сиңа белмичә ярамый, — диде бикә, житди итеп. — Мин юри «белмим» дидем... синең сүзне өстен чыгару өчен. Барысы да аңласын — мондагы җир-суга, урманнарга, тауларга, киекләргә, агачларга — барысына да син баш, син хуҗа.

— Мин нишләргә тиеш соң, әни?

— Син аларга рөхсәт бирергә тиеш.

— Минем исемнән син рөхсәт бирсәң ярамасмы, әни? — диде тагын углан, китәргә җыенып.

— Алай да ярар, — диде бикә теләр-теләмәс кенә. — Син ашыгасың бугай, улым?

— Ашыгам. Ук атарга чыкканнармы — шуны беләм дә...

Тагын углан сүзен әйтеп бетерә алмады, — шул чакны бикә янына ашыгып ишек сакчысы кортка килеп житте. Ул кемнәрнеңдер килүен әйтте. Килгән кешеләр йөзбашы Җирән белән бер-ике аксакал булып чыкты. Шуннан соң күп тә үтмәде, әнисе әйткән осталар килеп житте. Җирән белән аксакаллар көтүлекләр турында сүз кузгаттылар, корал ясаучы осталар — агаччылар, кырмачлар — әнисе әйткән теге яхшы каенлык турындагы үтенечләрен кабатлады.

Күрекле бикә, тиешле сүзеңне әйт дигән сыман, өлкән улына мәгънәле генә күз карашы ташлап алды. Тагын углан түргәрәк килде, әнисе янына биеккә, йомшак мендәргә утырды.

— Мин әле үзем өчен җир карамадым,— диде ул аксакалларга җавап итеп.— Үземә, әнием Күрекле бикәгә урда урыны, көтүлекләр билгеләгәч, мин сезгә әйтермен. Җирне бөтен ил-көн белән бергәләп бүлерсез.

Яшь бәкнең мондый карарын ишетеп, аксакаллар канәгатьләнү белдерделәр. Алар чыгып киткәч, Албуга осталарга борылды.

— Сез әйткән каенлыкны минем үз күзем белән күрәсем килә, — диде ул. — Зурмы ул, нинди рәк? Ук сабы белән сөңге сабы ясарга гына яраклымы ул, әллә арба ясарга дамы? Безгә ук та, сөңге дә кирәк, күп кирәк. Безгә шулай ук яхшы арбалар да, урын-җир, ятак, савыт-саба да кирәк.

— Шулай, шулай, олуг тучи бәк тагын углан! — диештеләр агаччылар, кырмачылар күңелле шаулашып.— Урман монда күп, теләсә нәрсәгә житәрлек. Кирәк булса, без сиңа менә дигән карагай бүрәнәләрдән ике кат буралы итеп, биек, иркен кышкы сарай салып бирәбез. Бер дә каганныкыннан ким булмас. Яшь бичә белән рәхәтләнеп торырсыз кышкы суыкларда.

— Кышкы сарай, бүрәнә өй... — диде тәгин углан үзалдына сөйләнгәндәй итеп.— Шәп булыр иде ул ике колач юанлыгындагы карагай бүрәнәләрдән иркен сарай салып куйсагыз.

— Салабыз, салабыз — боерык кына бир! — диделәр осталар күңелләнеп.

— Юк, быелга ашыкмыйк әле без, — диде тәгин углан, үзенә үзе каршы килеп. — Безгә башта күп итеп корал, арба житештерергә кирәк.

— Үзеңә карыйсың, олуг тучи бәк тәгин углан. Кыш озын — сөңге сабына да, ук сабына да агачны таудай өеп куярбыз.

— Сез тау-тау өеп куйган ук, сөңге сапларына ярый ла тимер житкереп булса!

— Тимер генә им түгел! Тимер житмәсә, таш, сөяк куярлар, — диде өлкән яшьтәге бер оста.— Бозылды халык — ук башына да тимер, сөңге башына да тимер, пычак та тимер. Элек бер дә тимер дип аптырап тормаганнар.

— Бу якларда тимер ташы чыга торган иске каналар[1] бар дип сөйлиләр, олуг тәгин углан, — диде Жирән сүзгә катышып.

Бикә өенә килеп кергәннән бирле бу аның Албугага карап әйткән беренче сүзе булды. Моңарчы ул үпкәләп, хәтере калып һәм шул ук вакытта бераз гына шүрләгән кыяфәттә, ничек тә аның ягына карамаска, аның күз карашы белән очрашмаска тырышты. Хәзер аның тавышы бераз гына кысылып, карлыгып чыкты. Үз-үзен тотышында, тавышында аның яшь бәк белән татулашу, аңа ярарга тырышу нияте дә бар иде.

Албуга боларның барысын да күреп, тоеп утырды. Аннары ул шуны да күрде: озын мыеклы, шома битле, тук кыяфәтле таза йөзбашы Жирән шулай беренче мәртәбә авыз ачып сүз әйткәч, энисе ялт кына аңа — үзенең өлкән улы ягына карап алды. Энисенең бу житез күз карашында ул сагаю-шикләнү дә, курку һәм ялвару да сизгәндәй булды. Ул анда шул ирне якларга, кирәк булса, аның өчен бозылышырга да әзер бер тәвәккәллек күрде. Эчке бер сизенү ярдәмендә ул энисе белән йөзбашы Жирән арасында бикә белән кол арасында була торган мөнәсәбәттән дә зуррак, әһәмиятлерәк мөнәсәбәт барлыгын аңлап алды. Шул ук вакытта ул чи үгез тиресенә төренгән килеш, ярым үлек килеш еракта торып калган теге ирнең беркайчан да тук, шома битле булмавын, кирсенчә, аның бераз гына шадра булуын, ялалы, жөйле булуын да исенә төшерде.

«Антын бозган өчен генә түгел, тагын башка нәрсәләр өчен дә оны тыргә теләми микән ул тегендәге гарип ирне?» — дип уйлады Албуга энисе турында. Күрәсең, шулайдыр. Нинди кансыз була кайчагында бу өлкәннәр!

Жирәннең сүзләренә каршы тәгин углан тиз генә жавап кайтармады. Ул аның ике арадагы — бәк белән осталар арасындагы сүзне бүлдерүен һәм шуның белән сөйләшү йоласын санламавын бик яхшы аңлады. Ләкин ул әлегә үзен чын бәкләрчә, каганнарча тота белми иде. Шунлыктан ул Жирәннең әдәпсезлеген күрмәмешкә салынды.

— Безнең тимер ташы эретүчеләребез бармы соң? — диде ул көттеребрәк, беркемгә дә туры карамыйча.

— Бар, олуг тучи бәк тәгин углан! — диде Жирән ашыгып.

— Менә дигән тимерчеләребез бар безнең, углым! — диде бикә, йөзбашы Жирәнне яклап.

Аның тавышында куаныч сизелде.

---

[1] Кана (кан) — таш, руда казып ала торган тирән баз, чокыр.

## V

Әнисе янынннан чыккач Албуга, сугыш киемнәрен киеп, коралларын алып, Адай белән, егетләре белән далага — ук ату өчен билгеләнгән урынга юнәлде. Шуннан соң ул таулар арасына җир-урын карарга туры китмәкче булды.

Кояш әле ерактагы таулар арасыннан чыгып өлгермәгән иде, шулай да инде көн якты. Атларның шаулатып тын алуы да, ияр каешларының бер-берсенә тиеп ышкылуы да аермачык булып ишетелә торган тып-тын бер вакыт. Артта калган даладагыга караганда монда кар күбрәк, шунлыктан салкыны да йомшаграк, аграк, күңеллерәк сыман иде.

Тәгин углан үзендә искиткеч бер күтәренкелек тойды. Беренче мәртәбә ул каралар белән биектә, түрдә утырып сөйләште. Бәк булып, хуҗа булып сөйләште. Олы булып, акыл иясе булып сөйләште. Аксакалларның, осталарның йөзеннән ул күреп торды — алар аңа олылап, хөрмәт белән карадылар, аның сүзләреннән канәгать булып калдылар. Җирән белән дә араны җайлады — анысы да начар түгел. Дошманнар кими торсын. Әнисе дә канәгать калды.

Әйе, барысын да ул... тәгин углан җайлады. Аның күзенә генә карап тордылар. Моннан соң гел уйлап сөйләргә, кирәкле сүзләр генә сайларга тырышырга кирәк. Киләчәктә каралар белән турыдан-туры сөйләшергә ярамас. Каган кебек, олы бәкләр кебек, карачылар, ишек сакчылары булдырырга кирәк. Өйләнгәч, үзеннең урдан — өч кат божра белән әйләндереп алынган, кораллы торгаклар саклый торган биек Ак өең булгач, барысы да булыр. Булмый калмас! Тәңре улы гомер буена әнисе өендә, әнисе түрендә генә утырмас.

Аның күңеленә шундыйрак масаюлы уйлар килде. Әнисе өеннән ерагаеп, ачык далага килеп чыккач аңа ары-бире юырткан кешеләр, анда-монда туктап калган арбалар, ялгыз өйләр, терлек-туарлар очрады. Көн дә күреп гадәтләнгән өйләрне, арбаларны, терлекләрне ул әле яңа гына күргән кебек булды. Каядыр ашыгучы җайдаклар, кемнедер көтеп утырган арбалар, ялгыз өйләр белән, аяк астында җәелеп яткан җир белән үзе арасында ул ныклы бәйләнеш барлыгын тойды. Якындагы калкулыклар, ерактагы биек таулар, өстен боз каплаган Байык суы — барлык җанлы-җансыз нәрсә аны — яшь, бөек, акыллы хуҗаны олылыйлар һәм аннан ниндидер яхшылык, изгелек көтәләр иде сыман.

Шулай татлы да, дәртләндергеч тә уйлардан бераз гына башы әйләнеп, күз аллары томаланып барганда аның каршысына каяндыр меңбашы Кәлтә килеп чыкты. Кәлтә аны зурлап, олылап баш иде, сәлам бирде.

— Тотындыгызмы?

— Тотындык, олуг тучи бәк тәгин углан! Бүген иртәнге күлемдә атачак алайларга мин таң атканчы җыелырга боердым. Яктырта башлау белән атарга да керештек.

— Озак сөйлисең, меңбашы Кәлтә, — диде Албуга, шелтәләп түгел, аңлатып-төзәтеп. — Моннан соң сүзләрең кыска булсын, аңлаешлы булсын!

— Булыр!

Меңбашының шулай тиз отып алуына күңеле булып, тәгин углан көлеп куйды.

— Безгә таба ниндидер алай килә.

— Аңлашылып җитмәде.

— Күзәтүчеләр килеп әйтте: кемнәрдер якынлашып килә, — диде Кәлтә кабатлап, бераз гына «кыскартып».

— Кемнәр, күпме — белергә! — диде тәгин углан.

Меңбашы Кәлтә үзе янындагы ирләрнең бер-икесенә ым гына как-

ты, алар шундук китеп тә бардылар. Албуганың күңелле, татлы уйлары, суык җил суырып алган өй җылысы кебек, күз ачып йомганчы юкка чыкты. Чынбарлык — ачык дала, җир-күк күңелдәге хыяллардан кырысрак иде. Кемнәр булыр алар? Качып киткән дунхулар кире килеп арттан төшмәкче булалармы, әллә бөтенләй башка төрле ягылармы?

Албуга үзенең тынып, сагаеп калган егетләренә күтәрелеп карады.

— Тишек-Таш! — диде ул. — Кире авылга чап. Йөзбашы Җирәнгә әйт: андагы барлык ирләр коралланасын, тиз арада минем янга килсеннәр.

Тишек-Таш, аткан уктай томырылып, авыл ягына чапты. Албуга меңбашы Кәлтәгә борылып карады.

— Ату уеннарын туктатырга! Тупланырга боерык булганны көтеп торырга.

— Торырбыз!

Кәлтә үзенең егетләре белән атучылар янына китеп барды. Тәгин углан урыныннан кузгалмыйча шунда торып калды. Берникадәр вакыттан соң Кәлтә ашыгып кире аның янына килде.

— Мең кешелек алай белән Салчак алып килә. — диде ул.

Бу бөтенләй көтелмәгән, дунхуларның арттан төшүләре ихтималына караганда да көтелмәгәнрәк һәм гаҗәбрәк хәбәр булды. Албуга нәрсә уйларга да белмәде. Ник килә ул монда Салчак алып? Изге ният беләнме, явызы беләнме? Ни генә булмасын, ул сак, уяу булырга кирәк, дигән карарга килде.

Салчак алыпны ул үзенең тулысынча коралланган, атка атланган меңләп ире белән каршылады. Алар арбалардан, өйләрдән, көтүләрдән читтә, тигез далада очраштылар.

— Мин Сөн йортының башы бөек Туман каганның боерыгын алып килдем, олуг уң кул тучи бәк тәгин углан, — диде Салчак алып, аттан төшеп, аның алдында бил бөгеп.

— Нинди боерык?

— Бөек каган боерыгын бикә дә тыңларга тиеш, — диде Салчак алып туры гына җавап бирмичә.

Каган илчесенең үзенә бил бөгүе, «олуг уң кул тучи бәк тәгин углан» дип эндәшүе Албуганың күңелен тынычландыра төште. Тик менә энисе турында аның «бикә» генә дип әйтүе эчен тырнап куйды.

— Коралы ирләрең туктаган җирләрендә калырлар,— диде тәгин углан. — Өлкән бичә Күрекле бикәдән кеше килгәнче үзеңә дә көтеп торырга туры килер.

Салчак алыпның кемлеген белгәнгә күрә, Албуга аның белән шулай юри коры сөйләште. Яшь угланның үзен көттереп торырга ниятләвен белгәч, Салчак алыпның йөзе бозылып китте.

— Мин ашыгам, олуг уң кул тучи бәк тәгин углан, — диде ул. — Каган илчесен болай көттерү килешмәс кебек.

— Мин көттермим. Мин сине тыңлыйм, Салчак алып, — диде тәгин углан тыныч, дәрәҗәле итеп.

Каган илчесе телен тешләп тынып калды. Бикә янына җибәрелгән кеше әйләнеп килгәнче шактый вакыт узды.

Кеше бикәнең рөхсәтен алып килде. Тәгин углан белән Салчак алып бергәләп авылга юнәлделәр.

## VI

Каган боерыгын тыңларга бикә белән тәгин угланнан тыш, өлкән бичәнең барлык балалары, туганнары чакырылды. Шулай ук меңбашы Кәлтә, йөзбашы Җирән, бүтән йөзбашлары, унбашлары, аксакаллар,

агалар килде. Боерыкны Салчак алып үзе түгел, аның исеменнән сүз остасы — чәчән әйтте.

— Мин — Сөн йортының башы Туман каган боерам: өлкән бичәм Күрекле бикәдән туган уң кул тучи бәк тәгин углан Албуга үзенә буйсынган мең ире белән, кирәк-ярагы, өч аты, кораллары, азыгы белән, тугызынчы айның егерме җиденче көненнән дә соңга калмыйча, Урта кичү янына килеп җитсен. Минем боерык үтәлергә тиеш. Үтәлмәсә, баш тартучының башы чаптырылачак, бар байлыгы тартып алыначак.

Чәчән боерыкны ашыкмыйча, ачык итеп, кычкырып әйтте. Барысы да, каган исеменә хөрмәт йөзеннән, баш киемнәрен салып, аяк өсте тыңладылар. Чәчән әйтеп бетергәч, өйдә бик озак тынлык сакланды. Барысы да, авызларына су капкан кебек, миңгерәүләнгән кебек, нәрсә уйларга да, нәрсә әйтергә дә белми тик тордылар.

— Тагын кабатласынмы? — диде каган илчесе, өйдәгеләргә күз йөртеп.

Эндәшүче булмагач ул чәчәнгә тагын кабатларга кушты. Чәчән шул ук сүзләрне яңадан әйтеп чыкты.

Күрекле бикә кинәт битен каплап еларга тотынды.

— Яраткан колымны тартып алды, имгәтеп ташлады! Инде бердәнбер таянычымны да тартып алмакчы,— диде ул яшь аралаш.

— Яудан беркем читтә кала алмый, бикә, — диде Салчак алып.

— Әни! — диде тәгин углан.

— Синең яраткан колың масая башлады, шуңа җәзасын татыды, бикә, — диде Салчак алып тупас кына.

Ул болай да тупас, шөкәтсез бер кеше иде каган илчесе булу өчен ул бөтенләй яраксыз иде. Шундый кайгылы вакытта аның кирле-мырлы сөйләнүе өйдәгеләрнең күрәләтә ачуын китерде.

— Салчак алып, илче булсаң да, бу өйдә син — кунак. Кунакка тыйнак булу килешә, — диде Албуга кызарынып, әнисен яклап.

— Сезнең колыгызны имгәтүдә минем бер гаебем дә юк, олуг уң кул тучи бәк тәгин углан, — диде Салчак алып түбәнчелек белән.

Туңгак алыпның имгәтелүендә үзенең катнашы булуын ул мондагылар беләләр дип, бикә дә шуңа ишарәли дип уйлады, ахрысы. Мондагылар исә бу турыда берни белмиләр иде.

— Без сине гаепләмибез, Салчак алып, — диде тәгин углан.

Мондый сүз ишетеп Салчак алып авызын ачты да калды. Бөек далада каганның тугы теләсә нинди чирүдән дә көчлерәк булса да, монда Байык буена ул шулай да шүрләбрәк килгән иде. Шундый киң күңеллеме соң бу тәгин углан, әллә соң алар чыннан да берни белмиләрме?

— Урдадан чыгып киткәндә ул исән булган, бикә, — диде Салчак алып, баштагы тупаслыгын йомшарта төшеп.

— Ул анда үлеп ята! — диде бикә.

— Кайда үлеп ята, бикә? — диде Салчак алып, бөтенләй ягымлы итеп.

Аның шулай кинәт үзгәрүендә тәгин углан яшерен мәгънә тотып алды.

— Әни! — диде ул тагын әнисенә. — Каган илчесе белән сүз көрәштерү урынсыз. Боерык үтәлергә тиеш. Боерыкны мин үтәрмен, Салчак алып.

— Менә моны мактыйм! — диде илче, ачу китергеч бер өстенлек белән.

— Миңа синең мактавың кирәкми, Салчак алып, — диде тәгин углан. — Атамның — бөек каганның боерыгын мин сөенеп үтәячәкмен. Ул мине олы яуга чакыра. Уң кул тучи бәк тәгин угланның элеккечә яратуына ул чын күңелдән ышана. Минем өчен, әни, туганнарым, илем-

кѳнем, моннан да зур куаныч юк. Бүген мин көне буе юлга җыеначакмын, иртәгә таңнан кузгалып китәм.

Өлкән углының бу күтәренке, тантаналы сүзләренә бикә ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Ул аны бары каган илчесе алдында гына шулай тантаналы итеп сөйләде дип уйлады. Өлкән углының барысын да шулай тиз чамалап алуы, иң кыен чакта каушап, коелып төшмәве, анда Албугага карата янә дә ышаныч тойгысы тудырды.

— Салчак алып, мин сине кунак итә алмыйм — кичер мине, — диде ул кинәт хәлсезләнеп, урынына утырып.— Углым, ирләрем яуга җыенганда... мин генә кул кушырып утырмам ләбаса!

Каган илчесе чыгып киткәч Албуга әнисе каршысына тезләнде, аның тез өстенә салынып төшкән хәлсез кулларын үз кулына алды.

— Әнием! — диде ул яратып, иркәләп. — Мондый боерыкны мин күптән көттем. Бөтен ил-көн яу чабарга җыенганда, минем генә читтә калуым гел күңелемне тырнап торды. Бөтен ил-көн яуда чагында минем дә алып ирләр белән бергә буласым килә. Атам каганның күңеле йомшаган — ул мине үз янына чакыра. Менә күрерсең — яуда батырлык, кыюлык күрсәтсәм, ул безне яңадан Ак урдага тарттырып алачак! Ул чагында сиңа ялгыз башың кайгырырга туры килмәячәк.

— Ышанмыйм, — диде әнисе, хәлсез пышылдап.

— Мин барыбер аның боерыгына каршы килә алмыйм, әни, — диде Албуга, нык итеп.

— Әүвәл син аның беренче боерыгын үтәргә тиешсең, улым.

— Нинди беренче боерык ул тагын?

Бикә йомшак кулларын углының маңгаена куйды, сукыр кеше сыман аның битләрен, колакларын сыйпап-капшап карады, беләкләренең ныклыгын, тазалыгын чамалагандай итте.

— Улым! — диде ул йөрәк түреннән чыккан бер җылылык, якынлык белән. — Син Елдырым бәк кызы Алтын-Бөртеккә өйләнеп китәргә тиешсең. Ул синеке булып калырга тиеш. Яудан... кайтмасаң... улыңны сөеп юанырмын.

— Әни, мин!.. — диде шул чакны Адай, нидер әйтмәкче булып.

Кулын күтәргәндәй итеп әнисе аңа эндәшмәскә кушты.

— Адай синең урынга калыр, — диде бикә аның ни әйтергә теләвен белгән кебек.

— Әни, мине дә абый белән җибәр! — диде Адай.

Албуга күкрәген киерде, аягына басты.

— Адай, мин сиңа боерам: әни... туганнар, ил-көн — барысы да синең карамакка кала.

— Абый! — диде Адай, каршы килмәкче булып.

— Каган боерыгы гына түгел, минем боерык та үтәлергә тиеш, — диде тучи бәк тәгин углан коры гына.

## VII

Шулай итеп, яңа җирдә кешеләр иркенләп, тынычлап урнаша да алмадылар.

Яу чабуга, иксез-чиксез даланың бер читеннән икенче читенә тиз арада күченеп китүләргә, сугыш-талашларга кешеләр инде күптән күнеккәннәр иде. Аерылышу, озатышуларны да алар инде үз гомерләрендә күп күргәннәр. Яуларның-сугышларның берәүләргә байлык, бәхет, икенче берәүләргә үлем, коллык һәм мәңге кайгы-хәсрәт китерүен алар шулай ук бик яхшы беләләр. Шуңа күрә, яу турында хәбәр килгәч, тыштан алар гамьсез-тыныч калдылар, әчтән исә һәркемнең йөрәге янды. Берәүләр сөекле иреннән, сөекле баласыннан аерылды, икенче берәүләр карт ата-анасын ташлап китәргә тиеш булды. Берәүләрнең

коралы, каты киемнәре бик үк яхшыдан түгел, икенче берәүләрнең юллык азыгы җитешсез иде. Һәркемнең кайгысы — хәл ителмәгән олы һәм кечкенә борчуы, мәшәкате бар.

Эссе җәйдә кинәт күктән китереп койган яңгыр кебек, кыш көнендә томалап яуган тоташ кар кебек искәрмәстән килеп төшкән каган боерыгы бар нәрсәне үзенчә хәл итте. Бөтен ил кайгысы алдында вак-төяк кайгы-мәшәкатьләр, кар астында тигезләнеп калган җирнең кутырлары, кирәксез агач-ташлары сыман, томаланып, тигезләнеп калды.

Алар көне буе юлга әзерләнделәр. Әзерлек төнгә дә калды. Китәсе ирләр коралларын, тәңкәле каты киемнәрен, ат кирәк-яракларын барладылар, каласы кешеләр юлга төенчекләр төйнәде, ирләрнең тегелеп бетмәгән киемнәрен тегеп бетерергә тырыштылар. Сугымчылар ал-ял белми терлек суйды — туңдырып юлга ит әзерләделәр.

Ирләрнең һәркайсына бер айга җитәрлек азык-төлек, өчәр ат, ун кешегә бер казан, ике кешегә бер өй — күтәрмә алырга кушылды. Шуның өстәвенә һәрбер сугышчы ат карау, корал ташу, өй кору, ашарга пешерү өчен үзенә бер кушчы — булышчы алырга тиеш. Кушчыларның беркадәре коллар, каралар иде. Ярлырак сугышчылар исә кушчы итеп үзләренең хатыннарын, үсмер малайларын, я булмаса турыдан-туры сугышта катнаша алмаган элекке сугышчыларны — яралы аталарын, улларын алдылар.

Төн урталарына барысы да әзерләнеп бетте. Тәгин углан Албуга әнисе өендә туганнарын, ил агаларын, аксакалларны, йөзбашларын, унбашларын җыеп үзенең саубуллашу сүзләрен әйтте.

— Оясыннан очып китәргә талпынган яшь бөркет кебек, канат кагарга өлгермәдем — буран чыкты! Анасыннан аерылмаган колын кебек, тояк ныгытырга өлгермәдем — давыл купты! Минем үз өем дә, үз бичәм дә булмады. Сөеклемнең күзләренә карый алмадым, йомшак чәчләреннән сыйпый алмадым, үз улымны күкрәгемә кысып, ата булып куанмадым. Әнием! Мин синең яшь бөркетең, мин синең яшь колының, мин синең яшь бозавың! Туганнарым, энеләрем-сеңелләрем! Илем-көнем! Сезнең кебек мин далада — көтү арасында тудым, сезнең кебек ит-сөт ашап үстем. Мине бөек атам Туман каган яуга чакыра. Мин үлемгә каршы яу китәм. Кире яныгызга кайталмасам, мине мәңге онытмагыз. Әнием! Учагыңа ягып казан асканда минем өлешемне дә саларга онытма. Сезнең өчен, җирем-суым, илем-көнем өчен каным коеп, тәңре катына очсам, мине дә яныгызда дип белегез. Яз көнендә төннек аша бер күбәләк кереп, битеңә, кулыңа кунса — куалама, ул мин булырмын, әни!

Аның саубуллашу сүзләрен бикә күз яшьләрен агызып тыңлады. Башка хатыннар да мышык-мышык борыннарын тарттылар. Бары ирләр генә кырыс, тантаналы бер тынлык саклап, ирлек дәрәҗәләрен саклап, таш кыядай, басып тордылар.

Саубуллашу сүзеннән соң тәгин углан агач күбәтәдән кымыз эчте. Кымызлы күбәтә өй эчендәге барлык кешеләрнең кулында йөреп чыкты. Шуннан соң Албуга үзенең соңгы боерыкларын әйтте. Беренче булып ул Җирәнгә эндәште:

— Җирән! Син минем әниемне саклаячак чиругә баш булып каласың. Әниемне, туганнарымны, илемне-көнемне моңарчы ничек саклаган булсаң, моннан соң да шулай ук сакла. Мин сиңа карата кырыс булдым. Оныт аларны. Мин синең кичерүеңне үтенәм.

— Минем сиңа берниндн үпкәм юк, олуг тучи бәк тәгин углан.

— Кәлтә! — диде углан үзенең меңбашына. — Син минем белән яуга барасың. Син хәзер үк тугыз йөз кешелек алай белән Дингез-күл ягына китәсең. Мин үземнең егетләремне, йөз иремне алып Елдырым бәк кышлавына юл тотам. Ярәшелгән Алтын-Бөртеккә өйләнеп, анда

бер өчне куныл, мин туп-туры Диңгез-күл буена юнәләчәкмен. Мине шунда көтеп торырсың.

— Көтеп торырмын!

— Адай! — диде Албуга, энесенә эндәшеп. — Син минем белән кияү-егет булып барырсың. Мине Диңгез-күлгә чаклы озатып куярсың. Шуннан кире монда эни янына кайтырсың. Диңгез-күл буенда торып калган теге алып ирне дә белеп китәрсең.

— Юк, юк! — диде кинәт бикә каршы килеп. — Белешмәсен. Ул инде күчте — төшемдә күрдем.

Албуга, әйтәсе сүзен онытып, төртелеп калды. Әнисеннән ул бөтенләй мондый сүз көтмәгән иде. Салчак алып алдында «имгәтелгән кол»ны исенә төшергәч, тәгин углан әнисен һаман аны исендә тота дип уйлаган иде.

— Төштә күргәннең газабын без менә өндә татыйбыз, эни, — диде ул бераздан күңелсезләнеп, аңа каты бәрелмәскә тырышып. — Син дә, башкалар кебек, төштә күргән өчен генә аны читкә тибәрсәң, бу кансызлык булыр иде.

— Куркам, улым, куркам.

— Төштә күчкән өндә күчми — син аны беләсеңдер, эни? Ул күчмәгән, ул исән, эни!

— Мин берни әйтә алмыйм, балам... балаларым, — диде бикә ыңгырашып.

— Синең белән миңа, эни, куркуны гына түгел, үлемне дә җиңәргә кирәк. Мин үлемгә барам. Мин үлемне җиңә алмасам, безгә яшәү юк! Имгәтелгән алып ир безгә шул турыда кисәтте түгелме соң?!

— Мин синең теләгеңә каршы килә алмыйм, улым. Тик анда... Диңгез-күл буена Салчак алыптан алданрак барып җитәргә кирәк. Ул монда каган боерыгын гына алып килмәгән, — ул аның... тегенең кайдалыгын да аңдышып килгән. Күңелем шулай сизенә.

— Мин дә сиздем аны! — диде Албуга.

— Без, бикә, Салчак алыпны монда бер-ике көн буза белән сыйлап тоткарларбыз, — диде Җирән, күрәсең, үз гомерендә беренче мәртәбә тапкырлык күрсәтеп.

— Мин, бикә... олуг тучи бәк, Салчак алыпка сиздермичә генә, хәзер үк... менә төн уртасында юлга чыгармын,— диде Кәлтә.

— Мин, әни, теге алып ирне таза-сау килеш синең янына алып кайтырмын! — диде Адай.

— Мин, эни, яудан җиңеп, бик күп байлык төяп кайтырмын! — диде Албуга.

— Ак юл сезгә, балаларым! — диде ана, ике як күкрәгенә капланган ике улының аркаларыннан сөеп.

## VIII

Елдырым бәккә түләнәсе калымның инде яртысы бирелгән иде. Ике якның да килешүе буенча, кыз янына Албуга быел кышкы олы җыеннан соң барырга тиеш иде. Калымны тулысынча түләргә каганның байлыгы җитәрлек булса да, калган өлеш турында сүз бары бер елдан соң гына булачак иде. Бер ел эчендә — быелгы кыш башыннан алып киләсе кыш башына кадәр — тәгин углан Елдырым бәктә кияү булып яшәргә, ягъни кызның ата-аналарына көтү көтәргә тиеш иде. Аның шул бер ел буе көтү көтүе түләнмәгән калым исәбенә суктырылачак иде. Кияү кеше көтү көтмәгән очракта, калымның калган өлеше мал белән, кием-салым, алтын-көмеш, савыт-саба белән түләнәчәк иде.

Үзенең булачак беренче бичәсен Албуга берничә мәртәбә генә күреп калды. Башка елларны Елдырым бәк урдага төрле җыеннарга,

олы бәйрәмнәргә килгәндә үзе белән һәрвакыт балаларын да алып килә иде. Быел да ул Сары-су буена ялгыз башы гына килмәде. Тик быел Алтын-Бөртек атлы кызы кияүгә чыгарга тиеш булганга, анасы белән, угланнары белән аны үз урдасында калдырды. Албуганың кызны инде бер елга якын күргәне юк.

Үзенеке буласын алдан ук белеп торганга, ахрысы, беркайчан да ул Елдырым бәкнең Алтын-Бөртек кызын уйлап сагышланмады. Ак урдадагы үзенең үги сеңелләренә, апаларына яисә яшьтәш кыз туганнарына нинди мөнәсәбәттә булган булса, аңа да ул шундый ук дусларча, туганнарча мөнәсәбәттә булды. Буләккә дип алган йөз баш ат, кырык баш дөя белән, кием-салым, алтын-көмеш, савыт-саба белән, колалар, кияү-егетләр белән караңгы таңда төн ягына — Елдырым бәк кышлавы ягына кузгалып киткәч, ниһаять, ул аны исенә төшерде, күз алдына китерде. Ләкин ул аны үзе белгәнчә итеп түгел, нишләптер Сөенеч кебек гүзәл итеп, читләштерелгән итеп һәм Табылдык кебек якын, ягымлы итеп күз алдына китерде. Аннары ул аның турында бик озаклап, татлы итеп хыяллана да алмады. Матур уйларын кысрыклап, шундук аның күңелен башка төрле уйлар — яу турындагы, әнисе, туганнары, туган җир турындагы бетми дә онытылмый да торган сагышлы, куркыныч уйлар биләп алды.

Кояш чыгып, җил уянганчы алар шактый ара китеп өлгерделәр. Елдырым бәк кышлавы Байык буеннан ике көнлек ераклыкта булырга тиеш иде. Урта кичүгә сонгармыйча барып җитү өчен, менә бу ике көнлек юлны кимендә бер көнгә кыскартырга кирәк иде. Шуны истә тотып алар туктаусыз чабып бардылар, бер ат арыгач, янәшәдән барган икенче атка атландылар, икенче атлары да арый башлагач, өченче атка күчеп утырдылар. Шулай күчеп атлана-атлана алар көне буе юлда булдылар.

Кичкә таба, кояш җир астына кереп баер алдыннан, алар өч өйлек бер авылга килеп җиттеләр. Бу Елдырым бәкнең Күник атлы карасы булып чыкты. Туктап алар Елдырым бәк авылын сорадылар. Өстенә озын тун киеп, билен киң каеш белән буган, сирәк сакаллы, озын, чандыр Күник карт аларга юл өйрәтте. Көне буе атта чабып килгәнгә арыган, йончыган яшь угланнарның кемлеген, кая баруларын белгәч, Күник карт кинәт кабаланырга тотынды. Тиз генә өй ишеген ачып, ул карчыгына нидер эшләргә, нидер әзерләргә кушты. Шуннан соң, чакчак кына титаклап, якындагы өйләрнең әле берсенә, әле икенчесенә барып әйләнде. Күп тә үтмәде, әлеге өйләрдән томырылып балалар, хатыннар, ирләр чыкты. Барысы да, күрмәгәндәй исләре китеп, бай киемле, баштанаяк коралллы тагын угланга, аның яшь егетләренә карап тордылар. Күник карт юлчыларны ашап-эчеп, кунак булып китәргә кыстый башлады.

— Без күп. Туктап сездә кунак булсак, көтүегездә бер сарык калмас, өегездә бер бөртек ярма калмас, — диде Албуга, китәргә ашыгып.

— Безнең күңел киң, — диде Күник карт. — Үзебезнең бәкнең булачак киявенә мин бүген берне бирсәм, иртәгә ул миңа уны белән кайтарыр. Синнән каршылык булмаса, мин хәзер бөтен көтүемне пешереп алдыгызга куям!

— Безгә барып җитәргә кирәк.

— Ашыкма, улым. Изге юлга чыккансың. Узган төнне таң алдыннан киленем ир бала китерде. Җиремә аяк басып, учагыма йолык бирер, онытып исәнлегенә иттән авыз итми китсәң, каргармын, — диде Күник карт.

Эшләр болайга киткәч, тагын углан атыннан төшми булдыра алмады. Үзе белән ул Адайны, Тишек-Ташны гына алды. Алар ит исе, аш исе чыккан җылы өйгә килеп керделәр. Өйдә урта яшьләрдәге тагын бер хатын да ярым-шәрә ике-өч бала бар иде. Күник карт олы кунак-

ларны түргә, үзе янына утыртты. Башта ул аларны кымыз белән сыйлады, аннары казаннан алып кайнар ит куйды. Шул чакны өйгә тагын бер ир уртасы белән яшьрәк егет килеп керде. Алар икесе дә төсләре-битләре, буйлары-сыннары белән аталары Күник картка охшаганнар иде.

— Монысы минем өлкән углым Көчек. Шуның малае бар инде, — диде ата кеше, ир уртасына күрсәтеп.

— Улыгыз таза-сау үссен, — диде Албуга атаны котлап. — Анасына әйтегез: мин аның тизрәк савыгуын телим. Бәби күчтәнәче итеп миннән бер түтәрәм койрык мае бирерләр. Малаеңа миннән — яше тулмаган бер тай булыр.

— Бай бул, олуг тучи бәк! — диде бәхетле ата куанып.

— Менә монысы төпчек улым. Өйләнмәгән, — диде Күник яшь егетне күрсәтеп. — Бавыр! Атлан да, чап урдага! Кияү килә, каршы алыгыз, диген.

— Ярый, әти, — диде оялчан егет.

Тәгин углан нәрсә дә булса уйлап, әйтеп өлгергәнче ул өйдән чыгып та китте.

— Күрдеңме?! — диде Күник карт үзенең олы кунагына, күрәләтә мактану белән.— Баскан урынында торалмый. Бер-ике көннән яуга китә. Монысы да... Көчек тә китә. Быел менә ике улымны җибәрәм. Исән кайтырлармы, юкмы — бары да тәңре кулында...

— Бавыр углың ошады миңа. Минем аңа да берәр бүләк бирәсем килә. Ни бирим?

— Син аңа яхшы җәя бүләк итеп бир. Аның яу өчен яраклы яхшы җәясе юк,— диде Күник карт.

— Синең үзеңә, карчыгыңа ни бирим? — диде булачак кияү юмартланып.

— Миңа бер садак[1] тулы ук бирсәң, шул җиткән. Карчыгыма — түн, менә өлкән углым Көчеккә — бер яхшы ат бирерсең,— диде Күник карт тартынып тормыйча.

— Тагын? — диде тәгин углан.

— Менә... балаларга, — диде карт, өй эчендәге балаларга күрсәтеп.

— Мин аларга уенчыклар, таш савытлар, уенчык җәяләр бирермен. Боларның барысы да миннән кияү бүләге булыр. Минем өчен, минем ирләрем өчен изге теләктә торыгыз. Мин дә кыз куеныннан туры яуга китәм!

— Шулай мени? — диде Күник карт, аптырап, гаҗәпләнеп.

Өй эчендәгеләрнең барысы да, беренче күргән кебек, тәгин углан белән аның егетләренә күтәрелеп карадылар. Моңарчы берни эндәшмичә, башын иеп нидер эшләп булашкан урта яшьләрдәге хатын да, исе китеп башын калкытты.

— Үзең яшь, үзең кияү булып барасың... нинди яу ди ул сиңа? — диде ул кызганып. — Кызың җылап калыр инде, мескенкәем.

— Бу минем икенче хатыным, — диде Күник карт. — Беренчесен моннан ун ел элек җирләдем.

— Берни эшләп булмый — боерык! Каган боерыгы! — диде тәгин углан, хатынга җавап итеп.

— Боерык булмагае, әлләни булсын — син кияү ич! — диде хатын тынычлана алмыйча. — Бәк кияве була торып!

— Ул үзе уң кул тучи бәк тәгин углан! — диде Көчек, үги анасына кычкырып аңлатып.

Хатын бераз гына чукрак иде ахрысы — Көчекнең ничек кычкыруыннан Албуга шундый фикергә килде.

— Кит әле, ташка язмаганны! — диде чукрак хатын ышанасы килмичә.

[1] Садак — ук савыты.

— Язган инде, язган, анасы,— диде Күник карт өлкән улгын яклап.— Ни күрәсебез барысы да маңгайга язып куелган. Без аны укый гына белмибез. Ике улым, өч энем яуда үлеп калды. Быел менә соңгыларын озаттым. Ике улымны да. Сезне дә кушсам, өч улым, биш улым була. Бишектәге онытымнан башка беркемем калмады. Исән-сау кайтыгыз, улларым.

— Шулай булсын, ата! — диде Албуга, урыныннан торып.

Өч өйлек авылның бөтен халкы аларны озатып калды. Көчек үзе теләп Елдырым бәк авылына кадәр кылавыз булып барырга булды.

## IX

Елдырым бәк урдасы Күник карт авылыннан әллә ни еракта түгел иде. Урдага барып җитәргә бер-ике чакрым кала юлчыларны Бавыр көтеп алды.

— Хәбәрне әйттем, сезгә шушыннан ары бармаска кушылды,— диде ул кияү буласы кешегә.

Албуга үзенең алаена шунда туктап авыл корырга боерды. Туктау белән берәүләр төргәкле киезләрен сүтеп җиңел өй торгыза башладылар, икенче берәүләр атлар белән булашты. Туктаусыз чабып килгән атлар бик өшәнгәннәр иде. Аларны тиз генә утларга җибәрмәделәр, — кисәк кар ашап эчләренә салкын төшмәсен, авырмасыннар өчен, өсләренә киез әчмәкләр каплап, шактый озак суытып тордылар. Ике-өч сәгать ач тотып суыткач кына аларны, кешәнләп, аяк астына тибенгә җибәрделәр. Атлар ашыгып куе үлән катыш кар кимерделәр — суы да, азыгы да бергә булды.

Йола буенча кыз ыруы җире кияү өчен, аның юлдашлары өчен «дошман» җир исәпләнелә иде. «Дошманнарга» үзләренең «яу» белән килүләрен сиздермәскә тырышып, өйләрдә учаклар тергезелмәде, кычкырып сөйләшү, шакылдау, тавышлану шулай ук тыелды.

Кияү бүген кыз янына урлап барачак иде. Туктау белән ул салкын өйдә юл киемнәрен алыштырды, аннан соң үз егетләренә бүләкләр өләште. Елдырым бәк кызына хәбәр алып баргач, далада үзен каршы алган Бавырга кияү беренче бүләкне бирде. Бер савыт ук белән яхшы җәя күреп Бавыр куанычыннан телсез-өнсез калды. Юка сөякләр белән ныгытылган, үгез сеңере, балык җилеме белән катырылган алыплар җәясен ул соңгы көннәрендә инде төшләрендә күрә башлаган иде.

Кыз янына барганда Албуга үзе белән егетләрнең бары уникесен генә — өйләнмәгәннәрен генә алды. Монда авылда калачак егетләргә, ирләргә баш итеп Тишек-Ташны билгеләде. Атларны, өйләрне бүген төнлә бик уяу сакларга кирәк булачак иде. Ник дигәндә, «дошман» яшьләре бүген аларга каршы теләсә нинди этлек ясарга мөмкиннәр.

Елдырым бәк урдасыннан бер чакрым чамасы читтә, бар ягы да ачык дала уртасында ялгыз өй корып куелган иде. Әлерәк кенә — кияү килере турында хәбәр алынгач кына куйганнар. Кияүне, кияү-егетләрне Бавыр туп-туры менә шул өйгә алып барды. Еракта өй күренү белән, кылавыз кире борылды. Ул кияү егет түгел иде, шунлыктан анда барырга ярамый. Кире озатканда Албуга аңа тагын ук тулы бер садак бирде.

Бавырдан аерылгач, як-ягына карана-карана ул үзе генә китте. Кияү-егетләр, кияүдән бераз калышып, шулай ук як-якларына каранып, әкрен генә арттан бардылар. Бу тирәдә кияү кешегә аеруча сак, уяу булырга кирәк иде.

Албуга Бавырдан аерылып бер йөз адым чамасы да китәргә өлгермәде, аты кинәт өркеп читкә сикерде. Албуга, иярennән ычкынып, чакчак кына җиргә мәтәлеп төшмәде — ярый әле аяклары өзәңгегә эләгеп

калды. Ияpдән инде егылып төштем дигәндә генә ул җир өстендә ниндидер карачкы күреп калды. Карачкы, бик җитез ыргылып, атның тезгенен тотып алды. Кияү, иярenә кире җайлап утырды да, бар көченә тезгенне тартты. Ләкин карачкы да ычкындырырга уйламады. Албуга аңа камчы белән сыдырмакчы булган иде, шулай да вакытында тыелып калды. Ачуын йотып ул бил каешындагы янчыгына үрелде. Аннан ефәк чүпрәккә төрелгән ниндидер каты нәрсә — таштанмы, алтыннанмы ясалган бизәнү әйбере алып, карачкыга:

— Мә, ал да шуны, юлыңда бул! — диде.

Атның тезгенен тотып алган карачкы көлүгә охшаш ниндидер өн чыгарып читкә тайпылды. Ул китү белән Албуга артыннан аның егетләре килеп җиттеләр. «Ярый әле, җиңел котылдым!» дип уйлады яшь егет. Ләкин шул ук мәлдә, каяндыр аяк астыннан дәррәү кубып, бер төркем кызлар килеп чыкты. Казлар сыман кыйгаклап кычкырган яшь кызлар, чыр-чу килеп, көлешеп, шаулашып, кияүне иярдән үк тартып төшерделәр — шаярып, әрсезләнеп аның беләгенә асылындылар, бил каешына тотындылар, бүләкләр салган янчыгын чишмәкче булып азапландылар. Кызларга әсир төшкән кияүне кияү-егетләр араламакчы булып карады, ләкин кызлар күбрәк, шаянрак, чаярак иде — кияү-егетләрне дә алар берәм-берәм атларыннан өстерәп төшерделәр. Атларны исә камчы белән сыдырып, һай-һулап далага кудылар.

Авылдан, урдадан читтәге ялгыз өйне, ата-анага «әйтмичә», «качыппосып», яшь кызлар, яшь хатыннар корган иде. Киезләрне, кирәгәләрне, өй өчен кирәк булган барлык нәрсәне алар үзләре күтәреп алып килгәннәр. Хәзер алар менә шуның өчен кияүдән бүләк дауладылар. Билендәге авыр янчыгын кияү кулына алды. Кызларның берсенә ул беләзек, икенчеләренә муенса, каптырма ише нәрсәләр бирде. Бүләген биргәндә кызларның әле кулына, әле беләгенә орынып алды, кайберсен шаяртып кочып алды, кайберсенең тун чабуын күтәрде. Кызларның шаярулары-на кияү үпкәләмәгән кебек, аның шулай кул озайтуына да кызлар үпкә белдермәделәр. Киресенчә, кияүдән бүләк алган, тәненә кияү кулы тиеп киткән кызлар, ышану буенча, быел ук кияүгә — һичшиксез, бай кияүгә! — чыгачаклар иде.

Егетләрдән бүләк сорамадылар. Аларга бары икеле-микеле шаян сүзләр генә әйттеләр. Кияүгә дә шундый ук икеле-микеле сүзләр әйттеләр, четрекле сораулар бирделәр. Үзенең бер дә төшеп калганнардан түгел икәнлеген күрсәтәсе килсә, кияү теләсә нинди сорауга оста, тапкыр җаваплар кайтарырга тиеш иде. Албуга баштарак чак кына каушап калды. Аның йомшаклыгын шундук сизеп алдылар һәм шаян кызлар, яшь хатыннар төрле яктан:

— Ояла, ояла!

— Ир түгелдер бу, кыздыр!

— Каяле, кая! — дип кычкырыштылар.

Бу кызларның, хатыннарның барысы да Алтын-Бөртекнең апалары, сеңелләре һәм җиңгиләре иде. Элеккерәк елларда күргән чакларда алар бер дә алай шаян-усал түгел кебекләр иде. Баксаң, әнә нинди икән алар!

Кызлар җитәкләп, көлеп-шаярып, кияүне ялгыз өйгә алып килделәр, ишекне ачтылар да, барысы да як-якка тайпылдылар. Өй эче караңгы иде. Албуга, керергәме-кермәскәме диебрәк торганда, кемдер шунда арттан төртеп җибәрде. Кияү, кыюланып, серле караңгылыкка атлады. Ләкин беренче адымыннан ук ул аяк астындагы нәрсәгәдер абынып китте, чайкалып алды. Егылмас өчен ирексездән ишек яңагына тотынды.

— Ух, үләм! — диде аяк астындагы кемдер бик каты ыңгырашып.

Тиз генә иелеп кияү аны күтәреп торгызмакчы булды.

— Ни булды? — диде ул.

— Үләм! Башыма таш төште! — диде идәндә, ишек төбендә яткан ниндидер хатын-кыз.

— Нинди таш?! — диде кияү шаккатып.

Якында гына тыңлап торган кызлар, яшь хатыннар бөтен даланы яңгыратып көлеп җибәрде. Шул ук мәлдә «үләргә яткан» хатын-кыз ике куллап кияүнең тун чабуыннан эләктереп алды.

— Бүләк! Бүләгеңне бир! — диде ул усал ысылдап, тешләрен шыгырдатып.

«Тагын «бүләк!» дип уйлады кияү, шундук янчыгына тотынып.

— Саранланма, кыз янына җиңел генә керә алмассың!

Албуга бүләк биреп түргә узды. Ул арада өйгә кызлар кереп тулдылар, учактагы утны дөрләтеп җибәрделәр. Өй эче яктырып китте. Идәнгә ак киез җәелгән, киез өстенә, түргә биек агач ятак куелган иде. Ятак өстендә, кабартылган ястык, мендәрләр арасында, яшел ефәк бөркәнчек бөркәнеп, кемдер тып-тын гына утырып тора иде. «Алтын-Бөртек!» дип уйлады кияү, әледән-әле шул якка каранып. Аның тизрәк кызның бөркәнчеген ачасы, кәләшенең тулган айдай сылу йөзенә карап сокланасы килде. Ятак янына сакка баскан кызлар аны якын да җибәрмәделәр.

— Уф! Үтерәсез инде сез мине, кызлар! — дигән булды кияү зарланып.

Кызлар аны үтермәделәр, киресенчә, үлмәсен өчен аш-су әзерли башладылар — шундук киез уртасына ашъяулык җәйделәр, күп итеп табак-савыт китереп куйдылар. Аулак өйдә хәзер урыйн туй башланырга тиеш иде.

Кияү өчен түргә, ятак янына калку, йомшак урын җәйланды. Кияү утырасы урынның сул ягына, киезгә тезелешеп кызлар утырды, уң ягына аның егетләре урнашты. Үзара такмаклар, тапкыр сүзләр әйтешеп яшьләр бер-берсен күзәттеләр, көлделәр, шаярдылар. Кияү ишектән кергәндә бусагада сузылып яткан хатын-кыз яшьләр арасында иң өлкәне иде. Табын әзерләү, утырышу — барысы да аның җитәкчелегендә, аның күзәтчелегендә башкарылды.

Табын әзерләнеп беткәч, гел елмаеп торган кысык күзле, ачык, ягымлы йөзле бу өлкән хатын Албуга янына килде. Бу вакытта кияү, үзе өчен җәйланган урынга да утыра алмыйча, кәләшенең йөзен дә күрә алмыйча, бер читтәрәк таптанып тора иде.

— Кияү! — диде хатын, Албуганың кулыннан тотып алып.

Барысы да тынып, түр якка — кияү белән әлеге җиңги ягына карадылар.

— Ерак юл килеп син бик ачыккансың — эчең эчкә ябышкан, хәлсезлектән әнә кулларың калтырый, — диде җиңги, кысык күзләре белән генә елмаеп.

— Минем кулым хәлсезлектән калтырамый, җиңги. Минем йөрәгем атлыгып тибә — шуңа калтырыйдыр ул,— диде кияү, оста телләнеп.

— Шулаен шулайдыр да, табындагы азыкларга ач бүре кебек карыйсың, кияү.

— Сүзең хак, җиңги: мин ач бүре кебек сусадым, зарыктым. Бер кашык суга салып йотардай булдым Гүзәл-Бөртегемне!

Шулай дип әйтү белән ул җиңгинең сузылган ак, матур кулына алтын алкалар салды. Ул шулай ук ятак янында «сакта» торган кызларга да бүләкләр бирде дә, чак-чак кына каушап, кызарып, үзенең Алтын-Бөртегенә якынайды. Җиңги белән кызлар читкәрәк киттеләр.

— Яшь танамны бер ел күргәнем юк, байталымны бер ел тотканым юк! Аккошымны кемнәр ябып куйган? Ватам-кырам читлекләрен — чык иреккә, ташлан минем кочагыма, тутый кошым! — дип сөйләнә-сөйләнә кияү калтыранган куллары белән ефәк бөркәнчекне ачып җибәрде.

Ачып җибәрде һәм... чак-чак кына артына авып китмәде. Ефәк бөркәнчек астында аның «тутый кошы», «аккошы», Гүзәл-Бөртеге түгел, ә йөзен җыерчык баскан, тешләре төшеп, ияге шөшләдәй очлаеп калган бер кортка утыра иде.

Шаян җиңги кияүне шундук арттан кочып алды, аны юри шап иттереп артына утыртты. Яшь кызлар, киресенчә, сикереп торып аны аягына бастырдылар. Кияү, ятак ягына борылып карарга да җирәнеп, якжакка сүзсез генә күз йөртеп чыкты. Әллә шунда берәр җирдә посып торамы соң аның ярәшелгән кызы?

— Эзлә, эзлә! — дип кычкырдылар усал кызлар көлә-көлә.

Бөтен өй эче ду килеп торды. Кызлар, егетләр, бар нәрсәләрен онытып, бөгелә-сыгыла, эчләрен тота-тота көлделәр. Ятак өстендә тыйнак кына утырып торган тешсез кортка да көткелдәде. Яшь чакларын искә төшереп көлдеме ул, әллә соң башкаларга күңелле булган кебек, аңа да бу аулак өйдә бик күңелле иде микән?

## X

Албуга, түгәрәк өйне бер-ике мәртәбә әйләнеп чыкты да, башкалар кебек үк көлә-көлә түргә, калку урынга килеп утырды. Алтын-Бөртек әле монда булмаска тиеш иде. Кинәт ул шуны төшенеп алды. Үзенең җиңел генә алдануы өчен аңа бик уңайсыз булып китте. Ләкин шул чаклы яшь, чибәр кызлар янында аңа һич тә күңелсез түгел иде.

Ашаганда шау-шу басыла төште. Кызлар «урлап» өйләреннән төрле тәмле азыклар, эчемлекләр — ит, каймак, эремчек, көлчә, кымызише нәрсәләр алып килгәннәр иде. Егетләр чыннан да ач бүреләр кебек ашадылар — алларына куйган бар нәрсәне ялт иттереп кенә торды. Кызлар үзләре бөтенләй диярлек ашамады — бары кияү белән егетләрне генә сыйларга тырыштылар. Шулай бераз тамак ялгап алгач, барысы да дәррәү кубып, шаулашып өйдән чыктылар. Албуга учак янында утырып, берүзе өйдә калды.

Кызлар, Алтын-Бөртекне «урларга» дип, Елдырым бәк урдасына киттеләр. Кызны «урлау» кыен булмады. Ата-анасына «сиздермичә» күзен бәйләп, баштанаяк бөркәндереп аны туп-туры бәкнең биек ак өеннән алып чыктылар да капка каравылы яныннан үттеләр һәм, «кача-кача», «курка-курка», ачык даладагы аулак өйгә таба йөгерделәр. Өйгә килеп җитәрәк кызларга кияү егетләре «һөҗүм итте». Алтын-Бөртек өчен ике арада кыска гына «яу» булып алды. Кызлар җиңелде, кәләшне егетләр әсир төшерделәр. Кечкенә дүрткел киезгә утыртып, киезнең дүрт ягыннан күтәреп тоткан хәлдә, Елдырым бәк кызы Алтын-Бөртекне егетләр үзләренең бәкләренә алып килделәр. Ялгыз өйдәге кияү янына кызны шулай кул очларына күтәргән килеш алып керделәр. Алып кереп, аның каршысына, йомшак киезгә утырттылар да, шундук кире чыгып та киттеләр.

Аулак өй янында яңадан күңелле шау-шу башланды. Төне буе далада яшьләрнең шат тавышлары, җырлары, такмазалары ишетелеп торды.

Кызга кияү үзе алып килгән бүләкләрен бирде. Кыз исә аны моннан бер ел элек чит ил сатучыларыннан алып калган һәм бары шушы көн өчен генә сакланып тотылган ят җимешләр белән, ит, кымыз, каймак белән сыйлады.

Алтын-Бөртек бар нәрсәгә исе китеп карый торган зур күзле, ак битле, таза, буйчан бер кыз иде. Күрешми торган бер ел арасында ул тагын да тулыланып, матурланып киткән. Кияү аның кара кашларына, ак кулларына тартынып кына карады. Кызның бар җире килешле,

ягымлы һәм тансык иде. Юка йон киемнәреннән татлы исләр килә. Тик шулай да кияү кешегә бу таза гәүдәле, эре сөякле кыз янында бераз гына кыен, уңайсыз булды. Бик якын утырса да, ул аңа ничектер чит тоелды. Анда чин кызы Сөенечтәге кебек бер күрүдә бөтен тәнгә ут кабыза торган эчке дәрт тә, ялкын да юк иде кебек.

Аулак өйдә беренче очрашу, танышу бик кыска булды. Сиздермичә генә ишек ярыгыннан күзәтеп торган җиңги, яшьләрнең үзара сөйләшер сүзләре беткәч тә, кояштай балкып, җилләнеп өй эченә килеп тә керде. Килеп керде дә, әле кияүгә, әле кәләшкә иплән кенә сүз кушкан булды,— ашарга-эчәргә кыстаган булды. Мондый эштә тәҗрибәле кеше буларак, яшьләрнең сүзсез-хәрәкәтсез утырып, бер-берсенә карата суынуларына ул юл куя алмый иде, билгеле. Чыннан да, җиңгәсе кереп уңайсыз тынлыкны бозгач та, Алтын-Бөртек җанланып китте.

— Кайтыйк инде, эти-әни югалтып ятадыр,— диде ул җиңгәсенә эндәшеп.

— Кайтырбыз. Таң атканчы утырмассың монда чит кеше янында,— дигән булды җиңги дә җиңелчә генә, артык хафаланмыйча гына.

— Нинди кайту ди ул! Кайтмагыз әле! — диде Албуга, кызның кулыннан тотып.

Кыз, йомшак кына каршылык күрсәтеп, кулын тартып алды, аягына басты. Кияү дә торды, кызның юлына аркылы төшмәкче булды. Җиңги кеше, икесенең дә арасына керде дә, бик тә ягымлы итеп, күңелләргә төшеп:

— Бүгенгә җитеп торыр! — диде.

Кызлар Алтын-Бөртекне атасы өенә алып кайтып киттеләр. Кысык күзләре гел елмаеп торган ягымлы җиңги, табак-савыт җыештырган булып, өйдә калды. Сиздермичә генә ул кияү-балакайны күзәтте. Ниндирәк ул? Кызны яратамы, яратырмы? Холкы нинди — артык җебегән яисә, киресенчә, усал, холыксыз түгелме?

Албуга аның үзен күзәтүен бөтенләй сизмәде. Ул башын иеп сүзсез генә утырып торды. Аның бик нык сөмсере коелган иде.

Хәйләкәр җиңги, табак-савытларын җыештырды да, китәргә әзерләнә башлады.

— Тыныч йокы, тәмле төш, кияү-балакай! — диде ул ярым шаяртып.

Бары шунда гына кияү-балакайның йокысы ачылып китте.

— Туктале! — диде ул, җиңгинең кулыннан тотып алып. — Ни... ничек соң? Нишләп болай булды әле бу?

— Ни мени? — диде җиңги көлеп.— Башта ук шулай диләр аны! Җиңгәң белән бер сердә булсаң, уңмый калмассың.

Бүләкләр тутырылган зур гына капчыгыннан Албуга хатын-кыз туны тартып чыгарды. Кеш тиресеннән тегелгән юка, җиңел тунны ул җиңгинең иңбашына салды.

«Качып-посып» кына алар Елдырым бәк урдасына киттеләр. Анда, бәкнең зур, биек өендә, ишектән кергәч тә уң якта, калын киез белән бүлеп куелган бүлмәдә кияү белән кыз өчен күптән инде урын җәелгән иде. Ят өйнең бусагасын атлап кергәндә ишек сакчысы кортка «йоклап» калды, ләкин кияү аның янына үзенең бүләген куеп калдырды. Өй эчендә ата-ана шулай ук берни белми «йоклап» ятты.

Кияүне таң атканчы уяттылар. Ата-ана күргәнче, аны тизрәк өйдән чыгарып җибәрделәр дә даладагы аулак өенә озатып куйдылар. Боларның барысын да шул ук җиңги башкарды.

Таң атып көн тугач Елдырым бәк янына кияү ягыннан кодалар китте. Алар арасында Адай да бар иде. Кодалар белән Елдырым бәк, Алтын-Бөртекнең әнисе калым турында, бүләкләр турында сөйләштеләр. Шунда ук туй турында да сүз булды. Кияүнең, каган боерыгы буенча яуга баруын истә тотып, туйны киләсе елга кичектерергә дип килеште-

ләр. Ашагач-эчкәч, ата белән анага кияү бүләкләрен тапшыргач кодалар кайтып киттеләр.

Төштән соң Елдырым бәк яшьләр өчен ат чабышлары, төрле уеннар, узышлар ясады. Яшьләр күбесенчә көч сынаштылар — ук аттылар, сөңге ыргыттылар. Ярыш башлыча ике ыру яшьләре — Куяннар белән Аланнар-күкәлләр арасында барды. Албуганың егетләре барлык төр узышта җиңеп чыктылар һәм бәк билгеләгән бүләкләрнең барысы да аларга тиде. Аланнарның кызлары гына түгел, Елдырым бәк үзе, аның батыр ирләре дә мондый нәрсәгә таң калдылар.

— Әллә алдан юри килешеп куйдыгызмы? — диде Елдырым бәк, үз яшьләрен чакыртып.

— Бернинди килешү булмады, бәк.

— Әллә нинди алар! Аларның уклары икенче төрледер, — диделәр Аланнар, кунак егетләрен хурламакчы булып.

Ләкин кунакларны ачыктан-ачык хурларга беркемнең дә теле бармады. Кияүнең егетләре, ирләре чыннан да «әллә ниндиләр» иде: аларның аткан бер уклары, ыргыткан бер сөңгеләре карачкыга тия торды; алар барысы да кыюлар, житезләр, өлгерләр. Елдырым бәк моңа сөенде дә, бераз гына көенде дә. Киявенең оста, булдыклы булуын ул бөтен күңеле белән тойды. Ләкин яшь киявенең — тучи бәкнең осталыгы, булдыклылыгы янында үзенең кайдадыр артта калуын аңлау, тою аңа, әлбәттә, күңелсез иде.

Кич Елдырым бәк кодалар өчен аш-су ясады. Кияү, боегып, зарыгып, өендә ялгыз утырып торды. Аңа аннан беркая чыгарга ярамый иде. Бары тик караңгы төшкәч кенә аның янына яңадан кызлар килде, жинги килде. Шулай ук үзләре далада корган авылдан кияү егетләр килеп житте. Аулак өйдә кичәгечә жыр-бию, уен-көлке башланып китте. Төн уртасында жинги яшь кияүне тагын бәк өенә, кыз янына алып китте.

Икенче көнне иртән кияүне кыз яныннан чыгып килгәндә «угрылыкта тоттылар». Шундук аны далага, Алтын-Бөртек атасының малларын көтәргә жибәрделәр. Өченче көнне ул Елдырым бәкнең болындай өен жылыту өчен, аркасына капчык асып, далада коры тизәк жыеп йөрде. Шуннан соң учакка утын, чыбык-чабык ташыды. Өйдә бәк белән, бикә белән очрашканда, ничек тә аларның күзенә карамаска, буйсыну белдереп, баш иеп, бил бөгеп торырга тырышты. Иң ахырда ул, алтын таста су жылытып, бәкнең аякларын юарга булышты.

Шулай итеп, бабай-әби йортында кияү, йола кушканча эшләргә тиеш кара эшләрнең барысын да эшләп чыкты. Шуннан соң кодалар белән бәк арасында яңадан сөйләшү булды. Елдырым бәк яуга китүче киявенә, кызының бирнәсе итеп, тулысынча коралланган, өчәр аты, кушчысы булган йөз илле кешелек алай бирергә булды.

— Кызым үз өемдә калыр,— диде бәк.— Калымның калган өлешен түләп бетергәч, яудан исән-сау кайтса, үзенә алып китәр. Яудан кайтмаса...

— Алтын-Бөртек үземә булыр! — диде Адай ашыгып һәм, кирәкмәгән жирдә кысылуын шәйләп, үзе тагын кып-кызыл булды.

Елдырым бәк озын буйлы, киң күкрәкле алып бер ир иде. Аның янында Адай әле бала гына. Шулай да «бала»ның сүзен беркем дә уенга алмады. Елдырым бәк яшь угланга өстән, югарыдан иелеп бер карады да, зур кулына кысып тотып аңа алтын кәсә белән буза бирде.

— Айак эчәбезмени, кода? — диде ул аңа.

— Эчәбез, кода бабай! — диде Адай батыраеп.

## XI

Кияү иртәгә китә дигән кичне Алтын-Бөртекне кызлар даладагы ялгыз өйгә алып килделәр. Беренче өй янына икенчесе — биегрәк, иркен-

рәк өй корылды. «Авылдан» кияү-егетләр дә килде. Иркен өйдә кызлар, егетләр ашадылар-эчтеләр, төрле уеннар уйнадылар. Бүген инде алар арасында җиңги дә, башка хатыннар да юк иде. Бүген яшьләргә тулы ирек бирелде. Борынгы йола шулай куша. Кияү ыруы белән кыз ыруы, яшьләрнең яшерен кавышуы аша, татын да ныграк дуслашырга, туганлашырга тиеш иде. Аннары, кияүнең кыз ыруындагы бер кызны кочарга хакы булгач, ул аны кочкач, үзенә алгач, аның шулай ук башка кызларны да кочарга хакы бар иде. Шулай ук кияү егетләренең дә, кияү белән бер ыру кешеләре буларак, кыз ыруындагы кызларны кочарга тулы хаклары бар иде. Шуның өчен дә алар кияү-егетләр дип аталалар да. Алар тәгин угланның мәңгелек сакчылары, якыннары һәм туганнары иде. Алар аның белән бер табактан бер үк азыкны ашыйлар, бер үк эчемлекне эчәләр иде. Шуның өчен яуда алар аны уктан-сөңгедән саклыйлар, кышкы суыкта — салкыннан, җәйге кояшта — эсседән саклыйлар. Ләкин хуҗалары алай-болай үлеп китсә, аның артыннан шулай ук тере килеш җир астына да керәләр иде. Менә шундый нык туганлык белән туган иде алар үзара.

Ул төнне егетләр, кызлар — зуррак өйдә, кыз белән кияү — кечерәк өйдә кундылар. Төн урталары узгач, кайдадыр якында гына ачы итеп сызгырган тавыш ишетеп, яшь кияү кинәт урыныннан сикереп торды. Астындагы мамык түшәге йомшак, өстендәге юрганы җылы, янындагы яшь кәләше кайнар иде. Менә шулай рәхәтләнеп йоклап ятканда, көнләшкән, үчлекләшкән сыман, кемнеңдер сызгырып җибәрүен аңлап та, аңлатып та булмый иде.

Ул сикереп торды. Бөтен тәне белән калтыранып, нишләргә, кая барырга белмичә, урынында басып калды. Ул арада аның яшь хатыны да уянды. Ул да, аны-моны аңламыйча сикереп торды. Кайнар тән җылысы, назлану сиздергән йокылы тавыш белән куркып:

— Ни булды? Ә? — диде.

Караңгыда ул үзенең яшь ирен күрә алмады. Ул аны тойды гына — җылысыннан, тәненнән килгән таныш, якын истән тойды. Баскан килеш ул аны кочаклап алды. Кайнар, тыгыз беләкләре белән, калтыранган тәне, дымлы озын чәчләре белән ул аңа елан кебек сарылды.

— Ник тордың? — диде яшь хатын үпкәләп.

Аның шулай үз итеп, якын итеп, куркып-каушап әйтелгән сүзләре аша йокылы-уяулы иргә ярату һәм дәрт тойгысы бирелде. Бөтен күңеле белән ул аның үзенеке булуын төшенде. Ике арада ирексез омтылыш, бердәмлек, туганлык тойгысы тудырган куәтле бер көч барлыкка килде. Ләкин тулы шатлык-куанычны бозып, шул ук мәлдә яшь йөрәккә агу булып «яу» дигән куркыныч уй тамды. «Байлык эзләп, бәхет, дан эзләп нигә җир читенә китәргә соң, тәңрем?» диде яшь ир гаҗәпләнеп. Шушы үзе түгелмени байлык, бәхет?!

Биленә, муенына аркан булып уралган чиксез бәхет, шашкын бәхет аны котылгысыз ирексезләп аска, төпсез бушлыкка тартты. Шул чакны яңадан ачы итеп сызгырган тавыш ишетелеп китте. Тышта, ишек артында кансыз-шәфкатьсез чынбарлыктан усал, көнчел тавыш яңгырады. Бу юлы икесе дә дерт итеп сискәнеп киттеләр — кемдер арттан, әйтерсең, шәрә кайнар тәннәрен камчы белән көйдереп алды. Дәрт, омтылыш, сихри көч сүнде, бәхет-байлык күз алдында чәлпәрәмә килде. Әйе, аны, күрәсең, чыннан да җир читеннән эзләп табарга кирәк иде.

— Миңа сызгыралар,— диде кияү, телгә килеп.

— Китәргәме?! Китәсеңмени? Китмә! — диде яшь хатын өзгәләнеп.

— Китмичә булмый.

— Китмә! Мин теләмим! Үзләренә булсын яулары!

Яшь хатын тавышында күз яше сизелде. Ирләрне яуга озатканда күз яше чыгарырга ярамаганлыгын ул белә иде. Үз-үзен тыеларга мәҗбүр итте.

— Мин кайтуга... икәү булып торыгыз,— диде яшь ир.

— Кал! Китмә! — диде Алтын-Бөртек үтенеп, таләп итеп.

Сызгыру тавышы өченче тапкыр яңгырады: моннан соң да өйдә калырга ярамаганлыгын аңлап, кияү киенә башлады. Ул арада Алтын-Бөртек үз киемнәрен актарып аннан бөти тартып чыгарды. Йомшак күн белән тышланган, нечкә каешка тагылган өчпочмакны ул иренең муенына такты.

— Бу безнең Аланнарның абасы,— диде ул.— Аны минем дәү әнинең этисе тагып йөргән — яудан исән кайткан, әнинең этисе таккан — исән кайткан. Минем эти тагып йөртте — ул гел җиңеп кайтты. Сиңа дип әни бирде. Ул сине үлемнән саклар. Югалтма.

— Югалтмам,— диде Албуга.

Алтын-Бөртек аны ишек төбенә чаклы озата килде. Баштарак ул аның белән шулай җиңелчә генә саубуллашып калырга уйлаган иде бугай. Ләкин иренең чынлап торып кулдан ычкынуын, китүен, ерагая баруын күреп, аның кинәт башына суккандай булды. Ул яңадан аның муенына сарылды.

— Китмә! — диде ул, хәлсез бер өметсезлек белән.

Яшь ир күндәм генә туктап калды. Аерылышу аның үзенә дә әйтеп бетергесез авыр иде. Яшь хатын тавышсыз гына сулкылдап еларга тотынды.

— Калдырма! Үзең белән алып бар,— диде ул иң ахырда.

— Киен, күтәрмен,— диде кияү.

Алтын-Бөртек ашыгып киенергә тотынды. Ул әллә чыннан да ире белән яуга китәргә җыена идеме, әллә өенә, урдага кайтырга ашыга идеме — Албуга моны аңлый алмады. Ул аны көтеп торган арада тышта кемдер ишек киезен кайтарып карады.

— Исәннәрме? Тордыгызмы? Тиз булыгыз! — диде тынгысыз җиңги, яшьләрне ашыктырып.

Өйдән алар икәүләп чыктылар. Чыгу белән, тыннарны куырып, кышкы салкын өтеп алды. Кайнар каннар суына төште, тиле уйлар сүрелә төште.

Көн әле тумаган, шулай да инде җирнең өсте агара, ачыклана башлаган иде. Кияү егетләр дә, кызлар да — барысы да инде торганнар, киенешеп тышта җыелганнар иде. Беркадәр читтәрәк иярле атлар да, ят ирләр, хатын-кызлар күренгәли.

— Ерак юлга чыгар алдыннан ашап алыгыз,— диде җиңги.

Култыклап — житәкләп диярлек ул аларны якындагы икенче өйгә алып китте. Анда инде яшьләргә табын әзерләнгән, кайнар аш куелган иде. Итне күп итеп бәк авылында пешереп алып килгәннәр.

Кияү белән кәләшне парлап түргә утырттылар. Егетләр — кияү ягына, кызлар кәләш ягына тезелешеп утырды. Иртәнге аш вакытында бернинди тавыш, шау-шу ишетелмәде. Беркемнең дә әле бу вакыттан ашыйсы да килми иде. Җиңги белән бер-ике өлкән хатын яшьләрне, аеруча егетләрне, туктаусыз кыстап тордылар. «Көне буена житәрлек ашагыз, ике көнлек итеп ашагыз»,— диделәр.

Алар тусып чыгуга, өй тирәсенә шактый күп кеше җыелып өлгергән иде. Боларның барысы да Алтын-Бөртекнең туганнары, якыннары иде. Арада аның этисе белән әнисе дә бар, тик аларга йола буенча, кияү күзенә күренергә ярамый иде, шунлыктан алар арттарак, башкалар арасындарак качып тордылар.

Беренче булып атка Албуга атланды, аннан бераз калышып егетләр атланды. Соңгы сүзләр, саубуллашу сүзләре әйтелде, күз төбенә килгән яшьләр сөртелде. Кияү яшь бичәсенең кайнар кулын соңгы кат кысты, тезгенне кагып җибәрде. Ул кузгалып кына киткән иде, Алтын-Бөртек аны тун чабуыннан чытырдатып тотып, бар көченә тарта башлады — Албуга атны тыя төште.

— Калдырма! Китмә! — диде яшь хатын буынсыз булып.
Шундук җиңги белән өлкән хатыннар килеп җитте. Үзен-үзе белештермәгән Алтын-Бөртекне алар кочаклап, як-ягыннан култыклап алдылар. Яшь бичә, башын артка ташлап, авызын ачып, тавышсыз гына еларга тотынды.
— Үз башына булгыры! — диде хатыннарның берсе ачуланып, артык шауламыйча гына.
Кияү, иярennән яртылаш иелеп, ике кулын бичәсенә сузды. Алтын-Бөртек шундук аның кулына тотынды. Арттан аңа хатыннар булышты, һәм ул күз ачып йомган арада ат сыртына — иренең алдына менеп тә утырды.
— Бераз җир барсын әйдә. Тынычлангач төшерерсең,— диде җиңги.
Алтын-Бөртектән күрмәкче дигәндәй, башка кызлар да ярдәге егетләр янына менеп кунакладылар. Яшьләр, ниһаять, кузгалышып китте. Бераз калышып аларны Елдырым бәк кешеләре озата бардылар.
Бер-ике чакрым чамасы баргач, төшәргә Алтын-Бөртек үзе сорады. Атлар туктады. Алтын-Бөртек тә, кызлар да барысы да җиргә коелдылар. Кияү белән егетләр яңадан кузгалып киткәч, ачуланган булып алар арттан таш, балчык бәреп калдылар, төрле мыскыл сүзләре әйткән булдылар. Ләкин, йоланы онытып, кайберләре чамадан тыш кычкырып еләргә тотынды, кайберләре исә күз яшьләрен сөртте.
Китте яшьләр. Яуга киттеләр. Үзләре белән, әйтерсең, өйләрдәге учак җылыларын, күңелдәге барлык татлы тойгыларны алып киттеләр. Төнге караңгыдан арынып бетә алмаган туган җир — туң үзәннәр, бозлы сулар, тәбәнәк калкулыклар мескенләнеп, ятимләнеп калган сыман булды.

## XII

Озакламый арттан Албуганың йөз кешелек алае куып җитте. Бераз баргач, алдан килешенгән урында, Елдырым бәкнең бирнәгә дип биргән йөз илле кешелек алае кушылды. Алар арасында өлгер егет Бавыр белән абыйсы Көчек тә бар иде.
Аланнар белән очрашкач, тәгин углан үз алаена туктарга боерды. Туктагач ул Аланнарның йөзбашы, унбашлары, алыплары белән танышты. Аларга ул үзенең котлау сүзләрен әйтте, аннары боерыкларны җиренә җиткереп үтәү турында кисәтте. Аланнар яшь кияүнең холкын белмиләр иде әле, шунлыктан алар аның боерык турындагы сүзләрен артык исләре китми генә тыңладылар. Сүзләренә колак салудан бигрәк, алар аның үзен күзәттеләр: кияү аларга яшь, чибәр һәм кызу канлы тоелды. Елдырым бәкнең ирләре барысы да утны-суны кичкән, таза, нык ирләр — сугыш осталары иде.
Яшь хатыны турындагы сагышлы уйларының үзен артка, киреге өстерәвеннән курыккан кебек, тәгин углан бабасы җирләреннән тизрәк ерагаерга тырышты. Туман каган белән очрашуның ничек булырын тулысынча күз алдына китерә алмаса да, шулай ук ул очрашуның күңелле булмаячагын алдан ук чамалап, белеп барды. Атасы алдында, илкөн алдында сынатмас өчен, Урта кичүгә ничек тә иртәрәк барып житәргә, барып җиткәндә дә, ирләрен, атларын югалтмыйча, эрәм-шәрәм итмичә барып җитәргә кирәк иде. Аңа ничек тә каганның мактау сүзен ишетергә кирәк! Кем белә, бәлки инде ул элекке уйларыннан кире дә кайткандыр, бәлки инде аның күзе ачылгандыр, төрле коткычыларны, ялган күрәзәчеләрне, бәлки, яныннан ук читләштергәндер. Шулай гына булсачы, таңрем!
Тәгин угланның күңеленә шундыйрак өметле уйлар килде. Шул ук вакытта аны икенче төрле уйлар да борчыды. Ул Дингез-күл буенда

торып калган алып ир турында уйлады. Аңа Салчак алып инде анда барып җиткәндер дә, урыныннан да кузгала алмаган гарип иргә берәр төрле явызлык, яманлык эшләгәндер шикелле тоелды. Атасы Туман каган алдында ул үзен аңа бәйле итеп һәм шулай ук нахакка рәнҗетелгән итеп тойса, алып ир алдында ул үзен никтер бурычлы итеп тойды. Бурычлы булганга, ул һәрвакыт аны юксынды һәм аның киңәшенә, мактавына, җылы сүзләренә мохтаҗлык тойды. Зур яу алдыннан, атасы каган белән очрашыр алдыннан аңа аның белән бер иркенләп сөйләшергә кирәк. Күңелендә аның күптән инде шундый зур бер теләк өлгереп җиткән иде.

Шуңа күрә дә ул Диңгез-күл буена барып җиткәнче, ашау-эчү, йокы турында уйланмыйча, булдыра алган кадәр тизрәк барырга, төн-көн барырга дигән карарга килде. Бу турыда ул үзенең йөзбашларына, унбашларына да җиткерде һәм боерык булмыйча торып туктамаска, диде.

Көндез алар бик кызу бардылар һәм җил туктап, караңгы төшкәнче шактый ара уздылар. Караңгы төшеп, күз бәйләнә башлагач, Аланнар туктап ял итәргә, төн кунарга теләк белдерделәр.

— Мин сезгә ни боердым? — диде тәгин углан Аланнарның йөзбашына.

— Боерык белән генә булмый. Кирәгеннән артык йөк төясәң, дөя дә аягын суза. Без дөя түгел, кияү, — диде Аланнарның йөзбашы.

Аланнарның йөзбашы бер ашаганда бер сарык ашап бетерә ала торган аттай таза алып ир иде. Шуның өстәвенә ул үзсүзле, кире һәм холыксыз да. Беренче очрашуда ук ул тәгин угланга никтер ышанычсыз булып тоелды. Үз-үзен тотышы, салкын күз карашы, сүзләре, кыланышлары белән ул яшь угланга буйсынмаячагын, ни булса да барыбер үз ирегең, бәйсезлеген саклап калачагын һәм ни генә кушсаң да, гел каршы киләчәген сиздергәндәй булды.

Менә хәзер дә ул үзен кыю, бәйсез тотты. Тәгин угланга ул хәтта бераз гына баласытып карагандай да булды. Аның мондый өстенлегенә тучи бәкнең җен ачулары килде. Ул кып-кызыл булды.

— Мин боермыйча туктамаска, йөзбашы Этимчәк! — диде ул ничек тә кычкырмаска тырышып.

— Без туктыйбыз. Сез теләсәгез нишләгез,— диде Этимчәк аның сүзләренә әз генә дә исе китмичә һәм, калкандай киң аркасы белән борылып, китеп тә барды.

Шул калкандай киң аркага Албуганың сөңге тондырасы килде. Ул ялт кына үзенекеләргә карап алды. Аланнардан алар азрак иде. Ерагая барган арка берәү булса, бер арканы саклап йөз илле киң күкрәк карап тора.

Күрәләтә каршы килеп, Куяннар белән Аланнарны дошманлаштырып монда берни кырып булмаячак иде. Ләкин шул ук вакытта кире беткән бу Этимчәкнең буйсынмавына юл кую да чиктән тыш хәтәр нәрсә иде.

— Тукта! — диде ул, бар көченә кычкырып.

Этимчәк, буйсыну белдереп, туктарга кирәк тапты. Озын торыклы, озын муенлы тулпар атын кире борып ул тәгин углан янына килде.

— Килештекмени, кияү?

— Килештек, йөзбашы Этимчәк.

Этимчәк, берни әйтмичә, борылып үзенекеләр ягына китеп бармакчы булды.

— Туктале,— диде Албуга.— Моннан соң миңа «кияү» дип эндәшмәскә! Мин синең киявең түгел — Елдырым бәк кияве, йөзбашы Этимчәк!

— Анысы шулай.

— Миңа «олуг тучи бәк» дип эндәшерсең моннан соң,— диде Албуга.— Каган боерыгын үтәп без яуга барабыз. Минем боерыкка буйсынмау белдереп син үз ирләреңә яман үрнәк күрсәтәсең, йөзбашы Этимчәк. Олы яу алдыннан ирләрне туарылдырырга түгел, тагын да ныграк тупларга кирәк. Яуда да мин — бер якка, син — икенче якка тартсаң, дошман безне аерым-аерым тукмап юк итәчәк.

— Кыл өзәр хәлең калмаса, боерык белән тун тегеп булмый,— диде Этимчәк киреләнеп.

Албуга җавап биреп тормады. Юк-бар нәрсә тыңлап торасы килмәгәнлеген сиздереп, ул Аланнарның йөзбашы яныннан беренче булып үзе китеп барды. Барлык ирләргә туктап ял итәргә боерды.

Көне буе ат өстендә килеп арыган ирләр куанышып җиргә төштеләр, аякларын яздылар. Кушчылар тиз арада җиңел өйләр-күтәрмәләр кордылар, учак якмый гына, коры-сары белән генә ашарга әзерләделәр. Атларны суынганчы, тирләре катканчы бер тирәдә туплап тоттылар. Атларга, ачык далада калкып чыккан кирмәнгә[1] көчле сак куелды.

Бик арыган булса да, ашагач тәгин углан йокыга китә алмый азапланды. Аның үзенә бер күтәрмә корылган иде. Йоклый алмый як-ягына әйләнгәләп ятканда янына Адай килеп керде. Тышта тагын кемнәрдер бар иде.

— Кемнәр алар? Ник кермиләр? — диде Албуга.

— Керсеннәрме соң? Берсе — Тишек-Таш, берсе — Бавыр,— диде Адай.

— Керсеннәр,— диде тәгин углан, урыныннан торып.

— Олуг тучи бәк! — диде Тишек-Таш ашыгып, пышылдап.— Аланнарны акылга утыртырга кирәк! Йоклаганда Этимчәкне, алыпларын кырып салырга кирәк.

— Болай калдырырга ярамый, абый! — диде Адай.

— Этимчәктән котылмасаң, сиңа бик авырга туры килер, олуг тучи бәк,— диде Бавыр да, сүзгә катышып.

— Сез шуңа килдегезмени? — диде Албуга, егетләрнең әле берсенә, әле икенчесенә карап.

— Шуңа,— диде Адай.

Тәгин углан, берни әйтмичә урыныннан торды, җылы киемнәрен киенә башлады.

— Чыкканчы монда уйлашырга кирәк, олуг тучи бәк,— диде Тишек-Таш кабаланып.

— Нәрсә уйлашырга? — диде Албуга, берни аңламаган сыман.— Син котырттыңмыни, Адай?

— Юк, без — барыбыз да! — диде Тишек-Таш.— Бу эшне болай калдырырга ярамый.

— Син, Бавыр, нишләп монда? Син дә Алан ич,— диде Албуга, Бавырны әле яңа гына танып алган кебек.

— Мин — синең яклы, олуг тучи бәк,— диде Бавыр.— Син мине егетең итеп ал. Мин сиңа эттәй турылыклы булырмын.

— Ярар, алырмын,— диде Албуга. Шуннан соң ул Адай белән Тишек-Ташка борылып карады.— Мин сездән киңәш сорамадым. Булды бер. Аланнар — батыр ирләр. Алар бердәм. Булды — ике. Аларны сез әйткәнчә акылга утыртырга ярамый. Булды — өч.

Егетләрнең өчесе дә тынып калды.

— Әйдәгез, алайса, төнге торгакларны карап кайтыйк, барыбер йокы килми,— диде тәгин углан, үзенә яхшылык эшләргә атлыгып торган яшьләргә карата йомшарырга кирәк табып.

— Абый, булмаса, син ятып тор. Без үзебез карап, тикшереп чыгарбыз,— диде Адай.

---

[1] Кирмән — ныгытылган торак һәм шулай ук хәрби лагерь.

— Болай булгач, син ят,— диде абый кеше тыныч кына.
— Мин ат өстендә килгәндә йоклап алдым,— диде Адай.
— Мин... боерам,— диде абыйсы тавышын үзгәртмичә.
Адай, үзенең олуг абыйсы янында тагын хата ясавын аңлап, шып булды. Аңа берсүзсез буйсынудан башка чара калмады.
«Йөз кеше — йөз төрле уй, йөз төрле холык, йөз төрле омтылыш»,— дип уйлады тәгин углан. Менә шул йөз якка тарта торган йөз кешене, мең кешене бер йодрыкка тупларга кирәк. Борынгы каганнар, атаклы субашлары һәрвакыт шул турыда хыялланганнар. Ләкин беркайчан да беркем дә теләкләренә тулысынча ирешә алмаган. Тынычта алар... сөн ирләре — кундәм, буйсынучан. Яуда, куркыныч алдында — таркау. Һәр-бер йөзбашы, меңбашы үз ягына тарта, үзе генә өстен чыгарга, үзе генә җиңүче булырга тырыша. Моннан соң киресенчә булырга тиеш. Тынычта алар үзләренчә яшәсеннәр, үзләренчә куансыннар, яуда, куркыныч алдында бергә туплансыннар. Бер йодрыкка! Карусыз, кыю, чыдам сөн иренә бары шул чагында гына бернинди дошман да каршы тора алмаячак.
Кем әйткән иде соң әле мондый сүзләрне? Әйе, теге алып ир әйткән иде! Ул әледән-әле әйтә торган иде. Белеп әйткән ул. Күрергә иде аны тизрәк!
Төнге торгакларны, көтүләрне бер мәртәбә карап әйләнеп чыккач, ул, бик нык йокысы килеп, кире өенә таба борылды. Өе янында аны ниндидер җәяүле карачкы көтеп тора иде. Бу теге йөзбашы Этимчәк булып чыкты. Тучи бәк белән әйтешкәннән соң аның да тынычлыгы качкан иде, ахрысы.
— Баягы тупаслыгым өчен кичер мине, олуг тучи бәк, — диде Этимчәк, үкенү белдереп.
Албуга, аның сүзләрен аңлап җитмәгән сыман, эндәшмичәрәк торды.
— Боерсаң, мин хәзер кузгалып китәргә әзер, олуг тучи бәк.
— Син үзең ни киңәш итәсең, йөзбашы Этимчәк?
— Минме?.. Мин... — диде Этимчәк, көтелмәгән сорауга тиз генә җавап таба алмыйча.— Бер туктагач, ял итсеннәр. Атлар да хәл алсын. Шуннан соң туктамабыз. Диңгез-күлгә җитмичә!

## XIII

Төн уртасы авышкач, алар яңадан юлга чыктылар. Таң атканчы бардылар, көне буе бардылар. Атлар арыды, кешеләр йончыды. Шулай да зарланучы, шыңшучы булмады. Кичәгечә күз бәйләнә, атлар сөрлегә башлагач, тәгин углан Этимчәкне чакырды.
— Нишлибез — туктыйбызмы?
Яшь тучи бәкнең үзе белән киңәшүе өчен Этимчәкнең күңеле үсеп китте.
— Боерсаң — туктарбыз, боермасаң...
— Син — әйт! — диде Албуга, аны бүлдереп.
— Туктарга кирәк, олуг тучи бәк,— диде Этимчәк.— Диңгез-күлгә ерак калмады. Шулай да минем бер киңәшем бар.
— Нинди киңәш?
— Синең икенче йөзбашың Тишек-Таш бар. Минем белән генә киңәшеп туктарга боерсаң, ул үпкәләячәк. Аның белән дә киңәшсәң, ул тыныч булачак.
— Менә монысы иң яхшы киңәшең, йөзбашы Этимчәк!
Тишек-Ташны да чакыртып, алар яңадан киңәштеләр дә туктарга булдылар. Төн урталарына чаклы йоклап алгач, яңадан кузгалып киттеләр. Диңгез-күл буена бер тын бик каты чаптырып барганнан соң, икенче төн башланыр алдыннан гына барып җиттеләр.

Күлнең төньяк яры буенда туктап, авыл кордылар. Тәгин углан, үзенең Байык буеннан килә торган төп көчләре белән шушы тирәдә очрашырга тиеш иде. Ирләр, авыр юлдан соң тынычланып, шундук йокыга талды.

Иртән аларны ниндидер кораллы ирләр уятты. Барлыгы унлап кеше иде. Аз санлы булуларына да карамастан, алар үзләрен хуҗаларча тоттылар. Болар Диңгез-күл сакчылары иде. Йокыларыннан көчләп уятылган ирләр сакчыларны Албуга өенә алып килделәр. Күзен рәтләп ачмаган йокылы-уялы тәгин углан аларны баштарак теге Байык буеннан килгән үз ирләре дип уйлады, ләкин шулай булса да ул аларның берсен дә рәтләп танымады.

— Сез кемнәр? — диде күл сакчыларының берсе, Албугага усал гына эндәшеп.

Ул да аны бик үк белми иде, ахрысы.

— Син үзең кем? — диде аңа каршы Албуга.

— Без — каган кешеләре,— диде күл сакчысы.

— Сез каган кешеләре булсагыз, мин каганның өлкән углы... уң кул тучи бәк Албуга,— диде тәгин углан, үзе белән сөйләшкән усал унбашына якынрак килеп.

Ат өстендәге унбашы шундук атыннан төште, буйсыну белдереп, тәгин углан алдында бил бөкте.

— Танымадым, кичер, олуг бәк,— диде унбашы.— Безгә боерылган: күлгә беркемне якын җибәрмәскә, диелгән. Син инде беләсең булыр...

— Байык буеннан чирү килгәне ишетелмәдеме? — диде Албуга аны тыңламыйча.

— Ябалак картны ат койрыгына тактылар — син әле белмәдеңмени, олуг тучи бәк? — диде унбашы шулай ук үз уйлары белән мавыгып.

— Кемнәр? Ник? — диде Албуга.

— Ярлы чиннәрнең берсе шымчы булган. Шул барып әйткән Исәнтәйгә,— диде алай башы.— Исәнтәй анда Ак өйдә каганның уң кулына әйләнде — аның урыны түрдә!

— Шымчыны нишләттегез?

— Без нишләтик аны — Исәнтәй янындадыр. Аңа безнең кул җитми. Ябалак кызганыч. Бөтен гомерен шушында уздырды — яуга йөрмәде, күченмәде. Кендеге бәйләнгән кебек, корткасы янында, күл буенда бер рәхәтсез гомер кичерде. Мәетен далага чыгарып ташладылар, өен яндырдылар, корткасын куалап җибәрделәр.

— Кайчан?! — диде Албуга әле һаман ышанасы килмичә.

— Кайчан булсын — моннан бер атна элек бугай.

— Кем? Исәнтәй үземе?

— Салчак алып,— диде күл сакчысы.

Албуганың кинәт күз аллары яктырып китте.

— Яралы ир исәнме? Яралы арыслан исәнме?! — диде ул, саңгырау кеше белән сөйләшкән сыман кычкырып.

Алай башы кем турында сүз барганын, билгеле, аңлады. Күзен читкә борып ул көрсенеп куйды.

— Белмим,— диде.

— Нәрсә белмисең — исәнме, юкмы?! — дип кычкырды Албуга.

— Белмим.

— Аны да... үтерделәрмени? — диде тәгин углан, тынын кысып, әкрен генә.

— Берни белмим,— диде аңгыра алай башы, бер үк сүзне тукып.

Ләкин менә шул «белмим»ендә аның нидер белгәнлеге сизелде. Үзенең ирләреннән уңайсызлана идеме ул, әллә башка нәрсәдәнме — шулай да аның нидер яшергәне күренеп тора иде.

Аяк буыннары йомшап калган тәгин углан күл сакчысы алай башын үз өенә чакырды. Учакка коры тизәк өстәп җибәргәч, ул киез өстенә

аякларын бөкләп утырды да кунагына да утырырга кушты. Утыргач, алар бер касәдән кымыз эчтеләр.

— Ни сорыйсың: атмы, тунмы, коралмы? — диде тәгин углан, туп-туры сүзгә күчеп.

— Үзеңнеке кебек озын торыклы тулпар ат бирсәң, аны миннән барыбер тартып алырлар,— диде кунак.— Үзем сыман тәбәнәк буйлы, юаш, чыдам атым болай да бар. Өстемдәге туным иске, иске булса да, җылы. Җәяне, укны мин үзем ясыйм — урман ерак түгел.

— Кызмыни? — диде тәгин углан, яшь алай башының тел төбен аңлап.

— Әйе, кыз, — диде кунак.

— Яудан алып кайтсам, теләгәнеңне алырсың,— диде Албуга.

— Юк,— диде кунак.— Миңа кыз син яуга киткәнче кирәк. Көн дә кирәк. Тун мине көндез җылыта, төнлә — суык.

— Каян алыйм мин сиңа хәзер генә кыз? — диде тәгин углан, мондый сату-алуга үртәлә башлап.

— Аны син алмассың, мин үзем алырмын, олуг тучи бәк,— диде кунак. — Миңа кыз өчен түләргә байлык кирәк. Мин аны сатып алам. Моннан өч көнлек ераклыкта, таулар арасында, бер ярлы чин картының гүзәл кызы бар. Шуңа күзем төште. Менә ул кайда кыз! Карт ярлы.- Аның җигәренә бер дөя, бер-ике ат, туенырына иллеләп сарык кирәк.

— Булыр,— диде тәгин углан.— Инде сөйлә. Берни калдырмыйча сөйлә.

— Сөйлим,— диде кунак, яңадан кымыздан авыз иткәч.

— Мин аңа ант та бирмәдем, сүз дә бирмәдем. Сөйләмәскә кирәклеген без үзебез генә беләбез. Шымчының Исәнтәй янына киткәнен ярлы чин качаклары сизенгәннәр дә борчыла башлаганнар. Шунда әлеге гүзәл кызның атасы да ишетеп алган моны. Шул килеп әйтте. Җәяү килгән. Аты да, дөясе дә юк. Ничек юлда аюга, бүрегә юлыкмаган! Сөйләде бу. Без куркуга калдык. Нишләргә? Ябалак карт әйтте: урдадан тикшерергә килсәләр, бар гаепне үз өстемә алам, диде. Болай да инде миңа күптән вакыт җиткән теге дөньяга китәргә, диде. Безгә ничек тә яралы ирне коткарырга кирәк, диде. Менә шул, олуг тучи бәк. «Арысланның» үзенә без берни әйтмәдек. Яткан килеш арбага чыгарып салдык. Атлар җиктек тә, терлекләрен куалап, бар байлыгын төяп, шул ук төнне таулар ягына алып киттек. Мин дә, абый белән эти. Сер чыгарлык түгел. Без аны шул чин карты янына, таулар арасыңа илтеп куйдык. Шунда мин аның кызын күрдем.

— Табылдыкнымы? — диде Албуга кинәт балкып.

— Юк. Чин картының кызын. Табылдыкны яралы ир янында калдырдык. Ул батыр, уңган кыз икән. Яралы ирнең баш очында гына утырды, дип сөйләде Ябалак карт.

— Табылдык... — дип куйды үзалдына яшь углан, сагышланып, гүзәл кыпчак кызын күз алдына китереп.

— Чин карты анда таулар арасында Исәнтәйдән качып ята икән. Анда аларны беркем табарлык түгел. Бездән соң бер көн үткәч тә күл буена Салчак алып килеп төшкән. Аннан ул әнә Байык буена китте.

— Алар... әле дә анда таулар арасында микән? — диде Албуга.

— Белмим,— диде кунак.— Чин карты әйтте: тыныч булыгыз, мин аларны беркем таба алмастай җиргә яшерермен, диде. Кызын •алырга барсам, мин барысын да белермен.

— Менә нәрсә, Җидекул... синең исемең Җидекул бит әле?— диде Албуга, кунакның йөзенә җентекләбрәк карап.

— Әйе, Җидекул, олуг тучи бәк! — диде унбашы, Албуганың үз исемен белүенә сөенеп.

— Менә нәрсә, Җидекул. Бу турыда башка беркемгә дә тишмәсәң, үлгәнче минем дустым булырсың.

— Ант! Ант! Ант! Мәңге колың булырмын, олуг тучи бәк.

— Яудан кайткач, мин сине эзләп табармын. Шунда без бергәләп алар янына барырбыз.

— Мин башкаларга сиздермичә генә белешеп торырмын, кирәк булса, берәр нәрсә белән булышырмын,— диде Җидекул.

— Булышу дигәннән, Ябалак картның корткасы кайда икән хәзер?

— Ярлы чиннәр янында булырга тиеш.

— Син аны берәр ничек минем әни янына, Байык буена илтеп куй. Минем әнигә барысын да сөйләп бир. Син сораган терлекне дә сиңа ул бирер.

— Барын да син әйткәнчә эшләрмен, олуг тучи бәк,— диде Җидекул.

— Онытма: теге таулар арасындагы ирне ничек тә сакларга, аякка бастырырга кирәк. Минем өчен, әнием Күрекле бикә өчен бөтен Сөн илендә иң кирәкле кеше ул, Җидекул! — диде тучи бәк Албуга.

## Алтынчы баб

### I

Шулай итеп, Банхуа-Исәнтәй Туман каганның уң кулына әйләнде куйды. Урдадан Туңгак алыпны кысрыклап чыгаргач, ул аның урынын җиңел генә биләп алды. Хәзер инде каган бер генә эшен дә кыек авызлы, ләкин туры сүзле, тик шулай да кара йөрәкле тылмачы белән киңәшмичә эшләми башлады. Элегрәк Туңгак алып белән каган күбесенчә ирләргә, атка, коралга, яуга-сугышка катнашы булган нәрсәләр турында киңәшә торган булса, хәзер ул Исәнтәй белән башлыча хатынкызга, кием-салымга, йорттагы төрле ыгы-зыгыларга кагылышлы нәрсәләр турында киңәште. Мондый катлаулы, четерекле эшләрдә исә Банхуаны һич тә тәҗрибәсез кеше дип әйтеп булмый иде. Кешеләр белән, аеруча хатын-кыз белән ул ничектер бик җиңел генә уртак тел таба белә. Моның шулай икәнлегенә каган инде берничә мәртәбә ышанырга мәҗбүр булды.

Урдага китертелүенең беренче көннәрендә гүзәл чин кызы Сөенеч каганга карата шактый салкын булды. Яшь кыз белән үзе арасында берниндн якынлык булмавына алып ирнең, билгеле, ачуы килде. Сөенеч урынында башка берәр кыз шулай ачуын китергән булса, ул аңа икенче әйләнеп тә карамас иде — шундук аны урдадан куаларга, я булмаса, иң яхшысы, берәр колга кияүгә бирергә боерыр иде. Бу юлы ул алай итә алмады. Бу юлы аңа түзәргә һәм гүзәл кызның холыксызлыгын, тәкәбберлеген татып, ярыйсы ук хурланырга туры килде.

Бөек ирнең хәлен яхшы аңлаган Исәнтәй чин кызы белән үзе сөйләшеп карарга булды. Сөйләште һәм бер сөйләшүдә барысын да җайлады да куйды.

— Сөенеч үзенең абыйсын сагына, аның өчен борчыла. Шуңа күңелсез,— диде ул каганга.

Каган кызның абыйсын урдага китерергә боерды. Мондый боерыкны Исәнтәй бик теләп үтәде — Чәнсинең тегендә, Таштугайда «хуҗа булып» ятуына аның инде күптән эче поша башлаган иде. Аннан соң, каган урдасына Чәнси үтеп керергә тиеш булып та, ул читтә торып калгач, тегендәгеләр, бик ерактагылар моңа ничегрәк карарлар икән?, дигән уй да аңа тынгылык бирми иде. Күңелләре булсын — әйдә, урда кешесе булсын аларның ышанычлы Чәнсиләре!

Чәнсине Исәнтәй каган кырнагы Сөенечнең ат караучысы итеп кую-

га иреште. Төнге салкында йомылып торып та, иртән кояш җылыта башлау белән ачылып киткән алсу чәчәк кебек, гүзәл кырнак кинәт бар көченә балкып китте һәм моннан соң инде беркайчан да үзенең бөек хакименә салкынлык, дәртсезлек күрсәтергә батырчылык итмәде.

Кыздагы мондый үзгәрешкә каган сөенеп бетә алмады. Яз көнендә күз карашын иркәли торган беренче яшел үлән кебек, җылы кояш, якты күк йөзе кебек күңеленә һәрвакыт бәхет-куаныч тойгысы өстәп торган кызны ул ратканнан-ярата барды. Яраткач, билгеле, аның кимчелекләрен дә күрми башлады.

Кимчелекләр исә юк түгел иде! Гүзәл чин кызының башкалар күзенә күренеп тә, бары каган күзенә генә күренмәгән кимчелекләре шул булды: башта ук ул үзенә түрдән урын даулады. Каган каршы килмәде. Чин кырнагы каган янында «табын күрке» булып кына түгел, тулы хокуклы бичә кебек, сул якта, биектә утыра башлады. Бары тик аңа башкалар — туган-тумачалар, агай-энеләр, бичәләр алдында баш игән кебек баш имәделәр дә, бил генә бөкмәделәр. Каганның ата-баба йоласын бозуы көн кебек ачык иде, ләкин яшьлек, гүзәллек һәм аның янындагы көч-куәт һәркемнең күзен томалады.

Башкалар чин кырнагының икенче кимчелеген дә бик тиз күреп алдылар. Алар аның абыйсы Чәнси белән кирәгеннән артык еш очрашуына игътибар иттеләр. Кайбер очлы күзләргә абый белән сеңелнең үзара мөнәсәбәте бик шикле тоелды. Ләкин бу хакта да сүз кузгатырга беркемнең йөрәге җитмәде. Мондый нәрсәләр турында каган алдында сүз кузгатырга батырчылык итәрдәй ике генә кеше бар — икенең берсе Кортка-бикә булса, икенчесе Баргынтай баба. Кортка-бикә читтә иде, турыдан-туры ул бернигә катнашмый, Баргынтай баба исә авыру иде.

Чин кырнагының кимчелекләрен Исәнтәй дә күрде. Күрде, ләкин төзәтергә ашыкмады. Аны әлегә аннан да зуррак нәрсәләр борчыды.

Туңгак алыпны читкә тибәреп, ул бик зур җиңүгә иреште. Тик шулай да бу әле тулы җиңү түгел иде. Бер кызганда аны — Туңгак алыпны — бөтенләй юк итә алмавына ул үкенеп бетә алмады. Каравыл агасы Салчак алыпны шундый ук үкенү газаплады, һәм алар — Исәнтәй белән Салчак алып — үзара бик тиз уртак тел таптылар. Котлуг бәк белән киткән алыпның бары тик Күрекле бикә янында гына булырга тиешлеген алар бик яхшы белделәр. Алар шулай ук аны Күрекле бикәдән җиңел генә тартып алып булмаячагын да аңладылар. Аны аннан йолкып алу, йолкып алгач, юкка чыгару өчен я аларның барысын да юкка чыгарырга, яисә берәм-берәм бүлгәләп, аерым-аерым юкка чыгарырга кирәк булачак иде. Бикәгә, уң кул тучи бәк Албугага каршы алар ачыктан-ачык корал күтәрә алмадылар һәм мондый эшкә каганны да котырта алмаячаклар иде. Өлкән бичә белән уң кул тучи бәккә каршы алар бары таулар аръягындагы дунхуларны гына котырта алалар. Ләкин дунхулар һичшиксез җиңәрләр, дип уйлау да бик үк ышанычлы нәрсә түгел иде.

Үзе өчен бик катлаулы, четрекле тоелган нәрсәнең бар ягын да уйлап карагач, бер көнне Исәнтәй сакланып кына каганга үзенең кайбер фикерләрен әйтергә кирәк тапты.

— Уң кул тучи бәкне яуга алып барырга кирәк, бөек каган,— диде ул.

— Яуга? Нинди яуга ул тагын? — диде каган.

Бу көннәрдә, Сөенеч белән эшләре җайлангач, Туман каган ил-көн, яу-сугыш кебек вак-төяк нәрсәләр белән бөтенләй кызыксынмый башлаган иде.

— Чингә каршы, бөек каган! — диде Исәнтәй, андагы бу үзгәрешкә исе китеп.— Син яуга киткәч, артыңда уң кул тучи бәк кала. Ул сиңа ачулы. Күрекле бикә ачулы, Котлуг бәк ачулы.

— Уң кул тучи бәк тәгин угланның көче юк, Исәнтәй,— диде каган.

— Көче булмаса, аның янында атаклы Тунгак алып бар, бөек каган!
— Син Тунгак алыпны яратмадың — шуңа куркасың аннан. Тунгак алыпның кулы да, аягы да юк. Карачкы итеп бастырып куеп, ул бары ук атарга гына ярый.
— Тунгак алып шул карачкы килеш тә куркыныч, бөек каган! — диде Исәнтәй.
— Курыкканга — куш, ботагы белән — биш! — диде каган, көлеп.
— Байык буеның теге ягында, таулар артында сугышчан дунхулар бар, бөек каган! — диде Исәнтәй бирелергә теләмичә.
Туман каган көлүеннән туктап калды. Дунхулар. Начин нойон аны уйланырга мәҗбүр итте.
Икенче көнне ул Салчак алыпка үзенең уң кул тучи бәк Албуга турындагы боерыгын җиткерде.
Исәнтәйнең түбәсе күккә тиде. Салчак алып Байык буеннан үзләренең төп хаталарын төзәтеп кайтканчы ул үзе монда Сөенечнең «кимчелеген» төзәтеп куярга булды. «Абый» кешенең кыланышлары беренче көннән үк аның саруын кайнатты. Монда, урдада, бераз аның белән янәшә торып карагач, үзе өчен ул аның артык кеше икәнлегенә төшенде. Кирәгеннән артык саксызлана торган яшь «абый»ның бөтен эшне бозып куюы бар. Аны ничек тә тизрәк моннан озатырга кирәк иде.
Җайлап кына ул тагын каганга үзенең кайбер фикерләрен әйтте.
— Синең яраткан кырнагың Сөенечнең бертуган абыйсы бик күңелсезләнә, бөек каган,— диде ул.— Сөенечнең абыйсы әйтә: тегендә мине көтеп торалар, ди. Сөннәр Чингә каршы яу чабалармы, юкмы? Кайчан, каян кузгалырга уйлыйлар — Чжао аксөякләре шул турыда белергә телиләр, ди. Аларга алдан әзерләнеп торырга кирәк, ди.
— Син аңа ышанасыңмы? — диде каган, Исәнтәйнең күзләренә туры карап.
— Бертуган сеңлесе синең куенында булганда ышанмаска көчемнән килми, бөек каган,— диде Исәнтәй.
— Миңа ул шикле тоела.— диде каган.— Ярар, китә бирсен.
Соңгы өч сүзенең мәгънәсе хакында уйлап бетердеме ул, юкмы...

## II

Мондагы хәле икеле-микеле булуына да карамастан, каган урдасыннан Чәнси теләмичә генә китте. Мондагы буш даланы, туң даланы ул яратмады. Тамырдагы кайнар канны бозга әйләндерә торган таштай суыкны, сөякләргә үтә торган ачы җилләрне яратмады. Мондагы киез өйләрне, арбаларны, кешеләрне яратмады. Ярата алмады. Тик шулай да аның бу яктан, бу кешеләр, мал-туарлар арасыннан беркая дә китәсе килмәде.
Туң даланы эретә торган язгы кояш та, Күк асты иленең хуш исле чәчәкләре дә, таллы елга буйлары да — барысы да, барысы да — монда, аның янында гына иде. Аның сөеклесе Пуй атлы кыздан аңа монда һәрвакыт җылылык, яктылык таралып тора. Монда шул Пуй булганга күрә дә тормыш аңа ямьле, күңелле һәм мәгънәле тоела иде.
Билгеле, аңа монда да салкын, бик салкын булган чаклар булды. Банхуаның таулар арасындагы таш оясында чагында ул сагышыннан, кайгысыннан акылдан шашар дәрәҗәгә җитеп калды. Бары менә монда урдага күченеп килгәч кенә аңа яңадан җан кереп киткән иде.
Менә аны тагын аердылар. Җылыдан, яктыдан, бәхет-куаныч чыганагыннан аердылар. Монда килгәндә ул кая баруын да, ник баруын да бик яхшы аңлап килде. Монда килгәндә ул кемнәрнеңдер теләген, боерыгын үтәгәннең соңында яраткан кызыннан аерылырга, кире әйләнеп кайтырга тиешлеген дә аңлап-белеп килде. Тик шулай да аның менә

хәзер аннан аерыласы да, кире туган җиренә әйләнеп кайтасы да килмәде.

Соңгы тапкыр очрашканда Банхуа аңа әйтте:

— Теге яктан боерык килде: сиңа бөек эш йөкләтелә,— диде.— Син бер угланны күрергә, аны ныклап исеңдә калдырырга тиешсең. Берәр җирдә яңадан очрашырга туры килсә, син аны танырга тиешсең.

— Мин аны кайда күрермен соң? — диде Чәнси.

— Ул сине Тарлавыкка чаклы үз алае белән озатып куяр, шунда күрерсең,— диде Банхуа.

Юлга чыгар алдыннан аның сул колагындагы алкасын салдырып алдылар, тамгалы яшма ташын — ышаныч билгесен кире бирделәр. Шуннан соң аны баштанаяк чин киемнәренә киендерделәр. Ләкин чин киемнәре белән кышкы далада мең адым да китеп булмаячак иде. Шуңа күрә, юка киемнәр өстеннән аңа тагын калын, тупас тире киемнәр кидерделәр.

Урдадан алар таңга таба, яктылы-караңгылыда чыгып киттеләр. Капка аша чыкканда ул соңгы кат артына — таудай калкып утырган биек Ак өйгә карады. Җылылык, яктылык чыганагы шунда булырга тиеш иде. Ул аны күз алдына китерде. Ләкин менә хәзер шунда, яктылык чыганагы янында, икенче бер кешенең, чит, ят, дошман кешенең булуы турында уйлагач, аңа кинәт чиркангыч булып китте. Шундук аның йокысы качты һәм шул ук мәлдә кемдер арттан пычак белән китереп кадагандай булды.

Әллә соң ул үзенең шулай тегеләргә — үзенең юлдашларына арттан пычак белән кадавын исенә төшерде микән? Кем өчен кадады соң ул теге вакытта? Ник кадады? Әлбәттә, аның өчен, гүзәл Йуй өчен кадады. Үзенә булсын өчен. Барыбер булмады. Бетте. Менә хәзер аның үзен бәреп ектылар. Аңа... биек Ак өйдәге яктылык, җылылык чыганагына хәзер менә күңелледер, рәхәттер. Аңа... аның ишеләргә берни булмый. Алар көләләр, шаяралар. Аларга кем белән дә күңелле!

Юл буена ул караңгы чырайлы булды. Юл буена ул үзенең бәхетсез язмышы, билгесез киләчәге турында уйлады.

Аны озата килүче йөз кешелек алай төштән соң бер сөзәк калкулыкның җилсез ягында туктап калды. Монда, сирәк урман белән капланган калкулык буенда, аларны башка кешеләр көтеп торалар иде. Алар бирегә иртәрәк килеп туктаганнар һәм, атларын тибенгә җибәреп, җиңел өйләр корырга өлгергәннәр. Озатып килүче алай башы аны шушы кешеләргә тапшырды. Аны озата килгән яшь ирләр урда ягына кире борылдылар.

Банхуа әйткән угланны ул беренче күрүдә үк таныды. Таныды һәм шактый гаҗәпкә калды. Ул аны белә иде. Бу аны чик буеннан Банхуа торагына кадәр озатып куйган ирләрнең яшь алай башы иде. Әйе, бу теге ул ишетеп тә, күреп тә белгән уң кул тучи бәк тәгин углан иде. Ул үзе генә түгел, аның монда кайбер егетләре дә аңа таныш сыман күренде. Уртадан озын буйлы, киң маңгайлы, киң күкрәкле бу таза яшь угланны ул бер мәртәбә күргәч, икенче мәртәбә теләсә каян, теләсә кем арасыннан аерып ала алган булыр иде. Ул үзеннән-үзе истә кала торган, күзгә бәрелеп тора торган кеше иде. Теге вакыттагы белән чагыштырганда ул ярыйсы ук үзгәргән дә.

Банхуаның коткылы сүзләрен истә тотып, ахрысы, аннан соң Йуй язмышында аның да күпмедер катнашы барлыгын белгәнгә күрә, Чәнси аны җентекләп, сәер бер тойгы белән күзәтте. Аның бу тойгысында чиксез нәфрәт тә, дошманлык та һәм шул ук вакытта аннан курку катыш җирәнү дә бар иде. Бу тойгыда шулай ук аны ничек тә түбәнәйтергә, аны бары начар итеп, ямьсез итеп күрергә тырышу да бар иде.

Яшь углан үзе аны беренче карашта ук таный алмады, ахрысы. Шулай да күз карашлары очрашкач, Чәнсине ул шундук исенә төшерде.

Җил кисеп карайган, кырысланган йөзендә аның, ихлас бер гаҗәпләнү билгесе булып, балаларча елмаю балкып китте. Әле генә Чәнсигә ач бүренеке сыман усал, комсыз булып күренгән күз карашында янә дә балаларча беркатлылык, эчкерсезлек чагылып калды.

— Синмени әле бу?! — диде тәгин углан элекке танышын очратуына чын күңелдән сөенеп.— Алып килгәч, менә илтеп тә куярга туры килә сине. Менә хәзер Ак урдага якын да җибәрмиләр. Каршыга чыгып әйттеләр: каган боерыгы, диделәр, Тарлавыкка кадәр озатып куярга, диделәр.

Ул үзенең шул кадәр күп сөйләп ташлавын, җитмәсә, сөнчә аңламаган кешегә сөйләп ташлавын чамалап, кинәт тынып калды. Әллә соң ул аның — шикле чин качагының күңел түрендә үзенә карата бөтенләй кире хис-тойгылар барлыгын сизенеп алды микән? Ни генә булмасын, ул да, Чәнси кебек үк, үзенең булачак юлдашын җентекләп карарга тотынды.

Чәнси аның сүзләрен яхшы аңламаса да, үзенә карата анда бернинди усаллык юклыгын сизенми калмады һәм шул чакны аның күңелендә нидер сынган кебек булды. «Әйе, әйе!» дигән сыман баш кагып, ул елмаеп куйды.

Икенче көнне кич, караңгы төшүгә аны таулар арасындагы ялгыз өйгә китереп куйдылар. Уң кул тучи бәк тәгин углан белән ул беренче мәртәбә очрашкан төштә аерылыштылар. Аерылышканда алар «Сау бул!» дигән шикелле бер-берсенә карашып алдылар, елмайгандай иттеләр. Озын туны аяк очына кадәр җиткән яшь, чандыр чин ирс ялгыз өй янында торып калды, өстенә сугышчы киемнәре кигән яшь сөн ире атына атланып таулар арасыннан төньякка таба китеп барды. Аның артыннан озак кына тояк тавышлары ишетелеп торды.

## III

Чәнсинең этисе Чәни түбәннән күтәрелгән кеше булган. Яшь чагында ул үзләре авылында гына түгел, бөтен тирә-якта иң батыр, куркусыз башкисәр саналган. Яше җиткәч, аны гаскәргә алганнар, чик буена җибәргәннәр. Анда да ул үзенең кыюлыгы, башсызлыгы белән танылып өлгергән. Соңнәр белән сугышларда ул берничә мәртәбә батырлык, тапкырлык күрсәткән. Аңа игътибар иткәннәр, мактаганнар, бүләк биргәннәр һәм югары үрләткәннәр. Югары үрли-үрли ул субашы дәрәҗәсенә ирешкән. Моннан җиде-сигез ел элек ул Йәнмынь янында Чин гаскәрләренә каршы сугышта батырларча һәлак булган. Чин угы туп-туры аның уң күзенә килеп тигән. Ул укны ярсып тартып алган, ләкин ук тимеренә ияреп аның күзе дә ите-каны белән актарылып чыккан. Үләр алдыннан ул акылдан шашкан. Үлгәнче ул бертуктаусыз «Чжао! Чжао!» дип кычкырган. Шундый турылыклы булган ул үзенең туган иленә!

Бу турыда соңыннан Чәнсигә этисенең элекке дуслары сөйләде. Аның хакында алар тагын күп нәрсәләр сөйләделәр. Этисе атаклы сугышчы булганга һәм бөтен гомере чик буе шәһәрендә, сугышчылар арасында үткәнгә, бала чагыннан ук ул батырлар, батырлыклар турында берсеннән-берсе мавыктыргыч хикәяләр ишетеп үсте. Шул рәвешчә ул Чжао йортының иң атаклы сугыш осталары Лэнпо белән Лиму турында да күп кенә нәрсәләр ишетте.

Менә шундый хикәяләр, җанлы тарихлар тәэсирендә, ахрысы, Чәнси дә яшьтән үк батырлык, дан һәм дәрәҗә турында хыялланды. Ләкин аның батырлыгы шул коры хыялланудан ары узмады. Кулына кылыч, ук-җәя тотып, аңа сугышырга насыйп булмады. Ул үсеп буйга җиткән-

дә аның туган иле — Чжао йорты инде аяк астына салып тапталган беткән, үлгән иде. Аның әтисе Чәни шундый яраткан Чжао җирләре инде Чин биләмәләре булып исәпләнелә иде.

Меңләгән Чжао аксөякләре белән бергә аларны, туган җирләреннән, туган йортларыннан аерып, Чин башкаласына күчерделәр. Өйләнгән бер абыйсы шул ук елны, корал асып, сугышка китте, сеңлесе Йуны Чин йортының ваны Инчжэн сарайларының берсенә кырнак итеп алдылар. Ире батырларча сугышта үлгән үги әнисен шулай ук сарайга алдылар. Кырнак итеп түгел, тукучы, тегүче итеп. Ул әле яшь иде, шулай да Чин ванының күзе төшәрлек чибәр түгел иде. Ә менә аның бертуган сеңлесе Йу искиткеч матур иде! Яңа тулып, буйга җитеп килгән чагы иде аның.

Чәнсине дә, абыйсы Жу кебек итеп, кулына корал тоттырып, каядыр көньякка сугышка җибәрмәкчеләр иде. Шул чакны көтмәгәндә аңа әтисенең элекке дусты Дунто ярдәм кулын сузды. Башкаланың көнбатыш капкасы янында сакта торучы алай башлыгы ярдәмчесе Дунто аны үз янына битекче итеп урнаштырды.

Хәзер дә аның, бала чагындагы кебек, бөтен вакыты иртәннән кичкә чаклы кораллы ирләр-сугышчылар янында үтте. Ул туктаусыз язу-сызу белән шөгыльләнде. Өлкәнрәк башлыклары кушса, тегендә-монда барып килгәләде, кайчагында исә, рөхсәт сорап, ялгыз әнисе янына кайтып әйләнгәләде. Кайткан саен аңа әнисенең бетмәс-төкәнмәс моң-зарын тыңларга туры килде.

Шулай бер көнне үзләренә кайтып кергәч, әнисе серле генә итеп:

— Кызым Йудан хат бар! — диде.

— Күрсәт әле! — диде Чәнси коты алынып.

Сарайлардагы кызларга туганнары, ата-аналары, дуслары белән аралашу, хат-фәлән алышу тыела иде. Кемнең дә булса сарай кызлары белән аралашуын сизсәләр, гаепле кешене шундук хөкемгә тарттыралар иде.

— Кемдер коймa аша менә бу таякны ташлап китте,— диде әнисе.

Улына ул бер буын озынлыгындагы нечкә генә бамбук таягы бирде. Таяк урталай ярылган иде. Чәнси, ике кисәкне бергә беркетеп бәйләгән җепне сүтте дә, таяк эченнән нечкә генә итеп төрелгән ак ефәк тартып чыгарды. Ефәккә кара белән шундый сүзләр язылган иде:

«Без монда биш йөз кыз. Барыбыз да яшь, чибәр. Инде ике ел булды — минем әле бер генә ир кеше дә күргәнем юк. Без ерткыч оясына азыкка дип ташланган корбаннар кебек. Кайгыдан, сагыштан мин үләрмен ахрысы. Абый! Коткар мине! Үлгәнче сезне, тауларны, елгаларны күрәсем килә. Йу».

Өйдә болай да кайгы-хәсрәт баштан ашкан иде. Төрлесе төрле якка таралган балаларын уйлап, карт ананың йөрәге инде болай да теткәләнеп беткән иде. Мондагы, иректәге тормыш белән чагыштырганда оҗмах булып тоелган тормышта — хуанди сараенда яшәп ятучы Йу турында инде әнисе дә, Чәнси дә, башкалар да ничектер онытыбрак торалар иде сыман. Ван сараенда булгач, аңа анда күңелледер, һич югы, тамагы туктыр, өсте бөтендер сыман тоела иде. Бу көтелмәгән хат-хәбәр андый гамьсез уйларның барысын да чәлпәрәмә китерде! Гомере буена иренең колы булып, бар кайгысын эченә йотып барган карт ана шул көннән башлап бөтенләй диярлек сөйләшмәс булды.

Шул көннән башлап абый кеше дә күзгә күренеп үзгәрде. Ул уйланды. Язмыш турында, көндәлек тормыш, кансыз, шәфкатьсез дөнья турында элеккегә караганда башкачарак итеп уйланды. Үзе белән бергә уйнап-көлеп үскән сеңлесе бик кызганыч булып, моңлы-сагышлы булып күңеленә керде дә утырды. Сеңлесе аңа хәзер элеккегә караганда да якынрак, кадерлерәк тоелды. Ул аны коткарырга тиеш иде. Бернигә карамыйча ул аны ерткыч оясыннан тартып алырга тиеш!

Лəкин ничек итеп? Ничек?!

Бу турыда ул əнисеннəн башка беркем белəн дə киңəшə алмады. Əнисе белəн киңəшеп торуның исə кирəге дə юк иде — ул барыбер берни аңламаячак, ул бары күз яше генə түгəчəк. Абый бары үзе генə уйланды. Уйланды һəм тапты.

Ул чəнсəн Лисының төп Чин кешесе булмыйча, Чу йортында туган, түбəннəн күтəрелгəн кеше икəнлеген белə иде. Ул шулай ук аның—Лисының — чыгышына, байлыгына карамыйча, башлы, булдыклы яшьлəргə якты йөз белəн каравы турында да ишеткəлəгəн иде. Бик озак баш ваткач, ул туп-туры Лисының үзенə ялварырга булды. Моның өчен ул Чин йортын баету, Чиннең, бөек Шихуандиның көчен арттыру буенча бик кыю киңəш уйлап тапты. Үзенең кыю уйларын-фикерлəрен бамбук таякларына күчереп, ул шуны Лисы кулына тапшырырга дигəн карарга килде.

## IV

«Олуг чəнсəн, синең бөек акылың, шəфкатьлеген турында мин күп ишеттем,— дип язды ул Лисыга тапшырылачак бамбук таякларына.— Шуңа күрə дə мин, элекке Чжао билəмəсенең Йəнмынь каласында су-башы Чəни гаилəсендə туган уртанчы бала Чəнси, сиңа шушы битек белəн мөрəҗəгать итəргə батырчылык иттем.

Олуг чəнсəн! Чин йорты элек — син Чингə килеп, Чин ванына хезмəт итə башлаганчы, бик кечкенə булган. Аннан да элегрəк, ишетүемчə, аның чиклəренең озынлыгы мең лидəн артык булмаган. Үзеңə буйсынган кешелəр белəн идарə итүдə сəлəтле һəм акыллы булуың аркасында, син, олуг чəнсəн, үз тирəңə булдыклы яшьлəрне тупладың. Хөрмəткə лаек кешелəргə бүлəклəр биреп, аларның күңелен күтəрдең. Шунлыктан синең кул астындагы кешелəр, икелəтə тырышлык белəн, тугрылык белəн хезмəт итеп, Чин йортының, Бөек Шихуандинең көчен, байлыгын арттыралар. Шуның өчен сине бөтен Күк асты илендə чын күңелдəн хөрмəт итəлəр һəм сиңа ун мең еллык гомер телилəр.

Бөек Чин йортының данын, билəмəлəрен арттыру өчен синең җаныңны да кызганмый тырышуың аркасында, Чин йорты үзара туктаусыз сугышып, талашып яшəгəн вак билəмəлəрне берлəштерде һəм бердəм, бөек дəүлəт төзелде.

Лəкин ил берлəшсə дə, аның читлəрендə төрле кыргый халыклар яши. Үзлəренең аңсызлыклары, томаналыклары аркасында алар Күк углы алдында бил бөгəргə, Чин йорты урнаштырган гадел тəртиплəргə буйсынырга телəмилəр. Кыргый халыкларның иң оятсызлары, иң явызлары — сөннəр. Башка кыргыйлар арасында алар үзлəренең ныграк оешкан булулары, көчлəре, кораллары белəн аерылып торалар. Үзлəренең җитез атларына атланып, кечкенə-кечкенə алайларга бүленеп алар талау өчен бер туктаусыз Чин җирлəренə һөҗүм итəлəр. Алар кыргый єрткычлар кебек, кыргый кошлар кебек. Аларны яхшылык белəн генə тəртипле итеп булмый. Аларны шулай ук көч белəн дə җиңеп булмый. Аларны бары хəйлə белəн генə җиңəргə мөмкин!

Моннан берничə еллар элек минем якташым, Чжаоның сугыш остасы Лиму, сөннəргə каршы хəйлə кулланып, аларның йөз меңнəн артык кораллы ирен юк иткəн, шунда ук даньлəн кабилəсен кырып бетергəн, дунхуларны пыр туздырып, линху кабилəсен бирелергə мəҗбүр иткəн.

Лимуның бу җиңүе турында Чин йортында, күрəсең, белмилəр яисə, белсəлəр дə, күптəн инде аны онытып бетергəннəр. Бик кызганыч!

Лиму төньяк кыргыйларны җиңə, лəкин ул аларны кырып бетерə алмый. Бу аның хатасы!

Олуг чəнсəн! Күк асты илендə мəңге тынычлык, ирек һəм бəхет ур-

нашсын өчен, төньяк хуларның берсен калдырмый юк итәргә киңәш бирәм. Моның өчен Лиму хәйләсен яңадан кулланып, сөннәрнең кереш тарта алган барлык ирләрен ачык яуда үтереп бетерергә кирәк. Ирләрен юкка чыгаргач, далага басып керү, андагы хатын-кызны, бала-чаганы, мал-туарны кулга төшерү авыр эш булмас.

Сөннәрне ничек кенә булса да барлык көчләре белән сугыш башларга мәҗбүр итәргә кирәк. Һәм тозакка эләктерергә. Монысы иң кыены!

Олуг чәнсән! Мин болай киңәш итәм. Мин, Чжао кешесе, Чжао гадәтләрен, йолаларын яхшы беләм. Чжаоның элекке аксөякләре турында минем күп нәрсәләр ишеткәнем бар. Чжаоның элекке аксөякләре исеменнән мине ялган илче итеп җибәрсәгез, сөннәрне Чингә каршы яуга кузгалырга котырта алыр идем. Ләкин мин үзем генә барсам, алар миңа ышанмаслар дип уйлыйм. Чингә каршы янәсе астыртын эш алып барган һәм, сөннәр чик аша чыксалар, монда корал тотып баш күтәрергә әзер торган Чжао аксөякләре исеменнән мин үземнең бертуган сеңлем Йуны бүләк итеп алып бара алам. Сеңлем минем яшь, матур, нәзакәтле. Җырлый, бии, уен коралларында уйный белә. Ул хәзер изге Шихуанди сарайларының арткы бүлмәләрендә яши.

Олуг чәнсән! Ни өчен мин үземнең бертуган сеңлемне кыргый хуларга илтеп бирергә, үземнең язмышымны шундый куркыныч астына куярга уйладым соң? Моның сере шунда: минем карт, ялгыз әнием бар. Аның ачлыктан, кайгыдан саргайган йөзен күреп минем йөрәгемә кан сава. Үземә тапшырылачак авыр, куркыныч эшне уңышлы башкарып чыга алсам, картлык көнендә мин туган анамның күңелен күрә алыр идем һәм шулай итеп аның алдында үземнең изге бурычымны үти алыр идем дип өметләнәм. Ата-анага игътибарлы булу, бу дөньяда аларга терәк булу — балаларның изге бурычы.

Менә шулар турында уйлап каравыңны үтенәм, олуг чәнсән».

## V

Үзенең Лисы янына үтеп керергә теләге барлыгын ул бары этисенең элекке дустына гына әйтте. Бу турыда Дунто чәнсән сараен саклаучы ирләрнең берсенә — үзенең күптәнге якын танышына җиткерде. Шулай итеп, байлык, дәрәҗә һәм көч иясе Лисының меңләгән сакчылары, хезмәтчеләре аша үтеп, битекче Чәнсинең үтенече тиешле җиренә барып ирешге.

Көннәрдән бер көнне бөтен Җунгода иң атаклы кешеләрнең берсе Лисының өч кат таш койма белән уратып алынган, капка баганаларына чаклы алтын-көмеш калайлар белән бизәлгән биек сараена чакырдылар. Эчке капкадан алып таш болдырга кадәр булган утыз-кырык адым чамасы җирне Чәнси, як-ягына башын калкытып карарга да кыймыйча, яртылаш бөгелеп барды. Болдырга аяк баскач, ике ягында да шомартылган таш баганалары, чигүле ефәкләре булган бүлмәгә чаклы түше белән шуышты.

Беренче килүендә ул олуг чәнсәннең багасына үзенең кемлеген әйтте дә, язулы бамбук таякларын калдырды. Икенче килүендә аны Лисының үзе янына алып керделәр.

— Мин синең таякларыңны укып чыктым,— диде түрдә аякларын бөкләп утырган симез, шома битле, зур корсаклы карт, ияк очыннан сузылып төшкән сирәк сакал төкләрен сыйпаштырып.— Син дөрес язгансың — төньяк хуларны юк итәргә кирәк. Без төньяк кыргыйларның кайда күпме кешеләре, күпме терлекләре барлыгын, кайчан кая күченеп китүләрен, башлыкларының үзара мөнәсәбәтләрен — барысын да белеп торабыз. Ләкин безгә белеп тору гына аз.

— Болай булгач, Лиму... — диде Чэнси ашыгып, башын калкытып.

— Лиму үз урынында, Лисы үз урынында! — диде олуг чәнсән. — Дошманның күп көч белән ябырылып килүен Лиму еллар буе койма эчендә көтеп яткан, шуңа күрә аны курkaклыкта гаепләп урыныннан алганнар. Изге Шихуанди алай көтеп ята алмый. Безгә аның урдасына, киез өенә үтеп керергә, аның ышанычын яулап алып, аңа тиешле киңәшләр бирергә кирәк.

— Мин барысын да аңладым, олуг чәнсән! — диде Чәнси түземсезләнеп.

— Сөннәрне кырып бетергән очракта да, урман араларында, далаларда теләсә кайда таралып яшәүче хулар калачак. — диде Лисы дәвам итеп. — Без кыргыйларны кыргыйлар кулы белән юк итәргә тиешбез. Ике юлбарыс сугышып хәлдән тайса, аларны берәм-берәм үтерүдән дә җиңел эш юк. Синең якташың Лиму да, башкалар да менә бу турыда ныклап уйламаганнар.

— Синең акылың, зирәклегең искиткеч! — диде Чәнси сокланып.

Бай киемле, горур, тәкәббер карт, күзенә туры карап әйтелгән мактау сүзләреннән күңеле булып, ахрысы, кинәт тынып калды, сакалын сыйпаштыргалап беравык утырды да, ягымлырак, җылырак бер тавыш белән ялгап алып китте.

— Анда чыккач, син Банхуа дигән сатучыны эзләп табарсың,— диде ул Чәнсигә.— Банхуа — безнең кеше. Барысын да аның белән киңәшеп, килешеп эшләрсең, уйлаганыңны башкарып чыга алсаң, башыңнан алтын-көмешкә, ефәккә күмелерсең, карт анаң соңгы көннәрен рәхәттә үткәрер, туганнарың җылы, төшемле урыннарга үрләр. Күк асты илендә ун мең ел буена исемең яңгырар. Сөйләң Йуны бирерләр. Калганын барысын да багалар аңлатыр.

Алтын-көмеш белән, ялт-йолт килеп торган шома ташлар, чигүле ефәкләр белән бизәлгән иркен бүлмәдә менә шундыйрак сөйләшү булды. Җиңел генә, үзеннән-үзе генә диярлек ачылып киткән биек капкалардан Чәнси исерек кебек алпан-тилпән атлап чыкты. Ул үз бәхетенә үзе ышанмады. Үзенең чиктән тыш батырлык эшләвен, үзенең шәп кеше булуын аңлаудан аның күз аллары томаланды. Бу вакытта ул сөйләксе Йуны да, карт анасын да нишләптер исеннән чыгарып ташлаган иде.

Сөйләксе Йуны ул бары берничә көннән соң гына исенә төшерде. Башкалада аңа әйттеләр: сөйләкне түбәсе ябулы арбада чик буена озаттык, ул анда синнән алдарак барып җитәчәк, диделәр. Ул, берсүзсез ышанып, чик буена ашыкты. Тиешле җирдә тиешле кешеләрне эзләп тапкач ул чик аша бергәләп чыгачак юлдашлары белән танышты. Шунда ук аңа сарай тоткыныннан котылган сөйләксе Йуны күрсәттеләр.

Баштарак ул аны ничектер танымыйчарак торды — шундый нык үзгәргән иде аның бертуган сөйләксе! Шулай да, күпме генә үзгәрсә дә, ул аны барыбер танырга тиеш иде лабаса! Ләкин ул аны һич кенә дә таный алмады. Үзенең бик каты алдануын күреп ул кинәт артына авып китә язды. Аның каршысында ул белгән, ул күрергә, ул коткарырга теләгән туганы Йу түгел, бәлки бөтенләй башка кыз, ят кыз басып тора иде!

— Йу! Йу кая, Йу?! — дип кычкырды ул үз-үзен белешмәстән.

— Мин Йу түгел, мин — Йуй! — диде кыз уңайсыз елмаеп.

— Сине кем җибәрде? Каян килдең син? — диде Чэнси.

— Шуннан... сарайның арткы бүлмәләреннән,— диде кыз.

— Шулай булгач, син минем сөйләм Йуны белергә тиеш. Кая ул? — диде Чэнси.

— Юк, мин аны белмим,— диде кыз никтер кызарып.

Ул вакытта Чэнси аның кызарынуына бөтенләй игътибар итмәде.

Ул вакытта аның күңеле кырылган, зиһене таралган иде, аның өчен бер нәрсәнең асты өскә килгән иде.

Шулай итеп, үзенең бертуган сеңлесе Йу урынына бөтенләй күрмәгән-белмәгән ят бер кызны алып, ике юлдашы белән ул хәтәр юлга чыкты. Йуй дигән бу кыз, чит булса да, бераз гына әрсез-оятсыз күренсә дә, шулай да чибәр иде. Һәм иң куркынычы да аның менә шул чибәрлеге иде.

Чәнси аңа гашыйк булды. Билгесезлек ягына атлаган беренче адымыннан ук ике ир кеше — үзен һәм «сеңлесен» саклап барырга, Банхуага илтеп тапшырырга тиешле ир кешеләр аңа артык булып тоела башлады.

## VI

Караңгы тарлавыклар, шәрә кыялар аша чыгып, туган җир туфрагына аяк баскач та, күз алдында якын күренешләр ачылгач та, бөтенесе яңадан аның хәтеренә төште. Монда, туган якта, җылы иде, кышның якынлашуы бөтенләй диярлек сизелми иде. Кешеләр җиңелчә киндер киемнәр кигәннәр. Сулар әле туңмаган — шаулап инешләр ага, су өстендә тезелеп үрдәкләр йөзә. Су буйларында — яхшылап эшкәртелгән саргылт туфраклы уңдырышлы җирләр, камыш түбәле балчык өйләр, балчык коймалар; ишәккә, карт үгезгә ике тәгәрмәчле арба җигеп, коры-сары утын төяп таулар ягыннннан кайтып килүче ярлылар. Еракта— җир белән күк арасында, тигезлек өстеннән калкып утырган зәңгәрсу биеклекләр; юл буенда очраган атлылар, кораллы ирләр — болар барысы да Җунго иде, туган җир иде.

Кораллы ирләр... Монда, чик буе җирләрендә, алар аеруча күп. Берәүләр каядыр үзәннәр ягына, көньякка ашыга, икенче берәүләр, киресенчә, каршыга, төньякка, караңгы таулар ягына баралар. Юл буйларында беркая бармаган, ашыкмаган кораллы кешеләр дә очрый. Алар, узган-барган юлчыларны туктатып, кемнең кая, ник баруын тикшерәләр.

Мондагы күренешләргә, мондагы кешеләргә яңадан күнеккәнче Чәнси шактый җир уйланып, хыялланып барды. Ул үзенең төрле сынаулар аша, куркыныч хәлләр аша исән-имин котылып чыгуы турында, юлда очраган кешеләр белән — ярлы игенчеләр, үзен озата баручы кораллы ирләр белән чагыштырганда, бәхетле, бик бәхетле булуы турында уйланды. Инде ул беркайчан тегe якка чыкмаячак, беркайчан Банхуаның җирәнгеч, ерткыч йөзен күрмәячәк. Билгеле, ул инде гүзәл Йуйны да күрә алмаячак. Күрмәсә күрмәс. Җунгода чибәр кызлар бетмәгәндер. Лисы аны алтынга күмәчәк. Байлыгың булса, сине яклардай ышанычлы кешең булса, калганы чүп кенә. Гүзәл кызларны ул кирәк кадәренчә сатып алачак. Иң элек ул үзенә яхшы сарай салдырачак. Өч кат коймалы итеп, Лисыныкы кебек биек капкалы итеп. Капка баганалары буялган, бизәлгән булыр. Капка түбәсендә кораллы сакчы өчен кечкенә бүлмә булачак. Аның сакчысы килгән-киткән кешеләрне шуннан тар ярыктан күзәтеп кенә утырачак. Аның иллеләп аты-арбасы, йөзләп хезмәтчесе булачак. Байлыгы булса, яши белер иде Чәнси!

Киткәндә Лисы аны ошатты кебек. Кайткач ни әйтер, нинди күз белән карар? Бөтенесе аңа бәйле, бөтенесе аннан тора. Ошатса ул аны үз янына киңәшче, булышчы итеп алыр, битекче булса да ярый. Көчле ул Лисы! Теләсә ул бөтенесен булдыра ала. Чин йортындагы барлык эшне шул Лисы башкара, диләр. Хәтта Шихуанди да, имеш, бары аның сүзенә генә колак сала, диләр.

Ташлы юлда арба бик каты дөбердәп, шакылдап барды. Чәнси тәгәрмәчләр шакылдавын да, тупас арбаның як-якка авып-түнеп китүләрен дә сизмәде. Бөтен күңелен татлы хыяллар биләп алганга, ташлы

юлдан дыңгырдап барган арба да аңа су өстеннән җиңел генә шуышып барган көймә сыман тоелды. Шулай бара торгач ул җайлап кына, рәхәт кенә йокыга китте.

Яңадан күзләрен ачып караганда ул үзенең һаман да шул ук арбада селкенгәләп баруын шәйләп алды. Якында гына ниндидер тавышлар ишетелде, кайдадыр ямьсез итеп ишәк кычкырды, кемнеңдер шулай ук ямьсез тавыш белән кычкырып җылаганы яңгырап торды. Төштәге кебек булып, йокы белән бергә татлы хыяллар да артта кала барды. Ямьсез тавышлар белән кычкыра торган, үкереп җылый торган ямьсез чынбарлык аны әкренләп үз кочагына ала барды. Ул теләсә дә, теләмәсә дә, тәрәзә ярыгыннан як-ягына карап-карап алды.

Якында гына, юл буеннан гына, бер-берсенә тотынып барган хәлсез карт белән хәлсез карчык күренеп калды. Карт әнисен исенә төшереп Чәнси шундук тәрәзәдән читкә борылды. Шактый озак баргач ул, яңадан тәрәзәгә үрелде. Юл читендә аунап яткан яшь бала мәете чалынып калды. Аның бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте. Ниндидер биек агач күперне чыгып, яшел үзәнлек уртасыннан бара башлагач, читтә, кечкенә чокыр янында олы кеше мәете күренде. Күмеп тә тормыйча, аны шунда чокыр сыман җиргә ташлап кына киткәннәр иде, ахрысы. Шунда ук шикле кыяфәттә сары, кызыл этләр иснәнеп йөри иде.

Бу күренештә аның эче жу итмәде. Аның эче ташка әйләнде, ташка әйләнде дә бугазына килеп тыгылды. Аның җылыйсы килде, кычкырасы килде. Ул бөрешеп арба кырыена посты һәм шуннан соң бер генә мәртәбә дә юл читенә күз ташламады. Болай да барысы да билгеле иде, барысы да таныш һәм җирәнгеч иде.

## VII

Бер көнне кич караңгы төшәр алдыннан арба туктап калды. Кайдадыр якында гына шаулап су акканы, атлы ирләрнең кычкырып үзара сөйләшкәне ишетелде.

— Җиттекмени? Кайтып җиттекмени башкалага? — дип кычкырды ул тыштагы ирләргә.

— Җиттек. Төш инде,— диделәр аңа ирләр.

Чәнси түбәсе ябулы арбадан иелештереп чыкты да җиргә сикереп төште. Озак утырып килгәнгә аның аяклары оеган, тәне авырайган иде. Төшкәч ул беравык җирне ныклап тоя алмыйча торды. Әле бер аягын, әле икенче аягын язгалады. Шул чакны аны ике яктан ике ир кеше култыклап алды. Нык куллы ирләрнең берсе аның билендәге хәнҗәренә үрелде, икенчесе зур учы белән бугазына тотынды.

«Юлбасарлар!» дип уйлады Чәнси, тынсыз калып. Ул үзен озата килгән кораллы ирләргә кычкырмакчы булды, ләкин аңа кычкырырга ирек бирмәделәр — шундук авызына юеш чүпрәк тутырдылар. Як-ягында бик күп кораллы ирләр күреп ул кинәт шиңеп калды. Аны озата килүчеләр кайдадыр юк булганнар иде. Болары ниндидер башка төрле ирләр, ят ирләр. Тик шулай да алар да юлбасарлар түгел иде, ахрысы.

Этеп-төртеп аны каядыр алып киттеләр. Олы юлдан беркадәр читтә, каршыда ул озынча балчык өй күреп алды. Арырак биек коймалар сузыла иде. Аны койма белән әйләндереп алынган ниндидер ишегалдына алып кергәннәр иде. Юк, монда юлбасарлар оясы түгел, ниндидер дәүләт йорты булырга тиеш иде. «Башкала капкасыннан кергәнче яхшылап тикшерергә уйлыйлар микәнни?» — дип уйлады Чәнси, үз-үзен тынычландырып. Ул тикшерүдән курыкмады — тамгалы яшма ташы аның үзе белән иде.

Аны озынча балчык өйгә алып керделәр. Керделәр дә ниндидер ка-

раңгы, салкын бер бүлмәгә ябып куйдылар. Кулларын артка каерып бәйләделәр, аякларына богау салдылар. Ул берни аңламады. Ул беркемнән берни сораштыра алмады. Төне буена ул ыңгырашып, бәргәләнеп-суккаланып чыкты. Арып-алҗып, хәлдән таеп бары таң алдыннан гына онытылып китте һәм, эт кебек бөгәрләнгән килеш, как, юеш идәндә газаплы йокыга талды.

Күп тә үтмәде, кемдер типкәләп, якасыннан тотып аны аягына бастырды. Йокысы ачылып җитмәгәнгә ул чайкалып китте. Шулай да аңа егылырга ирек бирмәделәр — ике яктан култыклаган килеш, өстерәп диярлек, каядыр алып киттеләр.

Аны киңрәк, иркенрәк икенче бер бүлмәгә алып керделәр. Шул чакны ул үзенең хөкемче — олуг яргучы алдында басып торуын аңлады. Камыш чыпта өстендә аякларын бөкләп утырган, башына салам эшләпә, өстенә керләнеп беткән ефәк халат кигән хөкемче зур башлы, зур йодрыклы һәм куркыныч күз карашлы бер кеше иде. Шулай да ул дәүләт вәкиле иде. Чәнсинең эченә җылы йөгерде — ни әйтсәң дә, юлбасар түгел, яргуласа да, түрә буенча яргулаячак, дөреслекне белгәч, бер сүзсез чыгарып җибәрәчәк, дип уйлады ул.

Хөкемче каршысына китергәч аның авызындагы чүпрәген алдылар, аякларын, кулларын чиштеләр. Үзен иректә сизеп ул иң элек эчәргә су сорады. Зур агач чүмеч белән җылымса су бирделәр. Эчкәч ул, ешеш тын алып, хәл җыеп торгандай итте, авыз читләрен сөрткәләде. Ямьсез, куркыныч карашлы яргучы аның һәрбер хәрәкәтен күзәтеп, сүзсез генә көтеп торды.

— Мин Чәнси...— дип сүз башлады тоткын, яргучының өметсез күзләреннән өмет көтеп.

— Беләм.

— Минем тамгалы яшма ташым бар иде. Аны монда алганнар.

— Анысын белмим,— диде яргучы, кырт кисеп.

— Мин бөек чәнсән йомышын йомышлап, башкалага кайтып барам.

— Мин дә аның йомышын йомышлап утырам,— диде яргучы, тоткынга сөйләргә ирек бирмичә.— Мине монда ул җибәрде!

— Минем тамгалы ташымны, коралларымны кире кайтарып бирергә боерыгыз! — диде Чәнси, кыза башлап.

— Андый боерык алдыннан мин сиңа берничә сорау бирермен, йомышчы Чәнси,— диде яргучы тыныч кына.

— Мин тыңлыйм, олуг хөкемче,— диде Чәнси, үз-үзен кулга алып.

— Син, йомышчы Чәнси, Янан, Хаоши дигән ирләрне беләсеңме? — диде яргучы мәкерле елмаеп.

Чәнси сискәнеп китте. Ул аңлап алды. Ул барысын да аңлап алды. Аның аяк астында кинәт җир убылып киткән кебек булды, аның күз аллары караңгыланып калды.

— Мин аларны беләм, олуг хөкемче,— диде ул төшенке генә.

— Белгәч, алар кайда?

— Алар тегендә калды, олуг хөкемче.

Тезләнгән җиреннән Чәнси кинәт сөрлегеп китте һәм балаларча кычкырып еларга тотынды.

— Мин гаепле түгел! Мин гаепле түгел! — диде ул такмаклап.

— Алар үзләрен үзләре кадап үтерделәрмени? — диде яргучы.

— Алар... мине үтереп, кызны көчләмәкче булдылар,— диде Чәнси кыюсыз гына.

Бу турыда ул инде күптән уйлана иде. Акланыр өчен аның берничнди дәлиле юк. Шулай да иң ышанычлысы, иң дөресе аныңча менә шундыйрак булырга тиеш сыман иде. Аннары бу хакта ул беркем белмәс, белсәләр дә, төпченеп тормаслар дип, төпченсәләр: алар качып киттеләр, шунда торып калдылар, дип әйтермен дип уйлаштырган иде.

— Шулай да булсын,— диде яргучы аның белән килешкәндәй

итеп.— Син, үзеңә тапшырылган кызның намусын саклап, аларны бербер артлы кадап үтердең. Шулаймы?

— Шулай,— диде Чәнси.— Алар мине үтергәнче, мин аларның үзләрен берәм-берәм аркаларына кадап үтердем.

— Шул сүзләрен язып куегыз,— диде яргучы үзенең ике ягында утырган ике битекчегә эндәшеп.

Битекчеләр Чәнсинең сүзләрен язып куйгач, яргучы яңадан сораулар бирә башлады.

— Хулар башлыгы өчен дип җибәрелгән кызны бөек Шихуанди сарайларының арткы бүлмәләреннән алдылар. Син аны белдеңме? — диде ул тоткынга.

— Белдем.

— Бертуган сеңлең Йуны хулар башлыгына бүләккә алып барам дип, олуг чәнсәнгә син битек яздыңмы?

— Мин яздым,— диде Чәнси, шыбыр тиргә батып.

— Сеңлең Йу кайда?

— Бөек Шихуанди сарайларының арткы бүлмәләрендә булырга тиеш,— диде тоткын теләр-теләмәс кенә, тагын да яманрак нәрсә сизеп.

— Сеңлең Йу урынына син Йуй дигән кызны алып бардың. Аны беләсеңме?

— Беләм. Йуй миңа үзенең каян алынуын, кем кызы булуын әйтмәде, олуг дали.

— Ул әйтмәгәнне мин әйтәм! — диде яргучы кинәт күк күкрәгән тавыш белән кычкырып.— Йуй дигән кыз синең бертуган сеңлең Йу белән янәшә бүлмәдән алынды. Син бөек Шихуандинең кырнагы Йуй атлы кызны тиешле кешесенә илтеп тапшырмыйча торып, аңа кул салгансың. Бу — угрылык!

— Мин аңа кул салмадым, олуг хөкемче.

— Сине үз өеңдә... Банхуа тоткан! — диде яргучы үтергеч итеп.

Банхуа исемен ишетү белән, Чәнси урыныннан сикереп торды. Аны кинәт ярсу, нәфрәт биләп алды. Кемнең кемне кочуында, кемнең кемне яратуында ни эшләре бар аларның?! Шихуанди сарайларында ун меңләгән, йөз меңләгән яшь кызлар сөйгән егетләреннән аерылып, кайгыдан-сагыштан саргаеп яталар. Ун меңләгән, йөз меңләгән яшь ирләр, сөекле хатыннарыннан аерылып, чит җирләрдә кан коялар. Нинди тигезлек бу?! Ни эшләре бар аларның, ни эшләре бар?!

— Ялган бу, ялган! — диде ул яргучыга, ярсып, йодрыкларын төйнәп.

Яргучы кораллы сакчыларга керфек какты. Тузына башлаган тоткынны сакчылар шундук эләктереп алдылар, көчләп, төрткәләп ишеккә таба әйдәделәр.

— Ялган бу, ялган! — дип кычкырды Чәнси бөтен өйне янгыратып.

## VIII

Икенче көнне аны тагын яргучы янына алып керделәр. Яргучы яңадан сорау алырга кереште.

— Син Дунто дигән кешене беләсеңме, Чәнси? — диде ул дәртсез генә.

— Белмим. Күргәнем дә, ишеткәнем дә юк.

Яргучы эндәшмәде, бары башын гына калкытты. Шул ук мәлдә дип әйтерлек Чәнсинең артында кемнеңдер ишектән килеп кергәне ишетелде. Керүче кеше түргәрәк узды да, Чәнси каршысында туктап калды. Чәнси керүче кешегә күтәрелеп карады. Шаккатып, куркып йөзен тиз генә читкә борды. Аның каршысында теге Көнбатыш капка янындагы

сакчы алай башлыгының ярдәмчесе, атаклы Чәнинең элекке дусты Дунто басып тора иде! Ул Чәнсидән тазарак, калкурак буйлы. Аннан өлкәнрәк тә, чыныкканрак та иде. Ләкин аны хәзер танырлык та түгел. Күрәсең, бик нык кыйнаганнар иде. Нindидер каты нәрсә белән сугып сул як яңагын ярганнар, күз төпләрен күгәртеп бетергәннәр. Аягында ул көчкә басып тора.

— Менә бу Дунтоны беләсеңме син?— диде яргучы Чәнсигә күтәрелеп карамыйча гына.

Чәнси эндәшмәде.

— Юк, олуг хөкемче, мин аны белмим,— диде ул яргучының үзе кебек үк тыныч, гамьсез булырга тырышып.

— Ялган сөйли башладыңмени, Чәнси? Дөресен сөйләсәң, үзеңә яхшырак булыр.

— Мин аны бөтенләй белмим, олуг хөкемче.

— Әйе, ул мине белми,— диде Дунто, сүзгә катышып.

Аның тавышы каяндыр тамак төбеннән гыжылдап чыкты. Чәнси белгән Дунто — аз сүзле, кырыс, ләкин яхшы күңелле Дунто чынында андый түгел иде.

— Нәрсәне белми соң ул? — диде яргучы, Дунтога карап.

— Ул мине белми.

— Син, Дунто, Чәнсинең атасы Чәни кулы астында хезмәт итмәдеңмени? Атасын яратканга, углын кызганып, син аны үз яныңа битекче итеп урнаштырмадыңмыни?

— Мин аны үз яныма урнаштырдым,— диде Дунто буталып.

— Шулай булгач, ул нәрсәне белми соң, Дунто? — диде яргучы.

— Ул минем Шихуанди сараеның арткы бүлмәләрендә яшәүче Йу атлы кызны коткарырга тырышуымны белми.

Менә нәрсә өчен китергәннәр икән аны монда! Менә кем китереп ташлаткан икән теге бамбук таягын! Әйе, әйе, ул аңа үзенең гүзәл сеңлесе Йу турында сөйли торган иде шул. Йу турында сүз чыктымы, урта яшьләрдәге, кырыс, аз сүзле, ләкин яхшы күңелле Дунто кинәт тынып кала торган иде. Элекке сугышчан дустының балаларын кызганды микән ул, әллә соң аның күңелендә башка төрлерәк уй-хисләр дә булды микән? Хәзер инде каян беләсең аны?!

— Ул тагын нәрсәне белми?— диде хөкемче.

— Ул минем Йу белән хат алышуымны белми.

— Йу атлы кырнак синең белән түгел, абыйсы Чәнси белән хат алышкан. Кем арадашчы булган?

— Мин! — диде Дунто, башын югары күтәреп.

— Языгыз,— диде яргучы ике ягындагы ике битекчегә.

— Улым! — диде шул чакны Дунто, Чәнсигә карап.— Алар мине барыбер үтерәчәкләр. Синең гаебең юк. Бөтенесен Йуй дигән кыз бутаган. Йу белән алар серләшкән булганнар. Йуй синең сеңлең Йуны күзәтче хатынга әләкләгән. Сеңлеңне... Йуны...

Ул әйтеп бетермәде, тотлыгып-тынып калды һәм ике куллап битен каплады.

— Йуны нишләткәннәр?! Йуны нишләткәннәр?!— дип кычкырды Чәнси, Дунтога таба омтылып.

Дунто өчен яргучы җавап бирде:

— Җинаятьче Йуны, тере килеш кайнар суга салып казанда кайнаттылар. Җинаятьне ачарга булышкан өчен, Йуй атлы кыз, үз теләге белән, хулар башлыгына бүләк итеп озатылды. Аны син алып бардың, Чәнси! Синең ялганчы йөзең фаш ителде, синең изге Шихуандигә, Чингә каршы җинаять эшләрең тулысынча расланды. Сине шулай ук үлем көтә!

— Мин Шихуанди өчен, Чин йорты өчен бик кирәкле хәбәрләр алып кайттым! — дип кычкырды Чәнси, аягүрә басып. — Йуның үлеме өчен

гаепләләр җәзасын татырлар әле! Минем монда тоткында ятуымны олуг чәнсән белсә, синең үзеңә дә бик каты эләгер, олуг хөкемче!

Тоткынның ярсый башлавын күреп, кораллы сакчылар урыннарында кымшанып куйдылар һәм икесе дә берьюлы диярлек яргучы ягына карап алдылар. Яргучының бер керфек кагуы белән алар аны, икесе ике яктан эләктереп алып, ерткыч сыман йолкып-ботарлап ташларга әзерләр иде. Ләкин яргучы корбанны сакчылардан ботарлатмады — ул аны үзе ботарлап ташлады.

— Синең карт анаң, барлык туганнарың коллыкка сатылды, Чәнси. Өегез, мал-туарыгыз, барлык байлыгыгыз тартып алынды,— диде ул бер-бер артлы санап. — Син олуг чәнсән җилкәсе артына яшеренеп калмакчы буласың. Ул эш барып чыкмас. Шулай ук теге яктан алып кайткан серле хәбәрләреңә дә өмет баглама. Син инде соңга калдың, Чәнси! Моннан өч көн элегрәк килеп җиткән икенче бер кеше син әйтәчәк хәбәрләрне түкми-чәчми сөйләп бирде. Сиңа Банхуа белән килешеп эшләргә кушылды. Син аны да алдамакчы булдың. Банхуа ахмак түгел — ул барысын да уйлап-белеп эшли.

— Банхуа! — диде Чәнси, тешләрен шыгырдатып. — Мин аны үз кулларым белән буып үтерәчәкмен!

— Йуйны да! Сеңлең өчен, минем өчен! — диде Дунто кан баскан күзләреннән утлар чәчеп.

— Теге дөньяда, теге дөньяда! — диде яргучы дәһшәтле көлемсерәп.

## IX

Чин йортының ваны Инчжән адәм балаларының кайберләре генә ирешә алган бик күп теләкләренә иреште. Унөч яшендә ул тәхеткә утырды һәм, егерме биш ел буена күршеләре белән сугыша-сугыша, җиңә-җиңә, бер-бер артлы алты йортны басып алып, үзе кебек үк ваннарның җирләрен, байлыкларын үз йортына кушты. Арадагы киртәләрне яндырып, йортларын җир белән тигезләп ул бөтен Җунгоны Чин дәүләте ясады. Аның даны Күк асты җирендәге борынгы биш патшаның данын берьюлы күмеп китте, аның көче, байлыгы дөньяда булган барлык ваннарның, патшаларның көченнән, байлыгыннан күп тапкырлар артып китте.

Шундый байлыкка, данга, көч-куәткә ирешкән патша үзенең һаман да башка бик күп бөҗәкләр — ике аяклы, ике куллы адәм балалары кебек үк адәм баласы булып калуы өчен бик хурланды, әлбәттә. Ләкин ул, бик нык теләсә дә, үзенә өченче кул да, өченче аяк та үстерә алмады, шулай ук башкалар кебек каты җир өстеннән йөрмичә, җир белән күк арасыннан йөзеп тә, очып та йөри алмады. Мондый нәрсәләр инде берничек тә аның теләгенә буйсынмый иде! Шулай да, башка бик күп бөҗәкләрдән аерылып тору өчен, ул иң элек үзен Күк углы, алла углы дип игълан итте һәм үз-үзен берлектә «мин» дип түгел, күплектә «без» дип атый башлады. Аннары ул үзен элеккечә Инчжән ван дип түгел, Шихуанди дип атарга боерды. Бу исә бөтен дөньяда беренче патша — беренче Күк углы дигән мәгънәгә туры килә иде.

Шихуанди басып алганчы аның күршеләре — Чжао, Хань, Вэй һәм башкалар гел явызлык, бозыклык белән шөгыльләнделәр. Алай-болай Чин гаскәре берәр ныгытылган шәһәрнеме, авылнымы, иген яхшы уңа торган берәр елга үзәнлегенме сорап килсә, комсызланып ничек тә бирмәскә тырыштылар. Анысы гына җитмәгән, үз җирләрен, калаларын, хатыннарын-балаларын саклап алар хәтта Чингә каршы корал күтәрергә дә батырчылык иттеләр!

Ләкин алар барыбер җиңелде. Гаделлек, тигезлек өстен чыкты!

Шулай да эле алар бик озак Инчжэннең бөеклеген, изгелеген күрмәскә, танымаска теләделәр. Әле булса алар үз сарайларында яшәделәр, үз киемнәрен киделәр, үз көйләрен тыңладылар, үз җырларын җырладылар. Бик зур яманлык, бозыклык иде бу! Караларны — бөҗәкләрне юлдан яздыру, аларны Чин ванына каршы котырту иде бу. Югарыдагы Күк-алла билгеләгән туры, изге, дөрес юлдан читкә тайпылу иде бу!

Күк углы Шихуанди һич тә мондый нәрсәгә түзеп тора алмады. Җир йөзендә ул яңа тәртип — гадел, шәфкатьле тәртип урнаштырырга булды. Бу хакта Күктән изге боерык иңдерелде. Яңа тәртипкә каршы килгән, каршы килергә уйлаган яисә каршы килүе, каршы уйлавы мөмкин булган барлык аксөякләр, кара сөякләр юк ителде, каршылык оясы булган сарайлар җимерелде, элекке кораллар ватылды, элекке тәртипләр үзгәртелде, элеккечә сөйләү-җырлау катгый тыелды.

Бөек Шихуанди бар нәрсәне үзенчә эшләде, үзенчә яңартты һәм үзе керткән яңа тәртипләрнең Күк асты илендә үтәлешен төн-көн үзе тикшереп, күзәтеп кенә торды. Үзенең бер-ике ялагаеннан башка ул дөньяда беркемгә ышанмады. Аның баштанаяк коралланган сакчылары-ялчылары ары-бире чабып яңа тәртип урнаштырып йөрделәр. «Бөҗәк»ләрнең бер өлеше аның өчен иген кырларында, сазлыкларда бил бөктеләр, икенче өлеше чит җирләрдә кан койдылар, калган өлеше — коллар, җинаятьчеләр — тирән коелардан, тау-таш арасыннан тимер, бакыр, тоз чыгарды.

Күк асты иленең иң ерак почмакларыннан аңа тизрәк хәбәр китерү өчен, тауларны кисеп, үзәннәрне киңәйтеп, елгаларга күперләр салып, туры-тигез юллар суздылар. Ул, анда-монда барып, аңа башкаладан читтә төн кунарга туры килсә дип, илнең төрле почмакларында аның өчен җиде йөздән артык сарай салдылар. Сарайдагы бүлмәләргә, аның күңелен күрү өчен, чибәр кызлар тутырдылар, пәрдәләр, чаршаулар кордылар, кыңгыраулар, барабаннар куйдылар. Башкала янындагы Эпангун сарае үзенең зурлыгы, байлыгы, гүзәллеге буенча дөньяда кеше кулы белән торгызылган барлык сарайларны күмеп китәргә тиеш иде. Вэйшуй елгасының көньяк яры буенда Шанлин урманында төзелә башлаган бу сарайның көнчыгыштан көнбатышка сузылган буе — биш йөз бу, көньяктан төньякка сузылган аркылысы — илле чжан[1] булачак иде. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән Эпангун сараен салуда көне-төне җиде йөз мең җинаятьче эшли. Үзенең бөеклеген, изгелеген мәңгеләштерү өчен Күк Углы Шихуанди — Көнчыгыш диңгез, Көньяк диңгез ярларына, биек тау башларына үзен-үзе мактап, язулы ташлар куйдырды.

Әйе, бу дөньяда аның барлык теләкләре, барлык хыяллары тормышка ашты. Аның боерыклары тулысынча җиренә җиткереп үтәлде. Өстендә аның иң яхшы, иң затлы киемнәр булды, өстәлендә иң яхшы, иң затлы ризыклар булды, ятагында аны иң сылу яшь кызлар көтеп ятты. Бөтен Күк асты иле аның күзенә генә карап, аның авызына гына карап, кан калтырап торды. Түрәләр-багалар бары ул кушканны гына, ул кушканча гына эшләделәр; галимнәр, фикер ияләре, дога итеп, аның сүзләрен кабатлады.

Дөньядагы ике куллы, ике аяклы адәм балалары арасында Шихуанди, әлбәттә, иң бәхетле кеше иде. Ләкин шулай да аңа мондый бәхет кенә аз тоелды. Чиндәге барлык бәхетлеләрнең, бәхетсезләрнең язмышын үз кулында тоткан бу бәндә үзен чынлыкта бик бәхетсез дип исәпләде. Озын, юка борынлы, озынча кысык күзле, тар күкрәкле бу чирле-

---

[1] Эпан яисә Эпангун сараеның аркылысы хәзергечә — 170, буе — 800 метр булырга тиеш була. Бу һәм чжан — озынлык үлчәү берәмлекләре.

кәш Күк углын җир угылларыннан беркем дә яратмады. Аннан бары куркалар гына идe.

Адәм булып туганлыктан, кайчагында аңа да башкаларның — үзе кебек ике аяклы, ике куллы кешеләрнең, бигрәк тә хатын-кызның ягымлы күз карашы, чын күңелдән иркәләве кирәк иде. Үзенеке дип исәпләнелгән ун меңләгән, йөз меңләгән чибәрләр арасында ул беркемнең дә чын яратуын, чын якынлыгын тоймады. Аның сизгер күңеле моңа бик кимсенде, хурланды, аның моңа хәтере калды, йөрәге яраланды. Ул моны беркемгә сиздермәде, һәм бу анда дөньядагы үзеннән башка барлык терегә-үлегә карата чиксез нәфрәт һәм кансызлык тойгысы гына уятты. Иң якын кешеләренең дә үзенә куркып, чит итеп карауларын сизенгән саен ул тагын да алардан өстенрәк булырга, кул җитмәслек биеклеккә ерагаерга һәм алардан тәмам аерылырга тырышты.

## X

Күк углының нечкә тойгыларын бары беренче киңәшче — чәнсән Лисы гына яхшы аңлады һәм таштай каты куллы, ерткычтай комсыз, кансыз бу бәндәнең барлык яшерен уйларын-теләкләрен тормышка ашыра барды. Моның белән ул аңа әледән-әле үзенең турылыгын исбат итә алды һәм шул ук вакытта, Күк углының ышанычыннан файдаланып, үз байлыгын туктаусыз арттыра барды.

Шулай бер вакыт ул — олуг чәнсән Лисы — изге Шихуандинең үлем турында сөйләгәнне яратмавына игътибар итте. Күзәтә торгач ул аның — бөек Күк углының үлемнән куркуын аңлап алды. Хатын-кыз тычканнан, таракан ише нәрсәләрдән ничек курка торган булса, Шихуанди дә үлемнән шундый ук чиктән тыш бер курку, кот алыну белән курка булып чыкты.

— Күк асты илендә бик күп галимнәр, күрәзәчеләр бар. Алар кешене мәңге үлемсез итә торганниндидер серле үлән барлыгын беләләр,— диде Лисы бер көнне бөек Шихуандигә.— Синең кебек изге патшаны мин мәңге яшәргә тиеш дип уйлыйм. Әгәр син теләк белдерсәң, галимнәрдән, күрәзәчеләрдән белешеп, мин әлеге серле үләнне эзләп таптыру җаен карар идем, бөек хуанди!

Мондый сүзләр ишетеп Шихуандинең йөзләре балкып китте. Мәңге яшәү, мәңге үлемсез булу һәм мәңге хакимлек итү — аның күптәнге һәм яшерен бер теләге иде.

Лисыга ул Күк асты җирендәге барлык галимнәрне, күрәзәчеләрне, сихерчеләрне җыярга кушты. Галимнәрнең, күрәзәчеләрнең, сихерчеләрнең һәркайсы үзе белгәнне, үзе ишеткәнне сөйләде. Берәүләр әйтте: кешене үлемсез итә торган тере сулы серле үлән юк ул, диде. Икенчеләре әйтте: борынгы китаплардан язылган — булырга тиеш! — диделәр.

Тере сулы серле үлән юк дигән галимнәрне Шихуанди тереләй җиргә күмәргә боерды, тере су бар дигәннәрне үз янында сарайда калдырды. Шуннан соң аларны яңадан бергә җыеп, яңадан төпченә башладылар.

Элекке Чу йортында туган Сүйши әйтте: еракта, көнчыгыштагы тирән диңгез уртасында Пенлай, Фанҗан, Инҗоу дигән утраулар бар, диде. Шул утрауларда изге Күк кешеләре — гаиб ирәннәр яши, тере суның серен белсә алар гына белергә тиеш, диде. Өч мең яшь кыз угылан белән яшь ир угланнар алып, тиешенчә ураза тотып, арыкланып мин шул утрауларны эзләп кайтыр идем, диде.

Күк углы Шихуанди Сүйшинең теләгән үтәргә булды. Ул аңа бик күп акча, ярдәмче кешеләр — коралллы ирләр бирде һәм, диңгез буен-

дагы биләмәләреннән кирәк кадәр яшь кызлар, яшь ирләр җыеп алырга кушып, изге теләкләр, өметләр белән аны билгесез юлга озатты.

Сүйши китеп бер ел үтте, ике ел үтте. Изге сәфәргә киткән кешеләрнең берсе дә кире әйләнеп кайтып тере сулы серле үләнне тоттырмады. Күк углы сизелерлек дәрәҗәдә борчыла башлады.

Былтыр, көзге караңгы бер төндә, Шихуанди үзенең кораллы дүрт сакчы ирен алып, киемнәрен алыштырып, яшерен рәвештә урамга йөрергә чыккан иде. Ул төнге башкала урамнарын, өйләрен күрергә теләде. Әкрен генә, тавыш-тынсыз гына барганда, Ланьчи буасы янында аларга кораллы юлбасарлар очрады. Бөек патшаның коты алынды — куркудан ул хәтта телсез-өнсез калды һәм үзенең җан сакчыларына нинди дә булса боерык та бирә алмады. Җан сакчылар, билгеле, боерык көтеп тормадылар — шундук юлбасарларга каршы ташландылар. Юлбасарларның берничәсе качып котылды, берничәсе, урталай туракланган хәлдә, җир өстендә ятып калды.

Шушы вакыйгадан соң Күк углы үзенең тормышы турында элеккегә караганда да ныграк уйлана башлады. Бернигә карамыйча аның тере суын таптырасы килде. Серле утраулардагы гаиб ирәннәрне табарга дип ул яңадан көнчыгышка бер төркем галимнәр белән кораллы гаскәр җибәрде.

Нәкъ менә шул чагында моннан өч ел элек Сүйши белән бергәләп диңгез уртасындагы серле утрауларны эзләргә дип киткән күрәзәче-галим Лүшән кайтып төште.

— Өч мең яшь кыз, яшь углан белән бергәләп без өч мәртәбә диңгезгә керергә тырышып карадык,— диде Лүшән.— Беренче мәртәбәсендә, ярдан биш йөз ли чамасы ераклашкач, бик каты җил чыгып, давыл купты. Күп кешебезне югалтып, кире борылдык. Икенче мәртәбә кергәч, Пенлай утравына барып җитә яздык. Ләкин шул чакта бик зур балыклар юлыбызга аркылы төште. Өченче мәртәбә чыгуыбызда нинди-дер диңгез еланнары, койрыклары белән сугып, ике көймәбезне капландырды. Пенлай утравына барып җитәргә була, тик көймәләрне балыклардан, еланнардан саклау өчен, безнең белән бергә ике мең көчле укчы ир барырга тиеш.

Лүшәннең сүзләренә Шихуанди бер сүзсез ышанды. Көнчыгыш диңгез буена бару өчен ул куш-мылтык белән коралланган көчле укчылар җыярга боерды. Шул ук вакытта ул Лүшәнгә «Сызымлы күрәзә китабына» карап фал ачарга кушты: Төньякта яшәүче сөннәрне акылга утыртырга кирәк иде. Ләкин бу эшкә алла ничек карар икән?

Фал китабында: «Чинне ху харап итәчәк», дигән сүзләр чыкты.

Анда нәкъ шундый сүзләр чыгачагын Лүшән үзе дә, Лисы да алдан ук белеп тордылар. Хуларның Чинне харап иткәнен көтеп ятмыйча, аларга каршы үзе сугыш ачса, Шихуанди өч-дүрт ел буена тере суы табам, серле утрауларга барып җитәм, дип акча туздырып йөргән Лүшәнне, Сүйшине, алардан да бигрәк, бу хакта беренче булып киңәш биргән Лисыны күпмедер вакытка исеннән чыгарып торачак иде. Бу вакыт эчендә исә, казнадан акча каерып, бераз тагын типтереп яшәргә һәм үзеңнең кайбер эшләреңне җайлап куярга булачак иде.

Бөек патша, никадәр сизгер, оста һәм башлы булмасын, беренче ярдәмчесе Лисының да, ялганчы галим Лүшәннең дә хәйләсенә төшенә алмады. Хакимлегенең утыз икенче елында, тугызынчы айда ул гаскәр башлыгы Ментйәнгә өч йөз меңлек чиру белән Сөн җиренә басып керергә боерды.

## XI

Лисы тарафыннан бик оста оештырылган мәкерле коткыга бирелеп төньяк «ху»лар да Чингә каршы яу чабарга әзерләнделәр. Аларның да,

билгеле, тынычта, рәхәттә, муллыкта яшиселәре килде, ләкин тынычта, рәхәттә, муллыкта яшәү алар өчен таштан, балчыктан өеп биек сарайлар салу да түгел, тауларны, кыяларны кисеп, үзәннәрне үстереп, ике ярына биек коймалар утырткан туры юллар сузу да түгел иде. Алар өчен бай, рәхәт тормыш шулай ук бар илдәге яшь кызларны җыеп, аларны ефәк чаршаулар артында, кыңгыраулар, барабаннар янына ябып яткыру да түгел иде. Ир угланны алар яу өчен туган дип, кыз угланны — ир углан өчен туган дип исәплиләр.

Ат-сыер белән бергә үскән сөннәргә башкасы кирәкми дә. Диңгез уртасындагы серле утраулар да, серле үләннәр дә кирәкми иде! Аларның җирләре — житәрлек, сарайлары — далалары иркен иде.

Моннан утыз ел чамасы элек Чжаоның гаскәр башлыгы Лиму сөннәрнең бик күп кешесен харап итеп, дала җирләрне басып алгач, сөннәр бик нык хәлсезләнеп калганнар иде. Сөн иленд́ә йөз мең, ике йөз мең сугышчыны бергә җыю ул барлык халыкның иң таза, иң яшь, булдыклы өлешен бергә туплау дигән сүз иде. Шул кадәр күп кеше — халыкның иң таза, эшчән, булдыклы өлеше алай-болай яуда җиңелеп, кырылып бетсә, дошман ягында калса, бу инде Сөн иленең тамыры кору белән бер булачак иде һәм Сөн иленең беркайчан да аякка баса алмавы мөмкин иде.

Лиму белән канлы сугыштан соң нәкъ шулай булды да. Ләкин бу хәл инде күптән булып узганга, күпчелек аны онытып бетерә язган иде. Лиму белән сугышта катнашкан ирләрнең күбесе инде үлеп беткән, исән калганнары исә — хәлсез картлар. Ул чакта Туман каган да, аның субашлары, алыплары да, күп кенә бәкләр дә — барысы да балалар иде. Аның бүгенге көндәге атаклы ирләренең күпчелеге шулай ук хурлыклы җиңелүне үзләре күргән, үзләре татыган кешеләр түгел. Лиму турында, җиңелү турында алар бары ишетеп кенә беләләр. Шуның өстәвенә алар моннан җиде-сигез ел элек Туман каган житәкчелегендә элекке Сөн җирләрен — Лиму басып алган Арьякны яңадан, яулап алуда катнашкан кешеләр иде. Шунлыктан алар үзләрен җиңелүчеләр дип түгел, бәлки җиңүчеләр дип исәпләргә күнеккән иде.

Менә шуңа күрә дә сөн ирләренең күпчелеге яуга олы туйга, ярышка барган кебек атлыгып, ашкынып бардылар да. Куанкының сул ягында, Урта кичү янындагы тау аралары — тын үзәннәр, якындагы комлы далалар берничә көн эчендә атлар, кешеләр белән тулды.

Барлык бәкләр билгеләнгән вакытка, билгеләнгән урынга килеп життеләр. Ләкин елга аша әле чыгарлык түгел, Куанкыны тулысынча боз тотмаган иде — бөек елганың кичү турысында, уртада, кап-кара булып, җанлы булып су агып ята иде. Чин җирләренә керү өчен иң элек менә шушы кичү аша чыгарга һәм Арьяк далаларында таралып, анда бераз атларга, кешеләргә ял бирергә кирәк. Күп санлы атлар, кешеләр белән Арьякка бары боз өстеннән генә чыгып булган кебек, сугыш вакытында чигенергә туры килсә дә, елганың сул ягына шулай ук боз өстеннән генә чыгарга кирәк булачак иде. Чин ягына башка юл юк.

Кичүгә килеп житү белән, Туман каган үз өенә барлык бәкләрне, субашларын олы киңәшкә җыйды. Аның елганы тулысынча боз тотканын көтеп торасы килмәде. Бу якта алты йөз меңләп ат, дөя өчен көтүлекләр өч-дүрт көннән артыкка житәрлек түгел. Шул кадәр күп терлек-туарны бары тик Арьяк далаларында гына исән-имин саклап калып булачак иде. Атлар хәлсезләнә, кешеләр йөгәнсезләнә башлаганчы, мөмкин кадәр тизрәк тегеяк ка, куе үләнле болыннар ягына чыгарга, олы яу алдыннан тиешенчә көч тупларга кирәк иде.

Күрәзәчеләр әйтте: елгага аяклары бәйләнгән җирән үгез корбан итеп бирергә кирәк, диделәр, шулай итсәң, иртәгә үк суны боз тотар,

диделәр. Өлкәнрәк сугышчылар әйтте: мондый чакта суга элекке заманнарда камыш, чыбык-чабык көлтәләре бәйләп ташлыйлар иде, диделәр.

Туман каган көрәзәчеләрне, карт, тәҗрибәле сугышчыларны да тыңларга булды. Көрәзәчеләр, су иясенә багышлап, аяклары бәйләнгән җирән үгезне корбан иттеләр. Шул ук вакытта барлык ирләргә берәр көлтә бәйләргә дигән боерык бирелде.

Бер көн эчендә Урта кичү тирәсендә, елга яры буенда, камыш, чыбык-чабык көлтәләреннән таулар өелде. Елганың бер ягыннан икенче ягына, биш-алты турыдан кыл-аркан суздылар. Камыш, чыбык көлтәләрен, югары менеп, агым уңаена агызып җибәрделәр. Җиңел көлтәләр арканнарга эләгеп калды. Суга чыланган чыбык-чабыкка, камышларга боз сарылды. Бер кат көлтә күпере өстенә тигез итеп икенче кат көлтә җәйделәр, су сибеп аларын да туңдырдылар да, атлар таймасын өчен, көлтәләрне өченче кат түшәделәр.

Елга аша аркылысы илле адым чамасы булган шундый өч күпер салынды. Боз күпернең ныгыганын, калынайганын көтәр-көтмәстән, әзәзләп кешеләрне, терлекләрне икенче якка чыгара да башладылар.

Өч ягыннан — көнбатыштан, көнчыгыштан һәм төньягыннан бөек елга белән чикләнгән, аркылысы-буе өч йөз чакрым чамасы булган Аръяк далаларында вак-вак күлләр дә, елгалар-инешләр дә һәм терлек аягы басмаган яхшы көтүлекләр дә җитәрлек. Чин белән чиктәш булганга һәм моннан торып яу чабарга уңай булганга, бу яктагы көтүлекләр гаскәр өчен дип саклап тотыла, каганнарның кышлау җирләре санала иде.

## XII

Аръяк далаларында сөннәргә буйсынган бәйди, ләүфән кабиләләре яши иде. Чин белән чиктәш җирләрдә, көньяктарак сөннәрнең чик сакчылары тора. Монда шулай ук чин качакларыннан оешкан кечкенә авыллар да бар. Чин авылларының күбесе елга буйларына урнашкан иде. Алар анда, көтүлек өчен уңайсыз сазлы, ташлы җирләрдә, дөге игеп, яшелчә үстереп, балык тотып көн күрәләр. Менә шундый һәрбер авылда диярлек чиннәрнең ышанычлы үз кешеләре — шымчылары, озынколаклары бар иде. Сөннәр ягындагы һәр яңалыкны, һәр үзгәрешне алар теге якка җиткереп кенә торалар.

Бөтенесе җентекләп уйланылган яшерен хәйлә буенча эшләгәнгә күрә, Туман каганның кичүгә кайчан киләчәген дә, күпме көч белән киләчәген дәМентйән алдан ук белеп торды. Сөн чирүе, елга аша чыгып, Аръяк далаларында тарала башлагач, шулай ук аларның һәрбер хәрәкәтен ул ерактан ук белеп, күзәтеп торды.

Ментйән башлы, сак һәм кыю субашы иде. Ул сугыш турындагы борынгы китапларны биш бармагы кебек белә, ләкин шулай да китапларда язылганга сукырларча ябышып ятмыйча, шартына, урынына карап, һәр нәрсәне үзенчә хәл итәргә тырыша иде.

Төньяк чик буеннан башкалага эш белән килгәч, бервакыт олуг чәнсән аны үз янына чакырып алды. Ул аңа теге битекче Чәнси язган киңәшне укып чыгарга кушты.

— Син Лимуны беләсеңме, субашы? — диде аңа Лисы.

— Белмичә! Чжаоның атаклы гаскәр башлыгы Лимуны тар-мар итүдә катнашкан кеше ләбаса мин! — диде Ментйән.

— Юк, син аның әнә анда язылганча, хуларны ничек алдап җиңүе турында беләсеңме? — диде Лисы.

Ментйән бу юлы җавап бирергә ашыкмады.

— Мин анысын да беләм, олуг чәнсән,— диде ул бераздан уйла-

нып.— Чжао ваны, Лимуны куркаклыкта гаепләп, урыныннан гына алган. Лиму кебек мин чик буена сөннәрне алдап китерәм дип, балчык коймалар эчендә бикләнеп ятсам, менә җинаятьтә гаепләячәкләр, башымны чаптырып, базар мәйданында казыкка элеп куячаклар.

— Мин сине коймалар эчендә бикләнеп ятырсың дип өметләнмим,— диде аңа Лисы.

— Мин уйлап карармын, олуг чәнсән,— диде Ментйән туры гына җавап бирмичә.

— Синең өчен алдан барысы да уйланылган инде, субашы! — диде аңа каршы Лисы.— Сиңа бары ныклап торып сугышка әзерләнергә генә кирәк булыр. Калганын барысын да мин үзем җайлармын.

Бу сөйләшү моннан ярты ел чамасы элек булды. Лисы янында Ментйән Лиму белән булган вакыйгага исе китмәгән булып күренергә тырышса да, сөнгә каршы сугышка әзерләнергә дигән яшерен боерык алгач, ул аның белән ныклап торып кызыксына башлады. Барыннан да элек ул элекке Чжао ирләрен эзләтеп таптырды, алардан Лиму турында, моннан бик күп еллар элек булган атаклы сугыш турында, сөннәр турында сораштырырга тотынды. Сөннәр елга янына якынлашып килгәндә, ул инде күптән барысын да уйлаган, барысын да әзерләгән иде. Ул бары алар белән очрашуны гына көтә иде.

Озакламый сөннәр елга аръягына күпләп-күпләп чыга башладылар, чыкканнары бере Аръяк далаларына тарала барды.

Ментйән, Лиму тәҗрибәсен исендә тоткан хәлдә, барына күз йомып карарга, берниндн тынычсызлану билгесе күрсәтмәскә боерды. Бары күзәтү манараларындагы ирләр генә төне-көне дала ягын күзәттеләр дә, офыкта караеп атлы төркемнәр күренү белән, кипкән бүре тизәге яндырып, күккә төтен үрләттеләр. Һәм бик тиз арада чик сызыгы буенча сөн атлыларының якынлашуы турында шомлы хәбәр таралып өлгерде. Ментйәннең нык өйрәтелгән батыр ирләре, тыннарын кысып, каерылып капкалар ачылганны көттеләр. Ә сөннәр берни аңышмый иделәр. Ментйән сөннәрнең бер кешесе калмыйча бу якка — бөек елганың уң ягына чыгып бетүен генә көтте. Сөннәр исә нишләптер кичү аша чыгуны озакка суздылар.

Кичүдә сөннәр өчен көтелмәгән тоткарлыклар килеп чыкты. Үзәктәге күперне уң кул белән сул кулдагы күперләрдән бераз кичегебрәк салдылар. Бу турыда боз тотмаган су да киңрәк, агым да көчлерәк иде. Бер яктан икенче якка кыл-аркан тартканда, көймәгә утырып икенче якка ишә-ишә түбәнгә таба агып барган ирләрнең берсе, аягы таеп, суга егылды. Аны коткара алмадылар, ул шундук су төбенә китте. Мондый хәлне күреп, башкалар каушап калды һәм, башланган эшләрен җиренә җиткерә алмыйча, икенче якка, боз өстенә чыктылар. Боз ватылып анда тагын өч кеше су төбенә китте.

Бу хакта белгәч, каганның сул күз кабагы тартыша башлады. Су иясе күпер салуга каршы иде! Су иясенә багышлап ул тагын аяклары бәйләнгән бер үгез белән бер кара тәкә бирергә боерды. Икенче көнне күрәзәчеләр суга зурлап корбан бирделәр, күпер салынуын сорап, таңрега келәү әйттеләр. Туман каганга бу да бик аз тоелды. Ул комсыз ирләр төнлә Чин ягыннан әсир итеп алып кайткан ике чинне сугыш алласына корбан итеп бирергә кушты.

Бары менә шул эшләрне башкаргач кына каганның күңеле бер урынга утыргандай булды. Төнлә бик каты суытып җибәрде. Шундый нык суытты — якындагы урманнарда шартлап агачлар ярылды, кыя башларыннан ташлар ычкынып төште. Иртәнчәк, туң җир өстендә үлеп яткан берничә атны күреп, беркем дә моңа кайгы белдермәде. Киресенчә, суыктан атлар туңып үлүен изгегә юрадылар. Димәк, су иясе дә, сугыш-яу алласы да аларның теләгенә колак салганнар! Димәк, Чингә юл ачык!

Ул төнне елганы аркан сузып көлтәләр ташламаган төшләрдә дә тулысынча боз тотты. Ләкин шулай булуга да карамастан, Туман каганның икенче якка чыгарга нишләптер һаман аягы тартмады. Ул яңа ай башын көтәргә булды.

Гаскәренең бер өлешен чыгарып та каган үзе бу якка чыкмагач, Ментйән дә, теләсә-теләмәсә дә, көтәргә мәҗбүр булды. Аннан соң ул кичү ягына үзенең махсус кешесен җибәргән иде. Кеше билгеләнгән вакытка кайтып җитмәде. Яңа ай башына кадәр ике көн вакыт калды. Чик буйларында сөннәрнең зур-зур төркемнәре күренгәли башлады. Чик буе халкы куркып көньякка качыша башлады. Күзәтү манараларының әле берсеннән, әле икенчесеннән бөркелеп күккә төтеннәр күтәрелде.

Яңа ай башына бер көн калды. Кичүгә җибәрелгән кеше әле булса кайтып җитмәде. Ментйән өчен артык көтеп торуның кирәге юк иде. Тугызынчы айның утызынчы көнендә, салкын бер иртәдә барлык чик буендагы таш, балчык коймаларның киң капкалары ачылды, капкалардан дала ягына ташкын булып гаскәрләр ыргылды.

## XIII

Чин гаскәрләре Сөн җиренә йөзәр мең, йөзәр мең булып өч яктан басып керделәр. Сөннәрнең аз санлы чик сакчылары һәм шулай ук далада аңда-монда очраган вак-төяк алайлары шундук юк ителде. Шулай да аларның беркадәр өлеше, чиннәрнең зур көч белән ябырылып килүләрен күреп, төньяк далаларга качып киттеләр.

Төп көчләрнең капма-каршы килеп очрашуы сөннәр өчен бөтенләй диярлек көтмәгәндә булды. Алар әле ял итәләр, күктә яңа ай урагы күренгәнен көтәләр иде. Чиннәрнең шул кадәр көч белән, шул кадәр ябырылып килүләрен алар бөтенләй көтмәде.

Ментйәннең күп көч белән берничә урында чик аша үтүе турында ышанычлы хәбәрләр алынгач, Туман каган, барлык икеләнүләрен җиңеп, яңа ай тууын да көтеп тормастан, үзәкне тәшкил иткән үз чирүен дә елга аша чыгарды. Тәбәнәк, чыдам атларында нык утырган, җилдавылның карлысын да, комлысын да, уклысын да күп күргән сөн ирләре ярсып яуга ташландылар.

Елгадан бер көнлек ераклыкта, бар яктан да ачык шыр далада, тигез җирдә чиннәрнең алгы алайлары белән сөннәрнең алгы алайлары капма-каршы килеп очраштылар. Бар яктан да ачык шыр далада, юка гына кар каплаган туң далада беренче канлы сугыш булды.

Ул көн кояшлы иде, җилсез иде. Сугыш иртәге күлемдә, кышкы кояш аксыл җир өстеннән ике сөнге буе күтәрелгәч башланып китте. Беренче булып чиннәр һөҗүм иттеләр. Кояш яктысы аларга аркан иде— алар, күрәсең, шул уңайлыктан файдаланып калырга тырыштылар. Үзләренә каршы яктагы сөннәрне алар яхшырак күрде. Аларның уклары турырак очты, күбрәк яралады, күбрәк үтерде. Әле анда, әле монда туң җиргә шапылдап ирләр егылды, шакылдап авыр кораллар, калканнар төшеп китте; ачы чинап-кешнәп яралы атлар тәгәрәште. Сугышчыларның бакыр, тимер, сөяк-таш белән ныгытылган каты киемнәренә шык та шык килеп уклар тиеп китте; тимәгәне, куркыныч сызгырып, баш өстеннән очып үтте. Сөннәрнең алгы тезмәсе тиз арада сирәкләнеп калды. Арттагылар, чиннәрнең бик каты кысрыклавын күреп, чигенә үк башладылар.

Ләкин чигенә башлаган сөннәргә вакытында арттан ярдәм килеп җитте. Сөннәргә яңадан җан керде. Хәзер инде чиннәр каушап калдылар. Дошман өстенә янгыр булып уклар яуды. Чиннәр ягында үлүчеләр, яраланучылар күбәеп китте һәм бер мәлне, туктаусыз очкан ук

янгырына чыдый алмыйча, Ментйән гаскәрләре борылып качыша башладылар. Рухлары күтәрелеп киткән сөн ирләре, бар көчләре белән ябырылып, качучылар артыннан ыргылдылар һәм туктаусыз ук атаата, дошманны бер өзлексез кысрыклауларында булдылар. Алгарак узып киткәннәр, чиннәр арасына кереп, кылыч, сөңге сугышы башлап җибәрде — качып баручыларны кылыч белән чаптылар, сөңге белән кададылар. Туктаусыз дөпелдәп, ташкын булып барган меңләгән ат тояклары астына, җир өстенә иярләреннән аерылып, авыр гәүдәләр барып төште, сынган сөңгеләр, каешы өзелгән ук-җәя савытлары төшеп калды. Тояклар таптап бозга әйләнгән карлы җир өстендә, әле анда, әле монда кызыл кан таплары җәелеп калды. Елан сурәте төшерелгән яшел байракларын, алтын бүре, бөркет башы беркетелгән озын тугларын югары күтәреп, тезгеннәрен ирекккә җибәреп, ярсып, куанып сөннәр Ментйән гаскәрен шактый озак кудылар.

Бервакыт алар сугыш башланып киткән языдан бик нык ерагайдылар. Качып баручы чиннәр төркеме сирәгәйгәннән-сирәгәйде. Инде аларны бөтенләй куып җитеп, тәмам турап, чәнчеп ташларга да күп калмаган иде сыман. Ләкин шул чакны алда сирәк урман белән капланган калкулык күренде. Качып баручы чиннәр ничек тә шул калкулык артына җитәргә тырыштылар. Сөннәргә исә анда житкәнче үк аларны турап, юкка чыгарып бетерергә кирәк иде.

Ләкин куучылар кирәгеннән артык мавыгып киттеләр. Калкулык артында тагын бер кечерәк калкулык күренде. Тирә-як шикле рәвештә үзгәрә башлады. Менә шундый калкулыклар, әрәмәләр артында чиннәрнең яшеренгән көчләре булуы ихтималы турында куучылар башларына да китереп карамады. Сирәк урман белән капланган калкулыкка якынлашкач та, тыелгысыз ташкын булып бар көченә чабып килгән, бөтен тирә-якны кара болыттай каплап килгән сөннәр өстенә кинәт уңнан да, сулдан да куркыныч уклар ява башлады. Калкулык итәгендәге куаклыкларда, урман араларында, чокыр-чакырларда чиннәрнең нык өйрәтелгән укчылары яшеренеп яткан икән.

Сөннәрне әлеге калкулык тирәсенә алдап алып килгән чин алайлары корал тота алган, атта утыра алган төрле җинаятьчеләрдән оештырылган иде. Ментйән аларны алдан ук шулай алдавыч итеп әзерләде. «Хуларны җиңсәгез, сезгә ирек биреләчәк», диде ул аларга. Шуңа күрә дә алар баштарак сөннәр белән шулай бик каты сугыштылар да.

Сөңгедән кечерәк авыр уклар белән яисә, киресенчә, кечкенә сөңгеләр белән ата торган чин мылтыклары дала җайдаклары өчен иң куркыныч корал исәпләнелә. Чиннәр аны әле күптән түгел генә куллана башлаганнар иде. Керешен аяк терәп тарта торган бу куркыныч мылтыкның ук-сөңгесе бик еракка оча һәм теләсә нинди каты киемне, теләсә нинди калканны үтә-сүтә тишеп чыга ала иде.

Сөн ирләренең күпчелеге җиңелчә киенгән, җиңелчә коралланган иде. Кайбер ярлырак сугышчыларның катырылган үгез тиресеннән, я булмаса киң тояклардан, сөякләрдән, юка ташлардан теркәп тегелгән киемнәреннән, агач калканнардан башка бернинди саклану чаралары юк. Бары тик бәкләрнең, алып ирләрнең генә өс-баш киемнәре, калканнары тимер, бакыр белән ныгытылган иде.

Төрле яктан очкан сөңге-уклар туп-туры атлылар арасына килеп төште. Кот очыргыч бер дәһшәт белән, көч-куәт белән очып килгән чин уклары берсенең күкрәгенә килеп тиде, икенчесенең яңагын җимереп китте, өченчесенең атын бәреп екты.

Чиннәрне таптап үтәбез, сытып бетерәбез дип очынып-җилкенеп барган сөн ирләренең куркусыз йөрәкләренә кинәт шом йөгерде. Ташкын читендәгеләр, эшнең болайга китүен күреп, тизрәк табан ялтырату ягын карадылар. Алдагылар, уртадагылар, бер кая да борыла алмыйча, читенә алмыйча, туп-туры үлемнең авызына барып керделәр.

Алдагыларны чин мылтыкчылары кырган чакта, арттагылар кинәт борылып кача башладылар. Шул чагында Ментйән якында гына яшеренеп яткан төп көчләрен чыгарды. Качып барган, таралган, каушап калган сөн гаскәрен ачык далада тар-мар итү чиннәргә әллә ни авыр булмады.

Кечкенә бер елга буенда качучылар шулай да тоткарланып калдылар һәм борылып дошманга каршы сугыш башлап җибәрделәр. Ләкин киң далага җәелгән качучы гаскәрнең күп өлеше, тишек савыттан ага башлаган кымыз кебек, сугышка катнашмыйча, берән-сәрән елга аша чыгып, кичүгә таба элдерде. Чин мылтыкчылары котларын алган сөн ирләрен инде берни дә, беркем дә тоткарлый алмас кебек иде.

Качучыларның беренче төркемнәре кичүгә караңгы төшкәндә килеп җиттеләр. Беренчеләр артыннан икенче төркемнәр килеп җитте, икенчеләре артыннан өченчеләре кысрыклады. Берьюлы меңләгән, ун меңләгән атлар, кешеләр килеп тыгылгач, боз өстендә буталыш, ыгы-зыгы башланды. Шома бозда атларның аяклары тайды, әле анда, әле монда атлар егылды, атлары белән бергә боз өстенә кешеләр барып төште. Караңгыда бик күпләр, көлтә җәелгән күперне аермыйча, туп-туры шома боз өстеннән киттеләр. Уртада боз тотып җитмәгән ачык урыннар калган булып чыкты. Кешеләр, атлары-ниләре белән, авыр коралլары белән, ургылып аккан суга барып керделәр һәм, җан ачысы белән кычкыра-кычкыра, мәңгегә юкка чыктылар.

Елга ярына якын бер уңай җирдә сөннәр тагын бер мәртәбә чиннәргә каршы торырга тырышып карады. Ләкин тулы җиңелүдән аларны инде берни дә коткарып кала торган түгел иде. Куып килүче Ментйән ирләре, кичүгә якынлашкач, атларыннан төштеләр дә янә куркыныч мылтыклардан ата башладылар. Бу исә сөннәр арасындагы буталышны тагын да ныграк арттыра төште. Күзләренә ак-кара күренмәгән кешеләр, котылу эзләп, үзләренең туган якларына — иксез-чиксез далага омтылдылар.

Аръяк далаларында тау-тау үләләр калдырып, елганың уң ягында, күпердә — боз өстендә кычкырган, ашыккан, коты алынган сугышчыларын калдырып, Туман каган төньякка элдерде. Аның янында нибарысы ун мең чамасы ирләре калган иде.

Караңгы төшү сәбәпле, Ментйән елга аша чыгарга батырчылык итмәде. Чиннәр, төзәп-нитеп тормыйча, кораллары беткәнче кичү ягына аттылар-аттылар да, елганың уң як яры буена таралып, арып-алҗып йокыга талдылар. Икенче көнне таң ату белән алар сул якка чыкты. Анда торып калган бик күп арбаларны, терлек-туарларны, яралы, гарип, хәлсез кешеләрне кулга төшерделәр.

Ментйән Туман каганны куа китте. Каганның артына җитмәкче булып ул сөннәрне бер айга якын куып барды. Ләкин иксез-чиксез буш далада чиннәр туңып үлгән атлардан, анда-монда аунап яткан кеше мәетләреннән, анда-монда туктап калган, күчәре сынган, тәртәсе каерылган арбалардан башка берни тапмадылар. Далада әрле-бирле буталып йөргәннән соң чиннәр, ашарларына бетеп, кире көньякка борылдылар.

## XIV

Түрә буенча каганның өлкән бичәсеннән туган өлкән углы уң кул тучи бәк яу вакытында уң кул чирүгә субашы булырга тиеш иде. Ләкин Туман каган бу юлы түрә белән исәпләшмәде — уң кулның житмеш меңлек чирүен ул шикле углына ышанып тапшыра алмады. Уң кулга Туман каганның бертуган энесе Кара-Тирә би җитәкчелек итте.

Чәнсине Тарлавыкка илтеп тапшыргач Албуга Урта кичүгә көчкә

килеп җитеште. Юлда тагын берәр ничек тоткарланган булса, күрәсең, ана башы белән саубуллашырга туры килгән булыр иде.

Үзенең мең кешелек чирүе белән ул Кара-Тире би кулы астында сугышты. Кичүне чыгып, Арьяк далаларында урнашкач, Кара-Тире би аны үз янына чакырып алды. Кара-Тире би туры сүзле, тик бераз кискенрәк, тупасрак кеше иде.

— Олуг уң кул тучи бәк! — диде ул Албугага эндәшеп.— Агам каганның сине читкә тибәрүен мин өнәп бетермим. Мин сине туры ук астына җибәрмәячәкмен. Син үзең кайда булырга телисең?

— Син кая куйсаң, мин шунда булачакмын! — диде уң кул тучи бәк Албуга күп уйлап тормыйча.

Аның ачык җавабы бигә ошады.

— Син артта булырсың,— диде ул аңа.

— Юк, мин иң алда булырмын, Кара-Тире би! — диде Албуга.

— Син бер генә төрле сөйләш, олуг уң кул тучи бәк,— диде би.— Башта уйла, аннан әйтерсең.

— Мин инде уйладым: мин яуга беренче булып ташланачакмын, Кара-Тире би! — диде яшь углан кайнарланып.— Минем батырлык күрсәтәсем, атам каганга турылыклы булуымны белдерәсем килә! Яуда дошман башын чабып алып, атам каганның аягы астына китереп ташлыйсым килә, атам каган кулыннан буза эчәсем килә!

— Синең теләгеңне мин истә тотармын, олуг уң кул тучи бәк,— диде Кара-Тире би, аның мондый теләгенә артык куаныч белдермичә.

— Минем турыда атама яхшы яктан гына сөйлә, Кара-Тире би,— диде яшь углан.

— Мин синең сүзләреңне каганга җиткерермен,— диде Кара-Тире би.

Менә бу сөйләшү турында Албуга соңыннан кайта-кайта уйланды. Бу сөйләшүдә аңа нәрсәдер ялган булып, кирәксез булып тоелды. Кара-Тире бинең аны алдан ук никтер кисәтергә теләве ялган идеме, әллә соң үзенең би алдында кирәгеннән артык атлыгып торучы булып күренүе ялган идеме?

Ни булса булды, Кара-Тире би аның теләген аяк астына салмады. Ул аны туры маңгайга куйды. Яуга уң кул тучи бәк беренче булып ташланды. Ләкин аңа әллә ни батырлыклар күрсәтергә туры килмәде, шулай ук этисе каганның аягы астына үтерелгән дошман башын китереп ташлап, аның кулыннан буза эчәргә дә насыйп булмады. Сирәк урман белән капланган калкулык янындагы куркыныч үзәнгә аның мең кешелек алае ташкын уртасындарак барып керде. Чин уклары аның кешеләре арасына килеп төшә башлаганда, аларга инде артка борылырга да, читкә чыгып, дала ягына таярга да мөмкинлек юк иде. Алар, язгы ташу агызып алып киткән чүп-чар кебек, агач ботаклары кебек, тыелгысыз рәвештә туры упкынга барып керделәр. Каршыдан, як-яктан очкан сөңге-уклар аның иң якын егетләрен егып салды. Куркыныч ук-сөңге иң элек Кәлтәнең атланган атына тиде, аның муенын тишеп чыкты. Кәлтә җиргә егылып калды. Икенче ук бер егетнең эчен тишеп чыкты — ул шулай ук егылып калды. Өченче ук Бавырның атын чөйлектерде. Боларның барысы да Албуганың күз алдында булып үтте. Үз егетләренең ул кинәт кычкырып җибәрүләрен ишетте, җан-фәрманга чабып барган атларыннан ычкынып-ычкынып калуларын, ямьшәйгән кызганыч йөзләрен үз күзләре белән күреп калды. Бер мәртәбә куркыныч ук аның яңагы яныннан гына ыжгырып үтте. Ул ярсып: «Алас! Алас!» дип кычкырып җибәрде. Шул ук мәлдә Тишек-Ташның бар көченә кычкыруын ишетеп ул ялт кына уң ягына әйләнеп карады — куркыныч ук Тишек-Ташның күкрәгенә килеп кадалган иде, ул арты белән атыннан төшеп, авып бара иде.

Үлем угы аның үзенең атына да тиде — тимерле маңгаена шап итеп

кадалды. Албуга хәтта маңгай тимеренең, маңгай сөягенең шытырдап ватылганын да ишеткәндәй булды. Бичара ат, авыртуга чыдый алмыйча, кызганыч итеп чинап, кешнәп җибәрде һәм, маңгайдагы ук тимерен селтәп-алып ташларга теләгәндәй, башын каты чайкап, кинәт тигезләнгән югалтты, сөрлекте һәм авыр гәүдәсе белән, өстендәге кешесе-ние белән каты җиргә барып төште.

Ул егылды. Аның сул аягы атның корсагы астына туры килде. Аның яныннан, өстеннән корсак асларын күрсәтеп, башка атлар чабып үттеләр. Аның битенә, күзенә тояклардан ычкынган каты кар, балчык кисәкләре килеп тиде. Бер заман аның янына яралы ат гөрселдәп килеп төште. Якында гына кычкырган, елаган, йөрәк өзгеч тавышлар белән кешнәгән авазлар ишетелде. Меңләгән тояк тавышларының каты җир күкрәгенә тибеп барабан кагулары, көчле, дәһшәтле булып яңгырап торды-торды да, кинәт барысы да тынып калды.

Шуннан соң ул башка берни ишетмәде, берни күрмәде. Аны үле ат гәүдәләреннән дә авыррак, куркынычрак булып, ниндидер караңгылык, томанлык каплап алды.

## XV

Күпмедер вакыт үткәч, ул айнып-уянып киткәндәй булды. Каяндыр астан, ян-яктан салкын бәрә иде, аннары өстенә һаман да ниндидер зур, иләмсез нәрсә басып тора иде. Уянгач ул үзенең кайдалыгын чамаларга тырыша башлады. Тирә-як тып-тын иде, караңгы иде. Ул капшанырга, үзенең аяк-кулларын барларга тотынды. Куллары, аяклары исән иде, тәнендә яраланган җире дә юк иде бугай, тик менә бер аягы гына нишләптер бик каты авырта сыман.

Үзен басып, кысып торган нәрсәне кузгатудан курыккан шикелле ул иплəп кенә, сакланып кына кыймылдый башлады. Капшана, кыймылдый торгач ул үзенең ике ат арасында кысылып калуын аңлап алды. Атларның икесе дә инде үлгән, тик икесе дә әле туңып катарга өлгермәгәннәр. «Мин исән! Исән!» диде ул үз-үзенә кыргый бер куаныч белән. Ул үзенең бик күп атлар, кешеләр белән каядыр чабып баруын, егылып калуын исенә төшерде. Ләкин менә хәзер ул кайда — үзләре ягындамы, чиннәр ягындамы, даладамы, елга буендамы — моны инде ул берничек тә белә алмады. Башта ук егылган төштә — далада булса, никтер аңа һаман да якында гына коточкыч тавыш, шау-шу ишетелеп торырга тиеш кебек тоелды.

Ул, кыймылдаудан, каядыр чыгарга азапланудан туктап, уйлаштыра башлады. Әгәр дә мәгәр алар җиңгән булсалар, аны бу килеш калдырмаслар — барыбер эзләрләр, табарлар иде. Эзләмәскә, тапмаска аларның хаклары юк! Кая аның ышанычлы егетләре, кая аның коралы ирләре?

Аның кычкырасы килде. Ләкин ике ат гәүдәсе арасына кысылган килеш ул берничек тә кычкыра алмады. Ярсып ул яңадан кыймылдарга, каядыр шуышырга тотынды, һәм өзәңгедә килеш ат астында калган сул аягын көч-хәл белән тартып чыгарды да, хәрәкәтен тоткарлаган ук-җәя савытларының каешларын ычкындырды. Бушанып, җиңеләеп һәм терсәкләре белән эткәләп-төрткәләп ул, кыймылдый-кыймылдый, ниндидер ачыграк урынга килеп чыкты. Иркенләп, күп итеп ул тын алды һәм сагаеп тыңлап тора башлады.

Бик якында гына ниндидер ыңгырашкан, шыңшыган, хәтта кычкырган тавышлар ишетеп ул аптырагандай итте. Бу ни бу?!

Ул моның ни икәнлеген ачыклый алмады — кайдадыр якында, бик якында, ашыгып пышылдашкан икенче төрле тавышлар ишетелеп китте. Ул әлеге пышылдашучыларның кайдалыгын да чамалый алды,

тик аларның ни сөйләгәннәрен генә аңлый алмады. Аларниндидер ят телдә пышылдашалар иде! Алар, ахрысы, чин кешеләре иде! Әйе, ыңгырашмый торган, сызланмый, кычкырмый торган ул таза кешеләр монда бары чиннәр генә булырга мөмкин иде.

Әле генә гөлт итеп кабынган сөенеч тойгысы гөлт итеп шундук юкка да чыкты. Димәк, чиннәр җиңгән. Димәк, ул — чиннәр ягында.

Ул кинәт тынып калды. Кычкыру, кемне дә булса ярдәмгә чакыру үе үзеннән-үзе истән чыкты. Инде нишләргә? Шушында ат үләксәләре арасында кысылып калган килеш мәңге юкка чыгаргамы, әллә соң таң атканчы берәр ничек качып котылыргамы? Кая, ничек качарга?

Ул берни дә уйлап таба алмады. Кузгалырга, тын алырга куркып һаман тып-тын ята бирде. Ләкин аңа кинәт болай хәрәкәтсез яту үлем белән бер булып тоелды. Ул яңадан каядыр үрмәли, шуыша башлады һәм искәрмәстән үле ат гәүдәләре өстенә килеп чыкты.

Кышкы төн серле һәм караңгы иде. Бик еракта, каракучкылланып торган төпсез күктә кар бөртекләредәй генә булып йолдызлар җемелдәшә, кар бөртекләредәй җемелдәшкән йолдызлар арасында сызылып кына чыккан яңа ай балкып күренә. Яңа ай, яшь, көчле ай. Сөннәрнең атасы, сөннәрнең алласы... Менә ул — аның углы Албуга, уң кул тучи бәк дошман ягында, ат үләксәләре арасында җирдә аунап ята. Нишләп бер көнгә иртәрәк чыкмадың соң Тәңрем, Атам?

Әйе, ул менә дошман ягында. Чин ягында. Моңа әле ышанасы да килми, ләкин моңа ышанмый да булмый. Чиннәрнең явызлыгы, кансызлыгы турында аның күп нәрсәләр ишеткәне бар. Үз кулларына төшкән «ху»ларны алар я кол итәләр, я терелэй җиргә күмәләр, я булмаса, текә яр янына китереп, чүп-чар түккән кебек, шаулап аккан елгага коялар дип сөйлиләр.

Тәңрем, олуг Атам! Нишләтерләр алар мине? Терелэй җиргә күмәрләрме, шаулап аккан елгага ташларлармы, әллә соң бакыр ташы, тоз ташы казырга дип кеше кире кайтмый торган тау-таш араларына озатырлармы? Мине... синең изге углыңны шулай җиңел генә юкка чыгарырлармы? Мөмкинме бу, олуг Тәңрем? Минем анда — туган даламда — изге анам калды, бичәм Алтын-Бөртек, туганнарым калды. Анда минем җирем-суым, анда минем илем-көнем. Шушы яшьтән мине үз яныңа алып, син аларны ятим калдырырсыңмыни?! Коткар мине бу тозактан, Тәңрем!

Күңеленнән шулай ялваргач ул үзендә көч артуын тойды һәм тагын бер мәртәбә омтылыш ясап карарга булды. Аягының авыртуын онытырга тырышып, ниндидер үле гәүдәләргә, җансыз аякларга басып ул ары үрмәләде. Якында гына тагын да чит телдә пышылдашып сөйләшкән тавышлар ишетелеп китте. Болар мәет талап йөрүче угрылар иде, ахрысы.

Ат, кеше мәетләре өстенә менеп баскан бер кешене алар күрмәделәр бугай. Ләкин Албуга аларның бер яралыны күсәк белән сугып үтергәннәрен аермачык күреп калды. Куркып, ул яңадан мәетләр арасына егылды. Бераз тыңлап, тынып ятты да, канга сусаган чүл бүреләре сыман исәнәеп, капшанып йөргән шикле бәндәләрдән ерагаерга тырышып, түше белән читкә шуыша башлады. Уң кулына ул мәетләр арасында тапкан саллы, яхшы сөңге тотты, сул кулына билендәге хәнҗәрен алды. «Башка күсәк белән китереп тондырганны көтеп ятмыйбыз әле!» диде ул үзенә-үзе, күңелен күтәреп.

## XVI

Шуыша-шуыша ул шактый җир китте. Угрылардан ераклашкач ул башын калкытып каранып торды да, аякларына басты һәм авыртына-

авыртына булса да, аксаклап булса да, иелә-бөгелә бара башлады. Мәетләр белән тулы үзәннән читтә, яланда аңа иясез атлар булырга тиеш сыман тоелды. Аты булса, аны инде беркем дә тота алмаячак!

Читкәрәк китә барган саен җир өстендә аунап яткан мәетләр дә сирәгәя башлады. Җир өстендә калкып, кап-кара булып яткан үле атларга елышып, кача-поса ул һаман дала ягына китә барды. Шулай барганда ул бер үлененң ук тулы садагын чишеп алды, икенчесенең җәясен алды. Шул чакны ул колак төбендә генә кемнеңдер: «Су!» дип кычкыруын ишетеп, сискәнеп туктап калды. Тыңлый башлагач, тагын да әле аннан, әле моннан ыңгырашкан тавышлар ишетелде. Берсе, саташыпмы, соңгы сулышы җитүен сизепме, еракта калган сөекле хатынын ярдәмгә чакыра, икенче берсе тәңрегә ялвара, өченчесе кемгәдер ләгънәтләр укып, балаларча үксеп елый.

«Су!» дип ыңгырашкан кешенең тавышы Албугага таныш сыман тоелды. Кызыксынып, куркуын онытып ул аның янына килде.

— Син кем? — диде ул пышылдап кына.

Су сораган ир шундук аның тун чабуыннан эләктереп алды.

— Су бир, туган, су! — диде ул аның соравын ишетмичә.

— Кем соң әле син? — диде Албуга һич кенә дә хәтерли алмыйча.

— Аягым сынды! Ах, аягым сынды! — диде яралы кычкырып.

Таза кешегә тотынып ул ничек тә аягына басмакчы булды.

— Этимчәк ич син! — диде кинәт Албуга, яралының йөзенә якынрак килеп.

— Йөзбашы Этимчәк! — диде яралы.

— Тотын миңа. Әйдә! — диде Албуга аны култыклап алып.

Этимчәк аягына җиңел генә басмакчы булды, ләкин, авыртуга түзә алмыйча, гөрселдәп кире ауды. Авыр гәүдәгә ияреп Албуга да аның белән җиргә егылды.

— Булмый, ташла! — диде Этимчәк, кинәт еларга тотынып.

— Шаулама! — диде Албуга, яңадан аягына басып. — Ат тотарбыз. Әйдәле яңадан киттек!

Этимчәк яңадан аягына басты. Албуга аңа таянырга кулындагы сөңгесен бирде. Алар яңадан кузгалып киттеләр. Шул чакны ниндидер карачкының дала ягына йөгереп китеп барганы күренде. Ул ялгыз иде, тап-таза иде.

— Бавыр! Тукта! — дип кычкырды Албуга йөгерүчене ерактан ук танып.

Карачкы туктады, якынрак килде.

— Мин Бавыр түгел, мин — Сөмәтәй,— диде карачкы.

— Сөмәтәй булсаң да... Бавыр,— диде Албуга, үзенең ялгышуына эз генә исе китмичә.— Бу йөзбашы Этимчәк. Тот кулыннан!

Сөмәтәй йөзбашының бер кулыннан, Албуга икенче кулыннан тотты. Алар шулай өчәүләшеп ары китеп бардылар. Үлекләрдән читтәрәк чыннан да иясез калган атлар күренде. Ашыгып шул атлар янына киттеләр. Иясез атларга атланып качарга чамалаган кешеләр бер алар гына булып чыкмады. Монда инде унлап кеше бар иде. Аларның кайберләре ат тотарга азаплана, кайберләре ияреп, коралын рәтләп азаплана иде. Бер-икесе, мәетләр ягыннан якынлашып килүче карачкыларны күреп, тиз генә атландылар да, караңгыда юк та булдылар.

— Ашыкмагыз! — дип кычкырды Албуга, башкаларның да тизрәк табан ялтыратырга чамалауларын күреп. — Мин — уң кул тучи бәк Албуга! Йөзбашы Этимчәк тә монда, Сөмәтәй дә...

Атлар тирәсендә булашкан ирләр тукталып, килүчеләргә борылып карадылар.

— Уң кул тучи бәк! Син нишләп безнең белән?! — диде ирләрнең берсе, чын күңелдән гаҗәпләнеп.

— Мин — Кәлтә! — диде икенче берсе куанып.

Кәлтә инде атланган иде. Ул шундук атыннан төште, Албуга янына килде.

— Коткар безне!

— Алып кайт далага! — диештеләр ирләр шаулашып.

Кемдер шунда озын торыклы тулпар ат җитәкләп килде.

— Сиңа, олуг тучи-бәк! — диде.

— Тавышланмагыз! — диде Албуга, үз тирәсенә җыйналган ирләрнең әле берсенә, әле икенчесенә карап.— Коралларыгыз бармы?

— Бар!

— Каты яралылар бармы?

— Юк!

— Атлар җитәрлекме?

— Җитәрлек!

— Аты булган, коралы булган сөң ирен далада кем тота алсын? — диде тагин углан. — Без — үз җиребездә, үз далабызда. Туган җир безгә юлдаш булыр, туган күк безгә бөркәнчек булыр. Без котылырбыз. Минем боерыкларны гына тыңларга!

— Тыңларбыз. Алып кайт!— диделәр ирләр бертавыштан.

Барысы да тотып алган атларга атландылар. Уң аягы тездән түбән сынып чыккан Этимчәкне күтәреп диярлек шулай ук атка атландырдылар. Үзен ат өстендә тоеп, яралы йөзбашы тынычланып калгандай булды. Тучи бәк аңа булышырга, ярдәм итәргә дип Сөмәтәйне билгеләде. Кәлтәгә ул үзе янындарак булырга кушты. Барлыгы унбишләп кеше җыелды. Кузгалып китәргә генә торганда, мәетләр үзәне ягыннан тагын ашыгып килүче өч-дүрт кеше күренде. Аларның да ат тотып атланганнарын гына көтеп тордылар да, төн таңга авыша башлаганчы дип, ашыгып китеп бардылар.

Далада төне буена яралы ирләрнең кычкырган, ыңгырашкан тавышлары ишетелеп торды. Тазарак ирләр, әледән-әле мәетләр арасыннан чыгып, ачык җиргә үрмәләделәр. Берәүләр шуышты, берәүләр йөгереп китте. Үзәннең төрле җирендә, ач бүреләр кебек, мәет талаучылар йөрде. Тазарак ирләрнең качып барулары, йөгереп китүләре аларны бөтенләй кызыксындырмады. Алар бары каршылык күрсәтүчеләрне генә я булмаса өстендә бай киеме булган яралыларны гына үтерделәр. Ике аяклы бүреләрдән читтәрәк дүрт аяклы чын бүреләр йөрделәр.

Таң алдыннан далада буран чыкты. Кешеләрнең шул кадәр кансызлыкларына, явызлыкларына ачуы килгән буран ярсып-ярсып кар ташыды һәм күз ачып йомган арада мәетләрне ак юрган белән каплап, күмеп китте. Тавышлар тынды. Иясез калган исән атлар, хуҗаларын кызганып, туганнарын кызганып, сузып-сузып кешнәделәр.

## XVII

Уң кул тучи бәк җитәкчелегендәге егерме бер кеше төньякка карап барды. Аларның иле, аларның төп җирләре-сулары, аларның маллары-туарлары шунда. Аръякны чиннәр басып алган булсалар да, каганның калдык көчләре бары шунда гына — төньякта гына булырга тиеш иде. Каган анда булмаган очракта да, дала беркая китмәячәк. Далада сөннәрдән башка беркем хуҗа була алмаячак, дала мәңге аларныкы! Кем белә, бәлки әле сөннәр бөтенләй үк җиңелмәгәннәрдер дә, ике арада, бәлки, кайда да булса каты сугыш барадыр.

Албуга шулайрак уйлады. Юлдашларына да ул шулай диде. Караңгыда бик үк кызу барып булмады. Бераз җир киткәч, алда бик күп учаклар күреп, алар туктап калдылар. Учак тирәсендә күренгәләгән

берән-сәрән кешеләрнең киемнәре сөннәрнекенә охшамаган иде. Болар чиннәр булырга тиеш сыман иде.

Алар шундук кире борылдылар һәм, күп санлы утлардан ерагаеп, кырт кына көнчыгышка борылдылар. Алар учаклар янындагы чиннәрне читләтеп, яңадан кичүгә таба хәрәкәтләнергә булды. Шактый озак бардылар һәм тирә-якта шикле берни дә күренми башлагач, атларын яңадан төньякка бордылар.

Менә озакламый уң кул якта — бөек кояш йокысыннан уянып җир өстенә күтәрелә торган якта — ирек һәм тереклек вәгъдә итеп, ягымлы яктылык тарала башлады. Кара төн, шомлы күренешләр, үлем һәм чиннәр белән бергә артта кала барды. Күз алдында күңелгә якын күренешләр — дулкын-дулкын җир өсте, түгәрәк күлләр, камышлыклар, комлы калкулыклар беленә башлады.

— Котылдык!— диде Этимчәк беренче булып.

Башкалар эндәшмәде. Бу әле чын мәгънәсендә котылу түгел иде. Тулысынча котылу өчен кичүне чыгарга, тарлавыклар аша үтеп, таулар өстендәге иксез-чиксез тигезлеккә менеп җитәргә кирәк иде.

Албуга ирләргә туктарга боерды.

— Без әле котылмадык,— диде ул Этимчәккә карап.

— Юк, котылдык! — диде Этимчәк.

Аның тавышында ярсу, өметсезлек һәм холыксызлык сизелде. Ул бик йончыган, күрәсең, үзен-үзе бик нык мәҗбүр итеп кенә бара иде.

— Мин шушында торып калам! — диде ул күрәләтә үртәлеп.

Албуга аңа эрнеп, сыкранып карады. Этимчәкнең сынган аягы җансыз нәрсә булып салынып тора, бәйләнгән ярасы аша кан саркып чыккан һәм боз булып каткан. Ат өстендә ул көчкә утырып тора иде.

— Кичүгә әле ерак. Безгә тагын да төньяккарак борылырга кирәк,— диде Албуга.

— Сез мине юри йөртәсез! — диде Этимчәк тагын үртәлә төшеп.— Мин калам. Үзем табармын юлны!

— Кузгалырга кирәк! Яктыра! — диде Кәлтә Албугага карап.

Этимчәк аркасында тукталып торуга аның гына түгел, башкаларның да эче пошкандай булды. Тап-таза кебек күренгән йөзбашының шулай ярсуы, холыксызлануы тучи бәккә бик кызганыч тоелды. Аның белән нишләргә дә белмичә ул каушап калгандай булды. Куеныннан алып ул аңа бер кисәк пешкән ит бирде.

— Эчәргә бирегез! — диде йөзбашы, итле кулны бәреп җибәреп.

— Берәрегездә кымыз юкмы? — диде Албуга ачусыз гына.

Кымыз беркемдә дә юк иде.

— Кар алып бир,— диде тучи бәк Сөмәтәйгә.

Сөмәтәй ялт кына сикереп җирдән учлап кар алды да йөзбашына бирмәкче булды. Этимчәк карны да бәреп кенә җибәрде.

— Улым, балам! Кил әле яныма! — диде ул кинәт Албугага эндәшеп. — Мин башка бара алмыйм. Мин барыбер аттан төшеп калырмын. Тоткарланма. Мине үтерегез. Башымны хатыным Талчыбикка кайтарып бирегез. Хатыным, малым, балаларым синңа булыр. Син — үлмә. Син — уң кул тучи бәк углан. Син үлсәң, Сөн юкка чыгар. Чин җиңмәде... Ышанмыйм. Булмый ул, булмый!

Ул бик авырлык белән сөйләде — әле кычкырып, әле гыжылдап, пышылдап сөйләде.

— Кәлтә! Сөмәтәй! — диде Албуга ирләренә эндәшеп. — Берегез уң ягыннан, берегез сул ягыннан барасыз. Егылтмаска, югалтмаска.

— Улым! Энем! — диде Этимчәк ялварып, аңа тагын нидер аңлатмакчы булып.

Албуганың икеләнүе тиз арада юкка чыкты.

— Кичүгә җитмичә туктатмаска! — диде ул ныклы бер карарга килеп.

Алар тагын кузгалып киттеләр. Шул вакыт далада җил чыкты, буран купты.

## XVIII

Буран чыгуга алар сөенделәр генә. Даладагы буран аларның күптәнге танышлары, күптәнге дуслары, юлдашлары иде. Алар бернигә карамыйча кичүгә таба хәрәкәтләнделәр. Җил аларга каршыдан, сул яктанрак исте. Алар дөрес бардылар. Җил көчәйгәннән-көчәйде. Болай булгач алар, һичшиксез, котылачаклар! Бөтен җирне-күкне каядыр ашыгучы, ыжгыручы болганчык кар-буран каплап алды. Төн караңгылыгыннан котылып җитмәгән кешеләрне бар яктан да аксыл караңгылык чорнап алды.

Алар, адашып, таралышып бетмәс өчен, бер-берсенә якынрак килделәр һәм, шулай бергә укмашып, бергә тупланып туктаусыз алга бардылар да бардылар. Мондый чакта иң яхшысы берәр ышык җирдә буран тынганны көтеп тору булыр иде дә, каян табасың хәзер монда ышык, аулак урынны?!

— Туктарга кирәк, туктарга! — дип кычкырдылар ирләр.

Тучи бәк Албуга башын чак-чак кына күтәргәндәй итеп як-ягына караса, каршыда агач сыман ниндидер карачкылар күреп алды. Ниндидер әрәмә буена килеп чыкканнар иде бугай. Алар туктадылар, җиргә төштеләр. Җилгә каршы каратып, атларын бер-берсенә якын тезеп куйдылар. Качышмасыннар өчен аларның тезгеннәрен бер-берсенә бәйләделәр. Үзләре, кочаклашып, бер-берсенә сыенып, атлары арасына бастылар. Монда аларга җил көчсезрәк тоелды.

Тавышы-тыны бетә башлаган Этимчәкне бик авырлык белән генә шулай ук җиргә төшерделәр. Күтәреп, култыклап аны Кәлтә белән Сөмәтәй җанлы койманың уртасына ук алып килделәр. Аны шулай ике яктан тоткан, култыклаган килеш басып тордылар.

Буран бик озак котырды. Бер урында кымшанмый торган кешеләр туңа, калтырана башладылар. Кайберәүләр тынычланып йоклап китте. Йоклаучыларны тарткалап-төрткәләп шундук уятырга тырыштылар. Бары тик Этимчәкне генә уятып булмады. Ул Кәлтә белән Сөмәтәй арасында басып торган килеш катып үлде.

— Сөмәтәй, аның башын кисеп алып, хатынына тапшыр,— диде Албуга, йөзбашының соңгы үтенечен исенә төшереп.

— Тапшырырмын,— диде Сөмәтәй, телен көчкә әйләндереп.— Минем үз башымны кем алып кайтып тапшырыр икән — анысын да әйтмәссеңме, олуг тучи бәк?

— Үзеңнекен — үзең! — диде Албуга ачуланып.

Буран бары кичкә таба гына тынды. Атларына, бер-берсенә сыенып торган, бөтенләй диярлек хәрәкәтсез калган, бил тиңентен карга күмелгән ярым үлек ирләр моңа ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Туңа язган аякларын көчкә кыймылдатып, кар ерып тучи бәк үзенең ирләрен барлап чыкты. Өлкән яшьләрдәге бер ир, атының арт аяклары арасына кысылып, бөгәрләнеп үлгән иде. Бер-икесенең хәлләре шулай ук шәптән түгел. Бары Кәлтә белән Сөмәтәй дә, тагын берничә яшь, таза ирләр генә сәламәт-көр күренәләр. Алар өлкән кешеләрнең аяккулларын удылар, көчләп диярлек аларны урыннарыннан кузгаттылар. Шуннан соң, шулай ук бик нык тырышлык белән, атларның тезгеннә-

рен чиштеләр дә, бер-берсенә булышып, иярләргә атлана башладылар. Кәлтә белән Албуга иң азактан атланырга булды.

Алар шулай көчкә кыймылдашып яңадан юлга чыгарга җыенып ятканда, як-якта ниндидер атлылар күренде. Барысы да берьюлы диярлек башларын калкытып, аптырап, ышанмыйча ят кешеләргә карап тордылар.

Болар чиннәр иде. Алар да бик нык йончыганнар, күшеккәннәр иде. Алар да кайдадыр шушы тирәдә генә буран тынганын көтеп торганнар бугай. Ләкин алар күп иде, бик күп иде.

Албуга да, башкалар да шундук ук-җәя савытларына тотындылар. Әмма туңган кулларның инде ук-җәя тотар хәлләре калмаган иде. Сөннәр ук-җәя белән булашкан арада чиннәр, бик каты шаулашып, аларны төрле яктан уратып алдылар. Сөн ирләренең башлары өстендә, үлем белән янап, озын саплы балта-сөңгеләр күтәрелде.

Башкалардан аерылып торган бай, таза киемле тучи бәккә чиннәр шундук игътибар иттеләр. Җансыз нәрсә күргән кебек, төртеп күрсәтә-күрсәтә, аның турында алар нәрсәдер сөйләнеп алдылар. Башындагы алпагы — каты бүреге аның көмештән, биленә буган киң каешына алтын тәкә, бүре, болан сурәтләре төшерелгән иде. Өстенә ул юка тимер калайлар тегелгән каты күбә кигән иде.

«Алтынга кызыктылар микәнни?» дип уйлады ул аларның шулай үзенә төртеп күрсәтә-күрсәтә сөйләнүләренә хурланып. Ул аларның үзен чишендереп, яхшырак нәрсәләрен талап алуларын көтте. Һәм аларның кайчан да булса үтерәчәкләрен белгәнгә күрә, күңеленнән: хәзер үк үләргә — барлык юлдашлары алдында берничә дошманны юк итеп, батырларча үләргә, дигән карарга килде. Күңеленнән чиннәр кызыгырлык әйберләрен хәтерли башлагач ул Алтын-Бөртек биргән бөрынгы бөтиен исенә төшерде. Аңа бик кыска вакытка гына җылы, рәхәт булып китте. Бөти аны сакларга тиеш! Юк, ул әле үлмәячәк!

Ул көтә башлады. Аңа беркем якын килмәде. Ул, ахрысы, чынлап та исән калды!

Аларга чиннәр үзләрендә булган барлык коралларын ташларга боердылар. Башта ук ташланмаган коралларны — пычак, хәнҗәр ише нәрсәләрне ташлагач, аларга атларына атланырга кушылды. Аларның кулларын артларына каерып бәйләделәр дә, ат тезгеннәрен үз атларының койрыкларына тактылар.

Шул рәвешчә аларны каядыр көньякка алып киттеләр. Юлда, далада сөннәрнең адашкан, я булмаса качып котыла алмаган берән-сәрән вак төркемнәре очрады. Чиннәр аларны да кулга алдылар, баштагы зуррак төркемгә куша тордылар.

Әсирләрне Чин ягына ике көн, ике төн кудылар. Ашарга, эчәргә берни бирелмәде. Бары ачыккан атларны гына тибенгә җибәрделәр. Ачлыктан, хәлсезлектән күпләр ат өстеннән төшеп егылып калдылар. Әсирләр үткән юл буйларында җылы туннары салдырып алынган шәрә мәетләр торып калды.

Таштан, балчыктан өеп мендерелгән чик буе манараларын үтеп, Чин җиренә килеп кергәч, аларны биек коймалар белән әйләндереп алынган иркен генә бер ишегалдына ябып куйдылар. Аякларында көчкә басып торган сөн ирләре тапталган пычрак кар яладылар, бил каешларын, каты кием күннәрен, сөякләрен кимерделәр.

Төнне кешеләр ачык ишегалдында кундылар. Бик күп ирләр туң җир өстендә, койма буйларында ятып калды. Исәннәрне ишегалдының икенче башына алып килделәр дә, ниндидер тар аралыкка куып керттеләр һәм, тегендә, далада, сөннәр терлек-туар санаган кебек, саныйсаный шул аралыктан үткәрә башладылар.

Менә шунда, бер генә кеше сыешлы тар аралыктан үткән чакта, үң кул тучи бәк тәгин углан Албуга санәп-карап торучылар арасында таныш сыман бер кешене күреп калды. Ул, үзе дә сизмәстән, гаҗәпләнеп кычкырып җибәрде. Санап торучы чин ирләре шундук аның ягына борылып карадылар. Албугага таныш сыман күренгән ир дә борылып карады. Ул да аны таныды. Ләкин гаҗәпләнмәде. Ул көлеп җибәрде. Сөенеп-куанып көлде. Тик аның бу сөенечле көлүендә дусларча эчкерсезлек түгел, бәлки тантана сизелде. Искәрмәстән корбанын эләктереп алса, ач шакал да, күрәсең, күңеленнән шулай тантана итәдер.

Бу кеше Чәнси иде. Хөкемче аны үлем җәзасына хөкем итте. Ментйән аны үзенен җинаятьчеләр гаскәренә алды. Атасы Чәни кебек, ул да сөннәргә каршы сугышты, бик каты сугышты, җиңде һәм исән калды. Әсирләр арасыннан аңа Туман каганның өлкән углы уң кул тучи бәк тәгин угланны эзләп табу бурычы йөкләтелгән иде. Менә ул тапты! Ул сөенми кем сөенсен... Җиңүчедән дә бәхетле беркем юк дөньяда.

*Беренче китап бетте*

## Укучының күңел дәфтәренә

**Грек мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Чит җирдәге үчактан, илнең төтене артык*
*Бер бәләкәй очкын да зур әйбердәр яндыра*
*Чебеннәрнең канаты үләр алдыннан үсә*
*Күршең йортына ут капса, үз милкеңне дә кайгырт*

**Зулу мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Агач яшь чакта бөгелә*
*Үлсен өчен кабер казыма*
*Көл дә, күмер дә утыннан була*
*Үлгән бала бишеген чыгарып ташламыйлар*
*Сөт саумаган кешене сыерлар тибә алмый*
*Бер сыерның мөгрәве ике йортта булалмый*
*Кара сыерның бозавы ак та, кара да була*

..............

## Фатих Хөсни

# МӘШӘКАТЬЛЕ ОЗЫН СӘФӘР

ЮЛ ЯЗМАЛАРЫ

### Җитте вакытлар китәргә



Мең тугыз йөз кырык икенче елның башлары, чатнама салкын январь урталары иде. Миңа очы-чачагы гына килеп житте, Сталинград фронтыннан Казанга бер капитан кайткан, имештер, анда татар телендә чыгарга тиешле фронт газетасы оештырырга булганнар, капитан шул газетаның редактор урынбасары булачак кеше, имеш. Ул фронтта эшләрнең уттай кызган чагында капитанның Казанга визиты, әлбәттә, тиктән генә түгел: журналистлык эшенә сәләтле берничә кешелек группа, шул группага тагын бер метранпаж, бер наборщик (хәреф җыючы) кушыласы икән. Безгә ул чагында бер детале килеп җитмәгән булган, биш кешелек бу группа үзе белән хәрефләр, кегльләр һәм башка мәтбага кирәк-яраклары тутырылган биш ящик та алып китәргә тиеш, имеш. Типография техникасы белән таныш кешеләр беләләр булыр, алып барасы бу «күчтәнәч» тоташ кургашын да аллюмин рамнар икән, кеше җилкәсе саен берәр ящик менеп кунаклагач, тимер юл транспортының ул еллардагы нагрузкасын да искә алганда, бу «деталь» дигәнебез яхшы ук саллы булып чыкты.

Тукта әле, алдан ук өркетеп куймыйк, иң әлек әлеге күтәрәсе-төшерәсе «җилкәләр»не ачыклыйсы бар.

Ибраһим Гази, мине бер күреп, шыпырт кына әйтте:

— Газета эшенә сине өйрәтәсе юк, ун еллар буена шул эштә чиләнгән кеше, киресенчә, минем синнән өйрәнүем ихтимал, әйдә, Пәтыйх малай, тәвәккәллик шул сәфәргә, Сталинград фронтында ташның кызган чагы, борынга аз гына булса да сугыш исе керсен.

«Пәтыйх малай» — аның миңа яратып, ихлас күңелдән эндәшүе — ул чаклысын да беләм, әмма ул моның белән генә дә калмады, шундук житдиләнеп, хәтта ничектер төкселәнә төшеп, өстәде:

— Бөтен рәтле ир-ат фронтта, без генә монда сузылып йөри алмабыз. Югыйсә, кырык комиссия аркылы үткәрделәр, күзләрнең яраксыз икәнлеген беләләр, шулай да яхшы түгел. Мине обкомга чакырып сөйләштеләр, мин китәргә булдым, үзеңә ошаган, үзең ышанырдай тагын берәр иптәш тап, диделәр. Ялгышмасам, сиңа ышанам бугай мин.

Ибраһимга мин дә ышанам, инде болай дустанә, уен-шуклык тоны

да кыстырып әйткәч, аның белән булганда жир читенә дисәләр, һич уйламыйча, жир читенә китәргә дә риза идем. Шулай да «сузылып йөрү» дигәне чак кына мин-минлегемне тырнады.

— Алай буй күрсәтеп сузылып йөргән юк анысы,— дип бүлдердем мин Ибрайны,— узган җәй, үзеңә мәгълүм, Афзал абый (Шамов), Жиһанша Алиевлар белән Алексеевский районында урып-җыю чорында үзебез атка әйләнеп, ат белән көлтә ташыдык, кибән куйдык, колхозга ярдәм иттек. Кышын, 35—40 градуслы суыкта трасссада окоп казыдык. Комиссия җәһәтеннән килгәндә, бәлки, синнән чак кына калыша торганмындыр, сине кырык комиссия аркылы үткәргәннәр икән, мин утыз тугыз аркылы үттем. Нишләмәк кирәк, тумыштан неврастеник булып тугач, бүген генә яңадан ясала алмыйм. Синең белән бер сөйләшкәннәр икән, инде, алайса, син сөйләш: шундый-шундый кеше бар, ярый дип тапсагыз, кушылырга риза диген. Шуның өчен син партиеены.

Бу әле мәсьәләнең хәл ителүе диган сүз түгел, ләкин бу инде минем өчен шуның башы иде.

# Юл хәстәре

Тиешле урыннарда кирәкле сөйләшүләр булгандыр, дүрт-биш көннән безнең биш кешелек группа әзер иде. Безне алып китәчәк капитан Гани Клиблиевтән башка, анда карт мәтбагачы, миңа корректор булып эшләгән чагымнан ук таныш метранпаж Сибгат абзый Фәйзуллин, әле генә полиграфик училище бетергән яшь комсомолец Равил Казаков, язучы Ибраһим Гази һәм шушы истәлекләрне кәгазьгә төшереп утыручы без фәкыйрегез кертелгән иде. (Соңыннан ачыкланды: Равил әлеге училищены бетерергә дә өлгермәгән, аны, бик тә чәчрәп торган үткен комсомолец булганлыктан, өлкән группаларның берсеннән алганнар икән). Капитан Клиблины да күреп таныштык, татарча мишәр акценты беләнрәк сөйләшә, Воронежда авыл хуҗалыгы техникасы институтын бетергән, сугышка хәтле Кырымда торган, шунлыктан, әлеге мишәр акценты янына тагын кырым татарлары сөйләшендәге кайбер шивә сүзләр дә кушылгалый, газета һәм, гомумән, язу-сызу эшендә эшләгән кеше түгел, шуңа күрә группадагы ике язучы — Ибраһим белән минем алда, ничектер, бераз уңайсызланыбрак сөйләшә, начальниклык тонын һич сиздерми иде. Танышу көннәрендә дә, соңыннан да бик оста такт саклый белде.

Хәстәрлек дигәнебез нәрсә, капитаннан башкаларыбыз хәзергә барыбыз да үз киемнәребездә, минем өстә ул вакытта яхшы ук шәп ялтырый торган күн пальто иде, капитанга бу ошап ук куйды, бүрек маңгаена бер йолдыз да китереп такканда, сезне почти хәрби кеше дип санарга була, дип шаяртып алды ул. Аннары һәрберебез юл кирәк-яраклары, кырыну әсбаплары салу өчен бер капчык — рюкзак кебек нәрсә алырга тиеш булдык. Капитан ачык итеп әйтеп кенә бетермәде, «юл кирәк-яраклары» дигәннән, беренче чиратта, әлбәттә, күпмедер азык күздә тотыла иде. Ачык кына әйтеп бетермәвенең сәбәбе дә аңлашыла: ул еллар өчен иң читене, әлбәттә, азык табу мәсьәләсе иде. Минем Мәрфугам ул елларда ипи эшендә эшли, ягъни Казанда калган һәм эвакуация буенча Казанга килеп егылган Мәскәү, Ленинград язучыларының ипи карточкалары буенча икмәк заводыннан кечти арба белән тиешле норма ипиләрен алып кайтып, шуны матбугат йортының кеше йөрми торган аскы бер подъездында сатып бирә иде. Ат аунаган җирдә ничек тә төк калмый булмагандыр, шуның өстенә базардан — спекулянтлар кулыннан ничек кирәк алай берничә талон сатып алып, ул ми-

нем юлга читенлек белән бер кирпеч арыш ипине юнәтә алды. Аннары Равилдә бар иде бер кирпеч — бөтен запасыбыз менә шул, бүтәннәребезнең капчыкларында кырыну әсбаплары, сөлге, сабын, булса тагын юлда күз төшерү өчен берәр китап-мазар булгандыр.

Мәрфуга исеме чыккач, сүз уңаеннан әйтеп узыйм: аның, мәрхүмәкәйнең, мине бу сәфәргә озатуы каршылыклырак булып чыкты:

— Кирәгең бик чыкса, яраклы дип тапсалар, болай, кешеләрне алган кебек, мобилизация буенча да алган булырлар иде, инде тора торгач, ике баланы минем бер үземә калдырып китәсең булып чыга... Шундый авыр бер чакта,— дигән төслерәк тә иде бер яктан. Икенче җәһәттән, газета чыгару эшенең ничек тә бераз ышыктарак булырын чамалап, әйдә, ни булса да, ахыры хәерле булсын, этисе, дип хәерфатиха бирергә әзерлеге дә ачыктан-ачык сизелеп тора иде.

Хәер, чоры да уен кору чоры түгел, эше дә җитди, теш агартып, сүз куертырга урын юк, җыенуыңны бел, Фатих.

Җыену дигәннән, ул эшнең иң авыр башы, әлбәттә, капитанга төште. Ул чактагы юл транспортын барыбыз да беләбез: яшел юл, барыннан да элек, яңа оешкан гаскәри берләшмәләргә, сугыш техникасына, фронтка билгеләнгән азык-төлеккә, фронт ягыннан госпитальләр, яралы солдатлар, сугышта җимерелгән техника кайта — шуларга иде. Әлегә ни эшләүләре ачык билгеле булмаган, башлыкларының кесәсендә фронт политидарәсе тарафыннан бирелгән дәрәҗәле һәм зур гаскәри җитәкчеләрнең имзалары төшкән шәп кәгазьләре генә булган биш каләм һәм хәреф чүпләү «гвардиясе»н сыйдыру, әлбәттә, уйландыра. Әле алары үзләре генә булсалар икән, бишесендә биш авыр ящик, белмәгән-күрмәгән кешеләр өчен ул ящикларда әллә сабын, әллә шартлаткыч материал?

Хәер, үз башыбызга төшмәгәч, без ул чаклы нечкәлекләрен белмәгән атлы күренергә тырыштык, бөтенесенә Клибли чапты. Җитмәсә, аңарга юлда туенып бару өчен азык-төлек проблемасы артыннан да чабарга кирәк иде. Ләкин бу мәсьәләдә ул үз кулына бирелгән бер кешелек азык-төлек аттестатыннан бүтән бер нәрсәгә дә ирешә алмады. «Менә китәбез! Менә китәбез!» дип, эшелон көтеп, Казан вокзалы белән җылы өйләребез арасында өчме-дүртме көн таптанганнан соң, салкын январь азакларының бер көнендә, ярым хәрби, ярым штатски эшелонның тыгыз һәм ыгы-зыгылы бер вагоныннан, ниһаять, без алалы-колалы «гвардиннарга» да урын таптылар.

## Инде Мәскәү вокзалын саклыйбыз

Дөресрәге, Мәскәүдәге Казан вокзалын барыбыз да беләбездер дип уйлыйм. Шулай да дөньяда кеше һәм солдат аллага шөкер икән, вокзалның барлык зур-зур залларын, хәтта коридорларына хәтле сырып алганнар. Биек гөмбәзләр астында әледән-әле команда тавышлары яңгырый, ишелеп-ишелеп китә торалар, киткәннәре урынына шулай ук ишелеп-ишелеп өстәлә торалар. Шул алышынып торулардан файдаланып, без әлеге ящикларыбыз белән аулак почмаккарак күченеп урнаштык. Монда ул хәтле гөжләү юк, туалетка да, кипятокка да ерак түгел, хәтта ара-тирә өйдә калганнарны сагынып алырга да була.

— Безне хатыннарыбыз: «Киттеләр болар, баралар болар!» — дип уйлый торганнардыр инде,— дип, моңсу гына әйтеп куйды Ибраһим. Һәм шундук ачылып, аңарга хас шуклык белән өстәде,— син, Пәтыйх малай, Мәрфугаңа телеграмма сук, булмаса. Килеп, күренеп, хәлеңне белеп китсен. Алла кушып, ут арбасына бер эләгеп, ераккарак олага калсак, аннары теге чакта Ялтада йөдәткәннәрең кебек, «Мәрфуганы

сагынам!» дип җылап йөрергә булмасын. (Телен тимерчедән тапатмаган Ибрай, әллә кайчангы, сугышка хәтле булып узган хәлләрне, ул, мин, Алиш — өчәү Ялтада ял иткәндә, минем, гадәттәгечә, йокысыз азаплавып, төннәрен алар ны — әле берсен, әле икенчесен — йөдәтеп йөргәннәрне искә төшерә.)

Тапты вакыт шаяртып торырга. Менә өч көн инде, шушы мәхшәрдә бөкшәеп утырабыз, кайчан һәм ничек китәсебезне белгән кеше юк, ул кайгыны юллап капитан чаба, аның кесәсендә фронт политидарәсе биргән олы документ. Бездә нәрсә? Татарстан Язучылар союзы тарафыннан, алай-болай кирәге чыкса дип тыккан таныклык. Янәсе, болар шундый-шундый адәмнәр, шундый-шундый изге максат белән баралар, боларны тоткарламавыгызны, кулдан килгәнчә ярдәм күрсәтүегезне үтенәбез. Кыскасы, Чувашстанның Шөмерле станциясендә үк көчен югалткан Филкин грамоталары.

Торып-торып, тагын Ибрайга җенем чыга, тапты вакыт авыз ерырга. Равилдәге кирпеч белән миндәге кирпечне мыскаллап бүлә-бүлә ашап бетердек дияргә була, тагын кайдан һәм ничек ризык табасыбызны белгән юк. Дөрес, капитан чапкан була, комендатурага да ул, азык табу артыннан да ул, Политидарә белән элемтәгә керү өчен дә ул. Ләкин хәзергә берсенең дә очына чыкканы юк. Эшелоннар яңа формалашкан дивизияләрне ташыйлар, азык-төлек тирәсенә, кулыңда аттестатың булмаса, якын да барма, Мәскәү күз яшенә ышанмый. Дөрес, безнең капитан, башкасына теше үтмәсә дә, җылауны булдыра иде булса кирәк. Ләкин үзе ашаган солдат казаннары тирәсеннән оялчан гына башын иеп һәм үз өлешеннән сыныклар арттырып алып кайтудан уздыра алганы юк. Бөтен җирдә әлеге сугыш чоры законы. Тиешле документың булса — ашыйсың, булмаса — ашамаган килеш әпәр ит.

Шундый аптыраган минутларның берсендә — тормыш кайчан да тормыш!— минем белән мондый бер хәл булды. Шәп ялтырый торган күн пальтодан әлеге теге үзебез алып бара торган әрҗәләр янында, рәсми булмаган дневальный сыйфатында, бик кукыраеп басып торганымны күреп, шома гына бер хатын, тиз генә як-ягына карангалап алганнан соң, миңа табарак елышып, кысылганрак тавыш белән:

— Сез концентрат сатучы түгелме?— дип сорады. Кесәмдәге блокнотымны моңарчы кузгатканым юк иде, теге хатын күздән югалуга, тартып чыгарып:

«Ходаем, шулай ук концентрат сатучыга охшый башладыммыни мин? Бик иртә түгелме соң әле?» дигән беренче юлларны төшердем.

Капитаныбызны тәнкыйтьләргә шулай ук иртәрәк икән, китә-килә әле ары, әле бире чабып йөрүләренең берсеннән ул миңа чын солдат йолдызы алып кайтып бирде. Мутон бүрекнең маңгаена кадап җибәрдек һ бөтенебез берьюлы «ах!» иттек. Өстә күн бишмәт, башта йолдызлы бүрек, кай җире чын солдаттан ким хәзер абзагызның. Ибраһим монда да тешен ялтыратып, көлмичә кала алмады:

— Сез аны башта ук бездән аерыбрак куйдыгыз, капитан. Инде килеп, бер үзенә бер йолдыз. Болай кеше аеруның безнең коллективка начар йогынты ясавы мөмкин иҗ.

Әлеге шук сүзләрдән һәм, бигрәк тә безнең беребезгә генә булса да, азмы-күпме кайгыртучанлык күрсәтүеннән очынып булса кирәк, икенче әйләнеп кайтканда ул нәкъ ике пачка, кабына алтын хәрефләр белән чит ил телендә нидер язылган кукуруз талкышы алып кайтты.

— Гадел итеп дүртегезгә бүлегез, азык юкта миндаль, кабыгы да азык,— диде ул, үзенең сугышка хәтле Кырымда яшәгәнлеген исенә төшереп булса кирәк,— чыгарып өлгерүләре булды бер ларекка, момент ташланулары булды кыз-хатынның. Соңгы ике пачкасын көч-хәл белән эләктереп калдым.

— Инглизчә язылган булса кирәк монда,— диде Ибраһим, капны

күрер-күрмәс күзләренә якын ук китереп. Бу очракта да үзенең безгә караганда укымышлырак икәнлеген күрсәтүе өчен ул эченнән генә тантана кичерә иде кебек.

— Дөрестерме-юктырмы, шундагы хатыннарның үзләреннән ишеткәнемне әйтәм: безнең союзникларыбызның бүләге, имеш,— һәм мәгънәле паузадан соң җитди генә итеп өстәп тә куйды,— икенче фронт ачуны һаман суза килүләрен әнә шундый кибәк белән капламакчы булалар, күрәсең.

Кибәк булса булды, ярап куйды безгә. Рюкзак төпләрендә җыелып калган ипи валчыкларын да кушкач, без аның белән Саратовка хәтле йөрәк ялгап бардык.

Нишләп Саратов? Нишләп барып җитәсе урынга барып җиткәнче түгел? И, беркатлы булганбыз да соң без ул вакытта. Кем соң әле без ул чагында? Кем сорый да, кемгә ничек аңлатып бирмәк кирәк? Чуар халык белән тулган составның, бәлки, Саратовтан ары йомышы булмагандыр. Ничек кенә димик, Саратов — Сталинградка якынрак. Авыр ящикларыбызны ничек кирәк алай урнаштырып, бер утыргач, кукуруз кибәгендә генә булса да барасы да барасы иде дә бит, юлда соң без дигәнчә генә мөмкинме? Ыгы-зыгы белән тулган сугыш чоры юлларында бигрәк тә.

## Ниләр күрдек, ниләр күрәсебез бардыр...

«Чолганышта калган Паулюс группировкасының, капитуляциягә килмәгәнлектән, безнең гаскәрләр тарафыннан тар-мар ителүе турындагы хәбәрне без юлда ишеттек. Икенче февральдә, Саратов вокзалының агитпунктында кичерәк буйлы, сипкелле йөзле, калын тавышлы агитатор, эстрада алдына чыгып, Совинформбюроның бу турыдагы махсус белдерүен, дулкынланудан беркадәр тотлыккалап, укып чыкты. Моны ишеткәч, кешеләр ничектер җиңеләеп калган төсле булдылар һәм, әлбәттә, әлеге сипкелле кеше күккә чөелде.

Без агитпункттан чыкканда, чатларга, вокзал стеналарына бу турыдагы махсус белдерүләр ябыштырылган иде, кешеләр колакларына гына ышанып җитмәгәндәй, белдерүләргә ябырылдылар...»

Бу юлларны мин 1944 елны язылган «Хуторда» дигән хикәямне китердем. Вакыйгаларның кайнар эзеннән алынып язылганлыктан, ул хикәядә шул көннәрнең ясалмасыз атмосферасы урыны-урыны белән яхшы ук сизелгәләп куя. Үземне тыеп калдыра алырыма ышанмыйм, аннан мин алда да чеметеп-чеметеп кенә булса да өзекләр китергәләрмен әле. Бигрәк тә Сталинградка якыная төшкәч.

Саратовта алынган бу сөенечле хәбәр, бер үк вакытта, безне берничә төрле каршылыклы уйлануларда калдырды. Беренче чиратта, әлбәттә, башыбыз күккә тиярдәй булып шатландык. Ниһаять, ниһаять! Гитлерның иң ышанычлы дивизияләрен сайлап, аларны үзенең иң булдыклы саналган фельдмаршалы кулына тапшырып, Идел елгасын һәм ул яктагы башка коммуникацияләрне буып алып, Россиянең көньягын төньягыннан аеру стратегиясе белән җибәргән удар тукмагы, ниһаять, җимерелгән. Мәскәү тирәсеннән бер кыйналып куылганнан соң, бу тукмалу дөньякүләм хурлыкка калу түгелмени!

Шул ук вакытта безнең күңелгә төшкән әйтеп булмый торган үз «стратегиябыз да» юк түгел, без бит данлыклы Сталинград фронтына барабыз дип чыккан идек, димәк, без соңга калганбыз булып чыга. Минә мә, йөри белмичә йөрсәң. Икенчедән, безнең капитанның Политидарә белән элемтәгә керә алмавының сәбәбе дә бераз аңлашыла башлады кебек. Сталинград фронты, хәрәкәттәге фронт буларак, беткәч,

аның Политидарәсе дә, әлбәттә, шул бер урында утырып калмагандыр. Димәк, безнең капитанга өстәмә бурыч: яңадан элемтә бүлекләрендә таптанырга, эзләргә, сорашырга, табарга кирәк.

Шуның өстенә тагын капитанның турыдан-туры бурычы: алып бара торган кешеләренең тамагын да кайгыртырга кирәк. Саратов безне сөенечле хәбәр белән каршылады, фельдмаршал Паулюс группировкасының ахыр чиктә капитуляциягә килергә мәҗбүр булуы турындагы хәбәрне, беренче буларак, безгә нәкъ менә Саратов ишеттерде. Ләкин Саратов безне, әлбәттә, пылау пешереп каршыламады. Сугыш чорының һәр шәһәрендә, һәр почмагында шулай булганы кебек, ашау-эчү, азык-төлек мәсьәләсе Саратовта да проблема иде. Безнең Казанда әле, кесәндә акчаң булса һәм кемнең нинди кәсеп белән чуалганлыгын йөреше-торышына, күзенең елтыравына карап, чамача гына булса да таный белсәң, итәк астыннан гына тәкъдим итеәә торган икмәк карточкасы сатып алып, аны икмәккә әйләндерергә мөмкин иде. Ә монда без чит-ят кешеләр. Базарларын да белмибез, базарында спекулянты үзен ни фасон тота? Анысын да белгән юк. Ә ашарга кирәк. Тамак фельдмаршалның хурлыклы капитуляциясе белән генә, әлбәттә, туймый. Ашау ягыннан, авыр туфрагы җиңел булсын, бигрәк тә Сибгат абзый тәкатьсез иде.

— Безне шушылай ачка киптерергә дип алып киттеңмени, иптәш Клибли?— дип китереп куйды ул мәсьәләне. Бу инде, әлбәттә, көймәсе комга тәмам терәлгәннән соң әйткән сүзе. Мәсьәләне болай кабыргасы белән куярга ярамаганлыгын ул үзе дә белә. Шуңа күрә сорауны да шыр акырып түгел, шыпырт кына бирде.

— Тукта, чү, Сибгат абый, дуамалланма ул чаклы, бер җае чыкмый булмас,— дип юата Ибраһим. Һәм, үзенә хас юмор хисен һич югалтмыйча, шаярткан булып азаплана,— беребез дә үйнап йөрми, беребез дә тик ятмый. Капитан әнә көне-төне юл ягын, Политуправление белән кавышу ягын кайгырта, Равил белән мин алмаш-тилмәшләп ящикларны саклыйбыз — дневалит итәбез, Пәтыйх әнә, күрмисеңмени, ящик өстенә башын кыңгыр салып, Мәрфугасын сагына...

Саратов вокзалында аяк өсли йоклап, бер төн уздыргач, икенче көнне төш авышканда капитаныбыз ничектер ачык чырай беләнрәк кайтты.

— Хәзер үк вагоннарга төяләбез дә китәбез икән дип уйламагыз,— ул, юкны өмет итмәсеннәр, диган кебек үтә кырыс әйтте бу сүзләрне,— ошысы хәзергә ачык түгел, бәлки көтмәгән яктан кинәт ачылыр. Мәгәр тамаклык эш чыгарга тора, әгәренки сез хуп күрсәгез.

Идел ярында сал таралып катып калган. Иделдә су кузгалып, агызып киткәнче шул бүрәнәләрне читкәрәк ташып, әрдәнәгә салып куярга кирәк, капитанның «тамаклык» дигәне шул икән. Көнгә алтышар йөз граммнан әпәй бирәчәкләр, ихтимал, бер мәртәбә кайнар аш та эләгер, ди.

Шундый ганимәт күренеп торганда, риза булмыйбызмы соң! Газета чыгарырга дип җыенган кешеләр, менә без бүрәнә чыгарабыз — барыбер сугыш чоры эше. Әлбәттә, бишебез дә түгел, капитан — әлеге дә баягы — уртак йомышларны юллап чаба, беребез вокзалда хәреф ящикларын саклап дневальный тора, өчебез «тамаклык» эшли. Соңыннан аны дүртәү бүлешеп ашыйбыз. Капитан өлешкә керми, кыстасак та керми, белгән кеше юк, ул юлда берәр нәрсә кабамы, әллә тизрәк китү өмете белән тукланып чабамы?

Оптимист үзе, кайтып күренгән саен безгә җан өрергә маташа:

— Иртәгә кабы китеп бармабызмы әле, егетләр, шулайрак әйттеләр,— ди.

Ләкин Сибгат абзый капитанның «иртәгесен» күтәп чыдый алмады, кичен бүрәнә ташудан кайтты да, бөтенебез алдында берьюлы катгый хөкемен әйтеп салды:

— Мин гомердә мондый авыр эштә эшләгән кеше түгел, бүсерем кузгалды,— диде ул, барыбызны да шаккатырып. Һәм туп-туры капитанның өстенә китте,— менә касыгыма кулыңны тидереп кара, әгәр ышанмасаң.

Ибрай — тилчә тел — шунда да теленә салынырга маташты:

— Доктордан язу алып кил, Сибгат абзый. Касык ул нәстә? Касык кайсыбызда да бар.

Сибгат абзыйның касыгы белән эш ул чаклы катлауланырга өлгермәде, икенче көнне искәрмәстән генә җае чыгып, без шул якка таба барырга тиешле эшелонга төялдек — ящикларыбыз белән. Һәм капитаныбызның әлеге шул бердәнбер продаттестаты буенча тигән сухой паегын алып.

## Без дигәнчә чыкмады

Без көньяк-көнчыгышка таба курс алган идек, арада йөргән сүзләргә караганда, маршрутыбыз да шул якка — Сталинградка таба иде, ләкин без дигәнчә булып чыкмады. Сугыш чорының аңлашыла торган тактикасы: кеше арасына җибәрәләр бер сүз, гамәлдә эшләнә икенче төрле. Хәер, бөтен кешенең барлык эшне дә алдан белеп торуының кирәге дә юктыр, күпне белер өчен аның үз кешеләре бар. Саратовтан китеп озак та тормадык, ул чагында әле Идел буе немецлары республикасы дип атала торган бер почмакта — кечерәк кенә Урбах станциясендә безгә көтелмәгән хәбәр җиткерделәр: эшелон — Сталинград ягына түгел, Красный Кут юнәлешендә юлын дәвам итәчәк, имеш. Кыскасы, без — биш кешелек команда — ящикларыбыз янында, рельслар арасында, җилдә басып калдык. Җил дигәннән, без җилләрне дала якларына якынайган саен күрә бардык, әмма бу Урбахтагы кебек ачы, үтәли тишеп үтә торган чәнечкеле җил бер җирдә дә каршыламаган иде һәм, алла кушып, каршыламасын да... Бәлки, бу безгә көтелмәгән яктан китереп суккан язмыш — кыр уртасында, билгесезлектә, ризыксыз һәм баш төртер урынсыз утырып калуыбыздан да шулай тоелгандыр. Ничек кенә булмасын, без күпмедер вакыт ящикларыбыз өстендә, бер-беребезгә ни дә булса әйтер сүз тапмыйча, сүзсез-өнсез утырып калдык.

Һәм, ниһаять, капитан телгә килмичә булдыра алмады:

— Болай аптырап калырга ярамый,— диде ул, кинәт кузгалып,— мин әйләнеп килим әле, монда нинди дә булса комендатура кебек нәрсәсез булмас. Әнә арырак безнең брат та бик кайнаша, күрәсең, вокзал кебек нәрсәләре дә шундадыр. Сез моннан кузгалмагыз, мин начас кына юыртып килим әле.

— «Начас» дигәннең тәрҗемәсе ничек була, Пәтыйх? — дип шаярткан булды Ибраһим. Күренеп тора, бу әллә ни күңел көрлегеннән чыккан шаярту түгел, бирешмәскә тырышып әйтелгән сүз генә иде.

Озак кына торып килде капитан, ләкин күзләре өметсез үк түгел иде.

— Мин сөйләшеп килдем, монда ящиклар янында беребез калып тора, бүтәннәребез котелокларыбызны алып, за мной марш.

Чапмыйча соң! Шундый сүз чыгып торганда! Яртымы, берме сәгатьтән соң без, әлеге шул ятак хезмәтен дә үти, вакыты белән өстәлгә дә әйләнә торган ящикларыбыз өстендә, кашыкка эләкмәүче сирәк бәрәңге һәм балык кисәкләрен куа-куа, котелокларыбызда айкала идек инде.

Эчкә җылы кергәч, барыбыз да терелеп киткәндәй булдык һәм, шул форсатны ганимәт санап, капитаныбыз янә бер шатлыклы хәбәр өстәде:

— Моннан кайчан китэсебез хэзергэ билгеле түгел, китэ алырбызмы, юкмы?— Күренеп тора: бу керешне ул аңлы рэвештэ ясады, малайлар бик очынмасынга,— китэргэ булгач, анысы китэрбез. Э хэзергесе минутта бу аждак җилендэ озак утырырга ярамас, ящикларыбызны җилкэгэ алыйк и китэбез моннан йөз метрдагы гостиница дигэннэренэ. Җылы булыр дип вэгъдэ итмэделэр, но җиле булмас.

Капитанның «Гостиница» дип зурлап эйткэне, чамача, болайрак булып чыкты: поселоктан читтэрэк, вокзалга житэр-житмэс, урта бер җирдэ, кыр уртасында диярлек тэбэнэк кенэ бер агач өй. Түрдэ өч тэрэзэ, янда ике. Яндагы тэрэзэлэрнең бер «күзе» ватык, аңа карындык корылган. Карындыкның бер почмагы кипкэн, җилдэ бэрелеп-сугылып тора. Өй эче подтопка һэм шуңа ялганып сузылган бүлмэ тактасы белэн икегэ бүленгэн — фантазияң эшлэсэ, эйтергэ мөмкин: югарыгы палата, кара халык палатасы. «Югарыгы палата»да хуҗабикэ үзе тора, бу як «палата»ны без — кара халык яулап алырга тиеш булдык. Лэкин шулай да эйтмичэ булмый: хуҗабикэ безне бик алай ачык чырай белэн каршыламады.

— Нэрсэ ягасын дип сораучы юк, э кешесен җибэрэлэр,— дип сукранды ул башта. Аннары капитаннан талон таптырырга тотынды. Капитан мондый сорау булачагын алдан күргэн икэн, коменданттан алып килгэн кэгазь кисэген тиз генэ чыгарып биргэч, «Инде тавышы тынды» дигэн хуҗабикэбез, безнең ящикларга бэйлэнэ башлады.

— Ул ящикларыгызны өйалдында гына калдырыгыз. Белэсезме, аларга ияреп күпме суык керэсен? Болай да рэтлэп ягылмаган өйгэ?

— Белэбез, эбекэй,— диде өзеп,— үз чиратында син дэ белергэ тиешсен: безгэ бу мөлкэтне үзебездэн аерырга ярамый. Хэрби йөк, понимаете.

Болай дип куйгач, карчык та карулашмады. Хэтта бераздан безнең яктагы өстэлгэ артиллерия гильзасына көйлэнгэн ут та чыгарып куйды. Ул, элбэттэ, бик яктыдан түгел иде, эмма өй эченең фэкыйрьлеген ача төшебрэк күрсэтү өчен бик тэ житэрлек иде. Түрдэ аркылыга бер караваг, янда аяклы-очлы ике караваг куелган иде.

— Менэ урыныгыз шушы булыр, ничек урнаша аласыз, анысы сезнен эш,— диде карчык һэм, безнең тагын ниндиерэк сорауларыбыз буласын көтмичэ, үз ягына чыгып китте. Карындык корылган «күзнең» ачылыпябылып торган почмагыннан урамда калган җил сузылып, безнең хэлне белеп тора һэм бер уңайдан гильза-лампа башыннан сузылган ялкын телен дэ арылы-бирele каккалап ала.

Эбинең безгэ эйтер сүзе бетмэгэн булган икэн, бераздан янадан безнең якка чыгып:

— Җылытыр ашамлыкларыгыз булса, подтопканы яккач куярбыз,— диде ул, ашау-эчү эйберлэре турында сүз кузгатасы булгач, яхшы ук мөлаемлана төшеп. Һэм шундук үзенең гадэти корылыгы белэн өстэргэ ашыкты,— только подтопкага ягарлык миндэ сыңар полен да юк, ул ягын үзегез карагыз.

Аллага шөкер, бездэ — беребездэ дэ — җылытырлык ашамлык эйберлэре юк, шулай да капитан бер акыллы сүз эйтмичэ кала алмады:

— Чынлап та, егетлэр, подтопканы ягып җибэргэндэ, ни... бер дэ начар булмас иде, минемчэ.

Һэм ул карындык «күзнең» җилдэн сэлам алып торган почмагына үзенең рюкзагын китереп каплады.

Бөтен җирдэ башлык кешенең боерык биргэнен көтеп кенэ булмый, капитанның подтопканы ягып җибэргэндэ начар булмаячагы турында ым кагуы һэм карындыклы «күз»не рюкзагы белэн каплавы безгэ турыдан-туры кагыла торган ишарэ иде. Без дэррэү кузгалып утын җүнэтергэ чыгып киттек. Лэкин ай-һай ла! Көнгэ караңгы капкан, чит-ят җир һэм, гомумэн, сугыш чоры: җүнэтергэ мөмкин булган койма-кыртэ

буйларын, сындырасын сындырып, йолкыйсын йолкып, безгә хәтле әллә кайчан «җүнәтеп» бетергәннәр иде инде.

Без таракан катырырлык салкын бүлмәдә, көндез үк ящикларыбыз өстенә утырып тутырган җылымса шулпа белән канәгатьләнеп, ятарга булдык.

Капитанга, башлык кеше итеп, түрдәге бер караватны бирдек, без икешәр-икешәр кеше яндагы ике караватка сузылдык. Гадәттә бик җитди күренә торган капитаныбыз, әллә үзенә бер карават эләккәне өчен безнең алда ничектер уңайсызланып, юмор кыстырып, безне юатырга маташты.

— Сезнең хәл, егетләр, губернаторски. Берегез җылысына икенчегез ереп китәсе, ә менә минем, бер ялгызымның, мөшкелрәк булмагае.

## Бирим дигән колына...

Күп сүзгә һәм кеше исемнәренә үзеннән «реконструкция» ясап әйтә торган Ибраһим Гази безгә мәҗбүрән килеп чыккан бу Урбахны да үзенчә атады.

— Ачәрвахтан башны тиз генә алып китә алсак ярый, Пәтыйх малай,— дип пышылдады ул иртән миңа,— теге астыртын тешли торганнары мине бигрәк яраттылар булса кирәк, бөтенләй йокы бирмәделәр, әкәмәт.

Җавап биреп тормадым, минем йокы ягы болай да шәптән тормаганлыгын белеп, юри үчекләп әйтә бу моны — белмимме соң Ибраһимның этлеген. Өебез суык, ягарга утыныбыз юк, капчык төпләребез селкенгән, җитмәсә бу төнлек тишегеннән кайчан һәм ничек китәсебез дә билгеле түгел, ишетүебезгә караганда, монда шул «адашкан» поездлар гына кагылса кагыла, имеш. Шулай да капитаныбыз йокламый, ул гадәттәгечә, чабуын белә, сораша, йөри, безнең нурсыз һәм шыксыз «кунакханәбездә» әллә нидә бер күренгәләп кенә китә. Бу аның, ихтимал, бездән уңайсызлануыннан да булгандыр, ничек кенә димә, безнең алда үзенең җаваплы командир икәнлеген белә ич ул. Шулай кайта-килә күренгәләп китүләренең берсеннән ул кош тоткандай шатланып кайтты.

— Борыннарыгызны салындырмагыз, егетләр, төнәген арты без моннан китәбез, ә бүген кичкә, кайсыгыз белән булса да берегез белән без кунакка чакырулы, ягылган мунча да булачак.

Аның «Төнәген арты» дигән сүзләре үзләре генә дә күңелне ачып җибәрде, төрле шивәләрдә сөйләп бозылып беткән телендә бу: «иртәгәнең иртәгесенә» дигән сүзне аңлата иде. Шуңа өстәп ул әле менә нәрсәләр дә әйтте:

— Чаба торгач, монда мин Воронежда бергә укыган однокашнигымны очраттым. Җимерелеп кайткан танкларны и башка шундый эре коралларны ремонтлый торган частьның командиры. Менә шул кеше инде безгә ярдәм кулы сузарга торучы рәхимле җан.

Ул әле әйтәсе сүзләрен әйтеп бетермәгән иде, бу урында үзенең хәрби кешелеген онытып булса кирәк, сүзен рапортка әйләндермәскә тырышып, бераз көттеребрәк әйтте:

— Төнәген арты Камышин ягына аларның ике автомашиналары китәчәк икән, шул машиналарга утырып без дә китәчәкбез. Камышин, әлбәттә, Сталинград түгел, шулай да ул Сталинградка якынрак. Бигрәк тә шунысы безнең өчен әһәмиятле: анда фронтның обменный пункты бар, ди.

Ә тагын бер паузадан соң, бу юлы инде тавышын кыса төшеп өстәде:

— Җитмәсә ул әле, безнең хәлгә кереп, үзенең санаулы азык-төлек

резервыннан безгә күпмедер харчә дә ташларга булды, бар бит дөньяда изгелекле кешеләр. Дөньяда дигәнем, минем однокашниклар арасында.

Ләкин шундук бөтенләй сүзсез диярлек, ике бармагын авыз тирәсендә уйнатып, кисәтергә дә ашыкты.

— Только, егетләр, бу турыда никому ни гу-гу. Үзенең нык исәпләнгән резервыннан бирә, понимаете... Безнең хәлгә кереп бирүе. Әйдә әле, Равил, син яшьрәк кеше, минем белән ияреп чык әле.

Иярмиләрме соң, тиле, шундый җунле сүз ишетелеп торганда! Озакламыйча Равил җилкәсенә эләктерәсе рюкзагын кадерләп култыгына кыстырган хәлдә кайтып керде, капитан үзе юк, тагы кайдадыр калган иде.

Өстәл тирәсендә, рюкзакка таба йөзебезне юнәлдереп, ләкин әлегә ачып карарга кыюлыгыбыз җитмәгәндәй, тантаналы тынлык саклап калдык. Ниһаять, чиштек бауларын, чыгардык эчендәге байлыгын. Һа, әйтәсе дә юк, байлык бу, байлык! Рюкзактан калын бер кирпеч ипи, өч селедка һәм берничә түтәрәм чи ит кисәге чыкты. Түтәрәмнәрне кулга алып капшый башлагач, күрдек: сөяге итеннән күбрәк һәм бу сөякләрнең нинди хайванныкы икәнлеген ачык әйтеп бирергә ул арада гына беребезнең дә башы җитмәде. Озак кына дискуссиядән соң, анда да белеп түгел, бу якның дала ягы булуыннан чамалап, Ибраһим, артык сүзгә урын калдырмыйча, өзеп кенә ярып салды:

— Дәвә ите бу, энекәшләрем. Ат итен дә, сыер итен дә күргән дә, ашаган да кеше абзагыз, аларның берсендә дә мондый зур сөякләр булмый.

— Ярар, аптырамагыз, сөякләрен олы кеше итеп, Сибгат абзыйга бирербез, мин үзем, алайга китсә, итенә дә каршы түгел.

Ходаем-аллам! Ничә көннәр ачлы-туклы киләбез, суыклар күрдек, кайчан барып җитәсебезне белгән юк, шулай да уен-көлке, үзара шаярышуны онытмаган икәнбез әле.

— Капитанның сезгә тапшырырга кушкан приказы тагын шул,— дип безне тизрәк җитди җайга салырга ашыкты Равил,— бу ризыклар янында кулын тыя белә торган тотрыклы бер иптәшебезне дневальный итеп калдырабыз да, бүтәннәребез, мобилизация тәртибендә, утын җунәтергә чыгабыз. И һичшиксез җунәтеп, итне котелокларга тигез бүлеп салып, подтопка плитәсенә куябыз. Пешә торсынга.

Утын юнәтергә?— кичә чыгып, өметсез борылып кайткан эш. Шуны бүген яңадан кабатлыйбызмы? Кара әле, рәхмәт төшкерене. Чынлапчынлап еласаң — сукыр күздән яшь чыга, диләрме әле? Еламадык, ләкин адәм күзеннән читтәрәк яртылаш кына булса да исән-сау калганып калган кирта-койма кисәкләрен таптык. Һәм яхшы ук бай «трофей» белән кайттык.

Хәзергә капитан үзе күренми, әмма эш ул кушканча бара: подтопкаларны ягып җибәрдек, дәвә түтәрәмнәрен кискәләп-сындыргалап котелокларга салып, утка куйдык, күзләребез ничаклы янса да, хәзергә ризыкларга кагылган кеше юк.

Шулай да минем эчтә бер кызыксыну яна: әлеге теге чакырулы кунакка, мунчалы кунакка капитан кайсыбызны алып барыр икән? Үзем-үзем әйтергә, эчтән уйларга да оялам, ләкин башта өмет корты эшли: ихтимал, мине алып баруы да. Өстә ялтыравыклы күн пальто, башта йолдызлы бүрек, миннән дә кулайрак тагын нинди кандидат бар?

Юк шул, баштагы өмет корты юкка котырган. Кич белән капитан мине түгел, Ибраһимны алып китте.

Аның каравы без — Сибгат абзый, Равил, мин — өчебез кичен әлеге дәвә сөякләреннән пешкән шулпа белән ужин ясадык. Капитан ипи кирпечен, җеп белән үлчи-үлчи, гадел итеп биш кисәккә бүлде һәм бик нык кисәтүне кирәк тапты:

— Порцияларыгызны кулга тию белән кабып йотасы түгел, әле иртәгә дә көн бар. Бигрәк тә сиңа әйтү, Сибгат абзый, бик комсыз карап тордың ипи бүлгәндә.

— Синекен сорамам, курыкма, капитан,— дип, коры гына җавап кайтарды тегесе дә.

Шулай да баш кешенең кисәтүе үзенекен итте, без өлешебезгә тигән «көмеш»не ялап-ялап кына булса да икенче көнгә дә җиткездек, кичә кунакта булган Ибраһимның хәтта әле аның иртәгесенә дә калган иде.

Бәхеткә каршы, капитанның «төнәген» дип куркытканы чынлыкка туры килмәде, безгә өлеш чыгарган рәхимле хуҗаларның Камышинга йомышлары ашыгыч иде булса кирәк, без иртәгесен, үтәли тишә торган ачы дала җиленә каршы, аллы-артлы ике автомашинага төялеп, тагын сәфәр киттек.

## Юлда

Бу шыксыз дала җилендә күңелле финал бер дә күренергә тормый. Салкыннан бик аптырагач, әле беребез, әле икенчебез, әле булачак бөтен редакциябез, машина бортыннан сикереп төшеп, җәяүләп юртабыз, әчкә аз булса да җылы керә. Машинадан узып ук китмәсәк, артта калу куркынычы һич янамый. Чөнки машиналар үзләре дә, юлга салган кар «барханнары» өстеннән, абына-сөртенә генә баралар. Баралар-баралар да, кар өеменә батып, үкереп еларга тотыналар. Арабызда тавышын-тынын чыгармаучы бер генә җан иясе — Сибгат абзый гына бар. Ул юлга чыкканда ук астына күп итеп печән җәеп, хуҗа шоферларның кайтышлый йөк өстенә ябарга дип ыргыткан брезентларына баштан аяк төренеп яткан иде, шул ятудан ник бер кузгалып карасын — зарланган тавышы да ишетелми, исәнме-түгелме икәнлеген дә белдерми. Әллә катып үлмәдеме икән, дигән шомга урын бар, иртә белән авызына локмә ризык капмаган килеш кузовка менеп чумды, чөнки кабарлык ризык заты калмаган, капитанның нык кисәтүенә дә карамастан, бер авызы тигәч, үзен тыеп кала алмыйча, үзенә эләккән бар күк өлешен валчыгын да калдырмыйча кичә ашап бетергән иде.

Тавыш-өн чыгармыйча брезент астында баручы Сибгат абзый, барыбыздан да бигрәк, капитан өчен җан көеге булды.

— Сибгат абзый... Әй Сибгат абзый,— дип хәвефләнү белән эндәшә капитан,— бармы синдә җан әсәре? Ник бер дә тавыш-тын бирмисең? Алла бәндәсе ич син дә.

— Ярамаган сүз бу, капитан. Дөрес сүз түгел бу,— дип капитанга аркылы төшә Ибраһим, әллә чынлап, әллә үзенең капитанга караганда күбрәк белгәнлеген сиздерергә тырышып, юрамалый маташтыруы,— без беребез дә алла бәндәсе түгел, алла бәндәсе булсак, алла соң безнең юлга шушындый сөңгеле җилен чыгарып куяр идеме?

Капитан мондый юк-бар сүзләрне колагына да элми, аның хатасы гел Сибгат абзыйда.

— Тик ятма, аяк бармакларыңны аман-аман кыбырсытып ят. Аяк бармакларыңнан керә кешегә... кату.

«Катып үлү» димәкче иде бугай ул, ләкин соңгы секундта гына уйлап алды булса кирәк: паника күтәрү булып чыга бит алай әйтсә! Шулай да, командир кеше буларак, катгый бер карарга килгән иде. Өстеннән шинелен салды да, Сибгат абзый өстендәге брезентны күтәреп, аңа шинелен бөркәде, брезентны шинель өстеннән япты.

Сибгат абзый исән генә түгел, һәрвакыттагы кирелеге дә үзе белән иде:

— Нәрсә син, капитан? Авыру дигәч тә, әллә син мине солдат хез-

мэтенә бөтенләй яраксызга чыгармакчымы? — дип авыз эченнән мыгырданды, ләкин «Ал шинелеңне! Үзең ки!» дип үк әйтергә йөрәге җитмәде.

Капитан гимнастерка эченнән калын җылы кофта кигән иде, әлбәттә, бу усал дала җиле аның җылы кофтасыннан гына курыкмагандыр, ләкин ул сер бирмәде, юл буе безнең бәбәгебез алдында, шинельсез килеш, аигүрә басып барды. Һәм менә күпме еллар үткәннән соң да, инде мәрхүм икән дигән хәбәрен белеп торганым хәлдә, ул минем күз алдымда, дала җиленә бирешмәскә тырышып, кузовта гел басып бара кебек гәүдәләнә. И, сугыш, сугыш! Син анда, үзеңнең алдынгы җәһәннәмеңдә, кешеләрне көйдерден дә көйдердең, ләкин синең артыңда да әллә ни ышык юк икән. Бездән яшерә алмассың, беллек без сине, икенче килә күрмә безнең урамга!

## Без менә Камышинда

•

Кайчандыр вак-вак һәм арзанлы карбызлары белән колакка кереп калган Камышин шәһәре, ниһаять, менә безнең алда. Сталинградка бик ерак булмаган бу шәһәр өстен бомба белән дөмбәсләүне байтак күргән булса кирәк: харабә хәленә килгән йортлар, яртылаш тасыраеп калган шыксыз стеналар, урам уртасына иңгән чокырлар, фанер кадакланган ватык тәрәзәләр, көрт баскан урамнар шуны раслап торалар иде. Анда-санда күзгә чалынган кешеләре дә күбесе хатын-кыз, карткоры, бала-чага, аларының да сугыш чоры паегында яшәгәнлекләре күренеп тора, бик алай мәтәлә-кадала чапмыйлар, кирәк йомышларына да мәҗбүрән генә атлаулары күз алдында иде. Менә шул җимерек шәһәргә җилле далада калтырап килгән без — биш мосафир килеп өстәлдек. Шулай да Камышин безне караңгы чырай белән каршылады дип әйтмәс идем мин. Барыннан да элек, без бу шәһәрдә фронтны һәм тылны күпмедер дәрәҗәдә бер-берсенә тоташтырып, почта алышып, үзара хәбәрләр ялгап торучы обменный пунктны таптык һәм шуның ярдәмендә Сталинград фронтының күп кенә гаскәри берләшмәләре, тылы һәм идарә органнары барып кушылган Көньяк фронтының Политидарәсе белән тоташа алдык. Ә бу безнең өчен иң әһәмиятле бер табыш, инде без кая барганыбызны ачык кына белми баручы, тик капшанып кына, тик җае чыкса гына һәм гаскәр төяп баручы эшелон комендантларының көйләре килсә генә эләгеп китә алучы биш мескен мөсафир түгел, ашау-эчү яклары таклы-җепле булса да, күкрәк киереп баручы кирәкле кешеләргә әвереләдек шикелле. Бездән еракта торган начальникларның боерыклары да килмичә булмагандыр, Камышинда без юл буе җилкәбездә диярлек килгән кургашын йөкле авыр ящикларыбыздан котылып, аларны шул якка үтүче эшелонга төяп җибәрдек. Үзебез ул эшелонга нилектән сыймаганбыздыр? Хәзергә хәтле шуңа төшенә алганым юк. Күрәсең, безне алып баручы капитанның мөгезе үткен булмаганлыктан гына булуы да мөмкин. (Җаяләр эчендә генә әйтеп үтү: без капитан Клиблинең керергә мөмкин булмаган җиргә дә ырып-ерып кера ала торган әрсезлеге җитәрлек булмаганлыгын юлда да, барып җиткәч тә әледән-әле күрдек.)

Шулай да, әрсезлеге җитәрлек булмаса да, ул безне ачык һавада калдырмады, башыбызны кар-яңгырдан капларлык түбә таба алды: без әлеге шул обменный пункт дигәннең рәтләп ягылмаган, без урнашканнан соң гына электрический камин белән аз-маз ышык төшерелгән бер бүлмәсенә урнаштык. Бу, әлбәттә, чагыштырмача урнашу гына. Монда карават-мазар юк, ятуыбыз-торуыбыз идәндә, әле ярый,

баш куюучен посылка, хатлар тутырылып пичәтләнгән зур-зур брезент капларны файдаланырга рөхсәт иттеләр.

Ибраһим Газиның бер вакытта да, бик авыр чакларда да бирешми торган оптимист җаны, юмор хисен югалтмаучы теле әле дә булса, килеп-килеп, искә төшә.

— И, Пәтыйх җаным, ятабыз бит адәм балаларының өзелеп-өзелеп язган сәлам хатлары өстендә, бездән дә бәхетлерәк тагын кем бар икән бу килбәтсез фани дөньяда? — дип сайрарга тотынды ул иртән күзен ачуга.

Кичтән дә локмә ризык капмый яткан, иртәгесен дә коймак пешкән нс килмәгән шыр ялангач таш тартмада Ибраһимның болай авыз ерып торуы җенемне чыгарды:

— Дүрт йөз грамм гына булса да көн саен үзенә тиешле паегын алып ашый торган кешеләр бөтенесе дә безгә караганда бәхетлерәк,— дип, күкерт урынына кабынып, аның авызын томаламакчы булдым мин,— син дә, Ибрай, яшь бозау шатлыгына биреләсең кайчак.

Ләкин Ибраһимның авызын томалау минем көчтән килә торган эш түгел, вакыты белән ул үзенең гаҗизләнгән җанын эчкәрәк яшерү өчен дә шулай теленә салына башлый иде.

— Әллә шушы сәлам хатлары өстенә баш куеп йоклаганныкы, Грушаны күрдем бүген төшемдә, аклы күлмәктән, башында зәңгәр косынка, коймак пешереп өлгертергә йөри иртәнге чәйгә.— Һәм тагы мине үчекләргә тотынды.— Син, Пәтыйх малай, Мәрфугаңны әллә бөтенләй оныттың ук инде? Теге чакны, Ялтаның иҗат йортында Алиш, син, мин өчәү ял иткәндәге кебек, «Мәрфуганы сагынам!» дип мендәр кочаклап елап йөргәнеңне күрмим.

— Кочаклап йөрерлек мендәре кайда соң монда?— дип, шырпылы гына җавап кайтардым мин, сөйләшергә дә, тыңларга да теләмәгәнлегемне ачыктан-ачык сиздереп.

Күпмедер вакыттан соң Ибраһимым, бу юлы инде гаять җитди рәвештә, минем каршыга үзе килеп басмасынмы! Һәм ниндидер заговорга әзерләнгән кебек, кысылган тавыш белән сүз башлады:

— Бу капитаннан да әллә ни өмет юк, чапкан була, чапкан була, толку мало. Мин үзем, гражданкада чакта, беләсең килсә — бел, комсомолның кантком секретаре булып эшләгән кеше, ул тирәнең телен беләм. Әйдә әле без, Пәтыйх малай, болай итик: Клиблигә бик сиздермичә генә, икебез гражданский властьларга мөрәҗәгать итеп карыйк. Син — Язучылар союзы члены, мин — Язучылар союзы члены, икебезнең дә кесәдә билетларыбыз, бәлки ни дә булса чыгар, чыкмаса тагы пролетариям нечего терять!— хәтта бусында да Ибрай үзенең Ибрайлыгын итмичә кала алмады, миңа төрттерә узды,— синең бу тюлень урнына ялтырап торган күн пальтоң булганда, житмәсә тагын башыңда йолдызлы бүрек... ни дә булса рәт чыкмый калмас.

Тәвәккәлләгән — таш ярган, диләрме әле. Таш ярмасак, ярмабыз, шулай ук баш та ярмабыз, киттек без Ибраһим белән. Беләсезме кая? Һәм кемгә? Туп-туры Горкомга, беренченең үзенә. Сугыш чоры, житмәсә тагын фронт сызыклары да үткән җир, эш башындагы кешеләрнең этикет саклау кыланышлары онытылган. Һич көттермичә, беренче үзе кабул итте. Миннән әллә ни чыкмаслыгын Ибраһим белә, сүзне һәм мәсьәләне ул башлады. Бик тә бетәшеп тә түгел, үзебезнең дәрәҗәбезне саклап, җае чыкканда юморын да кыстырып, ләкин хәлебезнең хәл эчендә калганлыгын һич яшермичә, йомышыбызны әйтеп салдык. Уен түгеллеге йөзебезгә дә, әлбәттә, чыккан булгандыр, шуның өстенә кесәләребездән Союз билетларыбыз да чыкты. Кешесенә туры килмәсәк, хәер, болар гына бәлки бернинди нәтиҗә дә бирмәгән булырлар иде, ләкин без, бәхеткә каршы, кешесенә туры килгәнбез. Секретарь безнең белән элек, бик тә үз кеше буларак, сөйләшеп алды.

сорашты, кайчандыр юл уңаеннан шушы җимерек калада Александр Твардовский да булып киткән икән, сездерер-сездермәс кенә ул факт белән дә мактанды, кыскасы, әдәбиятка бик тә хәер-хаһ кеше булып чыкты секретаребыз.

Әлбәттә, сугыш чоры — азык-төлекнең бик үлчәүле икәнлегең, без— Союз членнары алдында бераз аптырабрак калганлыгын ул да сиздерде — ләкин бер нәрсә дә эшләмичә ишектән кире борып чыгарырга да уңайсызлана иде — без дә моны сиздек.

— Рәсми юл белән берни дә эшләп булмый, егетләр, үзегез беләсез, сугыш чоры, кылны кырыкка яра торган вакыт, кырыкка гына ярып котылып булса әле... Шулай да берәр кнопкага басып карарга ярый.

Беләбез, беләбез, безгә дә бик уңайсыз, ләкин «кнопкалар»ның нинди тавыш биргәнен тыңлап бетермичә чыгып та китәсе килми.

«Кнопкалар»ның әле берсенә, әле икенчесенә, әле өченчесенә баса торгач, ахыры, бер рәтен таптылар булса кирәк, секретарь бөтен бер бит кәгазь алып, шуның нәкъ уртасына кыска гына итеп ике-өч авыз сүз язды һәм кая барырга икәнен адресы белән күрсәтте.

— Зинһар, гаепләмәгез только, егетләр, булганы белән бәрәкәт, дигәндәй, авызыбыздан өзеп...

Күңелебез йомшап калды, кайтканда Ибраһим да, мин дә сүзсез кайттык. Ни дә булса сөйләшеп, рәхмәт хисләре белән тулган күңеллә-ребезне гадәти хәлгә төшерәсебез килми иде. Сүзсез кайттык, ләкин үзебезнең кечкенә, әмма азыкка бик тә мохтаҗ коллективыбыз өчен бер зур кирпеч солдат әпәе, ике селедка, һәм өч концентрат брекеты алып кайттык.

## Шәфәкъмы бу? Таңмы бу?

Шәһәрме безгә ошады, безме шәһәргә үтә дә ошап калдык. Камышинда бер атнага якын тоткарланып, әлеге шул сәлам хатлары өстенә башларыбызны куеп йокладык. Рәтләп юынмаганныкы да булгандыр, башта борчу да бар һәм гомумән ул чагында кем дә аннан азат түгел, бездә дә булды күлмәк белән тән арасында куышып йөри торган «тешләк»ләр. Ләкин Ибраһимдагы бетмәс-төкәнмәс оптимизмны хәтта ул эшәке бөҗәкләр дә бетерә алмадылар.

— Ай-һай ла, бүген берсе тешләде! Пәтыйх, синеке, синнән кергәндер бу, малай. Мин үземнекеләргә иләшеп беткән инде, минекеләр алай явыз тешләмиләр иде.

— Җитәр, гел генә төшеңдә Грушаңны күреп, саташып ятарга димәгәндер,— дидем мин дә ачуым, чыгып.

Диалог шуның белән бетте, Ибраһим, салкын дип тормыйча, күлмәген салып, эзләнергә тотынды — рәхәт, бер үзебезгә бер бүлмә, читят кеше юк, әлеге «җанвар»лар барыбызда да җитәрлек, рәхәтләнеп сугыш хәзер шулар белән.

Ә утырып китә алганыбыз юк, яңа укмашкан хәрби частьлар белән тулган эшелоннарның күбесе Камышинда туктап та тормыйча выжылдап узып китәләр, капитанның комендатурадан кайтып кергәне юк, аны хәзергә «Менә иртәгә!» яки «Вот, вот!» белән юатып йөртәләр. Шул тирәдә чуала торгач, ахырысы, ул без барып кушыласы фронтның Политбүлеге белән тоташты булса кирәк. Күрәсең, мондагыларга фәрман-фәлән иңгәндер, ниһаять, капитаныбызга яңа бланкыга яңача итеп сугылган азык-төлек аттестаты ясап бирделәр, безгә дә сухой паек рәвешендә аз-маз өлеш чыга башлады һәм, гомумән, фронтка якынлаша барган саен ул яктан «демократия» киңәя төште. Ниһаять, бер көнне

без, Камышин белән саубуллашып, чуар халык белән шыгрым тулган бер составка ничек кирәк алай эләгеп китеп тә бардык.

Сталинградның үзенә түгел, Сталинград үзе ябык һәм янып ята иде әле ул чакта, аннан чак-чак кына көньяк-көнбатышка табарак — Красногвардейск дигән кечкенә бер шәһәрдә туктаттылар безне.

Әлбәттә, шәһәрнең үзендә безгә баш төртер урын табылмады, шәһәр, һәр торак пункты, кайтып килүче, китеп баручы яки ялга туктаган гаскәриләр, гитлерчыларның әсир алынган берләшмәләре белән тулган иде, комендатура безне шәһәрдән биш километр ары, чокыр-чакырлар арасына урнашкан бәләкәй бер хуторга җибәрде. Теге иңне сытып кергән торган кургашын ящикларыбыз инде юк, ихтимал, алар барасы җирләренә барып җиткәннәрдер, хутор икән — хутор, биш километрда икән — биш километрда, анысы өчен дә бик куанышып, җирле халыктан сораша-сораша, без җәяүләп кенә шул якка элдердек.

Бара-бара биш километр дигәннәре әллә тагы унбиш километрга әйләнде, караңгы төште, тик сул яктан ярым күкне билгәгән шәүлә без барасы юлны яктырта — моны шәфәкъ дип тә, таң дип тә кабул итәргә мөмкин — бездән сулдарак шул янып туктамаган Сталинград күтәрелә иде. Шәфәкъме бу, таңмы бу? Чынлабрак уйласаң, монда алар икесе дә бар: бу авыз гармуны сыздыртып, урыны-урыны белән мина, артиллерия уты туздырып килгән мактанчык Гитлер армадасының шәфагы, соңыннан Европа халыкларына азатлык алып барачак Совет Армиясенең таңы беленүе иде.

Менә без үзебезгә билгеләнгән хуторда. Ул көннәрнең кырыс атмосферасын дөрес чагылдыру ягыннан, вакыйгаларның кайнар эзләренә басып, 1944 нче елны язылган «Хуторда» хикәясеннән уздырып булмастыр, уздыруның кирәге дә юктыр дип уйлыйм.

«...Йомыры телебезне яссы итеп, яхшылап сөйләшкәч, берни дә ишетмәмешкә салышып ятучы карчык мич башыннан ашыкмыйча гына төшәргә мәҗбүр булды. Ул иң элек почмактагы икона тактасы алдына туктап, Мәрьям-ана сурәтенә бер-ике мәртәбә башын орды... Бары тик шуннан соң гына безнең янга килеп:

— Талоныгыз бармы? — дип сорады.

Һәм ул, бердәнбер ян тәрәзәгә якыная төшеп, янып ята торган Сталинград шәүләсенә чак кына күз төшерде дә, яңадан безнең янга килеп:

— Киленемнең юл эшеннән кайтасы бар, менә өй суык, ягарга бер агач утыным юк, — дип карчыкларча зарлана-зарлана яңадан мич башына үрмәләде».

Юл эшеннән кайтасы киленен көтеп ятканда, карчыкның ягылмаган салкын өенә — кунак өстенә кунак — җиккән үгезләрен тугарып, печәнгә кушкан юлчы ике хатын килеп керә.

«...Бер тын уйланып торганнан соң, казак хатыны (әйдәгез, аны шулай дип йөртик), җанын кая куярга белмәгәндәй, идән буенча бер йөренгәләп алды, ахырысы инде ашамаган килеш ятарга туры килә дип торганда, кинәт башын калкытып, якты күзләре белән безгә текәлде:

— Хлопцы! — без аның бары шул сүзен генә ишетеп калдык, ул яшен ташыдай атылып, өйдән йөгереп чыгып китте.

Ярты сәгать тә үтмәгәндер, кочагына кыска-кыска гына итеп кисқәләнгән утын төяп, кереп тә җитте ул.

— Нигә ватык чананы тагын утыз биш километр өстерәп йөртергә? Иртәгә ике үгезгә бер чана, утырабыз да чабабыз. Ә бүген менә мичне ягып җылынып җибәрәбез, дуңгыз маенда бәрәңге кыздырабыз. Син, Саря, дуңгыз мае ашамыйм дигән сүзеңне ташла, әйбәт азык ул дуңгыз мае, аннары тагын концентрат пешерәбез. Хлопцы, сездә инде шырпы булмыйча калмас.

Тәмәке тартмаганлыктан, миндә дә, иптәшемдә дә, наборщик малайда да шырпы юк иде, моның өчен казак хатыны безне тиргәп алды...»

Шулай кызып тотынсалар да, ашарга алай тиз өлгертмиләр. Без, аларга комачауламыйк дип, урамга чыгып киткән идек, ахырысы, озаграк йөргәнбездер, без кергәндә «бәрәңгеләр дә, концентрат та пешкән, хәтта кирәгеннән артык пешкән, котелоклардан ташый һәм төпләренә ябышып бетә язганнар, ә бездән, үзебез карарбыз, дип ышандырып калган Сария апа (мишәр хатыны) белән казак хатыны, мичтән төшкән жылы нурдан эреп, идәндә кочаклашып йоклап киткәннәр иде.

Үгезләр җигелгән чаналарга глубинкадан азык төяп кышкы салкында арып-талып юл килгән ике халыкның ике вәкиле — казак хатыны белән татар хатыны, аларның үзләре пешерергә куйган азыкларның пешеп житкәнен дә көтә алмыйча, кочаклашып идәндә йоклап китүләре — әллә бу Сталинград эпопеясенең якты бер сәхифәсе түгелме?

## Якташ белән очрашу

Гомумән, бу сәфәребездә очрашулар шактый күп булды. Иң элек, без монда күпләп-күпләп тере фрицларны очраттык. Аларны колонналап-колонналап, әлбәттә, нык конвой күзәтүе астында, лагерьлардан каядыр эшкә алып барулары идеме бу, әллә эштән соң кире лагерьларга озатуларымы? Безгә ул чаклысын нечкәләп аңлатып торучы булмады, ләкин без аларны күрдек. Кайчандыр Гитлерның иң ышанычлы дивизияләре саналып та, бу өзгәләнгән, йончылган төркемнәрдә хәзер бернинди сугышчан кыяфәт тә калмаган, башларын-муеннарын ни әләксә шуның белән ураганнар, ябыкканлыктанмы, өске мундирлары, шинельләре бушап, сузылып калган, шуларга абына-чалышая аякларын көчкә-көчкә генә атлаучы бу бетәшкән килмешәкләрне хәзер, салкын Рәсәй кышында, илсез-догасыз мескеннәр дип кенә карарга да мөмкин булгандыр. Ләкин астыртын янучы күзләренә караганда, юк, әле аларның агулары сыгылып бетмәгән, чак кына йомшарт тезгенне, алар яңадан синең бугазына ташланырга әзерләр...

Шулай да бу тирәдә безгә озак чуалырга ирек бирмәделәр, шул як хуторларда кыска гына ялда булган фронтовикларны төяп көньякка узучы эшелонга без «кара сарыклар»ны да ышаныр-ышанмас кына эләктереп, поезд Красногвардейск шәһәренең җимерек станциясеннән кузгалып китте. Капитан безгә соңыннан, кузгалып китеп бераз тынычланганнан соң, житкерде: берничә мәртәбә сугышта булып, ватылган-жимерелгән фронтовиклар арасында без, әлбәттә, төрлечә кызыксыну уятканбыздыр, поезд коменданты безнең капитанны алдан ук кисәткән: кесәләрегездәге кәгазьләргә караганда, сез болай ышанычлы кешеләр күренәсез, ләкин, агай-эне, болай бит... ни. Солдат сезнең хисләрегез белән түгел, солдат сезнең үзегез белән кызыксына. Тылдан киләсез, сораша-төпчәнә башлаулары мөмкин: тылда хәлләр ничек тә, анысы-монысы... Кыскасы шул: үзегезне аерымрак тотыгыз, телегезне бигрәк тә. Без сезне Зимовникига чаклы ничек тә исән-сау алып барып житкерербез, аннан ары безнең үз юлыбыз... Чын фронтовиклар юлы. Төшенгәнсездер, дип уйлыйм».

Төшенмәгән кайда: болай үзе ишарә генә кебек, ләкин бөтенесе ачык: ничек кенә ачлы-туклы азапланып бармыйк, без әлегә фронтовиклар түгел, солдат арасында кирәккән-кирәкмәгән сүзгә катгый рәвештә урын булмаска тиеш.

Ләкин без түгел, солдат үзе башлый сүзне. Безнең тыл кешеләреннән булуыбыз һәм яңарак кына тылдан килүебез солдатны, әлбәттә, кызыксындыра, без әйтмәгәнне ул үзе әйтә иде.

— И, туганнар, тотып карыймчы хет шушы гражданский киемнәрегезне,— дип, саф татарча сөйләнеп, безнең янга килеп утырды арадан

берсе. Кукмара районыннан икән, авылының исемен дә әйткән иде, ул чаклысы ук онытылган,— сугышның башыннан бирле чиләнгән көн, үз ягыбызда булса — икенче хәл, безнең анда, ичмасам, баш каплар урыннар бар: чокыр-чакыры, урманы, тавы дигәндәй... Монда гел дала да, гел җил. Җилне пуля, миномет сызгыруы гына баса торгандыр басса. Өченче тапкыр ранный булуым, ачу килмәслек түгел, тырный да уза, тырный да уза. Санбатка җибәреп атна-ун көн җамыйлар-җөйлиләр дә тагы шушы шыр далага китереп сылыйлар.

Бераз паузадан соң ул, балалар кебек, янә безнең киемнәребезне— әле беребезнекен, әле икенчебезнекен — сыпыргаларга тотынды:

— Без дә шушындый киемнәр киеп йөргән кешеләр ич кайчандыр. Сагындыра, туганнар, сагындыра гражданка.

Тагын бер кыска пауза, аннан соң тагын да өзгәләнебрәк сузып куя бу:

— Исән-сау кайтып, хатын белән малайны каршыма утыртып, бер чәй эчү көннәре җитәрме икән, малай? Болай үзе кырабыз инде кыруын Гитлер токымнарын, дай бух. Тиздән сукыр тәренең үзенә дә барып җитәрбез, псих тәренең... Ә туган ил сагындыра шулай да.

Бу әңгәмә газета аша, бүрәнә аша бүре күреп өйрәнгән журналист фантазиясе пешергән сөйләшү түгел, бу — сугышның газабын да күп күргән, шул ук вакытта ахыр чиктә безнең җиңәчәгебезгә дә ихлас ышанган чын фронтовик сүзе иде. «Исән-сау барып житеп, эшкә бер керешсәк, газетаны шулар телендә чыгарыр идек, алла боерса» дип куйдым мин, эчемнән генә алланы искә төшереп.

Ләкин бу юлдагы уйлану гына, әле барып җитәсебез, фронтның очын тотасыбыз бар, әле әнә Зимовникида безне тагын төшереп калдырасылар икән! Анысы нинди җир, нинди кала икән тагы? Ишеткән-күргән җирем түгел, ничек булса да, озак тоткарланырга язмасын, ипигә-шулпага аптыратмасын, аннары тагы аякка бер пар итекме-ботинкамы, күн әйбере бирсен. Югыйсә, ажгырып яз башланды бу якларда, күреп барабыз: кырда кар күзгә күренеп көпшәкләнде, ала-колага әйләнде, юл читләреннән, иңкүлекләрдән челтерәп кар суы ага, ә без — Равил Казаковтан башкаларыбыз — барыбыз да киез итектән.

Курыкканга куш килде, Зимовники дигән ул кечкенә шәһәр — район үзәге — тоташ язда утыра иде без килгәндә. Көн кичкә авышканлыктан, дөрес, урамны бераз чираткан иде, ләкин шулай да, ай-һай ла, киез итек белән басулары...

Капитан бу очракта да югалып калмады, иң элек безне бер түбәсе каплаулы өйнең өч-дүрт баскыч белән җирдән күтәртелгән крыльцосына тезеп куйды, аннары Равилгә үзенең киез итеген калдырып, аның күн итеген киде һәм — мәгълүм мәшәкать — Зимовникиның комендатурасын эзләп китте — ашарга нидер юнәтергә, кунарга җылы почмак табарга кирәк иде. Ләкин китешли безне кисәтергә шулай да онытмады:

— Куып ук төшермәсәләр, бу крельцодан җиргә төшәсе булмагыз, егетләр, өстегездән яумый, аяк астыгыз коры и терпи, казак, атаман әйләнеп килгәнче.

Без крыльцодан төшүен төшмәдек, ләкин көн кичкә авышып, кичке ачы дала җиле куыра башлагач, артык түзәрлегебез дә калмады, тындык һәм һичбер ялыну-ялварусыз, шул ук вакытта хуҗаларга дәгъва да белдермичә, бер-бер артлы җылы өйгә таба елыштык, ян эскәмиягә сүзсез генә тезелешеп утырдык. Сугыш күргән, теге як солдатлары да, безнекеләр дә узган хуҗабикәләр әллә ни тәкәллефләнеп тормадылар, хәер. Безнең туңып килгән кешеләр икәнебезне күреп, шундук мич ягып җибәрделәр һәм — иң аптыраткан хәл — өлкән хуҗа хатын, безгә яхшылык теләп, сүз катты:

— Мин барыбер яна, жылытырдай азык-төлек әйберләрегез булса, чыгарыгыз, жылынырга куйыйк.

Безнең жылытырга куярлык локмә ризыгыбыз юк иде, барыбыз да сүзсез генә башларыбызны түбән идек. Тик бераз әл-хәл алганнан соң гына Ибраһимыбыз телгә килде:

— Безне комендатура ашатырга тиеш, менә-менә капитаныбызны гына көтәбез.

Кара әле, ач әрвахны, тавышы бөердән чыга, сүзләрен кайдан тапты диген!

## Мич башында үткән бер төн

Ян сәкедә чыпчыклар кебек тезелешеп һәм хужаларның түр өстәлдә чөкердәшеп кичкене ашауларына ничек тә күз салмаска тырышып, вакытны ярлы тәкәбберләрдәй тәки суздык. Капитаныбыз озак йөреп, яхшы ук алҗып, ләкин ирешкән нәтиҗәләре өчен авызы колагына житеп, кайтып керде. Ирешкән нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гайбарәт иде: беренчедән, шундагы жирле гарнизон ашханәсендә, үз кешеләрен туйдырганнан соң, әгәр нинди дә булса ризык заты калса, безне дә жылы шулпа белән сыйлап чыгарырга булганнар. Икенчедән, комендатурадан төн кунып чыгу өчен бишебезгә биш талон алуга ирешкән, әмма Зимовникиның үзеннән түгел (анда бездән башка да берничә часть тора, өйләр солдат белән тулы), поселоктан читтә, берничә километр жәяүләп атлыйсы, ди. Өченчедән, иртәге көнне киез итекләрдән ничек кирәк алай су ерып үткәрсәк, иртәнең иртәгесенә Зимовникидан Ростов-Донга ягулык төяп, самолет китәчәк, безне шул самолетка, бензин мичкәләре арасына кыстырып, озатып җибәрү ихтималы күренеп тора, имеш. Уйлап карасаң, авыз ерырга житәрлек сәбәпләр иде болар. Кай пунктларда атналар, ун көннәр буена китә алмыйча, дөм билгесезлектә үткәргән без мөсафирларга тизрәк юлда булу, әлбәттә, хәерлесе иде.

Көньяк табигатенә хас рәвештә, без чыкканда, төнгә каршы аяк асты яхшы ук чираткан, карабрак атлаганда аякларны бик чылатмыйча да мөмкин иде. Тик теге гарнизон ашханәсендә дигәне генә корырак булып чыкты. Барыннан да элек, дежур солдатлар тәүлек буена аяк өс чабып тәмам арганнар, аларның, тизрәк эшне бетереп, кайтып китәселәре килә иде. Шуннан инде безнең ни дәрәжәдә кадерле кунаклар икәнлегебезне үзегез чамаларсыз. Шулай да, вәгъдә иман дигәндәй, бер сүз биргәч, безне ишектән кире борып чыгармадылар, аллюмин жамаяклар, тимер кашыклар янә шалтырады, безнең күңелне алгысытырга шунысы да бик җиткән иде. Ләкин жамаякка салынып, алга китерелгән кадәрлесе «Хужа Насретдин»дагы «баба шулпасырак» булып чыкты. Тамак туймаса да, эч жылынды, булганына бәрәкәт, әле ул чаклысын рәтләгәне өчен дә капитаныбызга һәм, бигрәк тә хужаларыбызга, рәхмәтләр яудырып чыгып киттек. Зимовники өстенә чекрәеп торган салкын айлы төн килгән, хәзер инде аякны бөтенләй чылатмыйча да атларга мөмкин иде.

Без, йокларга барасы хуторны сорашкалап, эчкә кергән әлеге жылы шулпа дәрте белән эзләп киттек. Төн якты, юл ярылып ята, тизрәк барып житеп, авасы килү омтылышы да арттан этә иде кебек. «Менә, менә! Якында гына» дигән иде кебек. «Менә, менә! Якында гына» дигән иде жирле халык, ләкин бара-бара бу «менә-менә» җәһәннәм ераклыгы булып тоелды. Җитмәсә, теге буш шулпа, ачу китереп, эчтә «голт-голт» сөйләшеп килә, юлда әле беребез, әле икенчебез туктап, аны бушата бара, нилектән болай еш тукталу белән кызыксынучы юк, сүзсез дә

чамалыйбыз, бәрәңге, балык кисәкләре генә йөзеп йөргән «Баба шулпасы» янына байтак кына казан юган су да кушылган иде булса кирәк.

Хәер, анда мыни хикмәт, тизрәк хуторга барып житик. Барып життек, ишекләргә сугыла башладык, ләкин ишекләрнең берсе дә ачылырга ашыкмый, бөтенесенә бездән алда өлгерә торган солдат — агай-эне монда да килеп тулган. Кайдан, нинди гаскәри тора, кая барышлый тукталу икәнлекне сорап торыш юк һәм, гомумән, капка төбендә сакта торучы гаскәриләрнең без узгынчы «карасарыклар» белән сөйләшеп торасылары да килми иде. Йөри торгач, шулай да бер рәхимле хохол табылды.

— Үземә дип әйтмим, минем хатада үземә дә урын юк, йоклый алмаганлыктан урам таптап йөрү,— дип башлап китте ул, әллә чынлап, әллә бездән тизрәк котыласы килеп,— әнә арырак, өч ихата узып, дүртенчесе, сезнең үз халкыгыз, татары-хлопцы, ул ничек тә үз кешеләренә борын төртерлек урын табар, только ни... «Дядя Зангри» дип эндәшегез, исемен бозып дәшкәнне өнәми.

«Дядя Заңгри» дигәне Заһри абзый дигән кеше булып чыкты, бик тә кочак җәеп каршыламаса да, еракtan килүче «үз братыбызны урамда калдырып булмас» булып чыкты.

Бик рәхәтләнеп, алдан ук рәхмәтләр укый-укый, стеналары балчык кирпечтән сугылып, пөхтә итеп агартылган тәбәнәк һәм мунча кебек җылы өенә тезелешеп барып кердек. Барып кердек һәм, бер мизгел аптырашып, бер-беребезгә карашып калдык. Идәнендә, түшәп салган кебек, солдатлар йоклап ята, өенең артык җылы булуында да шушы яшь, таза солдатлар гаепле түгел микән, дигән шук уй узды күңелдән.

Ләкин «үз братыбыз» безгә озак шаккатып торырга ирек куймады:

— Күргәнегез вона шышы, — диде ул өзеп,— мин сезгә гүрнәчә булыр дип әтмәдем, но төн үтәр урын табылыр, икегезгә вона җылы мич башы бар, җылы, ташы кызган, сүгән хәләл-җефетләрегезнең кочагында ятканкебек җатарсыз.

Без шундук Ибраһим белән күз кысышып куйдык — әгәр капитан үзе үк тентемәсә; хәләл-җефетләребезнең «кочагы» кебек җылы мич башы, әлбәттә, Ибрай белән минеке.

Һәм ул чын-чынлап шулай булып чыкты да. Ир урталары житеп килгән чак, гомер узып бара, кайларда гына баш куелмаган да, нинди генә мич башлары күрелмәгән, минем йокының бер җирдә дә рәтле булганы юк, неврастеник — алланың рәхмәте аркасында килгән бәла, ләкин шушы балчык кирпечтән сугылып өелгән ак, тәбәнәк өйдә, җылы мич башында Ибраһим белән арка терәшеп һәм, йокы аралаш, терсәкләребез белән бер-беребезне төрткәләшеп йоклаган йокыдан да тәмле йокы күргәнемне хәтерләмим.

Безнең ашыгыч чабасы җиребез юк, йоклаганбыз йоклый алганча. Торганда идәнгә түшәлгән солдатлардан җилләр искән, без үзебез генә калганбыз һәм йорт хуҗасы Заһри абзый безне, күптән күрешмәгән газиз туганнарын күргән кебек үз итеп, янә бер мәртәбә каршы алды, барыбыз белән дә ике куллап күрешеп чыкты, кайдан килүебез, кая баруыбыз белән кызыксынды. Безнең шулай мәшәкатьле озын юл үтеп, фронт итәген тота алмавыбыз турында ишетеп, үзенчә яхшылык белән һәм үзенчә уен-шуклык кыстырып, әйтте:

— Һай, сез барып, коригын тотканчы, безнең доблестный вояклaрыбыз гитлер свалатаның умыртка сөяген җимереп, война үзе во-всю да бетә калса, вона да шәп булыр иде, канатым.

Абзыйның теләге әйбәт, әмма зур җиз самавыр кайнатып, бәрәңге пешереп, безне түргә утыртып, җылы өйдә, ажгырып утырган самавыр башында пешкән кайнар чәй белән сыйлап чыгаруы, барысына карaганда да әйбәтрәк булды.

## Зимовники калды, без көньякка очабыз

Безнең бәхеткә каршы, аяз, салкын, кояшлы иртә иде. Аяк астын нык кына туңдырган, киез итектән хет җәннәтнең үзенә чаклы элдерт. Хәер, күп элдертергә туры килмәде, аэродром дигәннәре шунда, шәһәр артында гына икән. Бер-ике урында капитан теге фронт Политидарәсеннән бирелгән дәрәҗәле кәгазен чыгарып күрсәтте, бөтенесе шул, без аның артыннан сүзсез генә тыракладык. Алда бер әйттем дә бугай, әйтмәгән булсам, әйтү шушы: фронтка якыная барган саен, сәер хәл, демократия көчәя, волокита әзәя бара. Самолетның кайчан китәсен дә әйтеп тормастан, безне керттеләр, ахрысы, көннең тагы нзрәтә башлавын, ә безнең киез итекләрдән икәнлегебезне күреп, күңелләренә рәхим-шәфкать нуры иңде булса кирәк.

Әле дә булса күз алдымда: тыштан яшькелт-соры юл-юл буяулар белән буялган (маскировка өчен булса кирәк) котсыз зур транспорт самолеты иде. Утыру-мену әллә ни тәкәллефле булмады. Самолетның үзе кебек үк котсыз зур ящик, иң элек, беребез арты икенчебез, шул ящик өстенә сикереп мендек, шундук безгә самолет ишегеннән баускыч төшерделәр, бериндн команда-кушу ишетелмәде, хәер, заманасы безне инде өйрәтә башлаган, кая монда тавыш күтәреп команда биреп тору, үрмәлә тизрәк үрмәли алганча. Самолетның эче-котсыз зур бензин мичкәләре белән тулы, пилот кабинасы безгә бөтенләй күренми, кем алып барачак безне? Белгән кеше юк һәм әйткән кеше дә юк. Әлеге шул бензин мичкәләре арасында буш калган аралыкларга — кем ничек кысыла ала — кысылыштык. Арадан иң нык елтырап торганы Сибгат абзыйның күзләре (соңыннан, төрле хәтәр минутларда күңелгә иң элек шөбһә сала торган сигнал да аның шул зур кара күзләре була иде).

Бара-бара игътибар иттек: самолетның өстендә зур гына тишек-амбразура, шул тишектә зенитка мылтыгы белән коралланган солдат утыра, ул әледән-әле башын чыгарып, әйләнә-тирә этрафка күз сала, хәзергә ул-бу юк, зенитка һәм солдат тынычлар. Шулай да тылдан баручы без интеллигентларга шом керә башлады: гел болай тик кенә калмаулары да мөмкин ич аларның, димәк, якынлаша барабыз дигән сүз.

Сәгать-сәгать ярымнар чамасы очтыкмы икән самолетыбыз — кузгалгандагы кебек тәкәллефсез рәвештә, Ростовның күп мәртәбәләр дошманның налетын күреп, теткәләнгән аэродромына төшеп туктады.

Тәэсорат төрлебездә төрлечә булгандыр, хәзер — утыз биш-кырык елдан соң — хәтерне бимазалап торуны кирәк тапмыйм, Ибраһим Гази мәрхүмнең нәкъ шул көннәрдә, тәэсирнең һәм күзнең үткен чагында, кәгазьгә төшерелгән юллары бар икән, «Казан утлары» журналының 1980 елгы 5 нче санында «Көндәлектән бер бит» дигән баш астында язмасы басылган, бик тә төгәл билгеләнгән детальләр, өзекләрен йолкып шуннан күчерәм:

«Февраль ахырында самолет белән Ростовка килеп төштем. Кар бетеп бара. Шәһәр өсте күгелҗем томанмы-төтенме белән капланган. Менә самолетның тәгәрмәчләре җиргә тиделәр. Моторлар, гөрелдәп, самолетны аэродром янына тарталар.

Шәһәрнең теткәләнгән булуы өстән үк күренгән иде. Хәзер бөтен детальләре белән күз алдында: менә аэродром янында ук боеприпас төягән берничә немец вагоны өстенә бомба килеп төшкән. Вагоннарның кайсы кырын яткан, кайсы чәрдәкләнгән, авиабомбалар атылышып җиргә сибелгән, ләкин ни өчендер ярылмаганнар. Кырыкка бөгелеп, бөтерелеп беткән тимер-томыр тавы өелеп калган. Шартлау дулкыны якындагы өйләрне ишеп ташлаган.

Без тыкрык белән шәһәргә чыгабыз. Аяк астында телефон чыбыклары чуала, патроннар, снарядлар, гранаталар аунап ята. Янган, кырыкка бөгелеп куркыныч төскә кергән танклар, автомашиналар: кайбере үләксә шикелле сузылып ята, кайберләре үлем алдыннан, үлем газабы белән газапланган кебек, арт «аяклары»на басып, бөтен гәүдәсе белән алга ыргылып торалар.

Без, тимерчыбыкларга абына-сөртенә, шәһәрнең җимерекләренә таң калып барабыз.

Без барасы җир биредән 12 километр чамасы ераклыкта. Биредә гомумән кызык: берәүләр әйтә, 8 километр, ди, берәүләр — 12; кайвакытны барасың-барасың — һаман 8 километр кала, барасың-барасың— һаман 8...

Боз өсләп Дон аркылы чыкканда, патруль туктатып, безгә шикләнеп карады: сез, ди, чолганыштан кайтып килмисезме, ди, бик өс-башларыгыз тетелгән, ди. Ә без, чынлап та, окружениедә яткан кешеләрдән бер дә ким түгел: аякта киез итек, ботинкасы барның ботинкасы котың чыгарлык.

Үткәрде. Киттек. Бик озак эзләп йөри-йөри, ниһаять, таптык.

Ике-өч көннән соң Батайскидан без яңадан Ростовка күчтек. Без узган юлы Ростовның үзәген күрмәгәнбез икән әле. Ләкин үзәкнең исеме генә калган — үзе юк инде. Бер генә исән йорт калмаган: кара тәрәзәләр (дөресрәге, тәрәзә урыннары), саламдай тимер балкалар, ишелеп төшкән түшәмнәр, чәлпәрәмә килгән пыяла... тау-тау кирпеч — менә шул бөтен калган әйбер.

Халык гадәтләнгән. Янган йортларга берәү дә күтәрелеп карамый. Тик без генә аһ-уһ дип барабыз. Һәйкәлләр ватылган, бакчалар киселгән, тапталган, магазиннар яндырылган, бөтен җирдә тимер дә кирпеч, тимер дә кирпеч. Әнә кызлар көлешә-көлешә таган атыналар... Берәүләр мәктәптән кайтып килә.

Ростовта әлегә водопровод эшләми, электр, мунча юк, трамвай юк.

Кичә политотделның кадрлар бүлегенә — Ростовтан 35—40 километр җиргә (һәм аннан ары — хуҗалык бүлегенә) бардык... Баштанаяк пычракка манчылдым. Машинада утыра-утыра тәмам катпым.

Бүген ике сәгатьләр чистартынгач, ниһаять, пальтоларым, чалбарлар, бүрек, ботинкаларым бераз адәм рәтенә керде».

«Ботинкасы барның ботинкасы котың чыгарлык»— бу җөмләдә Ибраһим ике төгәлсезлек җибәргән. Күн аяк киеме бары тик икебездә. Берсе — алмаш-тилмәш киелә торган әлеге шул Равил Казаковныкы. Икенчесен, Камышин шәһәрендә тупланган тәҗрибәгә таянып, Ибраһим белән икебез НКВДның район бүлегенә барып, без теләнеп алган идек. Без аны байтак вакыт әле беребез, әле икенчебез алмашлап киеп йөрдек.

Ростовтан Батайскига күчкәндә, Дон елгасында боз өстенә туш җәелгән иде, күн аяк киеменнән мәхрүм кешеләр — без, капитаныбызның зирәк киңәше буенча, киез итек астына такта, калай кисәкләреннән күтәртмәләр тагып шуыша идек, тиктән генә «чолганыштан кайтып киләсезме әллә?»— түгел.

Январь азакларыннан февраль ахырынача — җәмгысе ай да биш көн, ачы дала җиле, салкын кыш, шыбыр сулы яз аша үтеп, әнә шул мәшәкатьле озын сәфәрне кичтек, татар солдатларына аларны җөдә дә (үзбәк газетчылары белән аралашу аркасында телгә кергән сүз!) сагындырган ана телендәге сүзне — фронт газетасы алып бардык.

## Юл буенда ялгыз ат...

Батайскида берме, икеме көн генә булганнан соң, без янә Дон елгасы аркылы Ростовка күчеп, шәһәрнең көнбатышындагы җимерек бис-

тәсенә урнаштык. Гомумән, Ростовның җимерек түгел җире калмаган, кулдан-кулга күчеп, ул тәмам теткәләнгән иде. Казакъ, үзбәк, рус телләрендә инде чыгып килүче газеталар, аларның редакцияләре, аларның зурмы-кечкенәме типографияләре — без хәзер инде ишле идек. Нинди транспорт белән, ничек күчкәнебезне ачык хәтерләмим, һәрхәлдә, күтәртмәле киез итекләрдә түгел, боз өстенә чыккан суны тундырган, төн караңгылыгында, әллә ни азапланмыйча гына күчтек шикелле. Шулай да колагымда «Поменьше шуму, ребята, не на свадьбу едим!» дигән кисәтү сүзләре сеңеп калган. «Шәһәрнең көнбатышына» дигәнем дә бик үк төгәл булмаска мөмкин, без әле монда яңа аяк баскан кешеләр, әйткәнемчә, күчү төнлә булды, кайда көнбатыш, кайда көнчыгыш — аерып кына әйтү читен иде.

Ростовка күчүебезнең икенче көнендә үк безне, кузовына нидер төялеп, брезент белән капланган машинага, йөк өстенә утыртып, фронтның Политидарәсе, штаблар һәм АХО (административно-хозяйственный отдел) урнашкан җиргә алып киттеләр. Кайда, нинди урын — шәһәрме-поселокмы икәнлеген белергә өлгермәдек, гомумән, монда безнең эше бу җиргә әле аяк кына баскан кешеләргә күпне белү, бөтенесе белән кызыксыну рөхсәт ителми иде булса кирәк. Күпне белү өчен безнең капитаныбыз бар.

Минем белгәнем шул булды: без озак бардык, тирә-якта еракларга җәелгән дала, язгы ачы җил — су җиле, кузов өстендә, күктә кукраеп баручы ят кунакларны үтәли кисә, мин үземне Чеховның «Дала» повестендагы Егорушка сыманрак хис итәм, бу җирләр миңа ят, берсен дә белмим, чынын гына әйткәндә, берсе белән дә әллә ни өзелеп кызыксынмыйм да. Уйлап барганым шул: «Бомбежкага эләкмәсәк кенә ярый».

Күп кенә хуторлар, поселоклар аркылы үттек, арада зур бер чиркәүле авыл да күренеп калды, чиркәүле, димәк ки, рус авылы булса кирәк, ә исеме Солтан-сала. Алай икән, кайчандыр бу тирәләрдә безнең агай-энеләр кыдырып йөргән икән. Күңелгә әллә ничек моңсу уйлар килеп китте...

Мин инде моннан, АХО дип атала торган ул зур җирдән безне киендереп-ясандырып, чын солдат формасына төреп кайтарырлар, дип уйлаган идем, и, беркатлы да соң мин! Алай ансат кына эшләнәме соң андый эшләр. Аннары тагы мин, фронт Политидарәсе һәм һәртөрле штаблар да шунда булгач, безне генераллар алдында «Рас, два»га бастырып ук йөртмәсәләр дә, һәрхәлдә буебызга-сыныбызга күз төшерми калмаслар дип уйлаган идем. Әлеге шул беркатлылык бәласе инде, минем күңелдә хәтта мондый яшертен уй да бар иде: Сталинград фронтын Көньяк фронты белән кушканнар, димәк, анда данлыклы Сталинград герое, 62 нче Армиянең атаклы командующие генерал Чуйков та булырга тиеш. Капитаныбыз юл буе аны мактап, данлыклы генералның стратегик һәм тактик осталыкларын — хәйләләрен сөйләп килде, генерал Чуйков минем хыялымда әкият героена әйләнгән һәм мин аны ничек тә күрергә, әгәр булдырып булса, интервью алырга тиешмен, дип күңелгә беркетеп тә куйган идем. Шуңа ирешеп, татар телендә чыга башлаган Көньяк фронты газетасының, әйтик, беренче номерында ук шул интервьюны бастырып чыгарганда, әмма да егетлек булыр иде. Кайда ул тиз генә андый бәхеткә ирешү! АХО ашханәсендә ашык-пошык украина борщы ашап чыгуны исәпкә алмаганда, без гомумән бүтән бер түбә астына да кермәдек. Безне кузовына утыртып килгән машина китеп, сәгатьләр буена югалып торды. Күренсә, безнең янда тик капитан Клибли гына күренгәләп китә, һәм аның бөтен әйткән сүзе: «Тик басып тормагыз, юкса катарсыз, йөренез, хәрәкәт кылыгыз»— була иде.

Машинабыз кич җитәрәк кенә әйләнеп килде, кузовтагы йөген бу-

шаткан, йөк урынына, шыр ялангач кузовка биш пар солдат итеге ташланган иде. Безнең күңелдән шундук: «Бу итекләр, шәт, безгәдер инде»,— дигән уй узды, ләкин шәхсән мин үзем, генерал Чуйковны күреп, аңардан интервью ала алмагач, бу йөрүдән һич канәгать түгел идем. Без кемне дә күрмәдек, безне кем дә күрмәде, шуның өчен, әгәр без уйлаган чынлыкка туры килеп, теге кузовта таркалып ятучы биш пар күн итек безгә насыйп була калса, тик шуның өчен генә язгы ачы җилдә ачык кузовта безне өшетеп йөртү кемгә кирәк булды икән?

Кояш яхшы ук түбән төшкән, офыкта шәфәкъ нурлары уйный башлаганда, без кайтыр юлга чыктык. Җил тагын да көчәя төшкән, хәзер инде көндез тапмаган тишекләрне дә табып, безнең җаныбызга үтә иде. Барабыз, барабыз, нәкъ И. Гази язганча: берәүләр әйтә 8 километр, ди, берәүләр 12. Барасың-барасың — һаман 8 кала яки һаман да 12.

Җилнең мәрхәмәтсезлеге дә түгел, янган хуторлар да түгел, ул хуторларда берәм-сәрән күздән үткән ябык кешеләр дә түгел, күңелдә бик озакка чаклы басып калган, әле менә хәзер дә ап-ачык булып, туктаган җирендә дер калтыранып, дала уртасында бер ялгызы басып торучы ябык ат булды. Тәмам җегәре бетеп, тарта алмас хәлгә килгәч, тугарып калдырганнармы аны, берәр яндырылган хутордан, хуҗаларын югалткач, чыгып киткән ат булдымы ул?— ничек дип әйтергә дә белмим. Бер ялгызы басып тора юл читендә, җилгә арты белән борылган, сизелер-сизелмәс кенә калтырана, эче утлыгып кергән, күзләрен яртылаш йомган, әллә бар аңа дөнья, әллә юк. Без якынайганда да шулай тора иде, без зырылдап узып киттек, башын күтәрмәде, ничек басып калган — шулай кала бирде.

Соңыннан мин, алгы крайга газета өчен материал эзләп барганда, кар астында җиргә яртылаш ябышып, катып калган немец солдатларын да күрдем, ат үләксәләре дә байтак очрады, рус редакциясенең бер сотруднигы белән передовойга барышлый, аның парабеллумыннан үлгән ат башына атып, хәтта чослыгыбызны сынашкан чакларыбыз да булды. Ләкин дала уртасында, олы юл буенда, юлдан узучыларга борылып та карамыйча, җилгә артын куеп басып калган әлеге иясез ялгыз ат, минем күңелдә фаҗигале тетрәнү кузгатып, шулай басып кала бирде. Әле хәзер дә «Менә авам! Менә авам!» дигән кебек, ләкин аумыйча-егылмыйча, җил уртасында басып тора кебек. Бәлки, бу минем үземнең дә крестьян тумасыннан булуымнандыр, бәлки, шушы ябык ат образында минем яртылаш ятимлектә үткән балачагым яңаргандыр — белмим, белмим — ләкин ул хәтердән югалмый, югалмый.

Сәбәпсез моңсулыкка бирелгән минутларда, үземне ялгыз хис иткән авыр көннәремдә ул ат аеруча терелгәндәй булып, күңелемне баса. Китми дә, чакырып, яныма да килми...

## Оча, оча... ләкләкләр оча...

Безнең бу якларда ләкләк дигән ул сәер кошны имгә дисәң дә таба алмассың, белмим, берәр адашканы ялгышып килеп чыкмаса. Ә көньяк өлкәләрдә алар чакырмый килә торган кунак. Искәрмәстән генә очып килер, өй кыегынамы, яки башка берәр биек агач башына килеп кунар, озын-озын тәпиләрендә тирбәлеп торыр, канат-кауырыйларын кагып купшыланыр, ишетелер-ишетелмәс кенә бер каңгылдап куяр һәм, «хушыгыз, җанкисәкләрем, килеп хәлегезне белдем, икенче әйләнеп килгәнче имин булыгыз!» дигәндәй, янә бер аваз салып очып китеп барыр. Ул як кешеләре ләкләкне ниндидер бер изге кошка санап, хөрмәтләп каршы алалар, әгәр шунда берәр агач башында оя корып, бала

чыгарса, өмет багълап ышаналар булды, хәвеф-хәтәрләр узды, безне борчуга салган чит-ят кешеләр инде, шәт, күренмәсләр...

Без чыгарган «Сталин байрагы» газетасын, нишләптер, шул ләкләк кошына ошатасым килде минем. Бәлки, бу минем газетаның ничек бездән киткәнен, ничек частьларга, полкларга барып җиткәнен, үз укучысын ничек табуын белмәгәнлектән дә килгәндер. Кайчагында минем күңелгә шикле бер уй: «ул чаклы зур дөньяга, ут һәм төтен тулган дөньяга, фронтка, алдынгы частьларга барып җитәме икән? Юлда ут чәчрәп көеп бетмиме икән? Ике генә битле, бигрәк кечкенә газета ич!» дигән шөбһәле уй да килә иде.

Хәлбуки, без булдыра алган хәтле тырыша идек. Русча чыга торган газетадан алып тәрҗемә дә итәбез, газетаның «кара эшенә» ярамый торган капитаныбыз, юл өсте очраткан узгынчы машиналарга утырып, Политидарәгә дә чаба. Хуҗа Насретдин мәзәкләрен тергезеп, аларны да сугыш эшенә — җиңү эшенә җигәбез, Ибраһим миңа: «Син бывший шаир кеше ич, Патыйк, язып җибәр берәр шигырь» дип тә кычкыра, халык мәкальләрен, табышмакларны да файдаланабыз — кыскасы, чыга инде чыгасы булгач. Ростовка күчеп, берме-икеме номер чыгаргач, аллага тапшырып, мине передовойга җибәрделәр. Хәрәкәттәге частьлардан материаллар кирәк. «Әле язгы затишье вакыты, сине полк командованиесеннән эчкәре үткәрмәячәкләр, күн пәлтәң белән, йолдызлы бүрегең үзләре генә дә ни тора, шуның янына Политидарә биргән таныклык кесәңдә, әйдә, ал беренче чирканчыкны син!» диделәр. Башка әллә ни белмәсәм дә, действительнидә дә булган кеше, сугышчан приказга каршы килеп тору ярамаганлыкны белә идем, калтырануымны эчкә йотып булса да: «Була, командованиенең сугышчан боерыгын үтәргә мин әзер!» — дигән булып честь бирдем. Әллә нәрсә булмады, чынлап та язгы юлсызлык вакыты, мәхшәргә туры килмәдем, якынча булып узган бәрелешләрдә күзгә күренердәй эш күрсәткән солдатларны, сержант һәм кече сержантларны үзләрен минем янга чакырып китерделәр, кыскасы, ике-өч көн эчендә — русчасын, татарчасын — бер блокнот материал төяп кайттым.

Аның каравы мин югында, монда — Ростов бистәсендә — фрицлар мәхшәр ясап киткәннәр. Җимерек шәһәрнең җимерек бер читендә типография дә ачып, русча, татарча, казакъча, үзбәкчә газета чыгарып ятканны кайсыдыр бер хаине теге якка хәбәр итеп тә өлгергән булса кирәк, гомумән, шәһәр, ничаклы җимерек булмасын, коммуникация үзәге булудан туктамаган иде, Фатих анда юк чакны чамалап, немецлар, эскадрилия арты эскадрилия очып килеп теткәләнгән Ростовны тагын бер кат теткәләп ташламасыннармы. Ибраһим моны миңа соңыннан, мин передовойдан әйләнеп кайткач, анда да үз башыннан кичкән хәл итеп түгел, Сибгат абзый башыннан кичкән хәл итеп, гадәтенчә чак кына юмор бизәкләре кыстырып сөйләде.

— ...Бер-бер артлы берничә волна шулай килеп, безгә атап алып килгән «бүләкләрен» ташлап киттеләр, дөнья бераз тынычлангандай булды, башкалар рәтеннән мин дә калыктым якты дөньяга. Типографиягә барып керсәм, әй, ротатор астыннан дүрт аякланып Сибгат абзый чыгып килә:

— Ибрай җаным, күрдеңме? — ди бу, гадәттәгечә зур кара күзләрен иләсләндереп. — Мин, малай, күрдем генә түгел, санап яттым: нәкъ йөз илле самолет иде... белмим, малай, башны исән-сау алкайтыр көннәр булыр микән безгә?

Ә мин анда, передовойда, минем тылдагы фантазиям ясаганча: гел атышып, гел үтерешеп кенә торалар кебек күренгән передовойда мена нинди хәл күрдем. Блиндажларның берсеннән якынрак кына чокырда учак яна, учак өстендә казыкларга аркылы куелган таякта, котелокта ит пешә. Соңыннан сорашып белдем: миңага эләгеп харап була

язган атны чалып өлгергәннәр дә, шунын итен бүлешкәннәр икән. Юл өзеге вакыты, бөтен кирәк-яракны, шул җөмләдән мондый чеп-свежий итне шундук китереп өлгертә алмыйлар. Шулай итеп шул, пешеп кенә чыккан ат ите белән, ходай кунагы итеп, мине дә кыстый-кыстый сыйладылар болар. Сыйлану арты, сусыз дә аңлашылса кирәк, тәмәкегә нәфесләре уянды. Кайсында махра, кайсында шырпы, ә арадан берсе кисәсеннән ертып алырга бик җайлы итеп шакмаклап төрелгән газет кәгазе чыгарды. Күз төшү белән танып алдым: без чыгарган газета. «Ах,— мин әйтәм эчтән генә...— Шуның өчен чыгарабызмыни без газетаны?».

Аннан арысын теге солдат үзе өстәде:

— Белеп... тәмен татып тартыгыз: үз телебездә чыккан газета бу. Шуннан китте сорашу, кызыксыну.

— Үзең укыдыңмы соң?— ди тегесе, тәкәллефләнеп торуны һич кирәк тапмыйча.

— Укымыйммы соң...

— Нәрсә турында яза? Туган яклар турында ни дә булса юкмы?

— Нәрсә язсыннар?— ди төрергә газета биргәне, иптәшенең үтә төпченеп торуын бик үк өнәмичә.— Нәрсә политрук сөйли — шуны яза: фрицның бәбәгенә терәп ата белсәң, син шәп. Шулай түгел икәнсең, читтәрәк басып тор, гәзит битенә үрмәләргә синең хакың юк.

Газетаны шулай да кулыннан ычкындырырга теләмәде, бер кисәсеннән башланмаган «Беломор» пачкасы чыгарды, икенче кисәсенә кадерле бөти сыман итеп газетаны тыкты:

— Берәрне мәнә хәзер тартабыз, калганы синеке, ә газета миндә кала. Үз телебездә чыккан газета ич, ни битең белән тәмәкегә кушып яндырмакчы буласың. Туган телне, панимаешь.

· Шунда мин чын-чынлап төшенеп алдым: юк, айдан артык салкын кыш, юеш яз ерып, тикмәгә генә алып килмәгәнбез икән аны, без очырган «ләкләк кошлары» арыган-алҗыган солдатларга ышаныч, туган телебезнең моңын, иминлек алып баралар икән!

Редакция штаты — хәреф җыючыны, метромпажны да кертеп исәпләгәндә — бөтенесе биш кешедән гыйбарәт. Үзе газета эшен рәтләп белмәүче капитан без барганчы ук, штат буш тормасынга, алгы сызыклардагы полктан ике егетне алып өлгергән. Аның берсен, безнең эштә әлифне таяк дип тә белмәүче мишәр егетен, Ибраһимны кадрга формалаштырганда, елатып ук димәсәм дә, теләр-теләмәс кенә киткәнлеген без күргән идек инде. Икенчесен, Аксубай районыннанмы, Актаныш ягыннанмы килгән Хисмәтуллин дигәнен, элекке укытучы, газета эшен белә дип әйтмәсәк тә, татарча ярыйсы гына яза торганын, бигрәк тә алгы сызыктан материал ташырга өйрәнеп килгәндә, аннары тагы тылда калган ике бала атасы икәнлеген дә искә алып булса кирәк, капитаныбыз үзе җибәрәсе килмәде. Хәер, мин дә олыгаеп бара торган агай-эненең авызыннан ризыгын тартып алып дигәндәй, аның урынына калырга бик ыргылып тормадым.

Ыргылып тормавымның кешегә бик шаулап булмый торган эчке бер сәбәбе дә юк түгел: менә алты ай, Мәрфугадан бер генә дә хат алганым юк. Ничек кенә димә, йөрәк тырнала бит, малай. Юкса, беләм: бик яхшы яклары янында Мәрфугам — җүләркәемнең бер алама гадәте бар: өйдән чыгып китсәм, хат язмый теңкәмә тия. Ярый әле, теге яки бу сәбәп аркасында, күп хәлдә кисә якларыбыз такыр булу сәбәпле, аны ияртмичә, курортка-мазарга ялгызым гына киттем, ди. Күңеләнә нәрсә килмәс кешенең, үзенчә миннән үч алуы: янәмәсе, саргай әле Хуҗа Насретдин ишәге кебек койрык очыңнан. Белеп, сагынганны аңлап, юри шулай эшли бу моны, факыр. Кайтып сорый башлагач, җавабы гамәленнән дә корырак чыга: почеркым начар, укымышым да шул хәтле генә, иптәшләрегез белән җыелып, минем хаттан көләр идегез

бугай. Ходаем-аллам! Бу да булдымы җавап. Син тор анда сагынып-саргаеп, ә аның, янәсе имеш, почеркы начар. Менә шулай газаплый иде ул мине, рәхмәт төшкере. Бу газета сәфәрендә дә шул гадәтеннән котыла алмады, авыр туфрагы җиңел булсын.

Болардан башка тагы бер адәм көлкесе сәбәп килеп чыкты. Бер чакны шулай капитан Клиблигә АХОга барырга кирәк булды. АХО дигәнебез шактый ерак, баруы-кайтуы, анда бару белән синең йомышны гына йомышларга кул сызганып тормыйлар, кыскасы, бер көн узачак та узачак. Шуны уйлап, бигрәк тә минем рәтле җылы аш күрмичә, коры-сары белән яшәвемне уйлап булса кирәк (ул үзе, әрсезлеге булмаса да, җылы күңелле, кеше турында кайгыртучан кеше иде), үзләре туена торган офицерлар ашханәсенә барып ашарсың, дип миңа айлык книжкасыннан шул көннең числосы билгеләнгән талонын кисеп калдырды. Мин бик шат, кеше рәтеннән талонымны биреп, штатски костюм-чалбардан, галстуктан килеш барып утырдым. Официантлар арасында, әлбәттә, бер-берсенә карашып алулар булды. Ләкин миңа берни дә сиздермәделәр. Башкаларга китергәнне миңа да китерделәр. Ашадым, сыйландым, минем өчен бу утыз көнлек ураза ның зур бәйрәме булды.

Ләкин бәйрәмнең зуррагы капитан башына төште. Икенче көнне кичен ул, бичара, бик зур хафага чумып, үтә дә нык борчылып кайтты.

— Хуш, Южный поселок,— дип куйды ул кайтып керү белән аһ орып,— капитан Гани Клиблиевнын синдә ашыйсы ризыклары шушының белән тәмамдыр, аркадашлар.

Аннары ул мине читкәрәк алып, әкренрәк тавыш белән болай диде.

— Сез, иптәш Хуснутдинов, әгәр чакырып, сорый калсалар, зинһар, мине подводить итмәгез, талонны урамнан таптым диегез, моның бернинди дә гөнаһысы юк, скандалга урын калдырмыйк.

Ул бу сүзләрне тавышын кыса төшеп, тик миңа гына әйткән иде, шулай да очлы колак Ибраһим эләктереп алган икән. Башка вакытта гел уен-көлке кыстырып, шаяртып сөйләргә ярата торган И. Гази бик җитди иде бу юлы:

— Артык каты ишетелсә, гафу итегез, иптәш капитан,— дип башлады ул, тавышына ук җитди кырыслык чыгарып, — сез үзегезнең кул астында эшләүче кешеләрне ялганларга өйрәтеп, бер дә килешмәгән эш эшлисез. Дала җилләре уйнап торган шушы бәләкәй генә Южный поселок урамында, янәсе имеш, «Мә, Фатых Хуснутдинович, тап мине. Мин монда тузан арасында яшеренеп ятам!» дип чәнчә бармак башы хәтле талон аунап ятсын. Булмаганны, колакка кермәстәйне...

Бу, әлбәттә, миңа да әйтелгән сүз иде. Мин дәшүен дәшмәдем, ләкин күңелем рәнжеде, Ибраһимга түгел, вак авантюра уйлап чыгарырга маташучы кешегә. Дөресен әйтим, мин үземне теге вакытта, җилгә артын куеп, юл читендә ялгыз басып калган ат хәлендәрәк сиздем. Мобилизацияләнеп алынган кеше түгел, үз теләгем белән килеп, газетаны җайга салышып, ничәмә-ничә мәртәбә передовойда булып, ташыйсын ташып, язасын язып, үз газетабызга, кызыклырак материал күренеп торганда, русча белгәнлегем белән мактанып, рус газетасына да күп хәбәрләр, корреспонденцияләр ташыдым. Басылырдае басылды. Мактанчыклыгым бер кузгалгач, инде бу хәтлесен дә әйтим. Ул фронтта чыга торган барлык милли газеталарны тәрҗемәдә булса да күздән үткәреп торучы җаваплы начальнигыбыз, рус газетасының редакторы полковник Троскунов бер летучка вакытында исемемне атап:

— Әнә татар газетасының литсотрудникы Хуснутдиновны алыгыз, күзләре очлы булгач, табарга кирәкле материалны таба. Үз газеталарына гына түгел, безнең русча чыга торган газетага да коеп кына тора материалларны,— дип әйтеп ташламасынмы!

Кадрга язылмавымның, командировканы очлап, Казаныма — Мәрфугам янына кайтып китәргә купшынуымның, тоташ хәрби киемле кешеләр арасында ярым гражданка кешесе булып, галстук тагып йөрүнең бик алай кызыклы эш түгеллеген, кыскасы, юл читендә җилгә артын куеп ялгыз басып калган ат хәлендә калырга артык теләмәвемнең кайбер сәбәпләрен моннан элек кылган бүлектә әйттем дә шикелле инде. Газетабыз хәзер үз вакытында төгәл генә чыгып бара, тәҗрибә тупла на, кул күтәреп узгынчы машиналарга эләгә-чүмәшә передовойга чабарга өйрәнеп беттек, бу яктан бигрәк тә әлеге Хисмәтуллин дигән сотрудникгыбыз, элекке авыл укытучысы тәмам каешланды, авылда калган ике бала атасы, передовойның нәрсә икәнлеген инде бер татыган, аның бичараның, яңадан ул җәһәннәмгә китәсе килми, шуңа күрә бар булганы белән ташый да ташый газета өчен материал. Чыгардаен да алып кайта, бөтенләй киртәгә кермәстәйләрен дә тутыра. Аның шул тырышлыкларын күреп торганым хәлдә, абзыйның урынын алып, яше ягыннан миннән өлкәнрәк кешене, ике бала атасын киредән элекке частена җибәрүләрен күңелем дә күтәрми, ә газета штатына алтынчы кеше сыймый, бигрәк тә шунысы күңелне алгысыта: фронтта эшләр алга бара. Безнекеләр Харьковны алдылар, шул кызулык белән башка кечерәк пунктлардан да өрделәр фрицны, уйлыйм: кирәк тапсалар, кайткач, мобилизацияләп алырлар, исән чакта бер күреп калуың бер гомер, китәм-китәм, капитан Клиблиев, бүтән чакта мине юлдан талон таптым, дип ялганларга өйрәтмә. Сүз уңаеннан әйтү, упкәләп әйтүем түгел, әгәр капитан үз сүзен үткәрә ала торган нык кеше булса, мине әллә кайчан хәрби формага төрерләр иде, ишетеп-белеп торабыз, башка фронтларда безнең ише газета чыгарышу өчен командировкага килгән кешеләрне беренче көннәрдән үк хәрби формадан киендерделәр.

Китәргә җыенуымның сәбәпләрен җитәрлек аңлаттым шикелле, ләкин бик үк аңлатып та булмый торган тагы бер сәбәбе табылды. Бик аңлатып булмый, чөнки башта мин моны үзем дә рәтләп аңламадым. Әлеге шул Южный поселокта торганда без яшәгән йортка чибәр генә, яшь кенә, көләч кенә бер апакай-аппаккай нияләште. Безгә дигәч тә тиктомалдан безгә түгел, безнең хуҗа хатын Федося түтигә килә бу. Әле бер йомыш, әле икенче йомыш белән. Ул да түгел, бөтенләй йомышсыз да килеп керә. Телгә беткән бер нәмәрсә шунда. Бер хут алса, безне дә читтә калдырмый... Әле салам кыстыра, әле мыскыл-хурлау сүзләре белән, әле үзәккә үткәзә торган итеп көлеп — ап-ак тешләрен күрсәтеп. Без дә бит җансыз кешеләр түгел, өйдән чыгып киткәннән бирле хатын-кыз күрмәгән, дөрес, беребездән беребез тәкъвә, беребездән беребез куркабыз, ләкин эчебездән генә: «Керсен иде. Тагы бер сөйләшсен иде теге шомлык»,— дигән изге теләктә күңелебез. Әлегә үсмер яшьтән узмаган Равилдән кала, арада иң яшьрәге мин, шуңа күрә ул керә-чыга йөргән көләчкә карата иң ихлас теләктәге кеше дә мин булганмындыр.

Бик сагындырып бетерми бу, керә йөри, керә йөри, атап кына беребезгә дә кадалмый, ә эчтә шайтан котырта: «Кадалсын иде, каһәр! Нәкъ менә миңа кадалсын иде!»— ди. Ир кешедә бер шайтан утырса, хатын-кыз эченә берьюлы өч шайтан сыя диләр. Тиктән генә шулай бөтерелмәгән бу безнең тирәдә, Федося түтидән сорашып, минем сухой паекта — коры-сарыда гына яшәвемне белеп алган, бер көнне шулай — алла сакласын гөнаһы шомлыгыннан!— өйдә минем ялгызымны гына туры китереп, турыдан-туры атакага күчмәсенме:

— Кара әле, порубка,— ди бу, бөтенләй үз кешесенә эндәшкән кебек итеп.— Тетя Федосканың әйтүенә караганда, син иптәшләрең арасында иң ятиме икәнсең. Хатының, әлбәттә, юк, булса да җиде йөз ча-

кырымдадыр, житмәсә сухой паекта утырасыз, имеш. Ә тетя Федоскаңы мин беләм, хитрюга, ягып, җылы аш пешереп ашатырга утыным юк, ди булыр. Ә минем күңел әрни. Шушындый беркатлы кешене, бала күңелле адәмне, җәелеп ашап-эчәр, сузылып куккә үсәр бер вакытында, каты-котыда тоту, житмәсә шундый зур эш белән газет чыгарып йөрган жиренда шулай ятим итү просто килешми. Мин моны жаным-тәнем белән әрнеп, бөтен Южный поселок исеменнән әйтәм.

Үзе яртылаш ишеккә борылган, әйтәсе дә, янәсе, чыгып китәсе. Мина яңы беләнрәк басып тора, шулай да, яңы белән генә торса да, күрәм, уттай янучы кара күзләреннән күрәм: эчендәге өч шайтаны берьюлы уянган моның, берьюлы минем өскә үрләргә торалар. Башка чак булса, бәлки, мин өркеп тә калган булыр идем, бу юлы бирешергә исәп юк, минем эчтә дә шайтан бар бит, өч үк булмаса да, берәү бар: ник җавапсыз калырга шушындый хуты чыгып торганда:

— Син, чибәрем, ни... өзеп әйт әйтер сүзең булса, — дим кинәт өянәгем кузгалгандай. — Бөтен Южный поселок исеменнән дә әйтмә, үз исемеңнән генә әйт сүзеңне: нишләтер идең син мине, әгәр, үзең әйтмешли, мин «ятим»гә карата күңелеңдә тычкан уты хәтле генә шәфкать уты булса?

— Нишләтер идемме? Нишләтер идемме?— капылт кузгала бу, яңы белән торган җиреннән йөзе белән борыла, ә йөзендә кызылы кызыл, агы ак, кровь с молоком, урыс әйтмешли, йот та җибәр бер кабуда.

Тыны кысылгандай була бер мәл, ни сайрар кош иде үзе, телсез калды. Ә теле ачылгач әйткән сүзе, бик ачык итеп, бер дә ясалмасыз әйткән сүзе менә бу:

— Күч тә кил минем өйгә. Минем өем дә, күңелем дә иркен. Утын запасым да аллага шөкер. Федоска — саран бака кебек каты-котыда тотмам. Менә күрерсең.

Ул бу сүзләрне чын күңеленнән әйтте, билләһи-газыйм, тамчы да ялган катнаштырмыйча әйтте. Шул секундта күзләрендә чагылып узган якты утта аермачык күреп калдым: әгәр кузгала калсам, ул мине шул минутта ук яртеп алып китәргә әзер иде.

Ә мин, тиле дигәч тә, тота-каба тигәнәк буе сикерүчеләрдән түгел. Башым үз урынында. Еракта булса да минем үз өем, үз өемдә ике балам, хат язмый торган үз хатыным бар: «Хат язмый торган» дигәннән, васвасәм кузгалды. Дөрес, ул моны «Почерыгым начар», «Минем хатымны укыгач, иптәшләрең белән, юк дигәндә, Ибраһим Гази белән җыелып көләр идегез бугай», дигән булып үзен акламакчы була. Ә белмәссең, минем янда сайрар кош очып йөргәндә, аның янында да шундый берәр әрсез алабай тыкшынып йөрсә? Минем Мәрфугам кеше күзе төшмәслекмени? Тәүбә-әстәгыфирулла, әйттем исә кайттым. Мәрфуга турында шундый уйны башка китерергә мөмкинме? Ә кинәт мөмкин булса? Ач күзле кешеләр кайда да бар. Бөтен кеше дә синең кебек беркатлы исәр түгел, Фатих.

Югарыда китерелгән сәбәпләр өстенә, кешегә-карага шауламыйча, болары турында уйладым да капитан Клиблигә үтә дә ачык итеп рапорт яздым. Рапорт икән — рапорт. Күп сүзле түгел, сентиментка һәм икеләнүгә урын калдырмыйча.

Шундый-шундый эшләр, иптәш капитан. Штатта артык кеше икәнлегемне үзем дә белеп торам. Чакырып алып киттегез — килдем. Ничек газап чигеп килгәнебезне үзегез белеп торасыз. Булдыра алган хәтле эшләдем, газета чыгару эше хәзер инде җайга салынды. Шушы әйтелгәннәрне исkә алып, тиешле формальностьларын җиренә житкереп, мине Политидарә исеменнән кире үз җиремә — үз семьяма командировкалавыгызны үтенәм.

Күпне сорамадым, әмма сораганнарым тулысы белән җиренә житкерелде. Хәтта әле өмет тә итмәгәне әлкте: фронт Политидарәсе

һәм фронт газетасы редакциясе исеменнән рәхмәт кәгазьләре язып бирделәр.

И, тотындылар, тотындылар мине, әле алдыма, әле артыма төшеп карарга. Төрле киңәшләр бирергә, Казанда калган туганнарыма, хатын, бала-чагаларыма сәламнәр өяргә. Минем китәсемне белеп әзерләгән ризык запасларыннан күчтәнәчләр яудырырга. Үзебезнекеләр бит, ясалып тору юк:

— Туктагыз, чама белегез, ат түгел бит мин, ничек күтәреп кайтыйм бу чаклы йөкне,— дим, аптырагач.

— Син күтәрмисең, поезд күтәрә,— диләр, нәзакатьләнеп тормыйча гына.

Сагыну хисен мин электән дә белә идем, сагыну хисенең ничек булганлыгын мин шунда — бергә газета чыгарган иптәшләремнең күзләрендә күреп, тагы да тирәнтенрәк кичердем.

## Кайту юлында

Ниһаять, мин кайту юлында. Редакциядәге иптәшләремнән кайберләре вокзалга хәтле озата ук чыктылар. Вокзал дигәнен әйтер идем, кыр уртасында, җилдә шыңгырдап утыручы сыңар бер өй — будкадан зуррак, авыл өеннән кечерәк. Уты-фәләне юк, булып та яшергәннәрме?

— Бик үк тантаналы озату булып чыкмады бу, әкәмәт. Оркестр да яллый алмагансыз,— дигән булдым, озата килгән иптәшләремә төчеләнергә ирек бирмәскә тырышып, — тизрәк поезд биреп, алып китмәсәләр, монда борын төртерлек урын да таба алмассың.

— Борын төртергә әнә җир,— дип авызымны томаладылар арадан берсе. — Өйгә кайтасы булса, мин әле, дурак, башымны кесәгә салып куеп булса да йоклар идем.

— Әйе, бик үк комфорт булмас, фронт полосасы буйлап боеприпас, азык-төлек ташу өчен ашык-пошык кына салынган юл.

— Төн чыкканчы хәвефсез-хәтәрсез бу араны исән-сау үтсәгез, аның каравы Зур юлга — Юго-восток юлына чыккач, көнозын җырлап кайтырсыз.

«Бу ара» турында тавышны кыса төшеп әйтелгән сүзләр күңелгә шом салды салуын, ләкин иптәшләр алдында сиздермәдем. «Бу ара» дигәне — йөз километрга якын нәкъ фронт полосасы буйлап параллель үтәсе, фрицның борын төбеннән, ә аның борыны исне бик тиз сизә. Ходаебыз үзебез белән икән, хәвефсез-хәтәрсез үттек. Көньяк-көнчыгыш юлына чыктык, барган саен Көнчыгыштан күтәрелә килүче кояш безне каршылап, юлны яктырта килә, яктырта килә... Төрле тип вагоннарны, ачык платформаларны, теплушкаларны таккан чуар составта кемнәр генә юк: госпитальдән чыгып, туган ягына поправкага кайтып баручы солдатлар, эвакуацияләнгән туганнарын эзли чыккан штатски анадыр, җимерелгән сугыш әсбапларын тылдагы ремонт мастерскойларына — заводларга озатучы командированный командирлар, кемне дә озатмавы һәм госпитальдән чыкканлыгы да ачык кына күренеп тормаган, ләкин коралы үзендә, аш кашыгы итек кунычында булган «Бөтенесенә әзер» гвардеецтыр — имгә яраклы халык без монда. Фронттан ераклаша барган саен бугазлар ачыла, җырлап җибәрәләр, ике сүзнең берсе сүгенү, арада бар шундыйлары: русча рәтләп сөйләшә белми, ә «мать»лап чатлап әйтүгә килсә — суга җибәргән балык.

Минем урыным ачык платформада, имгәнгән саранча кебек ботын күтәреп ята торган җимерек самолет канаты астына туры килде. Көн үзәге җитеп, кояш кыздыра башлагач, безнең бу урын, кем әйтмешли, «люкс»ка әйләнде. Кояш эссесен каплый, җилдән саклый, шул ук вакытта бөтен бер самолет ышыгында без нибары ике кеше: нинди дер

эш белән тыл ягына командировкага үтеп баручы бер лейтенант та мин. Мине үзегез беләсез: солдат та түгел, гражданский да түгел, сакал баскан бер аңлашылмау. Бәлки, шул сәбәпледер юлдашым лейтенант минем белән әллә ни җәелеп сөйләшми.

— Едим, как в гостях у тещи,— миңа бөтен әйткән сүзе шул бер җөмлә булды. Ә тирә-якны, кешеләрне күзәтергә дигәндә күзләре очлы, күрмәгәне юк. Юл буендагы дала, узган җәй бу тирәләрдә сугыш мәхшәре уйнаганлыктан, сөрелмичә-чәчелмичә калган. Шунлыктан төрле чүп үләннәре аралаш узган җәй коелып калган арыш, бодай сабаклары да калка башлаган. Әле баш күрсәтергә өлгермәгәннәр, шулай да сабаклары ризык булса кирәк. Шуларга өннәреннән башларын чыгарып, яки бөтенләй диярлек шыр далада калып, йомраннар сузыла. Тамен табып, карап барган кешеләргә тамаша бер.

Ә арада тамаша кылып кынә калмаучылар да бар. Ачык платформалардан шул йомраннарны автомат уты белән сыйлыйлар. Тидерә алганнары бар, тидерә алмаганнары да юк түгел.

— Ну, и народ... до чего дошли на казенном пайке,— дип авыз эченнән мыгырданып куйды минем яндагы лейтенант, автомат белән шаяручыларны өнәмичә.

Шундый вак-төяк «тамашалар»ны һәм, һич көтмәгәндә, юк кына җирдә тукталып калып, безгә ачык билгеле булмаган сәбәпләр аркасында, сәгатьләр буена тик торуларны исәпкә алмаганда, ярыйсы гына бардык. Көн кичкә авышты. Эңгер төшү алдыннан Морозовская дигән зур гына станцияга, берничә юнәлеш килеп тоташкан тимер юл төенә килеп җиттек. Монда, ерак та түгел, күккә таба муеннарын сузган зениткалар да күренгәли. «Ярый торган урын булыр бу, монда, шәт, фриц борынын суза алмас!» дип тынычланып уйлап куйдым мин эчемнән генә.

— Морозовская, узловская,— дип авыз эченнән генә сөйләнеп куйды лейтенант, планшетыннан карта чыгарып. Аннары капчыгыннан котелогын чыгарды, мин дә башсыз түгел, өлкән чинны кайнаган суга йөгертеп, үзем утырып калуның хәрби «шәригатькә» һич тә сыймаганлыгын, әлбәттә, белә идем.

— Бирегез котелогыгызны, мин алып киләм,— дидем, җәлт кенә сикереп төшеп. Лейтенант бернинди гаҗәпсенү дә, икеләнү дә сиздермәде, котелогын сузды.

Бик җилтерәп китсәм дә, алай җәһәт әйләнеп кайта алмадым. Кайнар су краны төбендә байтак кына кеше — чират җыйналган иде. Мин, кулымны пешерә-пешерә, әһелдәп кайтып җиткәнче көнгә караңгылык капкан иде.

— Менә хәзер җиренә җиткереп кенә чәйләп алабыз,— дип сөйләнә-сөйләнә, «люкс»ыбыз идәненә газета җәеп, чәй урыны әзерли башлаганда гына... муеннары аска килгерләре, ләгънәт төшкән фриц карчыгалары, зениткалар дип тормаганнар, килеп җиткәннәр. Үзара карашып алырга да өлгермәдек, беренче гөрес... Шундук икенчесе, өченчесе, ул арада безнең зениткалар гөрселди башлады, кайда ул чәй, якын гына килеп төшкән бомбаның элек җиле килеп бәрелде, шундук өскә чөйгән балчыгы башыбызга яварга тотынды. Ул арада безнекеләр дә тегеләрнең берсен бәрергә өлгерделәр, янып төшүче самолет тирәюньне кинәт, шомлы бер келпетү белән, яктыртып җибәрде. Мин бомбежкаларны аз-маз күргәләгән идем инде, ләкин бу чаклы якынын, нәкъ мине туры китерергә тырышкан кебек, баш түбәсенә үк китереп салганны күргәнем юк иде. Бер мәл нишләргә белмичә, аптырабрак калдым. Ләкин мондый очракта озак аптырап тору «рөхсәт ителми» икән, күрәм, составтагы кешеләр, борттан ничек әләксә шулай сикерешеп, юллар-рельслар аркылы як-яннарга сибелә башладылар. «Шулай кирәктер» дип җәлт уйлап алдым — баш белән түгел, курку инстинкты

белән. Бераздан без — бу орыштан исән-имин калган кешеләр юллардан һәм безне алып килгән составтан илле-алтмыш метрлар читтә — канауда жиргә сыланып «әлиф» ятә идек. Тәжрибәсе булганнар чамалаганнар, фриц әле бу беренче әйләнеш белән генә туктамаган икән, урап килеп, алар ян-тирәләргә пулеметтан сиптерә башладылар. Гомеребез бетмәгән булгандыр, бу юлы да канауга ябышып каткан кешеләргә туры китерә алмадылар.

Тагын бер әйләнеп уздылар да аннары киттеләр. Беразга дөнья тынып калды, әмма каналга сырышкан кешеләр кузгалырга ашыкмадылар. Күрәсең, дошманның тагын бер әйләнү ихтималы булуны төшенәләр иде булса кирәк.

Тик күпмедер вакыт узганнан соң гына канал терелде, кешеләр аякка басып, шау-шусыз гына киредән состав ягына таба якынлаша башладылар. Кешеләр нишли — мин дә шуны эшлим, ләкин баш белән ни дә булса уйлый алмыйм, баш миңгерәгән, бер мәл үзебезнең «Люкс»ны таба алмый аптырадым. Капшана торгач, таптым, ләкин бер нәрсә дә урынында түгел, платформабыз бомба чокырыннан атылган балчык белән тоташ күмелгән иде. Актарына-казына торгач, шулай да балчык арасыннан бүрегемне һәм аманәт кучтәнәчләр белән күпкән юл капчыгымны табып алдым. Әманәт жан саклый, дигән сүзе бар халыкның, күрәсең, бу очракта ул нәкъ безнең өчен, минем өчен әйтелгән булгандыр.

Шомлык түгел диген син, шунда шул, миңгерәгән башның бер чите кинәт ачылып китә, көләсем килә башлый, кешедән түгел, үз-үземнән.

— Ярый әле, эчендә башның үзе булмаган,— дип балчык арасыннан актарып тапкан бүрегемә эндәшәм мин тиле кешедәй.

Ә тагы беравык вакыт узып, акылны җыя төшкәч, тагы бер нәрсәне ачыклыйм: кара әле, минем ботым буенча ниндидер бер җылы шуыша түгелме? Капшыйм: шуыша. Ике-өч кат ыштан аркылы үтеп, кулымны, бармакларымны ботка тидерәм — кан. Тик менә хәзер генә башым эшли башлады, болай булган бит бу. Бая, бомбежка тынып торган арада, бүтәннәр рәтеннән мин дә мәтәлә-кадала канауга чапканда, бер жайсыз урында, рельсларга абынып, шәп кенә барып төшкән идем түгелме? Бөтенесе шунда булган булса кирәк. Минем чалбар кесәсендә һәрвакыт көзге кыйпылчыгы йөридер идеме? Йөридер иде. Почмаклары очлы, үзе калын, ышкый белеп ышкысаң, арканынны кисәрлек көзге кыйпылчыгы... Әйе, әйе, нәкъ шул үзе, рельсларга абынып барып төшкән минутында — кызулык белән син аны-моны абайлап өлгермәгәнсең, нәкъ шул көзге кыйпылчыгының очлы почмагы белән барып кадалган да инде.

... Безнең жирдән зур бер канлы тамаша булып Сугыш узды. Миллионнарча кешеләр аннан бөтенләй кайта алмыйча, мәңгелеккә ятып калды. Меңнәр, миллионнар гарип булып кайтты. Болары бөтенесе истә. Аларның күбесе китап, роман, трагедия формасында тарихка теркәлде — тарихны тетрәндергеч хәлләр болар. Тарих аларны югалтмыйча саклаячак. Ләкин дүрт елга сузылган бу авыр сугыш тоташы белән гел трагедияләрдән генә торды, дип кем раслый алыр икән? Юк, аның мәзәк яклары да булды. Сизгер укучы чамаламыйча калмагандыр: бу очракта мин аны нәкъ әнә шул мәзәк якларыннан килеп күрсәтергә теләдем, аңлы рәвештә шулай теләдем һәм болай күрсәтүнең дә үзенең закончалыгы бар.

*1980 ел*
*Казан*

# ЛЕВ ОШАНИНГА 70 ЯШЬ

*Һәрвакыт булсын кояш,*
*Һәрвакыт булсын һава,*
*Һәрвакыт булсын әни,*
*Һәрвакыт булыйм мин.*



*Күңелгә нинди якын һәм шул ук вакытта нинди гади сүзләр! Бу җырны Африка чүлендә һәм салкын тундрада, Австралиядә һәм Латин Америкасында, Европада һәм Азиядә дә җырлыйлар. Бу сүзләр — бөтен дөнья халыкларының уртак теләгенә, бу җыр бөтен дөнья халыкларының уртак җырына әверелде.*

*«Һәрвакыт булсын кояш», «Демократик яшьләр гимны» һәм тагын йөзләрчә җырлар, шигырьләр, поэмалар, шигъри повестьлар һәм романнар авторы, СССР Дәүләт премиясе лауреаты шагыйрь Лев Иванович Ошанинга 70 яшь тулды.*

*Иҗат юлы кебек, шагыйрьнең тормыш юлы да бик катлаулы. Мәскәү шәһәрендә токарь, Хибин тундрасында гади эшче, клуб мөдире, газета хәбәрчесе булып эшләгәннән соң, ул яңа гына ачылган Әдәбият институтына укырга керә. «Шигырьләрне кайчан яза башлаганымны хәтерләмим. Мин аларны һәрчак яздым бугай» ди шагыйрь үзенең бер мәкаләсендә.*

*Лев Ошанин бүгенге көндә дә яшьләр кебек янып яши, янып, ялкынланып яза. 28 ел буе тотош Әдәбият институтында шагыйрьләр семинары алып баруы — аның сүздә генә түгел, эштә дә яшьләр белән кулга-кул тотынышып атлавы турында сөйли.*

*Профессор Лев Иванович Ошанин семинарында әдәбият һәм тормыш мәктәбе үткән татар шагыйрьләре әле бүген дә олы җанлы, киң күңелле остазларына карата үз күңелләрендә чиксез хөрмәт һәм рәхмәт хисләре саклыйлар.*

*Шагыйрь Лев Ошанин Казанга, Татарстанга еш килә. Үткән килүендә ул болай дигән иде: «Минем язмышым Казан белән бик нык бәйләнгән. Сугыш вакытында монда минем гаиләм килеп сыенды, мин үзем дә шактый вакыт Казанда яшәдем. Аннары иң мөһиме, монда минем шәкертләрем яши. Алар минем якын дусларым гына түгел, алар — минем әдәби туганнарым. Ә шагыйрь өчен моннан да зур якынлык булырга мөмкин түгел...»*

*Дөнья гизеп чәчем агарса да,*
*«Ул яшь», диеп әйтсен и.л. халык*

*— дип яза Лев Ошанин үзенең бер шигырендә. Әйе, чыннан да шагыйрь көннән-көн активрак эшли, аның иҗаты киңәя, үсә, яңара бара. Иҗат бәйрәме белән котлап, бу санда без аның берничә шигырен укучыларыбызга тәкъдим итәбез.*

## Лев Ошанин,

рус шагыйре

### Әдәбият институтын тәмамлаган дусларыма

Җир түгәрәк, матур, гаҗәеп зур,—
Кая илтмәс безне юллары?!
Тик кайда да истән чыкмас инде
Герцен йорты, Тверь бульвары.

Шигырь өчен монда ант эчелде,
Яңгырады йөз тел тостлары.
Сез булганда, димәк, мин дә яшим,—
Исәнмесез, барча дусларым!

Безнең йортка Горький исем биргән...
Мондый бәхет тия кемнәргә?!
Димәк, безнең, мәңге шәкерт булып,
Узасы бар килер көннәргә.

Карт тупыллар, башын түбән иеп,
Шигырь укый монда ташларга...
«Шигърият ул — мәңге яшьлек» булса,
Яшьлек, димәк, монда башлана.

●

Мин үземне гел яшь санап йөрдем,
Бактым исә — чәчләр чаларган.
Мин дусларга һәрчак учак яктым,
Җавап көтми генә алардан.

Бар кешегә яхшы булып булмас,
Бар юлларны үтеп булмастыр,
Бар сылулар сыймас кочагыма,
Соңгы җырым ахры тумастыр...

Үткән юлым — уч төбендә кебек,
Мин бер юлдан туры атладым,
Гомер буе бер максатка бардым,—
«Мәхәббәт» дип аны атадым.

Мин дөньядан күпне өмет итмим,
Шигъриятка яшим табынып.
Мин бәхетле — кеше күңелендә
Бер шигырем янса кабынып.

### Урманда

Урман тып-тын. Ялгызлыктан туеп,
Ычкындырдым ишек келәсен...

Юрадым мин: әгәр кояш чыкса,
Минем янга бүген киләсең.

Күкләр күкрәп, яңгыр явып узды,
Яфракларга тезде энҗеләр.
...Килерсеңме, әллә юкмы, диеп,
Юрау юрыйм һаман мин-юләр!

Урман шаулый. Син киләсе юлдан
Кара мәче — кара төн уза.
Ә мин һаман күктән кояш көтәм,
Ә мин һаман көтәм могҗиза.

Урман тынды. Ялгызлыктан туеп,
Ычкындырдым күңелем келәсен...
Таңнар ата: Кояш чыгамы ул?
Синме әллә миннән көләсең?

## Сары колмак

Сары сарган колмак яфрагына...
Ерак әле, юкса, көзләргә.
Тәрәзәмнән карый сары колмак...
Көзгә кадәр ничек түзәргә?

Үрелеп карый бүлмә эченә ул,
Җир яктысы җитми, күрәсең.
...Мин үзем дә колмак сабагыдай:
Утлар күрсәм, кирә керәсем.

Тамыры соң әллә корыганмы?
Усал җилләр әллә тигәнме?
...Мин үзем дә авырлыклар күрдем,
Тик булмады башым игәнем.

Сары яккан колмак яфрагына
Туган якның ачы туфрагы.
...Сары сарган саен матурая,
Ыгый бара колмак яфрагы.

РАЗИЛ ВӘЛИЕВ тәрҗемәләре

# КАЗАНЫШЛАРЫБЫЗ ЕЛЪЯЗМАЧЫСЫ

Илебездәге күп санлы көндәлек басмалар арасында, юл күрсәтүче кораб кебек, иң алдан партия һәм совет матбугаты флагманы — «Правда» газетасы бара. Ул бер генә өлкәдәге мәсьәләне дә игътибар күзлегеннән читтә калдырмый. Ул Ватаныбыз халыкларының мәдәният үсеше проблемаларын да даими яктыртып килә. В. И. Ленин нигез салган «Правда» милли әдәбиятлар һәм сәнгать үсешенә гомум пролетар эшнең аерылмас өлеше буларак дөрес юл күрсәтеп килде, аларның үсүе һәм чәчәк атуларына ярдәм итте.

...Илдә гражданнар сугышы тәгәлләнү белән үк, партиябез халыклар алдына наданлыкны, укый-яза белмәүчелекне бетерү бурычын куйды. «Правда» газетасы шул эшне практик гамәлгә ашыру барышын һәрвакыт бәян итеп торды. Мәсәлән, партиянең Казан губерна комитеты секретаре «Казан шәһәрендә укый-яза белмәүчелекне бетерү» дигән мәкаләсендә болай дип язды: «...Казанда — 12360 кеше, губернада 600 меңләп кеше укый-яза белми. Күренә ки, партия, совет органнары һәм халык мәгарифе эшлекләре алдында яңа кеше, социалистик җәмгыять кешесе тәрбияләүдә ифрат зур бурычлар тора... Тиз арада биш мең мәктәп төзелде, бөтен көч наданлыкка каршы көрәшкә тупланды. Кайбер өязләрдә уку кирәк-яраклары эзләп табуда осталык күрсәтәләр. Мәсәлән, имәннән каләмнәр ясыйлар, такта эшлиләр» («Правда», 1920, 22 май). Халыкның аң-белемгә омтылышы, партия һәм мәгариф органнарының оештыру сәләте гүзәл җимеш бирде. 1921 елда гына да Татарстанда «65462 кеше укырга һәм язарга өйрәтелде» («Правда», 1921, 30 август). Бу искиткеч зур казаныш иде.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соңгы беренче төзелеш елларында «Правда» крестьяннарны коммунистик рухта тәрбияләүгә күп көч куйды. Егерменче елда ул беренче тапкыр авылларда оештырылган халык театрлары турында язып чыкты. Бу хакта Татарстаннан да материаллар бирелде. Газета шулай ук хатын-кызларны иҗтимагый эшкә тарту өлкәсендә Идел буе халыклары тәҗрибәсен киң яктыртты. 1921 елда аның битләрендә «Татар хатын-кызлары арасында», «Казанда хатын-кызлар бүлеге эше», «Татреспубликада хатын-кызлар белән эшләү» дигән материаллар басылды. Соңгысында мондый юллар бар: «Германия белән сугыш ирләрне тыныч хезмәттән аерды һәм хатын-кызларны тормыш йомыклыгыннан ваз кичеп, җәмгыять өчен эшләргә мәҗбүр итте. Шул рәвешчә, Казан завод-фабрикаларында эшләүче һәр йөз хатын-кызның утызы татарлар арасыннан иде. Бу татар хатын-кызлары гомерләрендә беренче мәртәбә җәмәгать эшендә катнашалар, руслар белән беррәттән профсоюзларда торалар, делегатлар сайлыйлар... Делегат хатын-кызларның 362 се төрле совет учреждениеләрендә, асылда, балалар бакчалары һәм йортларында, мәктәпләрдә эшли» («Правда», 1924, 15 май).

1923 елда «Правда» иң яхшы укытучыга конкурс игълан итте. Әйе, бу елларда хезмәт ияләренә аң-белем бирүдә укытучының мактаулы ролен күтәрү төп бурычларның берсе иде. Шушы максат белән газета халык мәгарифе органнары эшен яхшыртуга зур игътибар бирде һәм моңа җирле газета-журналларны тартуның кызыклы формасыннан файдаланды. «Бердәм тырышлык белән авылны безгә язышу өчен кузгатыгыз! Конкурсның шартлары турында иң ерак төбәкләргә җиткерегез! Аның бурычларын аңлатыгыз!» — ул әнә шундый чакыру белән җирле матбугат органнарына мөрәҗәгать итте. Бу чакыруга барлык газеталар, шул җөмләдән «Известия ТатЦИКа» газетасы да бердәм кушылдылар. Озак та утми Россиянең барлык өлкәләреннән укы-

тучылар хакында хатлар, мәкалә һәм очерклар кила башлый. «Правда»да чыккан шундый язмаларның берсе Татарстаннан укытучы Кашшаф Шәхәбетдиновка багышланган була.

Гыйлем нуры таратучыларның эш һәм тормыш шартларын яхшырту мәсьәләсе дә онытылмый, культура тормышында җиң сызганып эшләгән укытучылар тәҗрибәсе киң яктыртыла. Бу җәһәттән игътибарны «Укытучы җәмәгать эшендә» дигән мәкалә җәлеп итә. Ул Татарстанда 2141 укытучының эшен социологик тикшеренү нигезендә язылган («Правда», 1924, 15 май).

Газетаның еллар узу белән инде саргая барган саннарын укыганда, революциядән соң авылны яңарту, аның культурасын күтәрү өчен никадәр зур көч куелганын бөтен тулылыгы белән күз алдына китерәсең.

Гомумән, бөтен илебез халыкларының культура һәм мәдәниятын алга җибәрүдә партия Үзәк Комитеты карарлары төп юлны күрсәтте. Мәсәлән, 1925 елда «Правда»да безнең Татарстан мисалында мәдәният эшенең торышы турында карар басыла. Анда республика партия оешмалары алып барган эшкә тирән анализ ясала. «Сабан туе», «Агрокультура» дигән һәм башка язмаларда республикабыздагы культура үсеше яктыртыла. Газета Казандагы эшчеләрнең кичке университеты, шулай ук врачларның белемен күтәрү институты турында язып чыкты. Геометриянең атаклы галим Н. И. Лобачевский нигез салган теориясенә 100 ел тулу вакыйгасы ил күләмендә билгеләп үтелү уңае белән Казан университеты галимнәренең тирән эчтәлекле чыгышлары тупланмасын бирә. Физикларның Казанда уздырылган Бөтенсоюз съезды барышы тәфсилләп языла («Правда», 1925, 26 сентябрь; 1926, 15 октябрь; 1926, 27 февраль; 1927, 15 июнь; 1927, 27 август; 1928, 14 август). Элек-электән үк мәдәният үзәкләренең берсе булган Казандагы югары уку йортлары белемле һәм сәләтле белгечләр әзерләүне бу елларда тагын да арттыралар. Алар исә үз чиратында культура революциясе җиңүенә гаять зур өлеш кертәләр.

«Правда»ның иҗат оешмалары һәм коллективлары эшенә дә игътибары зур. Бу әйрүчә 1928 елдан соң ачык чагыла. Газета рус әдәбиятының милли әдәбиятлар белән бәйләнешын һәм дуслыгын үстерү юлында ышанычлы күпер ролен үти: Идел буенда яшәүче төрле милләт әдипләренең чыгышларын укучы игътибарына тәкъдим итә, татар язучыларының, мәсәлән, Мәскәүгә килүен зур вакыйга итеп күрсәтә, татар һәм рус язучыларының иҗади дуслыгын конкрет раслаган язмалар бирә.

«Правда» тарихи истәлекләрне сакларга кирәклеге мәсьәләсен дә күтәреп чыга, бөек революциягә багышланган яңа һәйкәлләр иҗат итәргә чакырып яза. Газета сүзенең халык күңеленә ничек барып ирешүен менә бу кыска гына хәбәрдән дә күрергә мөмкин: «Казанда Ленин көннәрендә 400 ләп ударник партия сафына керде. Ленинга һәм Бауманга һәйкәлләр салына башлады» («Правда», 1931, 24 январь). Хәзерге Ирек мәйданындагы зур һәйкәл Казанның күрке санала, иң зур бәйрәм тантаналары шушының янында уздырыла.

Кыскасы, республикабызның культура тормышындагы һәртөрле зур яңалык газета культураларыннан читтә калмаган. Менә ул Казанда культура һәм ял паркы төзелә башлавын хәбәр итә.

Культура революциясенең иң зур казанышы, әлбәттә, революция тудырган кеше икәнен күздә тотып, шундый кешеләр турында төрле жанрда һәм формада материаллар оештыра. Мисалга түбәндәге язмага күз төшерү урынлы булыр: «Халык санын алу кәгазендәге сорауларга җаваплар халыкның культура дәрәҗәсе гаять нык үсүе турында сөйли... Мәсәлән, Апас районының Кулар авылы бу елларда 13 укытучы, 4 агроном, 3 техник, 4 шофер биргән, 8 кеше югары белем алган, 11 е — техникумнарда, ә 70 кеше урта мәктәптә укый» («Правда», 1937, 1 январь).

Газета битләреннән тагын бер кызыклы мәгълүмат белән танышыйк. Ул Казандагы югары уку йортларында эшләүче педагогик кадрлар турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә: «Казанда 1 академик, 132 профессор, 231 доцент, 333 ассистент, 357 гыйльми хезмәткәр, 170 аспирант фәнни-педагогик эш белән шөгыльләнә. Шуларның 246 сы, шул җөмләдән 10 профессор, 55 доцент — татар милләтеннән» («Правда», 1937, 1 март).

Газетада республикабызда музыка тормышы, театрлар эше һәм татар язучыларының иҗаты турында сөйләүче язмаларны күп очратасың: «Кечә Татарстан республикасы

культура фронтында яулаган зур җиңүен бәйрәм итте. Яшь композитор Нәҗип Җиһановның «Качкын» операсы белән Татар опера театры ачылды» («Правда», 1939, 18 июнь). Ленинчыл «Правда» газетасының фатиха булырлык зур бәясе сәнгатебезнең бу төре канат җәеп үсүгә ярдәме, әлбәттә, һичшиксез зур икәне көн кебек ачык.

Танылган татар язучыларының юбилейларын һәм бүтән зур, истәлекле даталарны газета битләрендә билгеләп үтү дә инде күптәннән гадәткә керде. Мәсәлән, илебез халыклары беренче татар драматургы һәм татар театрына нигез салучы Галиәсгар Камалның 60 еллык бәйрәме, соңгарак Казанда В. И. Ленинның һәм А. М. Горькийның музей-йортлары төзү хәбәре белән дә «Правда»ны укып таныштылар.

Бөек Ватан сугышы башлануга ук «Правда» дошманга каршы көрәштә әдәбият һәм сәнгать әһелләренең, фән эшлеклеләренең урыннарын һәм постларын ачык әйтеп бирде.

Бигрәк тә атаклы галимнәр, ару-талуны белмәстән, көнне төнгә ялгап эшләделәр. Совет фәнен фронтка ярдәм юнәлешендә үстерүгә гаять зур өлеш керттеләр, халык хуҗалыгы өчен белгечләр әзерләү бурычын уңышлы үтәделәр. Аларның бу хезмәте партия һәм хөкүмәт тарафыннан югары бәяләнде — күпләре Дәүләт премияләре белән бүләкләнде. 1943 елның 4 апрелендә исә «Правда» газетасында Казан галимнәренең Башкомандующийга җибәргән телеграммасы басылып чыкты. Анда академиклар Александр Арбузов, Сергей Наметкин һәм Александр Порай-Кошиц үзләренә бирелгән 200 мең сум күләмендәге премия акчасын Ватанны саклау фондына күчерүне үтенәләр.

Газета фронт белән тыл бердәмлеген ныгытуның үзенчәлекле алымнарын таба һәм куллана. Мәсәлән, газета битләрендә бер-бер артлы төрле республика хезмәт ияләренең хатлары игълан ителә. Менә 1943 елның 5 мартында басылган шундый хатларның берсе — «Татар халкының татар фронтовикларына хаты». Ул — чын мәгънәсендә югары сыйфатлы публицистика осталыгы үрнәге. Хатның төп текстын К. Нәҗми, Г. Кашшаф, Х. Ярми язганнар, ә рус телендәге текстын ул чакта Татарстанга килеп торган күренекле язучы Константин Федин эшкәрткән. «Правда»да чыкканнан соң бу хат үзебезнең җирле матбугатта һәм фронттагы татар газеталарында дөнья күрә. Аннары Воениздатта 350 мең данә тираж белән аерым брошюра итеп чыгарыла. Хат меңнәрчә сугышчылар күңеленә барып ирешә, һәм алар барысы да дошманга каршы аяусыз, батырларча көрәшергә ант итәләр.

Татар әдәбияты һәм сәнгате ул дәһшәтле елларда йөрәкләргә мәңге онытылмаска кереп калган гүзәл әсәрләр бирде, халкыбыз тарихына кагылышлы рухландыргыч хезмәтләр дә язылды. Ләкин кайбер кимчелекләр һәм хаталанулар булуы да билгеле. Шул уңай белән ВКП(б) Үзәк Комитеты махсус карар кабул итте. «Правда» газетасы аларны төзәтү юлларын күрсәтә («Правда», 1946, 14 октябрь; 1947, 1 август, 27 август, 7 сентябрь, 7 октябрь).

Шуннан соңгы елларда «Правда» нигездә Казан югары уку йортлары тормышын, В. И. Ленин һәм А. М. Горький музейлары эшен, тугандаш республикалар белән дуслашу-аралашуның яңа якларын сөйләде. Ә патриот-шагыйрь Муса Җәлилгә үлгәннән соң Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исем бирелү турында СССР Верховный Советы Президиумы Указы игълан ителгәч, «Правда» рус шагыйре Степан Щипачевның «Үлемсезлек» дигән ялкынлы мәкаләсен басты. Моннан соң да газета үзенең дистәләрчә сәхифәләрен герой-шагыйрьгә багышлады, үлемсез «Моабит дәфтәрләре» шигырьләрен күпләп чыгарды. Бу исә М. Җәлил иҗатын хаклы рәвештә совет әдәбиятының алтын фондына кертү булды. Газетада рус теле аша дөнья әдәбиятына шулай ук Г. Әпсәләмов, Г. Бәширов, К. Нәҗми, Г. Кутуй, Ф. Кәрим һәм башкаларның иҗатына да лаеклы бәя бирелде.

1957 елда Мәскәүдә һәм илебездә олы вакыйга булган: татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәрен «Правда» җентекләп язып барды: «Татар артистлары һәм әдәбиятчыларының чыгышлары ахырга якынлашып килә. Декадага катнашучылар бу вакыт эчендә уннарча спектакль һәм концертлар куйды, башкала хезмәт ияләре белән бик күп иҗади очрашулар һәм әдәби кичәләр уздырды. Кунаклар кайда гына булмасын, концерт заллары яки театрлармы, клублар яки культура сарайлармы — барысы да тамашачылар белән шыгрым тулы иде...» («Правда», 1957, 2 июнь).

Бүгенге көннәрдә «Правда» коммунистик җәмгыять төзүче яңа кеше тәрбияләүдә

совет культурасы, әдәбияты-сәнгате һәм фәне ирешкән казанышларны халык йөрәгенә җиткерүдә мактаулы эшне киң колач белән башкара. Анда культурага кагылышлы теоретик хезмәтләр белән берррәттән, әледән-әле аерым төбәкләрдән килгән конкрет материаллар урнаштырыла. Мәсәлән, 1979 елда Татарстан хезмәт ияләре генә совет матбугаты флагманы — «Правда»га 146 хат юлладылар, шулардан 50 се аларның үзләренең иҗат әсәрләре иде. Хәзер газетаның иҗат интеллигенциясе белән элемтәсен тагын да көчәйтү өчен бөтен мөмкинлекләре бар, аның сафлары елдан-ел үсә һәм ныгый бара. Татарстан Язучылар союзы 162 прозаик, шагыйрь һәм драматургны, Композиторлар союзы 37 музыка сәнгате остасын берләштерә. Безнең 70 профессиональ рәссамыбыз бар. Театрларда һәм Дәүләт филармониясендә эшләүче 800 дән артык сәхнә остасы халыкка культура хезмәте күрсәтә.

Социалистик төзелеш колач җәйгән беренче көннәрдә үк әле һади Такташ каләм ияләренә үз йөрәкләрен газета ярдәмендә миллионнар йөрәге белән бәйләргә чакырып мөрәҗәгать иткән иде. Шагыйрьнең бу авазы күптән инде чынга ашты. 60 нчы елларда татар язучылары һәм публицистларының дистәләрчә шигырь, хикәя һәм башка әсәрләре «Правда» битләрендә басылып чыкты. Алар арасында Р. Төхфәтуллинның «Авылдашым Нәби» хикәясе, Ә. Маликовның «Дуслык юлы» дигән шигырьләр бәйләме, Ә. Ерикәй җырлары, М. Зариповың «Сабирҗан абый» дигән зарисовкасы һәм башка әсәрләр бар иде.

«Правда» торган саен киңәя һәм тирәнәя барган әдәбият һәм сәнгать алдына яңадан-яңа проблемалы мәсьәләләр куя. Аларны хәл итүдә татар әдипләре дә бик актив катнашып киләләр. 1963 елда «Правда» совет әдәбиятында авыл хезмәтчәннәренең рухи йөзен тулы канлы итеп чагылдыру мәсьәләсен күтәреп чыкты. Бу уңай белән танылган язучы Гомәр Бәширов хәзерге авыл кешесе образын иҗат итүдәге уй-хыяллары белән уртаклашты («Правда», 1963, 8 апрель).

Татарстан җирендә нефть промышленносте кызу темп һәм киң колач белән үстерелгәндә республика әдипләре «кара алтын» чыгару осталарына багышланган әсәрләр иҗат итә башладылар. Нефтьчеләрнең үзләре арасыннан да язучылар үсеп чыкты, бу төбәккә Казаннан да тәҗрибәле каләм осталары күчеп килде. «Татарстан нефтьчеләренең яшь каласы Әлмәт җәмәгатьчелеге,— дип язды «Правда» 1963 елның 8 апрелендә,— идея тормышында зур вакыйганы билгеләп үтте: биредә ТАССР Язучылар союзы бүлеге ачылды». Шушы кыска гына хәбәрне укып та эшчеләр сыйныфын — нефтьчеләрне һәм химикларны коммунистик рухта тәрбияләүдә татар язучыларының актив катнашын ачык тоясың.

1965 елда партиянең Татарстан өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советы әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге иң яхшы әсәрләрне билгеләп узу максаты белән Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясен булдырдылар» («Правда», 1965, 24 октябрь). Сөекле шагыйребез исемендәге бу олы бүләкнең ел саен бирелүе әдәбият-сәнгать үсешенә бәрәкәтле йогынты ясый.

«Правда» газетасының 1964 ел, 15 март санындагы «Әдәби сәхифә» безнең өчен аеруча кадерле. Анда «Безнең төбәк нефтькә дә, җырга да бай» дигән гомуми баш астында республикабызның танылган нефтьчеләре, язучылар һәм журналистлар чыгыш ясады, татар әдипләренең Мәскәүдә һәм Казанда чыккан яңа китаплары турында киң информация бирелде. Совет матбугаты флагманының бу тәҗрибәсен Татарстан журналистлары уңышлы кулланалар. Менә егерме еллап инде «Социалистик Татарстан» белән «Советская Татария» газеталарында атна саен «Әдәби сәхифә»ләр чыгып килә. Моны «Правда» 1978 елның 16 ноябрендә шулай ук уңай яктан билгеләп узды.

Соңгы ун елда «Правда»да татар прозасы үсешенең төп юнәлешләренә өч тапкыр җентекләп анализ ясады. «Бүгенге татар әдәбиятына хас үзенчәлек шунда,— диелә аның 1975, 25 февраль санында,— ул тормышның яңа бизәкләрен эзләп таба, чынбарлыкны бөтен тулылыгы белән сәнгатьчә тасвирларга омтыла. Элегрәк роман һәм повестьларның сюжеты асылда авыл тормышы материалы нигезендә корылса, хәзер исә әдипләр яңага, эшчеләр сыйныфы тормышына ныграк мөрәҗәгать итәләр, аның социаль һәм рухи дөньясын ачалар». Газетаның әнә шундый югары бәясе әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләрен яңа биекләргә рухландырып тора.

**АЛЬБЕРТ АЙНЕТДИНОВ,**
тарих фәннәре кандидаты

Шәмси Хамматов,
тарих фәннәре кандидаты

# ЯҢАДАН САФКА

*Тик бер өмит, дуслар: безнең сафта*
*Табар соңгы көрәш теләген.*
*Яраланган, ләкин тар коллыкка*
*Баш имәгән керсез йөрәгем*[1].

Муса Җәлил

## Ул еллар бушка үтмәде

Бөек Ватан сугышы елларында фашистлар Германиясен җиңү өчен барлык совет кешеләре фронтта, тылда гаять зур көч куйдылар. Шинель киеп, солдат юлына журналистлар, язучылар, шагыйрьләр дә басты. Дәһшәтле елларда җиңүгә рухландыра торган ялкынлы сүзләре дә аларның үткен коралы иде. Яу кырында аеруча батырлык күрсәткән әдипләргә Советлар Союзы Герое исеме бирелде. Алар арасында легендар Муса Җәлил дә бар.

Бөек Ватан сугышы елларыннан соң патриот-шагыйрьнең язмышы байтак вакыт билгесез булды. Бу хәл республикабыз партия оешмасын, коммунист шагыйрьне белгән барча кешеләрне, иптәшләрен, дусларын борчуга салды. Редакцияләргә шагыйрь язмышы белән кызыксынучылардан хатлар килә торды. Кызганычка каршы, кайберәүләр арасында М. Җәлил хыянәтче булган икән дигән ялган хәбәр дә таралган иде. Күпләр моңа ышанмады: «Муса чын коммунист, аның хыянәтче булуы мөмкин түгел», диделәр.

«Хәбәрсез югалды! — дидек без бервакыт аның хакында,— дип язды Мостай Кәрим.— Бөек Ватан сугышының иң утлы елларында Җәлилнең тавышы тынып калды. Хат та, хәбәр дә килми башлады аңардан. Ләкин күңел ышанмады... Җырның хәбәрсез югалуы акылга сыймый иде»[2].

Муса Җәлилне утызынчы еллар ахырыннан ук якыннан белгән, сугышның беренче айларында аның белән Марьино политкурсларында бергә укыган, хәзер Мамадыш районында яшәүче Нәзирҗан Габитов редакциягә мондый хат җибәрә: «Мин шагыйрь турында еш уйлана идем. Әсирлектән котылып кайтып, байтак еллар узгач кына чын хәлләр турында белдем. Муса Җәлил турында «хыянәтче» дип әйтүчеләргә мин бервакытта да ышанмадым. Аның хакында чынбарлык ачыклангач, үз күңелемдәге ышану һәм уйларның раслануына шатландым»[3].

Тарихка күз салыйк. 1942 елның урталарында Волхов фронтында чолганышта калып, М. Җәлил хәбәрсез югала. 1942 ел ахырында Казанда аның «Тупчы анты» исемле шигырьләр җыентыгы басыла. 1943 ел башында аңа тәнкыйтьчеләр Г. Кашшаф, Х. Хәйри, журналист С. Фәйзуллин «чын мәгънәсендә патриот шагыйрь», «Ватанны,

[1] Муса Җәлил. Әсәрләр дүрт томда. 2. Казан. Татарстан китап нәшрияты. 1976. 85 бит (Алда бу чыганакның томнары һәм битләре генә күрсәтеләчәк).
[2] Муса турында истәлекләр. Казан. Татарстан китап нәшрияты. 1964. 301–302 бб.
[3] Хат «Социалистик Татарстан» газетасы музеенда саклана.

совет кешеләрен сөю һәм алар өчен горурлык М. Җәлил шигырьләренең һәр юлыннан аңкып тора», «большевистик шагыйрьнең сугышчан оптимистлыгы»[1] әсәре дип бәя бирәләр.

Шагыйрьнең исеме сугыш елларыннан соң да онытылмый, шигырьләре, мәкаләләре басылып тора, әдәбият белгечләре аның иҗатына әледән-әле мөрәҗәгать итәләр.

«Большая советская энциклопедия»да 1946 елны (53 нче том, 650—655 битләр) «Татар әдәбияты турында» М. Җәлилнең М. Гайнуллин, Б. Яфаров белән бергәләп язган мәкаләсе басыла. Татгосиздат 1947 елны «Нәниләргә бүләк» дигән җыентык чыгара. Анда М. Җәлилнең «Күке», «Суык бабай», «Карак песи», «Куык» исемле шигырьләре басыла. Татар дәүләт опера һәм балет театры Совет Армиясенең 29 еллыгын яңа әсәр — «Илдар» операсы белән башлый. «Совет әдәбияты» (1947 ел, 6 сан) журналында бу вакыйгага турында менә шундый хәбәр басыла: «Илдар» операсында вакыйга Бөек Ватан сугышы елларында колхоз тормышы һәм сугыш кырларында совет солдатларының бөек батырлыклары турында бара.

Аның либреттосын Муса Җәлил, музыкасын композитор Нәҗип Җиһанов язган иде. Ул чакта Татарстан АССР Министрлар Советы Председателе урынбасары С. Батыев «Яңа бишьеллыкта Татарстан культурасы» исемле мәкаләсендә хәзерге совет тормышын яктыртып торган әсәрләр арасында «Илдар»ны уңай яктан күрсәтеп үтә[2].

Тәнкыйтьчеләр Гази Кашшаф, Гали Халит, әдәбият белгече М. Фәйзуллина, композитор Ю. Виноградов М. Җәлил иҗатына шулай ук югары бәя бирәләр.

Димәк, 1947 елның икенче яртысына кадәр Татарстан һәм ил матбугатында М. Җәлилнең әсәрләре, аның иҗаты хакында бик күп чыгышлар урын ала.

М. Җәлилнең фашистлар тоткынлыгында «палач балтасы» астында язылган шигырьләре исә Казанга 1946—1947 елларда килеп төшә. Шагыйрь «Моабит дәфтәрләре»ндә үзе турында болай дип белдерә: «...Берлинда сәяси яшерен оешмага катнашуда, совет пропагандасы таратуда гаепләнеп кулга алынды, төрмәгә ябылды»[3]. Татарстан партия оешмасы шигырьләр дәфтәрләре авторының язмышын ачыклау, аңа тагылган «хыянәтче» ярлыгын алып ташлау эшен башлап җибәрә.

«Читтән караганда сизелерлек булмаса да, соңыннан Җәлилнең керсез исемен акларга ярдәм итүче материаллар нәкъ менә шушы елларда туплана башлады. Җәлилнең яшерен оешмасын тоттыручы хыянәтчегә ясалган ябык суд процессы җәлилчеләр көрәшендәге күп вакыйгаларны ачыкларга ярдәм итте»[4].

Партия, дәүләт, җәмәгать эшлеклеләре, рус язучылары А. Фадеев, К. Симонов, Илья Френкель, Юр. Корольков, татар тәнкыйтьчеләре Г. Кашшаф, Р. Мостафин, әдәбият белгечләре Н. Юзеев, Р. Бикмөхәммәтов, язучылар Ш. Маннур, Ә. Исхак, Н. Исәнбәт, Р. Ишморат, шагыйрьнең башка каләмдәш дуслары, замандашлары, көрәштәшләре, иптәшләре, чит ил патриотлары М. Җәлилнең Бөек Ватан сугышы елларында фашизмга каршы көрәштәге батырлыкларын ачыклау, аның биографиясен һәм иҗатын тулыландыру эшенә җиң сызганып керештеләр.

Муса Җәлилнең иленә, халкына, семьясына бирелгән саф күңелле совет гражданы булуын ачыклауда аның тормыш иптәше Әминә ханым Җәлилова зур тырышлык күрсәтә. Күрәсең, сөекле тормыш иптәше — шагыйрьнең иң якын итеп әйткән сүзләре ышаныч биргәндер аңа:

**Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,**
**«Алмаштырган илен»,— дисәләр,**
**Син ышанма, бәгърем!**
**Мондый сүзне**
**Дуслар әйтмәс, мине сөйсәләр...**
**Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,**
**«Муса инде үлгән»,— дисәләр,**

---

[1] «Совет әдәбияты», 1943, 1, 7 саннар; «Кызыл Татарстан», 1943, 23 май.
[2] «Совет әдәбияты», 1947, 2—3 саннар, 119 б.
[3] Муса Җәлил. Әсәрләр, дүрт томда. 2 т., 553 б.
[4] Муса Җәлил. Библиографик күрсәткеч. 1919—1973. Казан университеты нәшрияты. 1976. Р. Мостафин кереш сүзе, 6 б.

**Син ышанма, бәгърем!**
**Мондый сүзне**
**Дуслар әйтмәс, сине сөйсәләр** [1].

Чыннан да, күңел төпкелләрен айкап чыгарлык бу ихлас шигъри юлларны намусы саф булган кеше генә яза алыр иде.

Ләкин бу юлларның раслыгын исбатлау өчен күп көч куярга туры килә әле. Шуның өстенә аның исемен мәңгеләштерү юнәлешендә дә зур эш башкарылды. Бу чыгышта төп сүз нигездә шул турыда барачак.

## Шагыйрь әйләнеп кайтты

1953 елның 25 апрелендә «Литературная газета»да Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» турында беренче хәбәрләр һәм «Моабитта язылган шигырьләр» исемле баш астында аның алты шигыре И. Френкель тәрҗемәсендә басылды.

Татарстан Язучылар союзында М. Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» табылуга багышланган җыелыштан соң язучы Фатих Хөснинең «Совет Татарстаны» газетасында «Җырчы һәм көрәшче кайтты» дигән отчет-язмасы чыга. «Муса Җәлил! Шагыйрь, коммунист, солдат һәм герой — менә ул тагын безнең сафыбызда. Юк, үлем андый кешеләрне җиңә алмый!» — ди анда шагыйрь җанлы оста прозаик.— Немец фашистлары тарафыннан үлемгә хөкем ителгән Муса Җәлил төрмәдә, үз сүзләре белән әйткәндә, «палач балтасы» астында искиткеч тормыш нурлары белән балкыган шигырьләр язып калдырган. Совет кешесенең какшамас ихтыяр көчен тагын бер кат раслый торган документлар — кешелек документлары болар... Дәүләт чикләрен һәм меңнәрчә километрлык ераклыкларны үтеп, менә ул җырлар безгә — шагыйрьнең туган җиренә кайтып төштеләр. 1944 нче елны... фашистлар кулыннан җәзалап үтерелгән Муса Җәлил бу ике дәфтәрне үлеме алдыннан үзенең тоткындаш иптәшенә — янәшә камерада утырган Бельгия партизанына биреп калдырган. Совет гаскәрләре Берлинны алгач, Моабит төрмәсеннән коткарылган әлеге партизан ул дәфтәрләрне Брюссельдәге совет консуллыгына илтеп тапшырган» [2].

Җыелышта доклад белән Гази Кашшаф чыга. Ул М. Җәлилнең үлем сәгатьләре көткәндә язган шигырьләре теркәлгән ике куен дәфтәреннән берничә шигырь укый:

**Җырлап үттем данлы көрәш кырын,**
**Җырлап килдем тормыш язына.**
**Соңгы җырым палач балтасына**
**Башны тоткан килеш языла** [3].

Шагыйрьнең ялкынлы сүзләре җыелышта катнашучыларга гаять зур тәэсир итә. Анда Әнвәр Давыдов «Литературная газета»да басылган тәрҗемәләрне укый. Ә. Исхак, Р. Ишморат, Г. Латыйп, С. Баттал, Я. Агишев һ. б. дулкынландыргыч чыгышлар ясыйлар.

Бөек Ватан сугышыннан соң М. Җәлилнең патриотик әсәрләрен пропагандалау эше әнә шулай башланды.

КПСС өлкә комитеты күрсәтмәсен үтәп, республика газета-журналлары М. Җәлил иҗатына багышланган материаллар, аның фашист төрмәсендә язылган әсәрләрен еш бастылар.

«Совет Татарстаны» газетасы 1953 ел, 30 апрель санында «Ялкынлы патриот шагыйрь Муса Җәлил» исеме астында сәхифә бирде. Анда шагыйрьнең «Кичер, илем», «Җырларым», «Ышанма», «Корыч», «Яңа ел теләкләре», «Хөкем алдыннан», «Кошчык» дигән шигырьләре беренче мәртәбә татар укучыларына тәкъдим ителде.

Гази Кашшаф «Корыч ихтыярлы шагыйрь» дигән мәкаләсендә Җәлилнең әлеге һәм башка әсәрләренә беренчел анализ ясаган иде. Тәнкыйтьчене иң элек шагыйрь

---

[1] Том 2, 210—211 б.
[2] «Совет Татарстаны», 1953, 29 апрель.
[3] Том 2, 214—215 б.

иҗатындагы һәм язмышындагы патриотизм хисенең чыганаклары кызыксындыра. Чыннан да, палачлар никадәр генә котырынмасыннар, никадәр шашынмасыннар, М. Җәлилнең яшәүгә булган омтылышын, туган илгә кайнар мәхәббәтен сүндерә алмыйлар. Шагыйрьнең баһадир йөрәгенә сокланмый калу мөмкин түгел. Мондый омтылыш, мондый ныклык, шушындый чыдамлык кайдан килгән, аның чыганаклары нинди җирлектән? «Моңа,— дип язды Г. Кашшаф,— җавап ачык: ул — совет кешесе, совет көрәшчесе, аны совет строе, партия тәрбияләп үстергән, аның намусы саф һәм хисләре изге. Соңгы сулышына кадәр Ватанга турылыклы булып калган шагыйрь иң самими хисләр белән юлбашчы образын йөрәгендә саклый:

**Аның исеме белән ачылган тел,**
**Үлгәндә дә аны кабатлар,**

— ди ул».

Җәлил иҗатын рус теленә киң пропагандалау эшенә керешеп, «Советская Татария» газетасы аның сигез шигырен, Бруно Зернитның «Кайнар йөрәк» исемле мәкаләсен бастыра [1]. «Яшь сталинчы» газетасында «Моабит дәфтәре» шигырьләре Әхмәт Исхак мәкаләсе белән бергә басыла [2]. Кыскасы, М. Җәлилнең поэзиядәге гражданлык батырлыгы бөтен матбугат органнарының, радионың игътибар үзәгенә күчә.

1954 елда М. Җәлилнең фашистлар тарафыннан үтерелүенә 10 ел тулу уңае белән матбугат аның иҗатын пропагандалау юнәлешендә янә бер кампания үткәрде. «Совет Татарстаны» газетасында М. Җәлилнең «Бар җырымны илгә багышладым, гомеремне дә бирәм халкыма» дигән шигъри сүзләре белән ачылган сәхифә бирелә. Анда шагыйрьнең 1942 ел, 12 январьда язылган көндәлегеннән өзек, «Бер үгет», «Алман иленә», «Хыял» исемле әсәрләре басылган, Мөхәммәт Садри, Гали Хуҗиевның публицистик чыгышлары урнаштырылган. «Муса Җәлилнең,— дип яза Г. Хуҗиев,— Моабит төрмәсендә язган шигырьләрен аерыла алмыйча, бөтен күңел белән бирелеп укыйсың. Чөнки бу шигырьләрдә Коммунистлар партиясе тәрбияләп үстергән совет кешесенең бөеклеге, аның Ватанга мәхәббәте һәм турылыгы, намусы һәм вөҗданы, куркусызлыгы һәм батырлыгы гәүдәләнә. Муса Җәлил үз тормышының бөтен мәгънәсен Ватанга хезмәт итүдә, аның азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен көрәштә үлемне җиңеп үлүдә күрә» [3].

Әлеге дата уңае белән Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында зур кичә үткәрелә. Анда Г. Кашшаф доклады тыңлана, рус язучысы Ю. Корольков, әзербайҗан халык шагыйре Самәд Вургун чыгып сөйлиләр [4].

«Совет әдәбияты», «Совет мәктәбе», «Азат хатын», «Чаян», «Пионер» журналлары, «Комсомолец Татарии» һәм район газеталары шагыйрьнең тормышын һәм әдәби эшчәнлеген киң яктырттылар. Шагыйрьнең йөрәк каны белән язылган әсәрләре, тормышы совет кешеләрен, яшьләрне патриотизм, халыклар дуслыгы рухында тәрбияләргә булыша, дошманнарга нәфрәт белән карарга өйрәтә. Үз иҗатының һәм язмышының яшьләрне тәрбияләүдә үрнәк булачагын шагыйрь алдан күреп язган бит:

**Чикләнсә дә гомер, яшьлек безнең**
**Эзсез сүнә, диеп уйлама!**
**Әйтсен яшьләр: менә шулай яшәп,**
**Шулай үлсәң иде дөньяда!** [5]

КПСС Үзәк Комитеты органы «Правда» газетасы М. Җәлил исемен бөтен илгә һәм дөньяга чыгарды. 1953 елның 6 июнендә анда Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гомәр Бәшировның «Үлемнән дә көчлерәк» исемле публицистик мәкаләсе басылды. Аны республикабыз матбугаты татарчага тәрҗемә итеп бастырды. «Совет шагыйре Муса Җәлил,— дип язды Г. Бәширов,— җәзалар астында калганда да

---

[1] «Советская Татария», 1953, 30 апрель.
[2] «Яшь сталинчы», 1953, 29 апрель.
[3] «Совет Татарстаны», 1954, 26 январь.
[4] «Совет әдәбияты», 1954, 2 сан.
[5] Том 2, 191—192 б.

котылгысыз үлем алдында торганда да, азатлык һәм намус эше өчен каһарманнарча көрәшә белде, бөтенесенә каршы нык торды, җиңүче булып чыкты.

Фаҗигале үлеменең якынайганын көткәне хәлендә шагыйрь мөмкин кадәр күбрәкне әйтеп калырга омтылды... Үзләренең көче һәм матурлыгы белән укучыны дулкынландыра ала торган мондый шигырьләрне шагыйрь караңгы төрмә камерасында да иҗат итә алган икән, аңа илһам бирүче мәхәббәт көченең никадәр зур булганлыгы һәм аның хисләренең никадәр саф булуы үзеннән-үзе күренеп тора!

...Совет Армиясенең җиңүенә нык ышанган хәлдә ул «Мәскәү килгәч» булачак шатлыклы көннәр турында зур дулкынлану белән язды. Җәза минутлары алдыннан, бу минутларны үзе кичереп һәм үзенең кичерешләре белән төрмә камерасын яктырткандай итеп, шагыйрь җиңүче совет халкының шатлыклы тыныч хезмәткә кайтуы турында, яңадан илдә яңа шәһәрләр күтәрелүе, яңа үрентеләр яшәрәчәге, бакчаларның чәчәк атуы турында җырлады... Көрәшче шагыйрьнең якты образы безнең күңелебездә озак, бик озак сакланыр».

«Правда» башлангычына бүтән үзәк матбугат органнары да кушылалар. Мәсәлән, «Известия» газетасы Г. Кашшафның «Үлемсезлек чыганагы» дигән мәкаләсен бастырды (1953 ел, 24 июнь).

1953—1955 елларда илебезнең республика, край, өлкә газеталары, журналларында шагыйрьнең иҗатына багышланган бик күп сәхифәләр, мәкаләләр, тантаналы җыелышлардан отчетлар, репортажлар бирелде. Аның шигырьләре рус, украин, казакъ, үзбәк, әзербайҗан, чуваш, башкорт һәм башка милләтләр телендә дөнья күрде.

Минә минем кулымда 1953 елның ахырында Татарстан китап нәшриятында басылган, Муса Җәлилнең Моабит төрмәсендә язган шигырьләр җыентыгының сигнал экземплярлы. Ул миңа КПСС өлкә комитетында эшләгән елларда бирелгән зур бүләк иде. Муса Җәлилнең тоткынлыктан әйләнеп кайткан үлмәс шигырьләрен ул көннәрдә уку зур шатлык һәм бәхет булды. Аның тиңдәшсез батырлыгы иҗат кешеләрен, партия, совет работникларын, хезмәт ияләрен горурландырды, тынычлык өчен көрәшкә рухландырды. Әдипнең Моабит шигырьләренең Мәскәүдә рус телендә чыгуы халкыбызның культура тормышында зур вакыйга булды. Ул «Советский писатель» нәшрияты тарафыннан 1955 елны «Из Моабитской тетради» исемендә җыентык итеп чыгарылды. Җыентыкка кереш сүзне шагыйрь Әнвәр Давыдов язган иде. Татар шагыйренең әсәрләре бөек рус теле аша барлык совет халыкларына, прогрессив кешелеккә җиткерелде. Шигырьләрне русчага тәрҗемә итүдә Илья Френкель, Анна Ахматова, Р. Моран, Б. Зернит, Т. Ян, Л. Пеньковский һәм башкалар катнашты. «Муса Җәлил шигырьләрен,— дип язды А. Ахматова,— мин һәрвакыт каушау һәм дулкынлану хисе тоеп тәрҗемә иттем. Бу сокландыргыч кешенең һәм яхшы шагыйрьнең фаҗигале язмышы хакында уйламыйча, аның әсәрләренә кагылырга ярамый» [1].

1954 елны (15—26 декабрь) Мәскәүдә Зур Кремль сараенда совет язучыларының икенче Бөтенсоюз съезды булды. Анда партия һәм дәүләт җитәкчеләре катнашты. Съездда М. Җәлил иҗатына югары бәя бирелде. «Совет әдәбиятының торышы һәм аның бурычлары» турындагы докладында Алексей Сурков совет язучыларының патриотлыгына үрнәк йөзеннән беренче итеп Муса Җәлил исемен атады. «...Совет язучылары сынау көннәрендә дә, җиңү көннәрендә дә үз халкы белә бергә булдылар. Берлинның Моабит төрмәсендә фашист палачлары тарафыннан гильотинада башы киселгән татар шагыйре Муса Җәлил үлем алдыннан ялкынлы юллар яза:

**Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,**
**Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә,**
**Кирәк икән, үләм аягүрә,**
**Балта белән башым киссәң дә»** [2].

Сәмәд Вургун да «Совет поэзиясе турында»гы чыгышында М. Җәлил хакында дулкынландыргыч сүзләр әйтте: «Бөек Ватан сугышы елларында,— диде ул,— халкыбыз өчен җитди сыналу, аның барлык көчләре сыналу елларында совет поэзиясенең иң яхшы сыйфатлары бөтен тулылыгы белән ачылды. Шагыйрь сүзенең «кеше көче

---

[1] «Казан утлары», 1966, 2 сан, 10 б.
[2] Муса Җәлил. Том 2, 206 б.

полководецы» булуы менә кайчан аеруча ачык сизелде. Бу-уңайдан таш тормә капчыгында, һәр минут үлем сагалаган бер вакытта көчле нәфрәт белән тулы шигырьләр иҗат иткән патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең якты образын искә төшерик... Без зур поэзиябезнең милли революцион-патриотик традицияләрен киләчәктә дә күз карасы кебек сакларга тиешбез»[1]. С. Вургун съездда катнашучыларга М. Җәлилнең «Ышанма» шигыренең тәрҗемәсен укый.

Съездда Муса Җәлил язмышының озак еллар буе билгесез булуына, аның шигырьләре басылып чыкмавына борчылып чыгыш ясаучылар да булды.

Шагыйрь С. Щипачев, мәсәлән, болай ди: «Бельгия партизанына — Муса Җәлилнең иптәшенә — аның васыятен үтәү һәм әлеге шигырьләр дәфтәрен совет кешеләре кулына тапшыру җиңел булмаган, әмма әлеге шигырьләрне бастырып чыгаруда киртә булган көчләрнең каршылыгын җиңү, Җәлилнең намуслы исемен каралтырга омтылучы кешеләрне җиңеп чыгу тагын да авыррак булды. Берничә ел элек үк инде шагыйрь Френкель Җәлилнең үлем алдыннан язылган шигырьләр циклын рус теленә тәрҗемә иткән иде. Алар хәтта «Новый мир» журналында чыгару өчен әзерләнеп тә куелган иде, әмма Казаннан шалтыраттылар, һәм шигырьләр дөньяга чыга алмады. Мәскәүдә Совет Язучылары союзының милли комиссиясендә дә Җәлилнең гражданлык намусын һәм поэзиясен якларга кирәклеген аңламаганнар. Менә шуңа күрә генә Җәлилнең рус теленә тәрҗемә ителгән китабы съездга кадәр чыгып җитә алмады».

Бу съезд эшендә катнашкан Татарстан Язучылар оешмасы вәкилләре Казанга кайткач съезддан алган тәэсирләре белән уртаклаштылар, зур форумда М. Җәлил исеменең олы хөрмәт белән телгә алынуын шатланып, горурланып яздылар. «Зур Кремль сараендагы меңнәрчә делегатлар һәм кунаклар, 34 илдән килгән чит ил кунаклары,— дип язды Г. Кашшаф,— Сурковның сүзләрен һәм Муса Җәлилнең Р. Галимов русчага тәрҗемә иткән шушы шигырен искиткеч бер дулкынлану белән тыңладылар. Бу — съезд трибунасыннан Муса Җәлил поэзиясенә югары бәя бирү һәм аны барлык совет халыкларына тәкъдим итү иде!»[2]

## Какшамас ихтыяр һәм ныклык символы

Бу юлларның авторы «Моабит дәфтәрләре» Казанга алынганнан соң Муса Җәлилнең чын коммунист, совет патриоты икәнен ачыклау өчен ул елларда күп көч куйган, бу җитди эшкә тиешле органнарны туплаган КПСС Үзәк Комитеты члены булган, партия өлкә комитетының беренче секретаре булып эшләгән Зиннәт Ибәтович Муратов белән берничә тапкыр очрашты. Ул безгә менә нәрсәләр сөйләде:

— Мин Муса Җәлил белән бергә Казанда егерменче еллар уртасында татар рабфагында укыдым. Мине комсомолның Югары шәһәр райкомы бюросы члены, рабфакның комсомол оешмасы секретаре итеп сайладылар. ЧОН отряды командиры булып та эшләдем. Муса рабфакта комсомол оешмасы активисты, стена газетасы редакторы иде. Ул елларда матбугатта аның мәкаләләре, шигырьләре күп басыла иде. Аның Париж коммунасына багышлап язылган пьесасы да сәхнәдә уйналуын бик яхшы хәтерлим. Яшьләр алдында үз шигырьләре белән чыгышлар, политик темаларга докладлар ясый, беседалар үткәрә иде. Шул елларда ук инде ул патриотик рухта тәрбияләнгән, Ленин партиясенә чын күңелдән бирелгән комсомолец иде. Бөек Ватан сугышы тәмамлангач, мин аның турында «хыянәтче» дип таралган хәбәргә һич тә ышанмадым, чөнки аның Коммунистлар партиясенең тугры улы булуына бик инангән идем. Шундый күңелсез хәбәр таралгач, мин аны электән үк якыннан белгәнгә, йөрәгем бик нык тетрәнде. Татарстан партия оешмасы коммунисты, танылган шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе М. Җәлилгә «хыянәтче» дигән тамга сугылса, халкыбыз, иҗат интеллигенциясе өчен нинди хурлык булачагын мин бик яхшы аңлый идем.

М. Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» Казанга алынгач,— дип дәвам итә ул аңа-

---

[1] Второй Всесоюзный съезд советских писателей. 15–26 декабря 1954 г. Стенографический отчет. Советский писатель, 1956, 17, 59–66.

[2] «Совет Татарстаны», 1955, 3 март.

ры,— без аны өлкә комитетында кат-кат укыдык, ныклап өйрәндек, фашизмга нәфрәт, Ватанга мәхәббәт белән сугарылган патриотик шигырьләренә сокландык.

Муса Җәлил эше һәм аның шигырьләрен матбугатта чыгару мәсьәләсе партия өлкә комитетында каралды. Өлкә комитетында шулай ук фашистик «Идел-Урал» легионының кара эше, анда татар хәрби әсирләре арасында фашизмга каршы яшерен көрәш алып барган оешма булганлыгы хакында да сүз булды. Мәгълүматларга карағанда, аңа Гумеров дигән кеше җитәкчелек иткән. Кайбер кешеләрнең раславынча, ул Муса Җәлил булган. Ләкин М. Җәлилне фашист офицеры киемендә күргәннәр икән дигән хәбәр дә килде. Шунлыктан КПСС өлкә комитетында тиешле дәүләт органнары белән бергәләп М. Җәлилнең фашистлар әсирлегендәге эшчәнлеген ныклап ачыкларга, шуннан соң гына аның әсәрләрен бастыру мәсьәләсен хәл кылырга дип сөйләшенде. Бу эш байтакка сузылды. Тикшерүләр раслаганча, М. Җәлил совет Ватанына бирелгән чын, керсез гражданин булган.

Хәтеремдә, Мәскәүдә тиешле оешмаларда күрсәтү һәм аңдату өчен «Моабит дәфтәрләре»н бер төркем әдип рус теленә тәрҗемә итте. Обком секретаре буларак миңа Муса Җәлил эше белән Мәскәүдә күп тапкырлар булырга туры килде. Аның Берлинда яшерен оешма туплавы, фашистларның «Идел-Урал» легионын таркату буенча зур эш алып баруы ачыклангач, КПСС өлкә комитеты көрәшче-шагыйрьнең батырлыгын билгеләп үтү турында партия Үзәк Комитетына мөрәҗәгать итте. Өлкә комитеты тапшыруы буенча берничә мәртәбә КПСС Үзәк Комитеты җитәкчелегендә булдым, М. Җәлилнең Бөек Ватан сугышы елларында тоткынлыкта фашистларга каршы көрәш оештырганлыгын сөйләдем. Аңа Советлар Союзы Герое исеме бирү мәсьәләсен кузгаттым...»

Чыннан да, 1955 елның 19 декабрендә КПСС өлкә комитеты исеменнән аның беренче секретаре З. И. Муратов КПСС Үзәк Комитетында түбәндәге записканы кертә.

«1955 ел, 19 ноябрь.
Мәскәү шәһәре
КПСС Үзәк Комитетына

Татар халкының күренекле патриот-шагыйре Муса Җәлилнең тууына 1956 елның февралендә 50 ел тула.

Үзенең әдәби эшчәнлеген 1919 елда армия газетасында башлап, Муса Җәлил социалистик хезмәтнең бөеклегенә, Коммунистлар партиясенә һәм совет халкына дан җырлаган күп кенә илһамлы художество әсәрләре иҗат итте. Ул татар совет культурасының иң зур эшлеклеләреннән берсе, актив җәмәгать эшлеклесе иде, Татарстан Совет Язучылары союзы председателе булып эшләде.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк Муса Җәлил фронтка китә. Армия тормышы шартларында шагыйрьнең таланты тагын да ачыла төшә. Аның фронтта язган шигырьләре халыклар дуслыгы, үз иленә мәхәббәт һәм тугрылыкның бөек идеяләре белән, хак эш өчен көрәшкә чакыру белән сугарылган.

Каты яраланган шагыйрь фашистлар кулына әсирлеккә эләгә. Әмма анда да, фашистларның Берлиндагы Моабит төрмәсендә хөкем сөргән иң авыр шартларда да, ул көрәшче-шагыйрь көче белән совет халкының батырлыгын җырлауны дәвам иттерә, аның җиңәчәгенә нык ышана. Биредә ул фашистларның «Идел-Урал» легионын таркату буенча зур эш алып бара һәм шуның өчен җәзалап үтерелә.


Коммунист-шагыйрь Муса Җәлил гомеренең азагына кадәр үз Ватанына һәм партиясенә турылыклы булып калды, ул герой булып яшәде һәм һәлак булды.

Муса Җәлилнең патриотик батырлыгын, аның Ватан һәм партия алдындагы хезмәтләрен исәпкә алып, КПССның Татарстан комитеты КПСС Үзәк Комитетыннан татар халкының патриот-шагыйре Муса Җәлилгә үлгәннән соң Советлар Союзы Герое исеме бирү турындагы мәсьәләне карауны һәм 1956 елның февралендә аның 50 еллык юбилеен үткәрергә рөхсәт бирүне сорый.

КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре
З. Муратов»[1]

---

[1] КПССның Татарстан өлкә комитеты партия архивы, ф. 15, тасвирлама 36, эш 318, 18 б.



Бөрлек илләрнең пролетарийлары, берләшегез!

Советлар Союзы Коммунистлар Партиясе
ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ
Казан, Молотов урамы 34.

Пролетарии всех стран, соединяйтесь!

Коммунистическая Партия Советского Союза
Татарский областной комитет
г. Казань, улица Молотова д. № 34.

№ 638/м3.

«19» XII 1955 г.

гор. МОСКВА

ЦК КПСС

В феврале 1956 года исполняется 50 лет со дня рождения выдающегося татарского поэта - патриота Мусы Джалиля.

Начав в 1919 году свою литературную деятельность в армейской газете, Муса Джалиль создал большое количество вдохновенных художественных произведений, воспевающих величие социалистического труда, славу Коммунистической партии и советскому народу. Он был одним из крупнейших деятелей татарской советской культуры, активным общественником, работал председателем Союза советских писателей Татарии.

С первых дней Великой Отечественной войны Муса Джалиль ушел на фронт. В условиях армейской жизни еще больше раскрылся талант поэта. Его фронтовые стихи одухотворены высокими идеями дружбы народов, любви и преданности своей стране, призывом к борьбе за правое дело.

Тяжело раненый поэт попал в фашистский плен, но и там, в тягчайших условиях фашистского застенка - берлинской тюрьмы Моабит, со всей силой поэта - борца продолжал воспевать героизм советского народа, твердо веря в его победу. Здесь он вел большую работу по разложению фашистского легиона «Идель-Урал», за что был казнен.

Поэт-коммунист Муса Джалиль до конца своей жизни остался предан своей Родине и партии, он жил и погиб, как герой.

Учитывая патриотический подвиг Мусы Джалиля, его заслуги перед Родиной и партией, Татарский обком КПСС просит ЦК КПСС рассмотреть вопрос о присвоении татарскому поэту - патриоту Мусе Джалилю посмертного звания Героя Советского Союза и разрешить провести в феврале 1956 года 50-летний юбилей со дня его рождения.

Секретарь Татарского обкома КПСС З. Муратов (З. Муратов)

КПСС Үзәк Комитеты Президиумы 1955 елның декабрь аенда Муса Җәлил хакындагы мәсьәләне тикшерә. 1956 елның 30 январенда ул М. Җәлилгә Бөек Ватан сугышында немец-фашист илбасарларга каршы сугышларда тиңдәшсез ныклык һәм батырлык күрсәткәне өчен, үлгәннән соң, Советлар Союзы Герое исеме бирү турында СССР Верховный Советы Президиумы кертүкән Указ проектын раслый. КПСС Үзәк Комитеты Президиумы карары 1956 елның 2 февралендә партиянең өлкә комитеты бюросы утырышында карала һәм хуплап каршылана. Шагыйрь Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме бирүгә багышлап 1956 елның 3 февралендә Офицерлар йортында башкала хезмәт ияләренең митингын үткәрергә карар кылына.

СССР Верховный Советы Президиумы Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме бирү турында 1956 елның 2 февралендә Указ чыгара. Ул матбугатта 3 февральдә игълан ителә.

«Совет Татарстаны» газетасы Указ чыккан көнне «Патриот-шагыйрь» дигән мәкалә бастыра. Анда болай диелгән: «Әйе, совет халыклары үзләренең җиңү бәйрәмендә көрәшче-уларын бервакытта да онытмыйлар, аларның батыр образларын һәрвакыт истә, йөрәктә саклыйлар. Батыр Муса Җәлилнең бөек, керсез йөрәге миллионнарны яңа батырлыкларга, яңа җиңүләргә чакырып тора. Ул гомер озынлыгын еллар саны белән үлчәмәде, бәлки Ватанга никадәр күбрәк файда китерсәң, шулкадәр гомерең озын була дип карады».

1956 ел, 3 февраль. Офицерлар йортының Колонналы залы. Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме бирүгә багышланган митингка без дулкынлану һәм шатлану хисләре белән җыелдык. СССР Верховный Советы Президиумы члены, партиянең Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре З. И. Муратов шагыйрь Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме бирү турында СССР Верховный Советы Президиумы Указын игълан итә һәм ялкынлы речь сөйли:

— Республикабыз хезмәт ияләре,— ди ул,— шагыйребез Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое исемен бирү турындагы Указны шатланып һәм горурланып каршыладылар. Алар моны үзенең тормышын совет Ватаны өчен биргән патриот-шагыйрь истәлеген гасырлар буена саклау турында партиябез һәм хөкүмәтебез тарафыннан күрсәтелә торган кайгыртучанлыкның яңа чагылышы дип карыйлар.

Совет кешеләре зур шагыйрь һәм татар халкының данлыклы улы Муса Җәлил исемен мәхәббәт белән искә алалар. Бөек Ватан сугышының авыр елларында, туган илебезнең язмышы хәл ителгәндә ул эшләгән тиңдәшсез батырлык эзсез югалмады. Бу батырлык кояш нуры кебек балкыды һәм балкыр.

Һәм менә бүген, Бөек Ватан сугышы җиңү белән тәмамланудан соң унбер ел үткәч, без бергә көрәшче шагыйрьнең истәлеген хөрмәтләү өчен җыелдык.

Безнең сөекле шагыйребез тугры, намуслы тормыш юлы, тиңдәшсез батырлыгы һәм иҗаты совет кешесенең — яңа эпоха кешесенең рухи бөеклеген гәүдәләндерә һәм Ватаныбызның бәхете һәм даны өчен көрәштә ныклыкның һәм батырлыкның гүзәл үрнәге, чын патриотлык һәм иҗади яңу үрнәге булып тора. Коммунист Муса Җәлил батырлыгы безнең йөрәкләребездә баһадир рухлы шундый кеше үстерган партиябез өчен горурлык хисе тудыра».

Оратор Муса Җәлилнең фашистлар тоткынлыгында да совет халкының дошманны җиңәчәгенә ышанып яшәвен, көрәшче һәм җырчы булып калуын дәртләнеп, илһамланып сөйли.

«Авыр яраланган хәлдә»,— ди ул,— гитлерчылар тырнагына эләккән Муса Җәлил тормышының соңгы минутынача Ватаныбызга, партиягә һәм совет халкына турылыклы булып калды. Коточкыч Моабит төрмәсенең чиксез газаплы тоткынлыгы шартларында ул Ватаныбызның дошманнарына карата чиксез нәфрәт белән тулган һәм безнең героик совет халкы яклап көрәшкән хак эшнең җиңәчәгенә нык ышану белән сугарылган рухланулы шигырьләр язды.

Үзенең утыз сигез еллык кыска гына, ләкин кайнап торган бөтен тормышын Муса Җәлил коммунизм төзү эшенә, Ватаныбызның куәтен ныгыту эшенә бирде. Үлем бусагасына килеп җиткәч, үлем җәзасын бирү турында хөкем чыгарылганнан соң да ул туган илебезнең даны турында уйлый.

**Юк, кайгырма, дускай, безнең гомер**
**Ил гомеренең тик бер чаткысы.**
**Без сүнсәк тә, безнең кыюлыктан**
**Арта бара аның яктысы.**

Муса Җәлил исеме татар халкына кадерле булган кебек үк, барлык совет кешеләренә дә кадерле. Партиябезнең турылыклы улы Муса Җәлил халыклар дуслыгының эзлекле көрәшчесе һәм җырчысы булды. Барлык милләтләрнең хезмәт ияләре Җәлилнең истәлеген тирәнтен хөрмәтлиләр һәм аны мәхәббәт белән: «Безнең Фучик!»— диләр.

Муса батырлыгы һәм аның яшәү көче белән тирән сугарылган шигырьләре безне дөньяда беренче Советлар иленең куәтен тагын да ныгыту өчен, бөтен дөньяда тынычлык эшенең тантанасы өчен үз-үзебезне аямыйча көрәшергә чакыралар» [1].

[1] «Совет Татарстаны», 1956, 5 февраль.

Митингта чыгыш ясаучылар һәммәсе М. Җәлил хакында чиксез рухланып сөйләделәр.

— Муса Җәлил,— диде эшче М. Ф. Мамакин дулкынланып,— тормышының соңгы көннәренә кадәр фашист палачларга каршы көрәшен туктатмады. Караңгы төрмәдә ялкынлы шигырьләр язып, ул совет кешеләренең геройлыгын, куәтле Ватаныбызның матурлыгын мактап җырлады. Шагыйрьгә мондый ныклык һәм батырлыкны безнең Коммунистлар партиясе бирде. Партия аны герой итеп үстерде һәм аның исемен мәңгеләштерде.

Менә митингта шагыйрь Шәйхи Маннур чыгышыннан кайбер дулкынландыргыч юллар:

— Халкыбызның патриотик батырлыгында совет кешеләре батырлыгының һәм кыюлыгының күп санлы гүзәл үрнәкләре, шул исәптән татар халкы улы Муса Җәлилнең дә мәңгелек батырлыгы бар... Моабит төрмәсендә дә гитлерчыларга каршы көрәшү өчен корал таба — бу корал Ватанга мәхәббәт гимны һәм героик тормыш җыры язган кечкенә генә карандаш кисәге һәм кәгазь була.

— Муса Җәлил,— диде композитор Нәҗип Җиһанов үзенең чыгышында,— зур шагыйрь булу белән бергә, гомумән татар сәнгатенең зур эшлеклесе дә иде. Татар совет опера сәнгатен аякка бастыруда аның роле зур булды. Ул алдынгы сәнгать өчен көрәштә килешмәүчән булды һәм милли музыка-драма репертуары булдыру өчен бик күп эшләде. Нәкъ менә шул елларда театрда «Шүрәле» һәм «Качкын» кебек спектакльләр, либреттоларын Муса Җәлил язган «Алтынчәч» һәм «Илдар» опералары туды. Мусаның батырлыгы бөтен язучылар, художниклар һәм композиторлар өчен иҗади рухлану чыганагы булып хезмәт итә.

Митингта шулай ук мех комбинаты эшчесе М. Җиһаншина, шагыйрь Гали Хуҗиев, 8 номерлы фабриканың баш инженеры И. Гафуров, майор И. Мочалов, язучы Кави Нәҗми һәм башкалар чыгыш ясадылар.

Митингта катнашучылар зур күтәренкелек белән КПСС Үзәк Комитетына котлау хаты кабул иттеләр. Анда мондый юллар бар: «Коммунистлар партиясе тарафыннан мәхәббәт белән тәрбияләп үстерелгән герой-шагыйрь Муса Җәлилнең мәңгелек образы безнең барыбызга да Ватаныбызның намусы һәм даны өчен көрәштә гаять зур ныклык һәм батырлык үрнәге булып, ялкынлы патриотизм, хезмәтне чиксез сөю һәм иҗади яңу үрнәге булып хезмәт итә. Сугышчы шагыйрьнең үткен каләме үзенең көчен һәм үткенлеген беркайчан да югалтмас һәм бөек эшкә — коммунизм өчен көрәш эшенә хезмәт итүен дәвам иттерер. Шагыйрьнең героик тормышы һәм ялкынлы сүзе яшь буынны Ватаныбызга, партиябезгә, халкыбызга чын күңелдән бирелгәнлек рухында тәрбияли, дошманнарга каршы көрәштә килешмәүчәнлеккә өйрәтә.

Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исем бирелү безне аның кебек үк нык һәм батыр булырга, һәм совет халкының яхшы тормышы һәм бәхете өчен көрәшкә бөтен көчебезне бирергә рухландыра» [1].

Партия өлкә комитеты Муса Җәлил исемен мәңгеләштерү өчен әледән-әле конкрет һәм эшлекле чаралар күрде. Ул 1956 елның февралендә шагыйрь туура 50 яшь тулу уңае белән аның юбилеен үткәрергә рөхсәт сорап партия Үзәк Комитетына тәкъдим кертте. КПСС Үзәк Комитеты секретариаты үзенең 1956 ел, 26 январь карары белән бу тәкъдимне хуплап карар чыгарды. Юбилейга хәзерләнү һәм аны үткәрү өчен төзелгән комиссия председателе итеп С. Г. Батыев билгеләнә. Партия өлкә комитеты район, шәһәр, республика газеталары, «Совет әдәбияты» һәм «Совет мәктәбе» журналлары редакцияләренә Муса Җәлилнең тормышын һәм иҗатын киң пропагандаларга, Татарстан китап нәшриятына 1956 елның 1 маена татар телендә өч томлык әсәрләрен басуны тәгаенләргә, ә 1956 елның ахырына рус телендә бер томлык әсәрләрен, шагыйрьнең тормышына һәм эшчәнлегенә багышланган альбом чыгарырга куша [2]. Шагыйрь истәлеген мәңгеләштерү максатында Татар дәүләт опера һәм балет театрына Муса Җәлил исемен бирү мәсьәләсен хәл кыла [3]. Муса Җәлилнең тууына 50 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында узды. Анда Казан шәһәре предприятиеләреннән, учреждениеләреннән, уку йортларыннан вәкилләр, фән, әдәбият һәм сәнгать эшлек-

[1] «Совет Татарстаны», 1956, 5 февраль.
[2] КПССның Татарстан өлкә комитеты партия архивы, ф. 15, тасвирлама 37, эш 48, 11—12 бит.
[3] Шунда ук.

леләре җыелган иде. Тантаналы җыелышны кереш сүз белән КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре С. Г. Батыев ачты. Муса Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлы турындагы доклад белән шагыйрь Әхмәт Исхак чыкты. Җыелышта катнашучылар СССР Язучылар союзы правлениесе секретаре Марков, Тула өлкәсенең Косая Гора заводы вәкиле Миронов, башкорт язучысы К. Мәргән, Рыбин (Чкалов), Вишневский (Мари АССР), Долгов (Чувашия АССР) иптәшләрнең чыгышларын зур кызыксыну белән тыңладылар. Гослитиздат редакторы Рябинина Президиумга Муса Җәлилнең әле яңа гына Мәскәүдә рус телендә басылып чыккан китапларын бүләк итте. Башкортстан вәкиле К. Мәргән дә герой шагыйрьнең башкорт телендә чыккан китапларын тапшырды.

КПСС өлкә комитеты бюросы карарын үтәп, Таткнигоиздат 1955—1956 елларда Муса Җәлилнең татар телендә йөз басма табактан да зуррак күләмдә сайланма әсәрләренең өч томлыгын басып чыгарды. Ул республикабыз культура тормышында әһәмиятле вакыйга булды. Әдәбият белгече Нил Юзиев бу хезмәткә газетада рецензия язып, М. Җәлил иҗатының бөтен илгә һәм дөньяга таралуын ассызыклап күрсәтте. «...Герой-шагыйрьнең әсәрләре хәзер төрле телләрдә яңгырый. Аның сугыш чоры лирикасы төркмән, казакъ, башкорт, үзбәк, корея телләрендә аерым җыентык булып чыкты. Аерым шигырьләре француз, немец, инглиз, испан, поляк, венгр, румын, чех һәм башка телләргә тәрҗемә ителде. Атаклы француз язучысы Луи Арагон үткән ел Парижда басылып чыккан китабында Муса Җәлилнең исемен фашистларга каршы көрәштә геройларча һәлак булган испан язучысы Гарсиа Лорка, чех патриоты Юлиус Фучик, Франциянең милли геройлары Жак Декур, Пери белән янәшә куеп, татар шагыйренең батырлыгы һәм шигырьләре турында зур соклану белән язды. Быел шагыйрьләрнең Бельгиядә үткәрелгән өченче бөтендөнья конгрессында делегатлар М. Җәлилнең якты истәлеген аягүрә басып, кайгылы тынлыкта билгеләп үттеләр»[1].

1957 ел культурабыз тарихына янә бер шатлыклы вакыйга белән керде: СССР Министрлар Советы каршындагы әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Ленин премияләре комитеты карары нигезендә (1957 ел, апрель) «Моабит дәфтәрләре» өчен Муса Җәлилгә Ленин премиясе бирелде.

Ленин премияләре комитетының әдәбият секциясе утырышында комитет члены әдип һәм академик Мохтар Әуэзов ялкынлы чыгыш ясый. «Аның шигырьләрен укыганда,— ди ул,— кайвакыт ирексездән күздән яшьләр атылып чыга. Җәлил мең үт йөрәкле кеше булып тоела. Җәлил дә, Данко кебек, үзенең ялкынлы йөрәген факел итеп дөрләтеп, сугышның бөтен мәхшәрләре аша үтә. Шушы мәгънәдә үлемгә хөкем ителгән тоткын шагыйрьнең батырлыгын ачкан җырлары бүген бездә, аның әсәрләренә бәя бирүчеләрдә генә түгел, гомумән аның шигырьләрен укыган һәрбер укучыда һәрвакыт шушы рухтагы күркәм ассоциацияләр уятачак. Бу кеше Юлиус Фучик шикелле үк муенында үлем элмәге булган хәлдә иҗат иткән»[2].

«Муса Җәлилгә,— дип язды рус язучысы Николай Тихонов бу уңай белән,—беренче шагыйрьгә бөтенхалык Ленин премиясенең бирелүе югары гаделлек, безнең барлык шагыйрьләребез өчен югары үрнәк булды. М. Җәлилнең зур исеме — совет поэзиясенең горурлыгы һәм даны!»[3]

Республика матбугаты патриот-шагыйрьгә Ленин премиясе бирелү вакыйгасына багышлап махсус сәхифәләр чыгарды. «Мәсәлән, «Совет Татарстаны» газетасының 1957 ел, 23 апрель санында әлеге уңайдан «Җырлап үттем данлы көрәш кырын, җырлап килдем тормыш языма...» дигән сәхифәдә татар совет әдипләренең (Р. Ишморат, Ә. Исхак, Г. Кашшаф, Г. Хуҗиев, Х. Туфан, З. Мәҗитов) мәкалә һәм хатлары, аңа багышланган шигырьләре басыла, М. Җәлилнең яңа табылган берничә шигыре урнаштырыла.

1957 ел, 24 апрель. Татар дәүләт опера һәм балет театры. Шәһәр җәмәгатьчелегенең Муса Җәлилгә Ленин премиясе бирелүгә багышланган митингысы. Тантананы КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре С. Г. Батыев ача:

— Муса Җәлилгә Ленин премиясе бирелү,— ди ул,— бөтен татар совет культурасының, татар әдәбиятының һәм совет поэзиясенең зур бәйрәме. Бу — партиябез һәм хөкүмәтебезнең ленинчыл милли политикасының гүзәл чагылышы[1].

---

[1] «Совет Татарстаны», 1957, 10 январь.
[2] «Социалистик Татарстан», 1981, 14 февраль.
[3] «Казан утлары», 1966, 2 сан, 10 б.
[4] «Совет Татарстаны», 1957, 26 апрель.

Ул чакта Татарстан Язучылар Союзы идарәсе председателе Г. Бәширов аны куәтләп болай ди: ...Бу — безнең бөтен культурабыз өчен шатлыклы бәйрәм. Герой-шагыйрьнең иҗат батырлыгына югары бәя бирелүе меңнәрчә совет кешеләре һәм барлык әдәбият җәмәгатьчелеге шатлык белән билгеләп үтә... Төрмә рәшәткәсе аша ул үзенең туган илен күрә, халкының җиңүен якынайту өчен көрәшә, гүзәл шигырьләрдә халык хисләрен һәм омтылышларын зур осталык белән чагылдыра. Менә шуңа күрә дә аның әсәрләре безне дулкынландыра, укучыда матур хисләр уята, халыкны кара көчләргә, вәхши фашистларга каршы көрәшкә чакыра... Илебез сәнгатенең күренекле вәкилләре С. Т. Коненков, Л. М. Леонов, С. С. Прокофьев, Г. С. Уланова белән бергә татар совет шагыйре Муса Җәлилгә Ленин премиясе бирелү — безнең барыбыз өчен дә зур шатлык [1].

Шуннан соңгы чыгышлардан да кайбер истәлекле юлларны китерик.

Казан мех комбинаты эшчесе М. Хәмидуллин:

— ...Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме бирелү — аның хәрби батырлыгын бөтен халык тарафыннан тану булса, Ленин премиясе бирелү — аның бай иҗатын, совет поэзиясе фондына энҗе булып кергән гүзәл шигырьләрен югары бәяләү ул.

Советлар Союзы Герое Л. Агиев:

— Патриот-шагыйрь Муса Җәлил сугыш кырында да, иҗаты белән дә онытылмас батырлык күрсәтте һәм дан казанды. Ул фашист төрмәсендә дә — иң авыр шартларда да дошманга каршы көрәшен дәвам иттерде, совет поэзиясендә мактаулы урын алырлык тирән эчтәлекле һәм югары художестволы әсәрләр язды. Болар бар да совет кешеләрен яңа батырлыкларга рухландыралар.

ТАССРның халык артисткасы В. Павлова сәхнәгә чыгып Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәр»еннән «Вәхшәт» шигырен укый. Газиз аналарны, балаларны вәхшиләрчә үтергән фашистларга утлы нәфрәт хисе белән тулы көчле шигъри юллар тагын бер кат күңелләрне тетрәтә:

**Күтәр, илем, хаклык байрагыңны**
**Буяп җирнең канлы яшенә,**
**Үлем булсын нуры, ана канын,**
**Бала канын эчкән вәхшигә!** [2]

Казан дәүләт университеты студенткасы Нәзриева:

— ...Татар халкының бөек улы Муса Җәлил — совет кешесенең нинди каһарманлыкларга сәләтле булуын күрсәтүче маяк ул. Без аның батырлыгын бөтен совет яшьләре өчен бөек үрнәк дип саныйбыз. ...Сөекле шагыйребезгә күрсәтелгән зур хөрмәт өчен партиябезгә һәм хөкүмәтебезгә чын күңелдән рәхмәт белдерәбез...

Соңыннан В. И. Качалов исемендәге Зур драма театры артистлары Н. Проваторов, И. Загорский, Р. Пестовскийлар башкаруында «Үлмәс җыр» спектакленнән өзек уйнала. Шагыйрь С. Хәким Муса Җәлилгә багышлап язган «Бер язмышта туган дуслык» шигырен укый, Ә. Давыдов Муса Җәлилнең батыр көрәшче һәм шигырь остасы булуы турында сөйли, опера театры артистлары Н. Җиһановның «Җәлил» операсыннан өзекләр башкардылар.

КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы 1955 елның ноябрь аенда «1957 елда Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы үткәрү турында» карар кабул иттеләр. Шул уңай белән КПСС өлкә комитеты бюросы һәм ТАССР Министрлар Советы карары чыкты. Бу документта Мәскәүдә декада үткәрү — совет Татарстанының формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культурасын үстерү турында Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте кайгыртуының яңа чагылышы дип күрсәтелә [3].

1957 елның май-июнь айларында Мәскәүдә уздырылган татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы Татарстан хезмәт ияләренең культура өлкәсендә ирешкән уңышларына

[1] «Совет Татарстаны», 1957, 26 апрель.
[2] Том 2, 182 б.
[3] Культурное строительство в Татарии, 206—208 б.

смотр булды. Анда, әйтерсең лә, М. Җәлил дә катнашты. Күп санлы очрашуларда аның әсәрләре яңгырады, Мәскәү җәмәгатьчелеге аларны алкышлап каршылады. «Җәлил» операсы күрсәтелде. Нәҗип Җиһанов «Җәлил»е «татар халкының данлы улы, коммунист, Ватаныбызның патриоты, Советлар Союзы Герое һәм Ленин премиясе лауреаты шагыйрь Муса Җәлилнең мәңгелек батырлыгын сурәтли»[1], дип язды «Правда» газетасы.

Без М. Җәлилнең исемен мәңгеләштерү өчен партия күргән чараларны, «яралангән, ләкин тар коллыкта баш имәгән керсез йөрәкле» көрәшченең эшчәнлеген пропагандалау формаларын күздән кичердек.

Француз язучысы Луи Арагон әйткәнчә, Муса Җәлил «үзенең һәрбер туганы — Казандагы һәм Новосибирскидагы, Одессадагы һәм Самаркандтагы, Владивостоктагы һәм Ленинградтагы, Тбилисидагы һәм Ригадагы туганнары өчен үлде. Ул шулай ук безнең өчен — французлар яки чехлар өчен дә үлде»[2].

Аның данлы исеме, гомерлек поэзиясе хәзер бик күп телләрдә яңгырый. Ул ялкынлы җырлары белән безнең белән бер сафта атлый һәм тынычлык өчен көрәшә. М. Җәлил исемен шәһәр урамнары, поселоклар, колхоз, совхозлар, мәктәпләр, пионер отрядлары, пароходлар йөртә. Ул көрәш һәм җиңү символына әверелде. Л. И. Брежнев әйткәнчә, «генерал Дмитрий Михайлович Карбышевның, шагыйрь Муса Җәлилнең, безнең Ватаныбыздан читләрдәге антифашистик көрәш геройлары... исемнәре безнең хәтеребездә һәрвакыт совет кешесенең какшамас ихтыяры һәм ныклыгы символы булып торыр»[3].

---

[1] «Правда», 1957, 31 май.
[2] Муса турында истәлекләр. Казан, 1964, 294 б.
[3] Л. И. Брежнев. Ленин юлыннан. Речьләр һәм мәкаләләр. 1 т. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1972, 142 б.

Салих Маннапов

# ХӘТЕР

*Сезнең онытырга хакыгыз юк, аңлыйсызмы?..*

Ә. Еники «Әйтелмәгән васыять»

Мин инде аны күрермен дип уйламаган идем. Күпме сулар аккан... Ә ул әнә, катлы-катлы итәк-чабуларын җыештыра-җыештыра, иреннәрен үзалдына нидер сөйләгән дә, җырлаган да сыман кыймылдатып, болдыр баскычыннан менеп килә...

Әдрәпи әбинең килеш-килбәтендә иң әсәрткәне — шомырт тамырыдай кара бармакларыннан да, аларга сырышкан саргылт балдакларыннан да бигрәк, әнә шулай, җәй чилләсендә кәбестә кебек кат-кат киенеп йөрүе иде. Итәкләренә басып абынмас өченмедер, ул бик вак атлый, әмма шактый җир китәргә өлгерә. Өй борынча хәл белешеп йөри дә, авыл биргән күчтәнәч-төенчекләрен күтәреп, олы юл ягына китеп югала. Атналар-айлар узгач, кайсыдыр хәбәр ишетеп кайта: «Имеш, Чистай юлында теге буранлы көнне туңып үлгән икән»,— ди... Янсә: «Юк, үлмәгән, каядыр Ташкент якларына китеп югалган»,— дип сөйлиләр. Карчыклар: «Мескен,— диләр,— адашкан шул инде»,— диләр, күз яшьләрен сөртәләр.

Без, малайларга, ул чакта әле аңлашылып җитми: ничек адашты икән, кайда адашты икән Әдрәпи әби? Төртмешрәк теллеләр аның турында «җиңел Аграфинья» дип ычкындыргаласалар да, килеш-килбәте белән бик сәер булса да, ул бит үзе дә ике сүзнең бере итеп: «Адашканмын шул мин... Адашып ла калганмын!» — ди.

Инде онытылып барганда гына, авылда янә «Әдрәпи килгән!» — дигән хәбәр тарала. Үлмәгән дә, югалмаган да икән. Иң күңелле вакытка — туйгамы, бәйрәмгәме махсус туры китергәндәй, ул үзенең дөньяда икәнлеген белдерә. Әдрәпи әбинең яңадан килеп чыгуы бөтен вакыйгалардан да мөһимрәк булып тоела башлый: аның шулай безне онытмавы, читләтеп үтмәве авылның дәрәҗәсен арттыра кебек. Ул олысын-кечесен танып, исемнәре белән эндәшә, әллә кайчан үлеп беткән авылдашлар турында сораша. Үзе һаман: «Мин адашканмын шул... Әле дә булса үзебезнең авылны, нәнәмне таба алмыйм бит!» — дип такмаклый.

Әдрәпи әбинең кайсы авылдан икәнлеген төгәл генә белүче дә юк шикелле. Күрәсең, ул билгеле бер вакыт эчендә җиргә әйләнеп кайтучы койрыклы йолдыз төсле, шактый ерактан, бик күп авыллар аша үтеп киләдер... Бәлки әле үз авылында, үз йортында да шулай кунак буладыр,— бары исенә генә төшерә алмый китә торгандыр...

Еллар үткәч, Әдрәпи әби белән шушы очрашу мине әллә ничек сискәндереп, уятып җибәрде: кадерле хатирәләрнең җуела башлавын, балачак сукмакларыннан, бабайлар кабереннән аерыла баруымны искәрткәндәй булды ул. Кешенең кыска хәтерлегә әйләнүе, үткәнен һәм нәсел-нәсәбен онытуы белән әлеге шул зиһене адашкан карчык фаҗигасе арасында коточкыч уртаклык бар икән ләбаса!

Кешелек тарихында хәтер тамырына балта чабуның күп кенә мисаллары бил геле. Халык кадәр халыкның үз тарихын, исемен, хәтта телен җуйган очраклар... Фашизмның кешеләрне номерлар белән алыштырырга, аларны туган ил белән то таштыручы күперләрне яндырырга маташуы...

Ләкин хәтернең тамырын корытуы җиңел түгел. Кешеләр, окоп эзләре тигез ләнгәч тә, сугыш мәхшәрендә югалткан туганнарын эзләп табалар. Хәтта тыныч көннәрдә үзләрен язмыш иркенә ташлап киткән качкын әтиләрен күрәселәре ки лә... Ике арага үз ихтыярлары белән ясалма киртә корган ата-аналарын аңларга теләп, туган телләрен өйрәнергә азапланалар... Әйтелмәгән насыяте калган Акъэби нең «Я — башкирин, бабушка, башкирин!» — дип күкрәк кагучы внукасы Геннадий сыман...

Хәтерсезлекнең төрле сурәтләрен чагылдыра безнең әдәбият. Бер карыйсың ул — Илдар Юзеевның «Сандугачлар килгән безгә» әсәрендәге урман каравылчысы Сәер чиргә сабышкан Хәмзин. Икенче карыйсың — махсус аппаратлар белән зиһе не юдырылган «ярымкешеләр» (Адлер Тимергалинның «Роберт, уян, сөеклем!» исемле бер хыялый хикәясендә). Мондый күренешләр, адәм баласының табигатенә чит булганга күрә, ак җирлектәге кара табыдай күзгә бәрелеп тора, игътибарны җәлеп итә, уйландыра. Әх, шулай авырулар галәмендә дә, фантастикада гына бул сачы ул онытучанлык галәмәте!..

Хәтер метафорасы безне тормышның нинди катламнарына алып керә, кеше күңеленең кайсы караңгы почмакларын яктыртып җибәрә соң? Әдипләребезнең әледән-әле артка әйләнеп карый башлавы ни белән бәйләнгән?

Бу сорауларга җавап эзләгәндә, сүзне һәркайсыбызның исендә калган әсәрләр мисалында дәвам итү урынлырак булыр кебек тоела. Чөнки тулы, әтрафлы анализ ясау ихтыяҗы калмаганда, берьяклы күренүдән тарсынмыйча, без хәтерне тормыш та төп таяну ноктасы итеп таныган геройларга да, дүңгәләк кебек җирсез-тамыр сыз бәндәләргә дә текәлебрәк карый алырбыз.

Халык үзенең әкият-мәзәкләрендә дә, җиде диңгез артына китсә дә, туган илен, асылын җуймаган каһарманнарны данлый, ә аз-маз читтә йөреп кайткач тырма ның да исемен «исенә төшерә алмаган» әтрәк-әләмнәрне хур итә.

Абиш Кекильбаев һәм соңрак Чыңгыз Айтматов әсәрләренә килеп кергән ка ·акъ риваяте, мәсәлән, хәтереннән мәхрүм калган адәм баласының кешелеклеген дә югалтуы турында сөйли.

Сарүзәк далаларын басып алган жуаньҗуаннар рәхимсез сынау уйлап табалар: такыр итеп кырылган башларына яңа суелган дөя тиресе ябыштырып, әсирләрне эссе кояш астына ташлыйлар. Чәчләре, тыгыз чи тирегә үтеп керә алмыйча, боры лып, кире баш эченә таба үсә. Бу газаптан исән калган зат үзенең кемлеген дә хәтерләмәүче, хуҗасының гына әмеренә буйсынучы колга — манкортка әйләнә. Аны инде әсирлектән коткару да мәгънәсез. Найман ыругыннан бер ана гына үзе нең улын бу афәтле язмыштан коткарырга, аның үлгән зиһенен уятырга тели. Ай һай, юкка гына!.. Манкорт энисен танымый, хуҗасының боерыгын үтәп, аның йө рәгенә ук ата. Найман-ананың башыннан ак яулыгы шуып төшә, ул ак канатлы кошка әйләнеп, кычкыра-кычкыра очып китә: «Исеңә төшер: син кем баласы? Исемең ничек синең?!» — дип кычкыра ул...

Манкорт турындагы риваять мине балачагым хатирәләре белән бергә буталып тетрәндерде. Авылын оныткан Әдрәпи әби язмышыннан мең мәртәбә куркынычрак булуы белән. Яшәешнең гасырларга киткән тамырларын ачып җибәрүе, илләр һәм халыклар язмышын колачлап алуы белән.

Заманалар буталышында, хәтер чоңгылларында адашып-иләсләнеп калган кар чык белән ятлар тарафыннан хәтере урланган манкорт арасында турыдан-туры уртаклык эзләмим. Әмма ыруыннан, энисеннән аерылган манкорт та, безнең Әд рәпи әби кебек, илдән-илгә каңгырып йөргәндер һәм «безне адаштырганнар шул... Адаштырганнар безне!» — дип сыктагандыр кебек.

Манкорт хакындагы риваять, Айтматов әсәренең[1] идея үзәгенә әверелеп, Җир һәм Галәм бәйланышларын сурәтләгән «космик миф» белән янәшә куела. Ракета

[1] Чингиз Айтматов. Буранный полустанок (И дольше века длится день). М., «Молодая гвардия», 1981.

күтәрелгәндә бөркелгән ут йомгагыннан ак кош аерылып калгандай һәм җир кешесенә: «Кем баласы син? Исемеңне хәтерлә!» дип кычкыргандай була. Романның бөтен агышы Җир язмышы, кешелекнең киләчәге турында кайгыртуга юнәлдерелгән. Манкорт турындагы риваять безгә: адәм баласының хәтереннән мәхрүм калуы — очраклылык һәм язмыш колына әверелүе ул, дип искәртсә, галәм белән бәйле киләчәк хикәяте исә шуңа өстәп үз кисәтүен белдерә: кеше, галәмдәге ят цивилизацияләр белән аралаша башлаганда да, үзенең тарихын һәм гасырлар дәвамында тупланган әхлакый тәҗрибәсен югалтмаска тиеш.

Манкортлык һәр адымда — хәлиткеч булганда да, әһәмиятсез генә тоелган хәрәкәттә дә күренергә мөмкин. Акъәбинең отставкадагы улы — үзенең үлеп баручы анасын: «Ну, ничего, тулке син паникага бирелмә», — дип юатырга азапланучы солдафон — имән муенлы, йомры башлы Суфиян, мәсәлән, шундый манкортларның берсе булырга охшаган. Ул әни дигән изге җан иясенә кадер-хөрмәт күрсәтүне онытып, кешелеклелеген үтергән — үз ихтыяры белән «чи тире киган.» Шуңа күрә Суфиян манкортка караганда да кызганычрак һәм куркынычрак.

Без манкортны әнисен үтергән өчен гаепли алмыйбыз. Үзенең үткәненнән ваз кичәргә мәҗбүр ителгән әсирнең бу адымы табигый һәм ихтыярсыз. Үлем түшәгендә яткан әниләре белән рәтләп сөйләшергә, аның васыятен тыңларга да теләмәгән балаларның хәтерен кем кискән соң? Алар әхлаклылыкның, тәрбиялелекнең нәрсә икәнен бик яхшы беләләр. Валентин Распутинның «Соңгы срок» әсәрендәге[1] Анна әбинең балалары да, әнә, кыяфәтләре, үз-үзләрен тотышлары белән бик зыялылар югыйсә. Әҗәлен көткән әниләренең һәр сүзеннән кызык табып, «Үлем турында сөйләп туйдырдың инде!» дип, көлә-көлә китеп баралар. «Үләмен мин, үләмен. Менә күрерсез. Бүген үк. Көтегез инде чемчек кенә, көтегез инде. Бүтән бернәстә дә кирәкми миңа»,— дип өзгәләнә карчык.

Акъәби дә, Анна карчык та бәгырь җимешләрен шәфкатьле булырга, кеше хәленә керә белергә өйрәткәннәр; бүген алар муллыкта яшәүче, җәмгыять тудырган мөмкинлекләрне икекуллап үз тарафларына юнәлтүче балалары шул сыйфатларын җуя бармаслармы дип борчылалар. Бу борчылу хисе, кырыс чынбарлык Әмирхан Еники белән В. Распутинны бер сызыкка — кеше тормышындагы иң фаҗигале хәлне — кешеләр арасындагы изге мөнәсәбәтләрнең таркалуын сурәтләүгә алып чыккан. Тамакка утлы төер утыртырлык язмышлар. Ләкин кешенең кайгысы түгел, яхшылыгы күзгә яшь китерә. Эшләнми калган игелек, тирән үкенеч тойгысы белән җәзалыйлар алар үзләренең ваемсыз геройларын. Бу геройлар чын бәһаны, белек һәм акыл көченнән дә бигрәк, кылган эшләренең әхлакый кыйммәтеннән чыгып алалар. Әлеге әсәрләрдән безгә: «Кыска хәтерле булмагыз, рухи һәм әхлакый сафлык чыганакларына юлны онытмагыз!» дигән өндәү авазы ишетелә. Бер өндәү генә дә түгел... Үзенең үткәненнән йөз чөереп кенә «кеше» булырга маташкан бәндәләр — мотлак өметсез: иң җаваплы мәлдә алар иманын — Илен дә сатарга сәләтлеләр, дип кисәтү.

«Әйтелмәгән васыять», Шәриф Хөсәеновның «Әни килде», Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән» әсәрләре — кыска хәтерле балаларны гаепләү генә түгел, алар — олы җанлы аналарга мәдхия дә. Ана белән бала мөнәсәбәтләрендә адәм баласының кешелеклелек тамыры, дөнья белән иң садә, иң тотрыклы бәйләнеше ачыла. Сафлыкка, ихласлыкка кайтырга чакыру, туганлык-кардәшлек элемтәләрен ныгытырга өндәү әсәрдән-әсәргә көчлерәк яңгыраш ала. Ана, Илдар Юзеевның «Соңгы сынау», Егор Исаевның «Хәтер хөкеме» поэмаларындагыча, метафорик мәгънәдә — Хәтер, Намус гәүдәләнеше булып күз алдына килә башлый. Ана образы артыннан халыкның рухи хәзинәсе, гореф-гадәтләре, тарихы, тормыш фәлсәфәсе күтәрелә.

Шундый әсәрләрнең берсе — Сибгат Хәкимнең «Васыятьләр» поэмасы. Олы төшенчәләрне уртак ясслыкта берләштереп, киң колачлы гомумиләштерүләргә омтылган әсәр. Вәхиләшү һәм мәхәббәт поэмасы. Соңгы йотым суын эчүче ананың яшәүдән, тормыштан туймавын һәм аның соңгы сүзләрен, соңгы күз карашын кү-

---

[1] Валентин Распутин. Повести. М., «Молодая гвардия», 1980.

целеннән кичереп утыручы улының әнисенә мәхәббәте... Изге тарих һәм хатирәләр яктысы, тигез янган унлы лампа уты сыман, бу йортны, бу әсәрне әчтән балкытып тора. Ана васыяте һәм Ленинның әйтеп яздырган соңгы хатлары, шул җирлектә халыкның сәламәт җанына һәм матур киләчәгенә ышаныч. Бу ышаныч хатирәләр белән генә түгел, халык иҗаты рухы белән дә беркетелә, ул ана, ил һәм халык төшенчәләренең аерылгысыз бөтенлеген раслый.

Ана төшенчәсе белән Ватан төшенчәсе риваятьләрдән үк бергә үрелеп килә. Муса Җәлилнең «Алтынчәч» либреттосындагы тугыз баһадирны үстергән Тугзак-ананы гына искә төшерик. Туган илен ятлар таптаганда табигать-ана кочагында үссә дә, Җик-мәргән үзенең ата-анасын, нәселен эзләп Тугзак әргәсенә кайта. Баскыннарны илдән куарлык көч аңа табигатьтән генә килми, ул әти-әнисе, агалары каны коелган туган туфракка таяна, нинди михнәтләр күрсә дә иленнән язмаган Тугзак-анадан фатиха ала.

Икенче бер әсәрендә Җәлил, киресенчә, ананың үзе үстергән кыю улларына таянуы, алар белән горурлануына басым ясый («Ана бәйрәме»). Бу очрак та шагыйрьнең халык иҗатына, мәшһүр Йосыф кыйссасына, Көнчыгыш әдәбиятында ананы, хатын-кызны тереклек чишмәсе итеп тасвирлау традицияләренә мөрәҗәгать итүе белән кызыклы.

Җәлил иҗатының үзәгендә анага һәйкәл тора. Ул һәйкәлнең нигезендәге иң тере чәчәк — Рәхимә апаның балаларына атап чыгарган шигъри хаты — васыяте... Димәк, Җәлил турында күпчелек әсәрләрдә шагыйрьнең иң хәлиткеч мизгелдә әнисен искә төшерүен сурәтләү һич тә очраклы хәл булмаска тиеш. Туфан Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» драмасында да, Илдар Юзеевның «Соңгы сынау» драматик поэмасында да бу алым аша шагыйрьнең тап төшмәгән намусы белән күзгә-күз калуы гәүдәләндерелә. Үлем алдыннан гына Җәлилне көчле һәм мәкерле Мефистофель тормышының иң газиз мизгелләренә — балачакка, яшүсмер елләрга кайтара. Иблис аны иң авыр газапка дучар итә — хәтер уты белән яндырып сыный. Шагыйрь үзенең үткән юлын күз алдыннан кичерә. Ләкин бу — чигенү түгел, үзен үлемгә алып килсә дә, Ватан өчен, киләчәк өчен көрәштән хасил булган тормыш юлы белән горурлану. Мефистофельнең киләчәк көннәрне дәһшәтле буяуларга манып өркетергә теләве дә шуңа күрә куркыта алмый аны.

Шагыйрьнең какшамас рухи көче бер сайланган юлына тугрылыклы булып калуда, хатирәләр тамырының тирәнлегендә һәм ныклыгында. Ул үзенең бөтен асылы белән туган халкыннан, тарихыннан үсеп чыккан, Алып батырлардан, Алпамышлардан көч алган. Җәлилне шул көч, Ватан һәм тарих алдындагы җаваплылык тигезсез көрәш мәйданына рухландыра, үлем яки хыянәт дигән соңгы чатта үлемсезлек юлыннан алып китә. Шагыйрь үлем турында уйламый булдыралмый, үлем турындагы уй — аның үткән юлын һәм Җиһүдән соң булачак тормышыны күз алдына китерүендә дә. Ләкин... вариантлар юк! Илгә кайту юлы бер генә. Шагыйрьнең бөтен тормышы, аның рухи паспорты — «Моабит дәфтәрләре», монологлардан торган бу оптимистик трагедия, «кеше гомеренең мәгънәсе һәм үлемсез дәвамы — башкалар хәтерендә, ил хәтерендә яшәү», дигән ышаныч белән сугарылган: «Эш күрсәткән ирне ил онытмас!»

Яшәү белән үлемсезлек арасындагы хәтер күпере, менә шул рәвешле, героик язмыш, сугышчан шигърият мисалында абайлана, һәм бүгенге әдәбиятта әлеге төшенчәләр тагын да тирәнәя, яңа яктан ачыла бара.

Вак мәнфәгатьләргә күмелеп, «кешечә яшәп калырга» тырыша-тырыша, рухи үлемсезлеккә ышанмый башладык түгелме? Үлем-җитем хәлләре эш арасындагы бер мероприятие, күздә тотылмаган бер чыгым гына булып тоела башламадымы? «Нишлисең, үләргә булгач кайда да барыбер... Өйдән мәет озату бик авыр, бик мәшәкатьле эш ул», — дип уфыралар Акъэбинең якын кешеләре. Ч. Айтматов романындагы Казангапның укымышлы улы Сабитҗан әтисен кая, ничек күмсәләр дә риза — ерак барасы булмасын да, тизрәк башкарып кайтасы булсын. Акъэбине җирләгәннән соң телләренә бер юньле сүз килмәгән Суфияннар кебек үк, Айтматовның Шәймәрдәне дә үзен бик авыр хәлдә хис итә: «Димәген ки, Казангап карт нитеп нитте инде! Димәген ки, үзенең юлын, теге ни, ну, фаразан, төгәлләде инде», — дип авыз эчендә ботка пешерә. Болар өчен үткән ни дә, хәтер ни. Вафат

булган кешене кая куярга да белмиләр. Ә бит халыкның гади генә йолаларына да нинди тылсымлы көч салынган! Аларның үз драматургиясе бар, житди мәгънәсе бар. Женаза йоласына да үлгәннәрдән бигрәк исәннәр мохтаж.

«Мәңгелек йорт»ка китүчене җир куенына тапшырыр алдыннан, ил картларыннан берәү, үз-үзенә эндәшкәндәй генә сәаль бирә:

— ...Нинди кеше иде?..

Җавап — аны һәркем үзалдына гына кабатлый — акрын, тыныч, саллы, — шыбырдап җиңел туфрак коелгандай:

— Әйбәт кеше иде.

Дөнья йортыннан күчкән кешесенә авылның бәясе шундый. Бер сүз белән.

Суфияннарга, Сабитҗаннарга, киткәндә, кем әйтер шушы сүзне? Алар өчен бит кеше үлгәнче генә бәяле. Идегәй карт сүзләре белән әйткәндә, «Аларга үлем һичнни түгел икән, тормышның да бәһасе юк булып чыга бит». Шулай итеп, яшәү мәгънәсе, аерым кеше һәм буыннар хәтере турындагы катлаулы мәсьәләләргә таба янә бер борылыш ясала. Кешенең рухи асылы ачылып китә торган мөһим борылышларның берсе. Истәлек алымы белән язылган әсәрләрнең уңышы, нигездә, әлеге шул борылышны табу-тапмаудан тора. Хәтер көче аларда тасвир алымы гына, хәтта тема яки аерым проблема гына да булып калмыйча, әсәрнең һәр күзәнәген хасил итүче, «төзүче» вазифасын башкара.

Әдәбиятыбыз тарихында, халык иҗаты җәүһәрләрендә бу көчне сыйфатлаучы төп билге — сагыну хисенең дәрәҗәсе. Туган якка, якын кешеләренә җан тартуы аларны онытмау һәм юксыну тойгысы... — Ул сабыр сагыш, уйлап карасаң, «Сак-Сок» бәетләреннән үк киләдер әле. Зур дөнья, катлаулы тарих җирлегендә сагыну тойгысы үзе дә күп катламлы, күп төсмерле. Рекрут, әсир, зимагур көйләре, «Кара урман» кебек моң чишмәләре авыр язмышка әчке протест, аны каһәрләү булып яңгыраган.

Туган-үскән туфрак турындагы хатирә кешене һәрвакыт бәрәкәтле хәрәкәткә, көрәшкә ымсындырып тора. Хәтта җиңелү белән тәмамланса да, бу көрәшнең төп юнәлеше — үз асылыңа кайтырга омтылу теләге — югалмый. Кайвакыт ул адәм баласының иң соңгы, бердәнбер юлы булып чыга.

Мәмлүк солтаны Бәйбарс турында Морис Симашконың «Әрем» исемле мәгълүм повестенда [1], мәсәлән, Мисыр тәхетен яулаган кодрәтле солтанга да язмыш шундый бердәнбер мөмкинлек калдырган. Илен, тудырган әнисен хәтерләми Бәйбарс. Тик... дан-дәрәҗәгә ирештем дигәч кенә... Үз куллары белән ятимә һәм кол иткән кыз баланың төшләнеп елавын ишеткәч... Шәфкатьсез хаким кинәт барысын да исенә төшерә: атасының монгол яуларыннан һәлак булуы, үзенең кол ителеп сабый чагыннан ук дала куеныннан аерылганлыгын... Кыпчак даласының җанга якын әче әрем исен! Бөек Бәйбарсны шул хатирә, тәхетен һәм байлыгын ташлап, ач далага — туган туфрагын эзләп китәргә мәҗбүр итә.

«... Тау битендәге үләннәрне селкетеп-тарап җылы гына җил исә. Ачы әрем исен китерә ул миңа — туган туфрак исен... Коры җирдә, эссе кояшта үскән ак әрем исе бик үткен була... Үзгәрми һәм бетми торган ис ул минем өчен!» Ә. Еникинең «Соңгы китабы» (беренче өлеше) менә шул сүзләр белән ябыла. Хәтер — үткән заманнар сөземтәсе генә түгел, кешенең бүген үз-үзен тотышына, киләчәктә кыласы эшләренә алшарт, нигез, сәбәпче дә икән ул.

Безнең заманда сагыну-җирсү халәте, нигездә, якты хисләр, кешелекле мөнәсәбәтләр чыганагына әверелә. Шуңа күрә, истәлек алымы белән язылган әсәрләр үткән көн күләгәсеннән аерыла алмау, борынгыны сагынып сыктау түгел, халыкның күңелендә, көнкүрешендә, кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләрдә тупланган бай хәзинәгә мөрәҗәгать итү булып аңлашыла. Әнә, Мөхәммәт Мәһдиевнең шәп йөрүче Зәкәрҗаны, улы үлгәч иләсләнеп калган Әсма карчыгы, яисә «артист» Гаптыр-Габдерәкыйпләре, аларның сүз тәмен белеп, «сайландырып» сөйләшергә яратулары... Без аларны баштарак кына, күрешкәнче генә ятсынып торганбыз икән: кабатланмас чырайлы Зәкәрҗаннар, Хәдичәттиләр безнең якыннарыбызны, авылдашларыбызны, танышларыбызны хәтерләтә башлыйлар. Язучы конкрет об-

[1] Морис Симашко. Маздак. Повести черных и красных песков. М., «Известия», 1979, 241—273 битләр.

разлардан, шәхси дөньялардан, алардагы кырыкмаса-кырык төрле мәшәкатьләрне тасвирлаудан киңрәк гомумиләштерүләргә алып чыга: җирне, ата-бабалар тәҗрибәсен онытмаска чакыра. Ул үзе дә иҗатының һәр яңа баскычында туган төбәгенә әйләнеп кайта, анда рентген кәгазендәге кебек яктырып калган яшьлек хатирәләрен барлый — «яшьлеген сагына». Туган як — әдипнең таяну ноктасы да, төп юнәлешен билгеләүче кыйбласы да.

Авыл — безнең өчен аеруча кадерле: ул әхлак һәм гадәт кагыйдәләребезне, эстетик культура традицияләребезне саклаучы күңел сандыгы. Анда туган тел чишмәләре аеруча саф көе саклана. Авылны искә төшергәндә андагы чикләнгәнлеккә дә күз йомарга ярамый. Шул ук вакытта бу — икенче чиккә ташлану булмаска тиеш.

Борынгы һәм бүгенге тормышны иҗтимагый-яшәү шартлары җирлегендә чагыштырып язылган әсәрләр — истәлек-повестьлар, истәлек-романнар безне менә шушы берьяклылыктан да саклау максатын куялар шикелле. Аларда авылның тарихи үткәнен һәм яңа шартлардагы үсешен аңларга омтылу өстенлек ала. Билгеле, төрле әсәрдә — төрле дәрәҗәдә, сүз төп тенденцияләр турында гына бара!

Салам түбәләр, сукыр лампаларның онытылуы түгел, коендырган суы белән бергә баласын да чыгарып ташлаган кебек, кыйммәтле рухи хәзинәнең югалу ихтималы борчый әдипләребезне. Ана сөте белән кергән хезмәт сөючәнлек, гаилә кануннары, туганлык һәм күршелек мөнәсәбәтләре, табигать белән якын кардәшлекне тою... «Табигать һәм кеше» — асылда, табигатьне кешедән сакларга кирәк дигән фикергә иллюстрацияләр генә китерүче модалы рубрика түгел. Табигатьне саклау безнең өчен иң беренче чиратта киләчәк буыннар каршында җаваплылыкны онытмау, тормыш табигыйлеген, кеше табигатенең сафлыгын саклау булып аңлашыла. Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә»ләрендә, Илдар Юзеев геройларының Тимер кешеләр белән көрәшендә, хәтта Аяз Гыйләҗевның «урман үзебезнеке» дигән кинаясендә дә — бу шулай: җирдән, традицияләрдән аерылу нәтиҗәсендә кеше тормышының табигый бөтенлеге, табигый тәсләре җуела баруы — бүгенге көннең һәм бүгенге әдәбиятның төп мәсьәләләреннән берсе дип тану. Бүгенге дисәк тә, шәхеснең рухи дөньясына шәһәр һавасының, цивилизациянең йогынтысы турында элек тә аз уйланмаганнар (Ф. Достоевский яисә Л. Толстой фәлсәфәсен, Такташның 20 нче еллардагы иҗатын искә төшерик). Һәр табыш нәрсәнедер югалту хисабына бара... Бу җәһәттән караганда, авылның үткәнен бизәп күрсәтү дигән дежур гаепләү дә көчсез булып кала. Киләчәккә карап шөкер итү, иртәгәгә карап фикер йөртү тарихның үз агышы белән билгеләнә. Яңа җәмгыять кешесен тәрбияләүче әдәбият искегә изге итеп табынмаган кебек, тамырны инкарь итүгә дә өнди алмый. Чөнки тарихка, бигрәк тә культура тарихына марксистик-ленинчыл мөнәсәбәт җитеп бетмәгән очракларның нигезендә югалтулар бәрабәренә булуы истә әле.

«Авыл прозасы» турында бәхәсләшүчеләр арасында хәзер: «Үткәнгә тиешле хөрмәтне күрсәттек, — җитте. Инде авылның бүгенге хәленә игътибарны тупларга кирәк», — дип чакыру көчлерәк яңгырый башлады. (Мәсәлән, «Вопросы литературы» журналының 1981 елгы 5 санында Игорь Шайтанов мәкаләсе). Төп мәгънәсен генә алганда, үткән белән бүгенгене каршы кую ягыннан бу фикернең бик иске булуы ярылып ята. Шул ук вакытта анда үзенчә хаклык та бар. Автобиографик әсәрләр белән мавыгу нәтиҗәсендә утыз-кырык ел элек булган авыл сурәте төрле вариантларда кабатлана башлады. Илленче еллардагы колхозны бераз сипләп кенә «бүгенге» дип күрсәтергә тырышу мисаллары да борчый. Хәтер көчле — яңа авыл түренә әллә кайчан хәл ителгән проблема менә дә утыра. Суы-газы килгән зур колхозда янгын сүндерү өчен куелган иске мичкә сыман. Үткән белән бүгенгене чәкәләштерергә мөмкинлек калуы тагын шул хакта сөйли: искә төшерү алымына нигезләнгән әсәрләрдә дә, хәтер проблемасын зур итеп куйган әсәрләрдә дә халык яшәешен тормышның тирән агымы белән бәйләп, колачлы итеп сурәтләү җитеп бетми әле. Бу фикерне, элекке студенты булуымнан һәм иҗатын ярату-ымнан файдаланып, Мөхәммәт Мәһдиев мисалында гына ачыклап үтәрмен, ахры.

Тормышчан конкретлыгы һәм шигъри җегәре белән, минемчә, бигрәк тә В. Астафьевка якын торган әдипнең гадәттә сюжет корудагы кимчелекләре телгә алына

иде. Ул шуннан соң «сюжет корып» күрсәтте шикелле инде. Шулай да Мәһдиевның көче — сюжетта түгел, табигыйлегендә, самимилегендә, җирдән килүендә. Аның язганнары — кеше хәтеренең гаҗәеп бер формага керүе. Ул әсәрләрнең кешелек тарихына кереп калган хәлләр һәм шәхесләр турында түгел, гап-гади авылның, гап-гади Әркәшләре һәм Хәдичәттиләре турында икәнлеген дә беләбез. Ә менә алардагы драматик киеренкелекне берни дә йомшарта алмый: сурәтләнгән вакыйгаларның гадәтилеге һәм кыскалыгы да, геройларыннан һәрвакыт диярлек мыек астыннан гына көлеп торуы да. Хәтта — әлеге дә баягы сюжет (дөресрәге, фабула) дигән нәрсәгә исе китмичә, укучыны үзе теләгән якка борып йөртүе — аны әчке сюжетка буйсындыруы да. Әгәр болар кимчелек саналса, «Без кырык беренче ел балалары»ндагы, «Торналар төшкән җирдә»ге үзәк өзгеч моңга фальшь, ялгыш нота керми калмас иде, мөгаен.

Нәрсә җитми соң бу — «хәтерләүче проза»га? Минемчә, тормышның үзе кебек күпкатламлылыкка, күпмәгънәлелеккә омтылу җитеп бетми. Хәзергә ул бик ачык һәм җанга якын курай көен хәтерләтә. Аның моңы кеше хәтеренең иң тирән чоңгылларында яткан саф тойгыларны уята. Ә бит язучы, тормышның берничә кылына берьюлы кагылып, хисләр давылы, фикерләр өермәсе дә кузгата алыр иде. Моңа дәлил — аның әсәрләрендәге кабатланмас образлар, характерлар полифониясе. Кызганычка каршы, кайчак ул соңгы ноктасы куелган вакыйгаларны сүтәдер, процессның үзенә ирек куймыйдыр, укучының, Чапаев турындагы кинононы карагандагы кебек, «бәлки ярга йөзеп җитәр?..» дип, өметләнеп тору ләззәтен киметәдер кебек. Бу хәл язучының үзенә дә комачаулый: тормышның катлаулы күренешләрен бөтен итеп алуы, төрле яклап чагылдыруы кыенлаша булса кирәк.

Шушы кыенлыкларның эзе үткәнгә, тарихка мөрәҗәгать итеп язылган башка әсәрләрдә дә сизелә. Күпмедер дәрәҗәдә халыкның зур культура һәм тарихи тәҗрибәсен катлам-катлам күтәреп, заманнар бәйләнешен кыю күрсәткән әсәрләрнең аз булуында да.

Дөнья бөтенлеген сурәтләргә, катлаулы төшенчәләрнең беренчел нигезен ачарга омтылу язучыларны балачак хатирәләренә алып кайта. Бу омтылыш Гомәр Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повестенда икеләтә көчлерәк. Анда авылның мәңгелек яшел чирәме, зәңгәр күге, гасырлар буе тупланган йолалар, гадәтләр хәзинәсе фонында, дөньяны сабыйларча бөтен итеп күрергә ашкыну белән бергә, гади халык психологиясенең тарихи бөтенлеге дә раслана. Язучының үз хәтерендә элекке көнкүреш детальләрен, әхлак, йола үзенчәлекләрен бөтен нечкәлегенә кадәр торгызып, шул туфракта үскән милли характерларны күз алдына китерә алуы зур гомумиләштерүләргә нигез булып ята. Татар халкының катлаулы язмышы һәм тарих каршындагы якты йөзе хакында шигъри повесть иҗат итеlә. Әнә шуңа күрә мондый әсәрләр рус телендә дә үзенең тирәнлеген, нәфислеген җуймый. С. Хәким әйтмешли, әдәби әсәр дөнья базарына дип махсус эшләнми, үз илендә танылса, үз культурасының аерылгысыз өлешенә әверелсә, аңа тел чикләре киртә була алмый.

Тарихи бөтенлеккә ничек ирешә соң Бәширов? Сюжет белән, яки тарихи вакыйгалар хроникасы беләнме? Юк,— минемчә, һәрбер кечкенә генә күренештә дә аерым шәхес һәм халык язмышына бәйле олы мәгънә ачу осталыгы белән. «Туган ягым — яшел бишек»нең тирәнлеге һәм колачы тышкы билгеләрдән бигрәк, халык рухын, кеше җанын аңлау тирәнлегендә һәм киңлегендә.

Гомерлек чирдән әкрен генә сызып баручы Фазулланы хәтерләгез. Аның бер хыялы — кызлардан сөю хаты аласы килә. Теләсә кайсы кыздан! Бер генә сүзле булса да! Үлгәнче... Ә үләсе килми Фазулланың. Ул бит яшь әле. Армиягә карадасы, сугышка алынасы иде кана: алай-болай яраланса, Мәскәү докторы берөчтән чирен дә дәвалар иде, бәлкем. Анда үлсәң дә, ичмасам, кеше исәбенә кереп каласың. Яисә күк капусы ачылганны күреп, үзеңә саулык теләп булса икән! «Син дә буш калма, яме? — дип киңәш бирә Фазулла нәни дустына.— Өс-башың бик тузган. Кышка яңа бишмәт сора...» Яисә — Герман сугышына китүче егетләрнең авыру егетне гармун уйнарга кыстаулары: «Син дә үләсе, Фазулла туган, без дә үләсе! Давай, агай-эне, бармакларың кыймылдаганда, бер әйттереп кал әле!» —

диләр. Фазулла бер күтәрелеп-ашкынып уйнап ала да, капылт кына туктап кала, сүрелә, сүнә... Үзәк өзгеч көй кебек.

Тарихи дереслекне тирән аңлап сурәтләгән әсәрләрдә трагедия дә тормыш дәвамын раслый, халыкның яшәүчәнлегенә ышанычны көчәйтә.

«Туган ягым — яшел бишек» повесте, шулай ук халкыбызның уртак Ватандагы тарихын җанландырган, татар улларының азатлык һәм бәхет өчен көрәшләрдә каһарман россияннар булуын раслаган башка әсәрләр — үзләренең асылы белән киләчәккә төбәлгәннәр. Т. Миңнуллинның «Канкай углы Бәхтияр»ы, Н. Фәттахның «Кол Гали»е, Г. Ахуновның «Ардуан батыр»ы, А. Расихның «Ямашев»ы... Алар — үткән көннәрдән киләчәккә адресланган хатлар, аларда — революцион рух дәвамы. Шуңа күрә, безнең тарихыбызга мөнәсәбәт мәсьәләсе, Константин Симонов сүзләре белән әйткәндә, чынлыкта коммунизм идеяләренең көченә, җәмгыятебезнең киләчәгенә ышану мәсьәләсе дә булып кала.

Тарихка, традицияләргә, үткәнгә мөнәсәбәт дәрәҗәсе адәм баласының бабаларыннан калган рухи мирасны үзләштерергә сәләтле булу-булмавын билгели. Ул гына да түгел. Хәтер тирәнлеге — дөньяга караш бөтенлеген, шәхес өлгергәнлеген күрсәтүче сыйфат та. Аны шушы өлгергәнлеккә ирешү юлындагы чакрым баганалары белән чагыштырырга мөмкин булыр иде. Хәзерге заманның кайбер яшьләрендәге традицияләргә җиңел караш аларның гражданин буларак үсешен тоткарлап торса, өлкәннәрнең хәтерсезлеге соңрак килүче буыннарда кире реакция тудыра — туганлык элемтәләрен яңартуга, тарихны аңлауга омтылышны көчәйтә. Хәтер диалектикасы әнә шундый бугай. Хәтернең актив көч булуы узган гомернең иң асыл вакыйгалары белән горурлану һәм кылган хаталарны онытмыйча, алар өчен күбрәк игелек эшләп калырга ашыгу рәвешендә дә күренергә мөмкин.

Әхәт Гаффарның «Бер йотым су» хикәясендәге герой әнә шундыйлардан. Аның хатасы — тормыш авырлыгы аркасында. Асылында бу герой бөтенләй башка, яхшы күңелле кеше, шуңа күрә дә аны бүгенге хәтере, бүгенге вөҗданы газаплый. Ә. Гаффарның иң уңышлы әсәрләрендә, бигрәк тә «Язлар моңы»нда галиҗәнап Вакыт хакимияте урнашкан. Хәтер аның геройларына «өченче үлчәм»дә яшәү — тормыш яссылыгыннан күтәрелеп, тиз агышлы чынбарлыгыбызда үз урыннарын табу мөмкинлеге бирә. Яшь язучының өлкән буын вәкилләрен тасвирлаган образлары да үткәннән бигрәк киләчәккә йөз тота, үткән белән киләчәк арасына рух күпере сала. Алар безгә мирас итеп халыкның кешелеклелек нигезләрен, үлемсез әдәп-низам кагыйдәләрен алып киләләр.

Билгеле, кайбер яшь язучыларыбыз иҗатындагы карт һәм карчыклар һәр очракта да халык идеаллары гәүдәләнеше булып җитми әле. Карчыклар экзотикасы белән мавыгу, хәтта сугыш һәм гариппәр экзотикасы (?!) да очраштыргалый әле бездә. Тумыштан сукыр булып туган кешеләр парадоксына корылган, яисә тормышка, мәхәббәткә, үлемсезлеккә ышанычны чегәннәр багуына алдану белән генә бәйләп аңлатырга азапланган әйберләр... Тагын да сәеррәге — холкы-фигыле, хәтта теле белән тамырына тартмаган ниндидер универсаль, космополит геройлар күренгәләп алуы... Шулай да болар, туган авылны һәм томанлы гына күз алларына килгән борынгыны сагынып сыктау кебек үк, уза торган чир. Һәрхәлдә, әтиләре каһында сугыш эченә кергән, әниләре канында окоп казырга йөргән буынның хәтере тирән, заман агышында үз урынын табарга омтылышы зур. Ә бу тормышта үз урыныңны табу — кемнең варисы булуыңны һәм мирас итеп нинди хәзинә алуыңны аңлау дигән сүз.

А. Тимергалинның «Мәңгелек хатирәләр» дигән әсәрен фантастика сөючеләр генә укыган булуы мөмкин. Әмма анда тасвирланган хыялый күренешнең тормышчан җирлеге һәм мәгънәсе шактый зур. Тылсымлы кристалл Хәйдәр бабайның баш миенә тирән кереп оялаган, тик әлегәчә яшеренеп-оеп кына яткан мәңгелек хатирәләрне уята.

Бүгенге әдәбиятта якын һәм ерак үткәнгә, аерым шәхес, буын, халык хәтеренә мөрәҗәгать итү, халыкчан характерларны киң тормыш материалында өйрәнергә тырышу нинди «магик кристалл» белән бәйләнгән соң? Бөтен дөньяда «борынгы»

стильнең бер модага әйләнүе беләнме? Әллә кечкенә генә мәйданда зур киңлек һәм тирәнлекләрне берләштерергә мөмкинлек бирүе белән җәлеп итәме хатирәләр алымы? Бер сүз белән генә җавап бирүе кыен, әмма бу тенденциянең чыганаклары төптәрәк ятадыр кебек. Ул җәмгыятебез ирешкән иң зур рухи казанышларыбыздан берсе — замандашларыбызның тарихи хәтере тирәнәюе, кешелекнең бөтен үсеш юлын катлаулы һәм югалмас мирас итеп күз алдына китерүе белән, бүгенге зур тизлекләрне ачык тойган әдәбиятның тормышка актив мөнәсәбәте белән бәйләнгән.

Әйе, уйлап карасаң, барысы да үз эзенә кайта. Хәйдәр карт хатирәләре аша борынгы тарих җанлана, бабайларның әйтелмәгән васыяте бүгенгә килеп ирешә, ул «яңа, таныш түгел» буынны кыю эзләнүләргә рухландыра.

Нелли исемле кыз Роберт исемле сөйгәнен хәтере җуелудан — ярымкеше-ярыммаймылга әверелүдән коткарып кала.

Найман-ана улын һәлакәттән саклап калу өчен бердәнбер юлны сайлый: манкортның үле хәтерен терелтергә дип өзгәләнә.

Минем Әдрәпи әбиемне дә туган авылы турындагы, игелекле кешеләр турындагы хатирә еллар буе дөнья гизәргә, безнең күңелләрдәге миһербанлылыкны уятып йөрергә — яшәргә мәҗбүр итә.

Әнә нинди көчкә ия икән ул — Хәтер. Үткән көннәр көле түгел, иртәгә туасы таңның кояшы икән ул. Буыннар арасындагы мәңгелек күпер — кеше нәселенең, халыкның, илнең үлемсезлеге икән! Моны онытырга хакыбыз бармы безнең?

# НӘСЕРЛӘР

*Нәсер, әдәби жанр буларак, проза белән поэзия арасында тора, шушы ике төрнең дә элементларын үз эченә ала. Нәсернең асылында, гадәттә, чәчмә белән язылган шигъри халәт һәм хис ята, әсәрдә субъектив бәяләү моменты, телнең эмоциональ хасиятләре зур роль уйный. Кайбер нәсерләрдә эчке ритмика да булырга мөмкин, ләкин ул шигырьдәге шикелле эзлекле рәвештә дәвам иттерелми. Һәрбер тойгы үзенчә булган кебек, һәр нәсер дә, хисләр чагылышы буларак, форма ягыннан аерылып тора.*

*Дөнья әдәбиятында нәсерләр язган зур әдипләр аз түгел. Русларда аны И. С. Тургенев проза белән язылган шигырь дигән шартлы термин белән атап һәм шулай язып, турыдан-туры шигъриятнең үзенә үк кертә, французларда Ш. Бодлер исә аңа чаклы ук «Проза белән язылган поэмалар» китабын чыгарган була.*

*Бу уңайдан, бәлки, ак шигырь (метрик үлчәүле, ләкин рифмасыз) һәм французча верлибр дип аталган ирекле шигырь (я метрик, я дисметрик үлчәүле, гадәттә рифмасыз) төшенчәләрен дә искә алып-ачыклап үтү кирәктер. Соңгысының классик үрнәге итеп, «Игорь полкы турында сүз» поэмасын, бельгияле Э. Верхарн шигырьләренең русчага тәрҗемәләрен, Пушкин, Фет, Бунин, Брюсов һәм Блоктан гаять камил полиметрия үрнәкләрен, Андрей Белыйның исә «Битлекләр» исемле бөтен бер романын — кыскасы, полиметрия белән язылган бүтән бик күп әсәрләрне китерергә мөмкин.*

*«Синие горы Кавказа, приветствую вас! Вы взлелеяли детство мое; вы носили меня на своих одичалых хребтах, облаками меня одевали, к небу меня приучали, и я с той поры все мечтаю об вас да о небе...» (М. Лермонтов).*

*Проза белән язылган бу өзек, әгәр аны тезмә юлларга бүлгәләп язсаң, әлбәттә, шигырь булып укылачак һәм яңгыраячак.*

*Рус поэзиясендә ирекле шигырьнең интонацион-фразалы төре һәм басымлы-акцентлысы бар. Шуларның һәркайсы исә һәм рифмасыз, һәм рифмалы була ала. Мәсәлән:*

*Жил старик со своею старухой*
*У самого синего моря;*
*Они жили в ветхой землянке*
*Ровно тридцать лет и три года.*
(А. Пушкин)

*Чуть ночь превратится в рассвет,*
*Вижу каждый д е н ь я*
*Кто в глав,*
*Кто в ком,*
*Кто в полит,*
*Кто в п р о с в е т,*
*Расходится народ в у ч р е ж д е н ь я.*
(В. Маяковский)

*Проза рифмасы белән язылган барча бу төр шигъри эчтәлекле әсәрләрне, нәсер дип чикләмичә әлбәттә, журнал күптәннән баса килә һәм алда да басачак. Тырышыбрак һәм ярышып язсак, аларның тагын да яхшыраклары дөнья күрер әле.*

*Нәсер — татар әдәбиятында да күптәнге һәм кыен жанр. Ф. Әмирхан, М. Максуд, Ф. Әсгать, Г. Кутуй һ. б. язучылар бу өлкәдә матур-матур үрнәкләр калдырды. Әмма соңгы елларны бездә нәсер жанрына игътибар кимеп, онытылып бара шикелле. Шуны истә тотып, укучыларыбызга берничә нәсер тәкъдим итәбез.*

## И. С. Тургенев

# МАША



Петербургта торган чакны — моннан күп еллар элек — берәр извозчик ялларга туры килгәндә мин һәрвакыт аның белән сөйләшеп китә идем.

Бигрәк тә төнге извозчикларны ярата идем мин, болары — шәһәр тирәсендәге авыллардан килгән фәкыйрь крестьяннар, атлары арык, чаналары арзанлы буяу белән буялган була; башкалага аларны алпавытка түләрлек оброк хәстәрләү һәм тамак кайгысы китергән.

Бер көнне минә шундый извозчик ялладым... Егерме яшьләрдә, озын буйлы, киң җилкәле, төскә-биткә дә шәп, күзләре зәңгәр, битләре алсуланып тора; кашына батырып ук киелгән ямаулы бүрек астыннан саргылт бөдрәләр күренә. Мондый киң җилкәләр ертык чикмәнгә ничек кенә сыйгандыр!

Әмма извозчикның сакалсыз, чибәр йөзе нигәдер кайгылы иде.

Без сөйләшеп киттек. Тавышында сагыш сизелә.

— Нәрсә, брат? — дидем мин.— Нигә болай төшенкелеккә бирелдең. Әллә берәр кайгы-хәсрәтең бармы?

Егет беравык дәшми торды.

— Бар шул, барин, кайгы бар, — диде ул, ниһаять. — Кайгының да нинди бит әле. Хатын үлеп китте.

— Ярата идеңме соң... хатыныңны дим.

Егет борылып карамады, башы гына бераз аска иелде.

— Яратмаган кая, барин. Менә сигез ай үтте... онытып булмый. Йөрәк сыкрый, йөрәк... Үлеме һич башка сыймый. Үзе яп-яшь, сәламәт иде! Бер көн эчендә ваба чире еккан да салган.

— Холкы шәп идеме соң?

— Их, барин! — дип авыр сулап куйды ул. — Шундый матур яшәп ятканда! Япа-ялгызы үлгән. Күмү хәбәре килеп төшкәч тә авылга чыгып чаптым. Өйгә кайтып җиткәндә инде төн иде. Ишекне ачып кердем дә торам шулай идән уртасында басып, ә үзем: «Маша! Маша!» — дип пышылдыйм. Чикерткә генә чырылдый. Түзмәдем, идәнгә утырдым да елап җибәрдем. Һәм шунда бар көчкә идәнгә китереп суктым! «Бирән корсак, мәйтәм!.. Аны йоттың... әйдә мине дә йот! Ах, Маша!»

— Маша! — дип куйды ул кинәт зәгыйфь тавыш белән, баудан әмәлләнгән дилбегәсен кулыннан ычкындырмый гына бияләе белән күз яшен сөртте, яшь тамчыларын читкә кагып төшерде, иңбашларын кыймылдатып алды һәм тынып калды.

Чанадан төшкәндә мин аңа биш тиенне өстәп бирдем. Ул, бүреген ике кулы белән тотып, бил бөгеп рәхмәт әйтте һәм январь суыгының чал томанында өртелгән буш урам буенча акрын гына атлап ары китте.

# ЧЫПЧЫК

Аудан кайтып килешем, аллея буйлап барам. Этем алдан йөгерә. Менә ул сагайды, адымнары акрынайды, җиргә сыенарак төште.

Мин, ни булды икән дип, аллея сукмагына күз салдым. Һәм шул вакыт сары томшыклы, йонлач башлы чыпчык баласын күрдем. Ул оясыннан егылып төшкән дә (көчле җил аллеядагы каеннарны тибрәтә чайкый иде), әле кауры чыгып кына килгән көчсез канатларын салындырып, кыймшанмый утыруын белә.

Этем аңа якынлаша башлагач, эт каршына янәшәдәге агачтан кара түшле карт чыпчык таш шикелле атылып төште — һәм, йоннарын ка-

бартып, тузынып, куркыныч та, бер үк вакыт кызганыч та авазлар чыгарып, бер-ике тапкыр этнең ачык авызына таба сикергәндәй итте.

Ул үзенең газизен, кечкенәсен коткарырга теләде, күкрәге белән аны эттән капларга тырышты... ләкин аның бәләкәй тәне дәһшәттән тетрәнә, карлыккан тавышы өзелә, тыны бетә, ул үзен корбан итәргә әзер.

Котоккыч җанвар булып күренгәндер аңа бу минутта эт! Шулай да ул үзенең хәвефсез ботагында утырып кала алмаган... Үз ихтыярыннан да көчле бер көч аны аска ыргыткан.

Трезор туктап калды, артка чигенде... Әлеге көч аны да җиңде, күрәсең.

Аптырашта калган этне мин үземә чакырырга ашыктым — һәм, чыпчыкка сокланып, аны олылап, ары киттем.

Әйе, көлмәгез. Күңелемдә чыннан да шушы бәләкәй, әмма батыр кошчыкка, аның мәхәббәтенә соклану туды.

Мәхәббәт, дип уйлап алдым мин, үлемнең үзеннән һәм үлем куркынычыннан да көчлерәк икән. Бары тик мәхәббәт аркасында гына тормыш дәвам итә.

*Апрель, 1878*

## ЭТ

Без бүлмәдә икәүдән икәү генә: эт һәм мин. Тышта җил улый, давыл котырына.

Каршымда, күзләремә карап, эт утыра.

Мин дә аның күзләренә карыйм.

Ул миңа нидер әйтергә тели сыман. Аның теле дә, сүзе дә юк, ул үз-үзен дә аңламый — ләкин мин аны аңлыйм шикелле.

Бу мизгелне анда да, миндә дә бер үк теләк яши, бер аермабыз да юк. Без — охшаш, без — тигез; һәрберебездә бер үк яктылык, бер үк ут дерелди.

Шунда үлем килеп, үзенең киң, салкын канатын җилпесә...

Бетәрбез, сүнәрбез төсле!

Соңыннан күңелләребездә нинди ут дөрләгәнен кем дә булса аңлармы?

Юк! Бу мизгелдә бер-берсенә кеше белән эт карап тормый, бер-берсенә охшамаган ике пар күз төбәлешкәннәр.

Һәм ул күзләрнең һәрберсендә — кешедә һәм эттә — ике тормышның бер-берсенә сыенышуы чагыла.

*Февраль, 1878*

**СОЛТАН ШӘМСИ** тәрҗемәсе

## Фатих Әмирхан

# ЧӘЧӘКЛӘР КИТЕРЕГЕЗ МИҢА!

*Гражданнар сугышын галәбәле[1] тәмам итеп, хезмәт мәйданына кайта торган иптәшләргә багышлана*

Ләтыйф төсләр, хуш исләр... Табигатьнең шулардан гүзәл тезеп барлыкка китергән шигъриятен үз алдымда күрергә, хис итәргә телим мин: китерегез миңа чәчәкләр!

[1] Җиңүле.

Язгы сәрен яңгырлардан соң күк йөзендә чыккан салават күперендәге нәзек төсләрнең барысы да ул чәчәкләрнең яңа ачылган гүзәл телкәйләрендә, ләтыйф барлыкларында шәүләләнсеннәр; табигатьтә булуы мөмкин хуш исләрнең барысы да ул чәчәкләрдән аңкып торсыннар да бөтен хуш исләр шигъриятен гәүдәләндерсеннәр.

Сүзләрдән, төсләрдән, музыка нәгъмәләреннән [1] шигъриятләр гәүдәләндермәсмени? Китерегез миңа хуш исле чәчәкләр!

Чәчәкләр китерегез миңа! Аларның бөреләре миңа каршы елмайсыннар да эчләрендәге ал-зәңгәр-кызыл-сары-күгелҗем-миләүшә төсләрнең барысын берьюлы эченә алган төсләрен күрсәтеп куйсыннар; аларның ләтыйф тулып җиткәннәре үзләренең гаҗәеп йөзләре белән миңа каршы шат көлсеннәр дә хуш исләрдән каһкаһәләрен [2] миңа үткен тойдырсыннар. Яңа ачылып килә торган ул бөреләр миңа яшьлегемнең алтын хыяллар белән мәңге исерек үткән мазыйларын [3] хәтерләтсеннәр. Ачылып җиткән ул көләч чәчәкләр миңа бөреләрен ача алмый шиңгән яшьлегемнең гыйвазы [4] булсыннар.

Миңа чәчәкләр китерегез! Мин аларны үземнең каләмнәрем, язылып бетмәгән һәм бетмәячәк дәфтәрләрем тирәсенә тезәрем. Мин аларны бөтен тирә-ягыма сибәрем, төсләре белән шагыйрәнә тәртипсез бер салават күпере, исләре белән хыялый-шигъри бер хуш ис диңгезе вөҗүткә [5] китерерлек итеп сибәрем: күзләр, шаммәләр [6] ирексез аларга омтылалар!

Китерегез, китерегез миңа чәчәкләр! Аларның гаҗәеп исләре мине исертсеннәр; мине, исерткечләр эчеп тә гомеремдә бер теләгәнчә исерә алмаган, гыйшык, мәхәббәт көннәремдә дә лаягкыл исерек булмаган мине исертсеннәр, мәст итсеннәр [7]. Аларның шатлыклы көләч төсләре минем мәңге карарсыз, мәңге эзләнә, ләкин нәрсәсендер мәңге таба алмый торган күзләремне үзләрендә карарландырсыннар; мәңге пошына, мәңге офыкларның аргы якларына омтылып та, омтылганнарына ирешә алмый торган йөрәгемнең хәсрәтле карарсызлыгына шигъри бер сәкинә [8] бирсеннәр, шул пошынуымны хуш исләрдә шагыйрәнә коендырсыннар!

Энҗе чәчәкләр китерегез миңа! Алар яшь кызның муәффәкыятьсез беренче гыйшыктан тамган күз яшьләре шикелле саф булсыннар, алар сөт тамчыларыдай тамып-тамып торсыннар. Аклыклары белән күзләрне чагылдырсыннар. Яшьлегемнең алсу таңында, әле егетлек тормышын ярым өн, ярым төш рәвешендә, керфекләре йомылган күзләремнең эчендәге нәсими [9] булдырак кына торып уздырган чагымда, мин аларны төшләремдә күрә идем. Алар ул вакытта хәзерге шикелле ап-ак кына түгелләр иде; аларның аклыгы өстендә энҗеләр өстендәге шикелле сып-сыек зәңгәрсу вә ул шәүлә эчендә алсу дулкыннар йөгергән була иде.

Китерегез миңа энҗе чәчәкләр! Мин шул бәхетле көннәремнең шигъри төшләрен исемә төшерермен. Миңа энҗе чәчәкләр китерегез! Аларның газаплы исертүчән салкынчарак исләре минем тирә-ягымны аңкытсын, бәлки, шул газаплы ләтыйф истә мин бәхет мөмкин булып та бәхетсез уздырган яшьлегемнең назирасын [10] табармын!

Ясмин чәчәкләре, резедалар китерегез миңа! Кайчандыр боларның

---

[1] Музыка парчалары. — Ф. Ә.
[2] Кычкырып көлүләрен.
[3] Узган заманнарын.
[4] Яшьлегем урынына тора торган. — Ф. Ә.
[5] Барлыкка.
[6] Ис сизү әгъзасы. — Ф. Ә.
[7] Бик каты исертсеннәр.
[8] Тынычлык.
[9] Эфирный. — Ф. Ә.
[10] Охшашын. — Ф. Ә.

исләре мине киң, йомшак-үткен, аксыл-алсу дулкыннар булып чолгый-лар да бөтен барлыгыма үтәләр, әллә кайларга, офыкларның аргы якларына, күгелҗем, алсу җиңел болытларның өске якларына тартып өндәп, кызыктырып торалар иде. Беренче мәхәббәт миңа резедалар хуш исенә төренеп килгән иде — сирпегез минем тирәмдә резедалар хуш исен! Беренче мәхәббәтнең ләззәтле пошыну, шигъри хәсрәт һәм хыялый бәхеттән гыйбрәт беренче сагышы миңа ясмин чәчәкләренең хуш исле дулкыннары өстендә килгән иде. Китерегез миңа ясмин чәчәкләре, китерегез миңа резедалар! Аларның гакылдан шашкан гашыйк серенадасы шикелле йомшак һәм хыялый җәелә торган исләре миндә түзәлмәслек бер теләк, бәхет, гыйшык теләге тудырсыннар! Сез беләсезме, музыка нагъмәләре белән чәчәкләр хуш исләре арасында гаҗәеп бер тәнасеп[1] бар бит!

Миңа гөл чәчәкләре китерегез! Шагыйранә мәһабәт Кавказ тауларының итәкләрендә үскән чәчәкләр булсыннар. Аларның ак, саргылт, ал, кара, зәңгәр һәм ялкын төсендәгеләрен мин кызыл чәчәкләрем белән аралаштырып тезәрмен, мин аларның, тереклекнең беренче шатлыгыннан елмайган яшь бала йөзе шикелле, куаныч тулы йөзләренә сәгатьләр буенча өзлексез карап торырмын. Китерегез миңа гөл чәчәкләр! Аларның ләтыйф аңкуларында, аларның шаммәләрне сыйпап, иркәләп чолгый торган исләрендә гаҗәп бер тынычлык, җанны ял иттерә торган рәхәт тынычлык бар бит. Туфаннар, зилзиләләр, күк күкрәүләр, яшен яшьнәүләр белән үткәрелгән яшьлектән соң мин һәр нәрсәләрдән артык, гөл чәчәкләр исендәге тынычлыкка мохтаҗ.

Китерегез миңа гөл чәчәкләр! Мин аларның хуш исләре дулкыннарында, тәфәккергә[2] чумып, тирбәнермен!

Гарлем[3] кырларын каплап үсә торган гаҗәеп кыяфәтле лаләләр нәселләр чолганышыннан дөньяга чыккан йөзләрчә төрле тюльпаннарның матурлыкларын миңа хикәя итәләр. Китерегез миңа гөл чәчәкләр! Мин аларны күз алдымда җәелгән киң кырларга сибәрмен, шул кырларда мин аларны назлап, иркәләп үстерермен. Минем гөл чәчәк кырым Гарлемның гасырлар буенча килгән нәфасәт шөһрәтен күләгәдә калдырыр. Минем гөл чәчәк кырымнан таралган хуш ис бөтен арган, талганнарга шагыйранә ял бирер!

— А, ишетсәгез лә, китерегез, китерегез миңа чәчәкләр!

*1921 ел*

Мәхмүд Максуд

# КАРАВЫЛДА

Тулган айның серле нуры бөтен дөньяны ямьләндергән. Әкрен генә искән җилдән яр буендагы агачлар җилфердиләр. Кечкенә генә су табигатьнең тәэсире белән үзенең ярларыннан чыккан да, җәелеп яткан болынны тутырып, киңәеп аккан матур бер елгага охшаган. Көзге шикелле шул суда ай шәүләсе, чиксез-хисапсыз йолдызлар шәүләсе күренә. Алар чын айга, чын йолдызларга караганда да серлерәк, моңлырак шикелле тоелалар. Әллә кайда, еракта, сандугач сайрый. Аның саф тавышы бозылган йөрәкнең салкын кылларын тибрәтә, йөрәкне дулкынлы тойгылар диңгезенә әйләндерә, төрле истәлек сәхифәләрен

[1] Бәйләнеш.
[2] Уйга.
[3] Бөтен Европага иң нәфис чәчәкләр үстереп тора торган кечкенә бер шәһәр

ачып бирә... Айның бер генә тапкыр көлеп каравы күңелдәге бөтен керләрне юган, сафландырган, синең бөтен кайгыларыңны бетергән шикелле була. Шул матур төндә, шул серле ай яктысында, сандугачларның моңлы җырларын тыңлый-тыңлый, әллә кайларга китәсе, әнә шул матур су өстендә матур көймәләрдә йөрисе, аннан теге яктагы калын урманга чыгасы, серле төнне серле урманда үткәрәсе килә...

Ләкин шул калын урманны искә алу белән, күңелдәге матур тойгылар бер минут эчендә юкка чыгалар, алар урынына ачу тойгысы, нәфрәт-җирәнү тойгысы уяна. Табигатьнең байлыкларыннан булган әнә шул урманда, шушы матур елганың әнә теге ягында гына дошман торганлыгы, шул матур дөньяда адәм балаларын җәфа чиктерергә теләгән, мең төрле михнәтләр эчендә яшәтергә теләгән дошман торганлыгы искә төшә. Шул дошман тарафыннан анда әллә никадәр эшчеләрнең, әллә никадәр ярлыларның җәберләнүләре, көчләп, сугышка китерүләре искә төшә. Әллә никадәр кан, әллә никадәр корбан соңында гына алынган азатлыкны ерткычларның буарга омтылулары аркасында корал күтәрергә мәҗбүр булуың, сугыш мәйданына килүең, атып үтерер өчен дошманны күзәтеп торуың искә төшә.

Искә төшә дә, йөрәгең жу итеп, әллә нишләп китә. Дошманга булган ачу тойгысы кабарганнан-кабара бара: тизрәк елганың теге ягына чыгасы, тизрәк алга барасы, тизрәк әнә шул кабәхәт дошманнарны җиңәсе, юк итәсе килә; дуслык-туганлык дөньясының ямьле кояшы тизрәк хезмәт ияләрен иркәләсен өчен, тизрәк дошманны бетерәсе килә. Изелгәннәрнең күз яшьләре акмасын өчен, тизрәк дошманны көл итәсе килә. Меңнәрчә ел җәбер-золым оясы булып килгән җир йөзе бөтен эшчеләрнең дус, туган булып яшәүләрен тизрәк күрсен өчен, тизрәк дошманны таптыйсы килә. Маңгай тирен агызып, беләген талдырып көн итүче киң күкрәкле, саф күңелле эшчеләр табигатьнең бөтен байлыкларыннан тизрәк файдалана башласыннан өчен, тизрәк дошманны җир белән тигез итәсе килә.

Күңел дулкынлана. Ай үзенең нурын сибә. Агачлар җилферди. Сандугач сайрый: «Сабырсызланма, туганкай, сабырсызланма. Дошманнарның актык минутлары җитте, тиз көннән син аларны җиңәрсең. Тиз көннән биек тау башларында, очсыз-кырыйсыз диңгез буйларында син кадаган кызыл байрак җилфердәр, үзенең нурларын чәчәр. Тиз көннән син, җилкәндәге мылтыкны ташлап, тыныч эшкә тотынырсың. Айның, син гашыйк булган әнә шул моңлы айның, нуры артыр. Минем җырым, минем тавышым сафланыр, матурланыр. Мин синең эшеңне, синең көчеңне мактармын. Җәйге төннәр хәзергегә караганда серлерәк, хәзергегә караганда нурлырак булыр. Шундый җәйге төннәрдә матур урманнарда, ямьле бакчаларда, салкын чишмә буйларында, синең көчеңне мактап, әлегә кадәр ишетелмәгән серле җырлар җырлармын, әлегә кадәр ишетелмәгән көйләр көйләрмен», — ди ул.

*1919, фронт.*

## Фәхри Әсгать

* * *

Без чәчәкләрдән — сүзләр, ә сүзләрдән чәчәкләр ясыйбыз.

Сез бәлки моңа гаҗәпләнә торгансыз, гаҗәпләнерсез дә шул, чөнки шагыйрьләрнең эшләре гаҗәбрәк.

Без гади җөмләләрне бер-беренә кушабыз, тоташтырабыз да, алардан чылбыр, бизәкле чәчәкләр чылбыры ясыйбыз. Ул чылбырлар белән сизгер йөрәкләрне үзебезгә тартабыз, бәйлибез...

*6 XII. 21.*

*
* *

Исендәдер, ул вакытны җәйнең урталары иде.

Без ул көннәрне, Утар елгасы буенда тирләп-пешеп печән чаба идек. Арыш күптән баш кыскан иде инде.

Без ул төнне синең белән, икәүдән икәү, арыш арасында йөрдек. Төн болытлы, күк катлаулы кара ябынчалар белән капланган иде.

Ара-тирә көн ягыннан битләрне сыйпап җылы, йомшак җилләр исә; диңгез — арыш диңгезе салмак кына дулкынлана, кайдадыр, арыш арасында, гел бертөрле тавыш белән туктап-туктап, тартарлар кычкыралар...

Без ашыга-ашыга арыш арасыннан чәчәкләр, синең чәчеңә үрелгән тасмалардай, җете зәңгәр чәчәкләр җыйдык. Мин ул чәчәкләрне синең дулкынланган коңгырт чәчләреңә катыштырып үрдем. Кояшта янып каралган маңгайларыңны, тулы җилкәләреңне зәңгәр чәчәкләр белән бизәдем.

Нинди матур иде ул чәчәкләр...

Без, арыш арасында йөри торгач, боргаланган агым суга барып чыктык; барып чыктык та, текә яр буена утырдык.

Елганың карачкыл сулары, каядыр омтылгандай, ыргылып-ыргылып агалар. Дулкыннар, әллә нинди ят тавышлар белән, үзара сөйләшәләр, чылтырыйлар. Сөт кебек аккүбекләр юаш дулкыннар белән акрын-акрын тирбәләләр иде...

Мин синең кояш нурларында янган кара туткыллы йөзеңә текәлеп карадым. Миңа җавап урынына, куе караңгылык аша, синең чыланган карлыгандай кара күзләрең, чәчәкләр елмайган төсле елмайдылар.

Йөрәкләр бер-берсенә ашкындылар, куллар сарылдылар, иреннәр мәңге аерылмаска теләгәндәй кушылдылар...

Еракта күк гөрелдәде. Күзләрне чагылдырып яшен яшьнәде. Эре яңгыр бөртекләре бер-бер артлы тупырдадылар.

*1925*

*
* *

Кышкы озын төннәрдә, урамнарда әче җилләр сызгырып, иләмсез тавышлар белән үкергәндә, бөгел дә тәрәзәдән кара.

Бәлки кар, бураннар арасында билдән көрткә батып, адашып йөрүче юлаучыны исеңә төшерерсен.

*1925*

## Гадел Кутуй

# САГЫНУ

Мин чит илдә матур гөлләр, хуш исле чәчәкләр исним. Ләкин күпме генә иснәмим, барыбер һава җитми, сулыш кысыла. Гүя үз илемнен энҗе чәчәкләре түгел, аның әреме дә бүген миңа шифа булыр иде.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Мин шаулап аккан елгалардан, тирән коелардан алып, сап-салкын су эчәм. Әмма күпме эчсәм дә, сусавымны баса алмыйм. Мин үз илемнен борынгы Иделен, тын Доньын, якты Арагвасын, шигъри Дим буй-

ларын сагынам. Гүя бу мөкатдәс елгаларның суларын түгел, хәтфә болынлыктагы чишмәләребезнең бер йотым суын да бүген мин ширбәт итеп эчәр идем.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Мин Карпат тауларына мендем, Финляндия күлләре янында ял иттем. Ләкин Эльбрус шикелле мәһабәт, Казбек шикелле гүзәл тауларны, үз илемдәге Аккош күледәй сихри күлләрне очратмадым.

Синдәгедәй илаһи матурлык, синдәгедәй шагыйранә мәһабәтлек бер җирдә дә юк, туган ил!

Мин чит авыллар һәм чит шәһәрләр аша узам. Җиңү мине Берлинга алып бара. Чит ил балалары миңа бәйләм-бәйләм чәчәкләр сузалар, чит ил картлары миңа хәмер тәкъдим итәләр, чит ил кызлары миңа җимешләр сузып елмаялар һәм ялваралар:

— Син безне үлемнән коткардың, инде кил, чибәр егет, кунак бул, бездә кал! — диләр.

Әмма мин елмая алмыйм, чөнки хәмерләре исертми, елмаюлары җылытмый. Мин юлымда дәвам итәм. Мин газиз илемне, аның ямьле бәйрәмнәрен, аның талган аякларны да биетә торган хәмерләрен, йөрәккә җылы өргән нечкә билләрен сагынам, гөнаһсыз балаларын күргәндәй булам.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Мин горур атлыйм. Чөнки мин чит илдә әсир булып түгел, җиңүче булып йөрим. Миңа һәр йортның капкасы, һәр өйнең ишеге ачык. Ләкин берсенә дә керәсем килми минем. Мин ата-баба корган илемдәге изге йорт турында уйлыйм һәм шунда тизрәк кайтып керер өчен Берлинга ашыгам. Берлинга мин, илем белән аерылу кайгысын моннан соң һичкайчан татымас өчен чиксез ачу белән барам. Ачуым шулкадәр көчле, сагынуым шундый татлы ки, мин түзмим, җырлап җибәрәм.

Иле ямьсез, суы тәмсез,
Өйгә кайтасым килә!

— дип җырлыйм мин.

Без мәйданга керәбез. Поляк яшьләре, безне котлап, үзләренең иң матур җырларын җырлыйлар. Әмма минем күңел еракта. Мин үзебезнең Кызыл мәйданыбызны сагынам һәм туган илдән килгән хатларны укыйм. Дусларым, кардәшләрем миннән, сагынасыңмы, дип сорыйлар. Минем бугазыма төен тыгыла. Мин төенне йота-йота җавап язам:

Телеграмм баганасы — олы юлга маяк ул,
Сагынасыңмы дип сорыйсыз — сагынмаган кая ул!

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Сине сагынган саен, миндә көч-дәрт арта, рухым канатлана. Чит илдә йөреп, мин ачык аңладым: совет кешесе өчен үз иленнән дә изгерәк, үз иленнән дә кадерлерәк, үз иленнән дә гүзәлрәк ил дөньяда юк ул.

Сагынган саен сагынасы килә. Сагынуым шундый көчле булганга, кайтуым да ышанычлы. Кайтыр булмасам, бу кадәр сагынмас идем.

Сагындым, бик сагындым сине, изге туган ил!

*1944*

Җәбрән Хәлил Җәбран,

гарәп язучысы

*1883—1931*

## КҮҢЕЛ ҖЫРЫ

Күнелем төбендә җыр ята һәм ул минем сүзләрем киеменә сыеша алмыйм. Җыр йөрәк орлыгы эчендә ята, һәм ул ак кәгазьгә кара булып төшәргә теләми...

Аны кемгә җырлыйм икән, ул бит минем күңелемне генә биләргә күнеккән, мин аның бүтәннәр колагына дорфа булып ишетелүеннән куркам?

Әгәр син минем күзләремә карасаң, анда шул җыр күләгәсе чагылганын күрерсең. Әгәр син минем бармак очларыма кагылсаң, анда шуның калтыравын сизәрсең.

Минем кулларым хәрәкәте, йолдыз балкуын чагылдырган күл сыман, шул җырны күрсәтә, күз яшьләрем, эсседә тирбәлгән чәчәк серен ачкан чык тамчысы кебек, шул җырны ачып бирә.

Ул җыр тынлыкта киң булып җәелә, ә тавышлы чакта бөтенләй кеп-кечкенә булып йомарланып кала. Ул минем түшемдә кабатлана, әмма өнемдә яшеренеп юкка чыга.

Ил җәсмин чәчәгеннән дә хуш ислерәк — аны кем иреннәре колитәр икән? Ул гүзәл кызлар эч сереннән дә яшеренрәк — аның турында белдереп, нинди кыллар чыңлар икән?

Диңгез шавы белән сандугач җырын кем берләштерер? Сабый сулышы белән давылны кем бергә кушар?

## ЯҢГЫР ҖЫРЫ

Без — тәңре кулы югарыдан сипкән көмеш җепләр. Безне табигать элеп ала, һәм безнең белән тугайларны бизи.

Без — муллык һәм мәхәббәт алласы Астартаның таҗыннан сибелгән гүзәл зөбәрҗәтләр, безне таң иртәсе кызы урлап алган һәм кырларга чәчкән.

Мин елыйм — һәм калкулыклар елмаялар, мин түбәнгә төшәм — һәм чәчәкләр өскә калкалар.

Болыт һәм кырлар — гашыйк парлар алар, ә мин — алар арасында теләктәшлек хәбәрчесе. Мин җиргә коеп явам һәм берәүләрнең сусавын басам, берәүләрне газапланудан дәвалыйм.

Минем килүемне күкрәүләр тавышы белән яшен кылычлары хәбәр итә, күккә сузылган салават күпере минем сәяхәтнең тәмамлануын белдерә...

Мин диңгезләр йөрәгеннән күтәреләм һәм эфир канатлары белән канатланып очам. Әгәр юлымда бакча күренсә, мин түбәнгә төшәм һәм чәчәкләр иренен үбәм, агач ботакларын кочам.

Тын минутларда мин үземнең нәфис бармакларым белән тәрәзә хрустальләренә бәрәм һәм шул тавышлардан сизгер йөрәкләр генә аңлый торган җыр туа.

Мине һава эсселеге барлыкка китерә, ә мин һава эсселеген юкка чыгарам — үзенә ирдән алган көч белән хатын-кыз да нәкъ шулай җиңә.

— Мин дингез көрсенүе, мин — күкләр күз яше, мин — кырлар елмаюы. Мәхәббәт тә нәкъ шундый хисләр дингезенең көрсенүе, ул — уйланулар күгенең күз яше һәм ул — күңел кырларының елмаюы.

## ГҮЗӘЛЛЕК ҖЫРЫ

Мин — мәхәббәтнең юл күрсәтүчесе, мин — күңел өчен татлы шәраб, мин — йөрәк азыгы.

Мин — үз йөрәген яңа һәм яшь көннәргә генә ача торган гөлчәчәкмен, мине кызлар өзеп ала һәм үбеп күкрәкләренә кадыйлар.

Мин — бәхет йорты, мин — шатлык чыганагы, мин — тынлык башлангычы.

Мин — гүзәл кызлар елмаюы. Мине күргән яшь егет үзенең авыр сагышларын оныта, аның тормышы татлы төшләр чәчәк аткан болынга әйләнә.

Мин — шагыйрьләр илһамчысы, мин — рәссамнар житәкчесе һәм музыкантлар мөгаллиме.

Мин — сабый бала карашы. Аны ягымлы аналар күрә дә тез чүгә һәм тәңрегә рәхмәтләр укый.

Мин — язмыш кебекмен: бүген төзим һәм иртәгә тар-мар итәм. Мин — олуг: терелтәм һәм үтерәм.

Мин — миләүшә чәчәге сулышыннан да нәфисрәкмен һәм давылдан да көчлерәкмен.

Мин — хакыйкать. Сез белә алган нәрсәләрнең, кешеләр, бу иң яхшысыдыр, бәлки!

ЗӘКИ НУРИ тәржемәсе

Әлфи Касумов,
әзербайҗан язучысы

## КИЧЕКТЕҢ...

Миңа син килгән, аста, тәрәзә буенда караңгыда басып тора, диделәр. Тәмәке тартасың икән. Берсе артыннан икенчесен. Иңнәрең калтырап куя. Син, мөгаен, елыйсыңдыр. Башкалар, миңа килүче башкалар шикелле..., Хәзергә мин чиктән тыш хәсрәткә баткан, кайгыдан тинтерәгән булсам да, беравыкка үзеңне кызганып куям. Тик шул мизгелдә синең аркада татыганнарым бөтен барлыгымны биләп ала да хәсрәтем тагын да тирәнәя, тагын бәгырем телгәләнә.

Ник килдең? Берәү дә чакырмады бит сине. Берәү дә хәзер сине монда көтми. Монда инде сине күптән көтмиләр.

Ә элегрәк күпме көннәр сине көтеп узды! Ул сине ничек кенә көтте! Аның белән мин дә.

Син безне ташлап киткәндә уртак улыбыз әле бик нәни иде. Ташлавыңны мин аңладым, ә ул әле моны аңларлык түгел иде. Ул минут саен: «Әти кайчан кайта?» дип сораганда йөрәгем сулкылдый башлый иде. Нинди җавап бирә ала идем соң аңарга? Ул кабатлый торган сораулар, әгәр шулай әйтергә яраса, синең белән аерылудан дәһшәтлерәк иде.

Ул, кайчан кайтасыңны армый-талмый сорый-сорый, сабыр гына сине көтте. Аның сагынуы йөрәгеңне кузгатмый калмас, дип уйлап үзем дә сине көттем. Тик син кайтмадың.

Бервакыт кичкырын тәрәзәбез каршыннан сиңа охшаган бер кеше узып китте. Буе-сыны да, киемнәре дә нәкъ синекедәй. Улыбыз «әти» дип кычкырып, тәрәзә төбеннән шуып төште дә урамга атылды. Ул, алла нича баскычны берьюлы сикереп, бөтен көченә шул ир артыннан томырылды. Әмма теге кеше борылып карамады. Шул ир артыннан йөгергән малайны күреп, узгынчылар туктап калды, күзләрен моң басты, ә минем йөрәгем өзгәләнде. Ниһаять, теге ир улымның эндәшүен ишетте һәм артына борылды. Тик ул син түгел идең.

Менә шул минутта улыбызның йөзен күрсәң иде! Аптыраудан яңаклары кызарып чыкты, иреннәре дерелди башлады, күзләренә яшь тулды.

Мин инде бу вакыйга аны айнытыр, сине искә алудан туктатыр, дип уйлаган идем, тик ул үз әтисен көтте дә көтте.

Язын ул сине без кайчандыр бергәләп барган һәм ошаткан таулар арасыннан эзләде — тавышы тарлавыкларда кайтаваз булып яңгырады. Аңа таулар кушылды, шарлавыклар — гөрелдәп, агачлар шыбырдашып җавап бирде, тик син... син дәшмәдең.

Ыңгырашуым томанга әверелде,
Тик син кайтмадың.
Өметем шөбһәгә әверелде,
Тик син кайтмадың!

Җәйге челләдә ул сине диңгез буенда көтте. Килмәдең. Күктән утлар яуды — син юк идең. Хәвефләнгән дулкыннар кыяларга бәрелде, үрсәләнеп, акчарлаклар аваз салды — син дәшмәдең. Бер генә сүзең дә безгә килеп җитмәде.

Яндым, көйдем, ялкынымны диңгез дә сүндерә алмады. Ничек кенә көттем мин сине!

Көз җитте. Йокыга талыр алдыннан табигать бөтен төсләрен балкытып, ямьле буяулары белән безне куандырды. Улыбыз, сокланудан шашып, сине чакырды — дөньяның бөтен алтыннарын бүләк итәргә ашкынды, тик син чукрак һәм сукыр идең, йөрәгең улыңның сагынулы авазына җавап бирмәде. Яфраклар, иңри-иңри, ботакларыннан җиргә коелды. Алар аяк астында кыштырдап җан биргәндә йөрәкләребезне син таптыйсыңдыр сыман тоелды.

Кышкы ачы салкыннарда урамга чыгып, килер юлыңа карап күз талдырдык. Без сине көттек. Өебезнең бәс кергән — кыш бабай бизәгән тәрәзәләренә текәлеп, кар абагалар арасыннан салынган сукмакларга карап тордык, ул сукмаклардан син кайтырсың төсле иде. Әмма кайтмадың. Ул һаман сине чакырды, ләкин җавап бирмәдең, эндәшмәдең. Җилләр генә җавап бирде — алар хәсрәтләнеп тәрәзәбезгә сугылды, тизрәк эчкә кереп җылынып өчен, ярсый-ярсый ишегебезне какты. Ә син дәшмәдең. Йөрәгем гасабиланып катты...

Хәзер ник килдең? Төзәлә башлаган җәрәхәтләрне ярсытырга, йокыга талган хатирәләрне уятыргамы? Ник килдең?

Өметләрем инде көлгә әйләнде, тормышым газапка әверелде, үткәннәрне яңадан терелтергә хәзер инде хәлең җитмәячәк.

Вөҗданың уянуга, йөрәгеңдәге боз эрүгә ышанмыйм.

Ник килдең? Башкалар сафына кушылгансың. Барысы да килде, алар белән син дә. Ни өчен? Миннән улыңны талап итәргәме? Үзеңә шикелле озын буйлы, кашлары, күзләре — барысы, барысы да үзеңә охшаган улыңны алыргамы? Аның йөрәге ата мәхәббәтенә сусаган иде.

Кичектең, өметсез кичектең шул. Үлем синнән алдарак өлгерде.

Улымны аңа бирмәс өчен мин бик озак тартыштым: еладым, мәрхәмәт күрсәтүен, улымны алмавын үтендем, тик ялваруларымнан файда чыкмады. Язмыш улым белән миңа нигә кырыс булды икән? Соңгы минутларда сине тагын ярдәмгә чакырдым, әмма килмәдең. Тавышыңны да чыгармадың. Күкләр күкрәде, дулкыннар гөрселдәде, җилләр улады. Ә синнән ник бер ым-шым ишетелсен.

Ә хәзер килгәнсең. Нәрсәгә? Улың янына, инде буй җиткән улың янына килдеңме?

Син кичектең...



## СОҢГЫ ХАТ

Кичә хатыңны алдым.

Башларым әйләнеп китте — күк йөзе өстемә капланды, тәнемне үтәли җил өтте, буыннарымда каным катты. Яшеннәр яшьнәде, күкләр күкрәде. Битләремә учаклар ягылды.

Кичә хатыңны алдым. Боздай салкынны.

«Хатларымны кире кайтар. Мәхәббәтемне кире кайтар. Без беркайчан да очрашмаган, бер-беребезне беркайчан да яратышмаган, язышмаган төсле булсын», — дигәнсең.

«Мин яңа мәхәббәт ташкынына юлыктым», — дигәнсең.

Котлыйм! Киләчәк киемнәреңне котлыйм һәм хатларыңны кире кайтарам. Без бергә яшәмәгән көннәр моңына, ачылмаган, әмма инәләрен йөрәгемә чәнчегән розаларга төреп кайтарам. Йөрәгемнең сызлаган яраларына, җанымның тормышка ашмаган хыялларына төреп, кире салам. Безне бәйләгән җепләр өзелде. Хәзер икебез дә иреклe инде.

Әмма хатларыңны конвертка салып, барып чыкмаган мәхәббәтнең адресын язып куйгач, уйга калдым: безне шушы язулы кәгазь кисәкләре генә бәйләп торадыр идемени соң? Безгә шул кадәр бәхет китергән хисләр бетсен өчен шушы хатларыңны кайтару чынлап та җитәмени?

Әйт әле, ул чакта йөземдәге бармакларның, роза исләре аңкыган бармакларың эзен ничек юк итәргә? Миңа сәгатьләр буе төбәлеп торган, әле хәзер дә иркәләп караган гаҗәеп күзләреңнең җылысын ничек аерырга? Кыялардан кайтаваз булып яңгыраган тавышларыбызны ничек аерырга? Чыклы болыннардан янәшә йөгергән аяк эзләребезне кая куярга? Яфракларга, чәчәкләргә, үләннәргә сеңеп өлгергән мәхәббәт һәм тугрылык тулы сүзләреңне ничек кайтарырга?

Ә мине көйдерә торган күз яшьләреңне ничек киптерергә, әле бүген дә күңелемдә саклаган, аерылышкан чакта моңсуланган карашыңны ничек нурландырырга?

Гәргәр елгасы буендагы елак талларның ботагына асылынып калган «Яратам», «Онытмам» дигән пышылдауларыңны ничек кире кайтарырга? «Мин сине биш ел да, унбиш ел да көтәрмен!» Бу сүзләрне син әйттең һәм аларны тау елгасы агызып алып китте. Мин аларны хәзер кайтара алмыйм, чөнки алар мәңгелеккә китеп югалды. Алар кырлар һәм яланнар, бакчалар һәм болыннар буйлап таралды, хәзер тарлавыклар, яшел үзәннәр, мин белмәгән киңлекләр кочагында тибәләләрдер!

Мәхәббәтебез шаһитлары бары үзебез: син дә мин генә. Син язасың. Хуш исле язгы кичләрдә безгә елмаеп караган һәм юмарт нурларын сипкән айны нигәдер оныткансың. Безне янәшә чагылдырган елганы, күк гөмбәзенә чәчәкләр сыман сибелгән җемелдәвек йолдызларны да оныткансың. Дуслыгыбызга сокланган яки көнләшеп караган егетләрне һәм кызларны да исеңнән чыгаргансың.

Үтенечеңне канәгатьләндерәм — хатларыңны үзеңә кайтарам...

*1979*

**ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ** тәрҗемәсе

Софрон Данилов,
якут язучысы

## СИНЕҢ ТАВЫШЫҢ

Яшел чирәмле сукмак мине балачагымда ук туган аласыман читкә алып чыгып китте. Мин тау сыртына күтәрелдем, офык киңәйде, аннан инде яңа юллар башланды. Алда шомлы куе тайга улый, шәрә тау-кыялар тора, төпсез упкыннар сагалый. Һәм мин икеләнеп, барыр юлымда тукталып калам.

Кинәт — әллә җирдән, әллә күктән — йөрәккә өмет сала торган тавыш ишетелә:

— Дустым, алга атла. Син барысын да җиңәрсең, теләгеңә ирешерсең.

Бу — синең тавышың иде.

Мин, башымны югары күтәреп, алга атладым.

Чытырманнар аша үттем, тау-кыяларга мендем, елга сулары белән тарлавыкларны кичтем. Юллар мине күгендә торналар очкан тыныч һәм киң үзәннәрдән читкә алып китте, алдымда калын урманнар, ул урманнарның кеше аяк басмаган караңгы чокырлары пәйда булды. Һәм мин, арып-талып, басып тора алмас хәлгә җитеп, җиргә сыенганда һаман саен синең тавышны ишетә идем:

— Дустым, тугры юлыңнан тайпылма. Алга атла! Мәхәббәтем һәрвакыт синең белән булыр!

Һәм миңа шунда көч иңә, күңелем яшәрә, хәят суы эчкәндәй була идем. Арыганлык бетә, хыялым язгы күк кебек яктыра.

Туган аласымның яшел сукмагыннан читкә чыгып киткәнемә инде байтак еллар үтте.

Хәзер ул сукмаклар инде ерак. Ерагын ерак та, ә шулай да якын: тавышыңны ишеткән саен ул сукмакка әйләнеп кайтам.

## ИҢ ГҮЗӘЛ ХАТЫН

Бәхәс кузгалды: нинди була соң ул иң гүзәл хатын? Берсенә көйдереп ала торган кара күзлесе ошый, икенчесенә — соргылт-зәңгәрлесе, ә кемгәдер — коңгырт, мөлаем күзләр. Берсе кыска чәчләрне ярата, икенчесе — балтырга тикле төшкән толымнарны. Берсе озын-зифа буйлы хатыннарга соклана, икенчесенә бәләкәй буйлы, җиңел-җыйнак хатыннар ошый. Һәм һәрберсе үз карашын алга сөрә, үзенекен генә дөрес дип саный. Күпме генә бәхәсләшсәләр дә, бер-берсен барыбер күндерә алмадылар.

Киттеләр дөньяны күп күргән ил картына.

— Без менә күп бәхәсләштек, ләкин уртак бер фикергә килә алмадык. Әйтегез әле, хөрмәтле ага, иң гүзәл хатын нинди була ул?

Карт еракта зәңгәрләнеп торган тау түбәләренә беравык карап торды да якты елмаеп:

— Яшь хатын, — диде.

*1974*

СОЛТАН ШӘМСИ тәрҗемәсе

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

24—25 февральдә язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында әдәби ел йомгакларына багышланган җыелыш булып үтте. Җыелышны Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Ф. Миңнуллин ачты. Аннары аерым жанрлар буенча докладлар тыңланды: М. Вәлиев — проза, Р. Вәлиев — поэзия, Р. Мөхәммәдиев — тәнкыйть, Р. Игъламов — драматургия, Р. Кукушкин — балалар әдәбияты, К. Тимбикова — очерк һәм публицистика, Р. Кутуй — рус әдәбияты, К. Миңнебаев — тәрҗемә, М. Мәһдиев — авыл һәм әдәбият, Э. Нигъмәтуллин — әдәбиятта интернациональ дуслык.

Докладлар буенча фикер алышуда шагыйрьләр С. Хәким, Р. Фәйзуллин, И. Юзеев, китап палатасы директоры Ә. Хисамова, тәнкыйтьче И. Нуруллин, драматурглар Д. Вәлиев, Т. Миңнуллин, Татарстан радиосы хезмәткәре Э. Кудрецкая, прозаик М. Хәбибуллин, тәнкыйтьче А. Әхмәдуллин, «Казан утлары» журналының баш редакторы, шагыйрь З. Нури, Татарстан китап нәшрияты директоры Г. Шәрәфетдинов, тәнкыйтьче Р. Сверигин һәм яшь шагыйрь Н. Алешков катнашты.

Җыелышта КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. Мусин чыгыш ясады.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА

23 февральдә Татарстан Язучылар союзы идарәсенең чираттагы утырышы булды. Анда рус телендә чыгачак «Татар поэзиясе антологиясе»нең редколлегиясе расланды, «Идел белән Урал арасында» исемле коллектив җыентык тикшерелде.

Утырышта яшь язучылар Ф. Гыйльми, А. Хәсәнов, З. Мансуров, Ю. Сафиуллин, Ж. Дәрзаманов, Т. Әйди, Н. Измайлова, тәнкыйтьче Ф. Хатипов СССР Язучылар союзына член итеп кабул ителделәр.

* * *

18 февральдә әдәби тәнкыйть секциясендә яшь тәнкыйтьчеләр Р. Гайнанов белән С. Маннапов (Мөдәррис Вәлиев) иҗаты турында сөйләшү булды. Фикер алышуларда Г. Халит, М. Вәлиев, И. Нуруллин, Н. Юзиев, Х. Госман, Ф. Миңнуллин, Х. Хәйри, З. Мәҗитов, Р. Мөхәммәдиев, Ф. Мусин, Р. Кукушкин һәм башка иптәшләр катнашты.

Секция С. Маннаповны СССР Язучылар союзына членлыкка тәкъдим итте.

* * *

10 мартта проза секциясенең чираттагы утырышы булды. Көн тәртибенә республикабыздагы социаль-экономик һәм демографик мәсьәләләр хакында сөйләшү куелган иде. Доклад белән Мәскәүдә яшәүче философия фәннәре кандидаты Н. Фәтхуллин чыкты. Соңыннан фикер алышу булды, докладчы язучыларны кызыксындырган күп кенә сорауларга җавап бирде.

## Х. ЯМАШЕВНЫҢ ЮБИЛЕЙ КИЧӘСЕ

5 февральдә Оренбург шәһәренең «Россия» культура сараенда халкыбызның күренекле улы, ленинчы большевик Х. Ямашевның 100 еллыгына багышланган юбилей тантанасы булды. Х. Ямашевның тормыш юлы һәм революцион эшчәнлеге турында доклад белән юбиляр исемен йөртүче шәһәр китапханәсендә эшләүче әдәби түгәрәк җитәкчесе З. Шакиров чыкты. Ул 1907 елның 4 гыйнварында Оренбургта чыккан беренче большевистик газета «Урал» турында сөйләде. Х. Ямашевның газетаны чыгаруда зур роль уйнавын әйтеп узды.

Кичәнең икенче бүлегендә «Россия» культура сараеның татар үзешчән сәнгать коллективы концерты булды.

Бу хакта безгә яшь хәбәрчебез Галия Сибгатуллина язып җибәрде.

## ЖУРНАЛГА — ПОЧЕТ ГРАМОТАСЫ

Якташларыбызның сугыштагы батырлыкларын актив рәвештә яктыртканы һәм яшьләрне патриотик рухта тәрбияләүдә актив катнашканы өчен, Сугыш ветераннары комитеты президиумы «Азат хатын» журналын Почет грамотасы белән бүләкләде. Грамотага комитетның председателе ике тапкыр Советлар Союзы Герое, армия генералы П. И. Батов һәм җаваплы секретаре, Советлар Союзы Герое А. П. Маресьев кул куйган.

* * *

Аксубай районының «Авыл таңнары» газетасы каршында Хәсән Туфан исемендәге әдәби берләшмә эшли башлады. Аның җитәкчесе итеп газетаның редакторы С. Хәмадиев сайланды.

Берләшмә ВЛКСМ өлкә комитеты карары нигезендә оештырылды.

* * *

Кукмара районында эшләп килгән «Салават күпере» иҗат берләшмәсенең февраль аенда булган чираттагы утырышында район халык театры режиссеры, яшь шагыйрь һәм прозаик Р. Хуҗиннның яңа повесте, хикәяләре һәм шигырьләре укып тикшерелде. Тикшерүдә язучылардан Л. Ихсанова, М. Насыйбуллин, тәнкыйтьче Ф. Галимуллин, район газетасы редакторы Ә. Фәтхуллин, иҗат берләшмәсе җитәкчесе Ш. Мостафин h. б. иптәшләр катнашты. Р. Хуҗинның иҗатына тәпле анализ ясалды, әсәрләренең уңай һәм кимчелекле яклары күрсәтелде, файдалы киңәшләр бирелде.

* * *

Үзбәкстанның «Укитувчи» нәшриятында «СССР халыклары әдәбияты» дип исемләнгән дәреслек-хрестоматия басылып чыкты. Анда Советлар Союзында яшәүче халыкларның әдәби мирасы тупланган.

«Идел буе халыклары әдәбияты» дигән бүлеккә татар халык шагыйре Г. Тукай әсәрләре кергән, патриот-шагыйрь М. Җәлил шигырьләре дә урнаштырылган. Проза әсәрләреннән язучы Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романыннан өзекләр бирелгән.

## КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР

3 февральдә «Казан» санаториясе клубында язучы Г. Ахунов китап сөючеләр белән очрашты. Әдип матур әдәбият яратучыларны республикада һәм илдә барган әдәби хәрәкәт белән таныштырды. СССР төзелүгә 60 ел тулу уңае белән Татарстан Язучылар союзы башкарган эшләр турында сөйләде.

* * *

4—5 февральдә язучы В. Нуруллин һәм шагыйрь Р. Миңнуллин Актаныш районында китап сөючеләр белән очраштылар. Район культура сараенда, Такталачык, Яңа Әлем культура йортларында, Актаныш урта мәктәбендә уздырылган әдәби кичәләрне укучылар яратып кабул иттеләр.

* * *

Язучы Ш. Рәкыйпов һәм шагыйрь Р. Фәйзуллин культура работникларының белемен күтәрү курсларында чыгыш ясадылар, төрле сорауларга җавап бирделәр.

* * *

Күренекле татар совет шагыйре С. Хәким мәгариф работниклары йортында уздырылган очрашуда катнашты, татар теле һәм әдәбияты укытучыларын үзенең иҗаты белән таныштырды.

* * *

Язучылар М. Хәбибуллин һәм М. Скороходов Чаллы, Яңа Зәй шәһәрләрендә булып кайттылар, промышленность предприятиеләрендә һәм мәктәпләрдә әдәби очрашулар үткәрделәр.

* * *

Казанның медицина училищесында шагыйрь Р. Гатауллин, җырчы Р. Ильясов һәм баянчы Р. Халитов катнашында әдәби-музыкаль кичә үткәрелде.

* * *

Казанның 12 нче мәктәбендә өлкән шагыйрь М. Садри патриот-шагыйрь М. Җәлил иҗатына багышланган әңгәмә үткәрде, истәлекләр сөйләде.

* * *

15 февральдә Казанның 10 нчы интернат-мәктәбендә тәрбияләнүчеләр күренекле шагыйрь С. Хәким белән очраштылар. Шагыйрь аларга үзенең яңа шигырьләрен укыды, иҗат планнары белән уртаклашты.

* * *

16 февральдә Казанның «Салават күпере» исемле балалар клубында «Яшь геройантифашист көне» дигән кичә үткәрелде. Анда шагыйрь һәм прозаик Н. Дәүли дә катнашты.

* * *

Бөтенсоюз пропаганда бюросының 16—18 февральдә Мәскәүдә үткәрелгән XIV семинарында шагыйрь Р. Фәйзуллин һәм язучы Р. Кәрами катнашты. Р. Кәрами семинарда чыгыш ясады һәм ТАССР Язучылар союзының матур әдәбиятны пропагандалау бюросының эш тәҗрибәсе белән уртаклашты.

* * *

Язучылар А. Гыйләҗев, Ш. Галиев, И. Юзеев һәм Т. Миңнуллин 15—17 февральдә Уфада башкорт шагыйре һәм драматургы Р. Сафинның 50 еллык юбилеена багышланган тантаналы кичәдә катнаштылар.

Татарстан кунаклары Башкорт дәүләт университетында очрашу уздырдылар. Анда шагыйрь һәм драматург Ә. Атнабаев та катнашты. Язучыларыбыз үз әсәрләрен укыдылар, студентларның һәм укытучыларның күп санлы сорауларына җавап бирделәр.

## КИТАП СӨЮЧЕЛӘР ИГЪТИБАРЫНА!

Татарстан китап нәшрияты өч томлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н бастырып чыгарды. Күптән түгел сүзлекнең соңгы өченче томы дөнья күрде. Казаннан читтә яшәүчеләргә бу китапның өч томын да түбәндәге адрес буенча соратып алырга мөмкин:

*420084, г. Казань-84*
*ул. Баумана, 19, магазин № 1*
*отдел «Книга-почтой».*

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 7321

**КИЛӘСЕ САН КамАЗга БАГЫШЛАНА**

*Публицистика*

Р. К. Беляев. **Батырлык һәм матурлык тантанасы.**

*Проза*

Разил Вәлиев. **Иске сәгать дөрес йөри.** Повесть

*Поэзия*

Кадыйр Сибгатуллин. **Хыялыбыз башкаласы.**
Н. Мадьяров, Я. Игәнәй, Х. Хөснуллин, Н. Алешков, П. Юлаев. Шигырьләр

*Әдәби тәнкыйть*

Тәлгат Галиуллин. **Еллар чакырдылар еракка...**

*Сәнгать*

Г. Вәлиева. **Чаллы талантлары.**

**КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)** ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал, орган Союза писателей Татарии